# Казан утлары

3
МАРТ - 1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

3
МАРТ
1972

## Бу санда:

Ф. ЯРУЛЛИН. Җилкәнне җилләр еккач. Повесть . 3
И. ЮЗЕЕВ. Карурман. Поэма . . . . . . . . 78
Ш. ЯНБАЕВ. Ике бүләк. Хикәя. . . . . . . . 84
Г. АФЗАЛ. Сабан туе. Шигырьләр. . . . . . 89
М. МӘҺДИЕВ. Фронтовиклар. Роман. . . . . 95
К. БУЛАТОВА. Таныш моңнар. Шигырьләр. . . 117
Л. ШАКИРҖАНОВА. Синең күңел. Шигырьләр. . 119

КАМАЗДАН ОЧЕРКЛАР

Р. ВӘЛИЕВ. Каурыйлар чыныкканда . . . . 121

СӘНГАТЬ

Ә. ГОБӘЙДУЛЛИНА. Табигатьнең сәхнәгә бүләге 130
Р. БАТУЛЛА. «Акчарлаклар» сәхнәдә . . . . 135

ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 50 ЕЛЛЫГЫНА

Г. КАШШАФ. Нигез ташларын салганда . . . 139

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. ҖӘЛИЛ. Педагогия училищелары өчен төзелгән татар әдәбиятын укыту программасы проекты турында . . . . . . . . . . . . . 159

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

А. ГЫЙНИЯТУЛЛИНА. Бәхетле язмыш кешеләре . 163

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**М. ХАРИСОВ.** Театр һәм драматург . . . . . 174

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . 180

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Х. МӘХМҮТОВ.** Алтын бөртекләр . . . . . . 182

ИСТӘЛЕКЛӘР

**С. ЧАНЫШЕВ.** Мирхәйдәр Фәйзи . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

**Баш редактор: Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 3/XII-1971 ел. Басарга кул куелды 25/I-1972 ел. ПФ 09003. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87046 экз. Заказ И-892. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1972 ел.

**Фәнис Яруллин**

# ҖИЛКӘННЕ ҖИЛЛӘР ЕККАЧ

ПОВЕСТЬ

> Җирдә нишә торса торсын,
> Эзе калсын тирән булып;
> Үзе үлсә, эше калсын
> Минем яшәрлек иман булып.
>
> *М. Җәлил.*

## I

1958 ел.



Июль урталары. Әрәмәдә чалгы кайраган тавышка колын кешнәүләре кушыла. Кызлар башлаган җырны кошлар күтәреп ала. Агачлар шавын арбалар шыгырдавы күмеп китә.

Кызлар, сузылып яткан печән покосларын, иңнәгә җәелгән келәмне җыйган кебек, бөтереп җыеп баралар. Тырмалары чәч тарагы урынына шомарган. Егетләр печән күбәләрен, кашык белән ботка чумырып алгандай, җиңел күтәрәләр. Атлар, көчле кырмыскалар төсле, үзләреннән берничә тапкыр зур йөкне сөйрәп эскерткә ашыгалар. Кояш түбәнәйгән саен эскертләр биегәя бара. Эскерт башындагы картларның шәүләләре озынайганнан-озыная.

Көн сүрелә, ләкин эш кыза гына...

Беркемнең дә туктарга исәбе юк иде, тик үзеннән зур сумка күтәреп килгән почтальон кызны күргәч, кайберәүләр сәнәкләрен җиргә кадый башладылар. Гөлсәйдә түти дә, яңа гына сыныл чыккан тырма сабын куаклыкка ыргытып, почтальон тирәсенәрәк елышты. Ул кипкән тамагын кырып:

— Кызым, миңа хат-фәлән юкмы? — дип, берничә кат эндәшеп карады да, җавап бирүче булмагач, алъяпкычындагы кып-кызыл җиләкләрен яулык почмагына авыштырып төйнәп куйды.

Хат ташучы, өләшәсе почтасын өләшеп бетергәч, Гөлсәйдә түтигә сәер һәм кызганулы караш ташлады һәм ак алъяпкыч кесәсенә кулын тыгып, бер читтәрәк басып торучы Фәүрия янына килде.

Фәүрия авылда китапханәче булып эшли. Ләкин печән һәм урак өсләрендә шулай гадәткә кергән инде: кем генә булма, син болында яки басуда булырга тиеш. Хәтта почтаны да колхозчыларның эшләгән җирләренә китереп тараталар. Болай эшләү агитаторларга да бик кулай, чөнки тозлы су сибеп тә бер урынга җыеп булмаган халык, почтальонның сумка күтәреп килүен күрү белән, тупырдашып шул төбәккә агыла башлый. Кулга газета килеп кергәч, үзеннән-үзе әңгәмә куерып китә. Агитаторларга бары тик моны тиешле юнәлешкә борып җибәрергә генә кала.

Бүген дә укытучы Кәүсәрия, уңайлы чакны туры китерүдән куанып, халыкара хәл турында фикер алышу башлап җибәрде. Башка вакытларда мондый әңгәмәләрдә бик теләп катнаша торган почтальон кыз Линуза буш кулы белән Фәүрияне култыклап бераз читкәрәк алып китте.

— Әйдәле, Фәүрия парин,— диде ул пошынулы тавыш белән. Бу авылда бер чоргы кызлар үзара шулай «парин» дип эндәшәләр, ә төчерәк теллеләре «паринкаем» дип үк җибәрә.— Менә миндә Гөлсәйдәттәйгә телеграмм барые бит. Хат юкмы дип килеп сорагач та, йөрәккәем «жу» иттереп куйды. Бирергәме, юкмы?..

— Кая әле, кая? Әллә Фәниярныкымы? — диде Фәүрия кабаланып.

Фәнияр — Гөлсәйдә түтинең улы. Моннан бер ел элек армиягә алынган иде. Киткәнче Фәүрия белән дуслыклары барын һәм атна саен Фәниярдан Фәүриягә адресланган хатлар килеп торуын яхшы белгән почтальон кыз Гөлсәйдә түтигә килгән телеграмманың моңа да кагылышы барын сизә иде шул. Айдан артык инде егеттән хәбәр-хәтер булмаганлыктан, өтәләнеп авыл Советын әллә ничә тапкыр ураучы, ләкин «миңа хат юкмы?» дип сорарга горурлыгын җиңә алмаучы Фәүрия ул көннәрдә Линузага көлке тоела иде.

Телеграммада Фәниярның бик авыр хәлдә ятуын хәбәр иткәннәр иде. Шомлы хәбәр язылган кәгазь кисәген кулына алгач, Фәүрия кинәт җиргә чүкте. Болай да кечкенә буйлы кыз тагын да кечерәеп калган кебек булды. Куллары калтыранды, күзләре дымланды. Телеграмманы алъяпкыч кесәсенә салырга теләде, ләкин кәгазь җанлы нәрсә шикелле карышты, кесә төбенә һич кенә дә кереп ятарга теләмәде. Кыз үз янына килеп баскан ананы сизмәде дә.

— Әллә малайдан хат бармы? — дигән сүзгә сискәнеп, башын күтәрде. Шунда гына ул калтыранган куллары белән үзенә таба үрелүче Гөлсәйдә түтине күрде. Фәүрия җавап бирергә теләп авызын ачты, сүзләре чыкмады. Берничә тапкыр тамак кырганнан соң гына:

— Юк, Гөлсәйдә түти, хат түгел...— дип әйтә алды.

Ул арада кыз кулындагы кәгазь кисәге анага күчте. Гөлсәйдә түти укырга дип телеграмманы күзләренә якынрак китерде, беренче юлны уку белән күзләрен яшь томалавын сизеп яулык читенә үрелде. Шул вакыт яулык почмагына төйнәлгән эре, кып-кызыл җиләкләр яңа гына печәне чабып алынган такыр җиргә коелды. Бу җиләкләр Фәүриягә ананың җиргә тамган күз яшьләре сыман тоелды.

Гөлсәйдә түти җиләкләрне улына дип җыйган иде бит. Эшләп йөргәндә җиләклерәк алан күрде исә, тал башына берәр учма печән бәйләп китәр дә, кешеләр төшке ялга туктагач, ипләп кенә барып җыяр. Кайткач, җиләкләрне чыпчык чүпләмәсен өчен, иләк астына таратып кояшта киптерер. «Мичтә киптергән җиләкнең тәме бетә»,— ди торган иде улы Фәнияр. Инде быелгы җиләкләре генә дә өч оек куныйчы булды. Бөтенесен бергә җыеп малаена җибәрергә кирәк иде дә бит, өйдә ир ат булмагач, посылка әрҗәсе кадаклар кеше дә юк шул. Әрҗә ясатырга дип әзерләп куйган фанерлары да бар, югыйсә...

Кайгысыннан һәйкәл кебек катып калган Гөлсәйдә түтине Фәүрия юатырга тырышты:

— Бик бетеренмә әле, Гөлсәйдә түти, кеше башына чир килми тормый, терелер. Фәнияр андый-мондый авыруга гына бирешә торган егет түгел.

— Ие шул, ие,— диде ана һәм кызны гомерендә беренче тапкыр күргән шикелле йөзенә текәлде. Бу минутта аңа Фәүрия үтә якын, үтә ягымлы күренде. Кеше кайгысын үз кайгысы кебек кабул иткән һәм бөтен йөрәге белән шул кайгының авырлыгын уртаклашырга әзер торган кадерле җан иясенең үз янәшәсендә булуы сөендерде ананы. Ул тынычлана төште.

Гомумән, Гөлсәйдә түти шатлык килсә дә, кайгы килсә дә күтәрелеп бәрелә торганнардан түгел. Бөтенесен эченә генә салып куя да кешеләргә сиздермичә үзалдына яши бирә. Кырык икенче елны, иренең үлү хәбәрен алгач та, ул агарып киткән чәчләрен кешеләр күрмәсен дип, кара шәлен кысып бәйләде дә сабыр гына, борсаланмыйча гына эшли бирде. Балалар әтиләренең үлемен озак вакыт үткәч кенә белделәр. Анда да энисенең сырма кесәсе тузып тишелгәч һәм әлеге хатның почмагы кесә тишегеннән карап йөри башлагач кына өлкән кызы Вәсимә күреп алды. Яман хәбәр китергән язуны, укый белә торганнары укып, белмәгәннәре тотып карап, өй эчләре белән елашып утырганда, Гөлсәйдә түти кайтып керде дә: «Нигә җылашасыз, балалар? Әткәгез бит хәзер генә үлмәгән. Әллә кайчан килгәние бу хат. Әллә кайчангы өчен җылап тормыйлар»,—диде. Әнкәләренең бу сүзе балаларны гарьләндереп җибәрде. Алар сулкылдауларын тыяр өчен иреннәрен тешләделәр.

## II

Улының авыруын белдергән телеграмманы алган кичне үк Гөлсәйдә түти юлга әзерләнә башлады. Чормадан кипкән җиләкләрен алып төшеп, бер капчыкка тутырды. Карлыган кагын, миләш вареньесын, каклаган казын салды. Камырын күкәйгә генә изеп төш пешерде. Бар нәрсә тәртипкә китерелеп төйнәлде. Капчыклар һәм олы сумкалар, походка юнәлергә торган солдатлар шикелле билләрен буып, тезелешеп ишек төбенә килеп бастылар.

Гөлсәйдә түти юлга Мамадышта шоферлыкка укып ятучы өлкән улы белән чыгарга уйлаган иде. Телеграмма суктырып чакыртып җибәрде, инде менә-менә кайтып төшүен көтеп тора. Ләкин чәчрәнләп Фәүрия килеп керде һәм, берәүнең дә ай-ваена карамыйча, Гөлсәйдә түти белән барачагын белдерде. Гөлсәйдә түти моңарчы аны җиңелрәк холыклы, егет-җилкәннәр белән чытлыкланырга яратучы бер кызга санап йөри иде. Малае белән чуалуларын да озын колаклар аркылы ишетеп белә, тик моны яшь, алгысучан кызның чибәр егет каршында үзен күрсәтергә теләп бөтерелүе генәдер дип уйлый иде. Аннары, Фәүрия читтән килгән кеше булганлыктан, кызның ата-анасы нинди кешеләр икәнен дә белми. Ә авылда бит ата-аналарына карап балалары хакында хөкем йөртү бар.

Гөлсәйдә түти үзе рәтләп белмәгән кыз турында җиңелчә уйлавы өчен оялып куйды. Бу тәүфыйклы баланың чит-ят кеше өчен өзгәләнеп, Себер тикле Себергә барырга әзер торуы улы хәсрәтеннән катып калган ана күңелен йомшартып җибәрде. Шул ук вакытта Фәүриянең кыюлыгына да сокланды ул. Ни әйтсәң дә авыл кызлары мондый эшне булдыра алмаслар иде. Яныш, авызларыннан ялкын бөркелсә дә, эч серләрен аккан суга гына сөйләрләр дә йөрәкләрен уып кайтып китәрләр. Ә Фәүрия уйлаганын һичкемнән курыкмый-оялмый эшли торган кыз икән...

Фәүрия — гаҗәп тиз кабынучан, тиз сүрелүчән кеше. Ярсыган вакытларында аның кулына нинди генә эш тоттырма, умыртып эшләр.

Таулар күчерер — арымас, көннәр буе йөгерер — ялыкмас. Коры печән чүмәләсен ялкынга чорнарга бер очкын җиткән кебек, Фәүриянең күңелен җилкендерергә бер җылы сүз җитә. Бары тик ул сүз чын йөрәктән әйтелгән генә булсын. Менә әле дә Гөлсәйдә түтинең:

— Бу хәтле дә миһербанлы бала булырсың икән, бәхетләрең арта төшкере,— дигән сүзләреннән очынып, үсеп китте. Гөлсәйдә түтинең кулындагы табагачын алып, янган мич каршына үзе килеп басты.

Кичке чәйне бергәләп эчтеләр. Ә иртәгесен колхоз машинасының кысан кабинасында Фәүрия белән Гөлсәйдә түти Урыссу станциясенә киттеләр.

Купега билетлар беткән иде, Фәүрия:

— Гөлсәйдә түти, купега билет юк икән, общийга булса да алыйммы? — диде.

— Купе дигәне тизрәк барамыни, кызым? — диде Гөлсәйдә түти.

— Юк, купеда да дүрт тәүлек барырга анысы, тик анда үз өеңдәге кебек тыныч. Ишеге ябылган, урыны җәелгән.

— Барыбер, шулай булгач, упшыйга гына ал, алайса. Юлда булуың әйбәт,— диде Гөлсәйдә түти.— Урыны җәелсә дә, йокы алдырып булмас. Инша алла, аяк өсте дә барып җитәрбез. Кешеләр белән арурак булмасмы. Ишеге ябулы җирләргә бер дә кереп бикләнәсе килми.

Вагон шактый тыгын һәм сәркү булып чыкты. Бер солдат ачык тәрәзә янындагы үз урынын бирмәгән булса, Гөлсәйдә түтигә авырга килер иде. «Кая барсаң да тәүфыйклы бәндәләр очрап тора тагын. Юлның башы хәерле башланып китте, ахыры да матур булыр әле, алла бирсә»,— дип уйлады Гөлсәйдә түти, аяклары арасына төенчекләрен кыстырып, тәрәзә янына әйбәтләп урнашкач.

Беренче көнне сиздермәскә тырышып чыдап барса да, иртәгесен Гөлсәйдә түтинең йөзендә йончу билгеләре күренә башлады. Ул утырган җирендә әз генә йокымсырый да «дерт» итеп уянып китә. Уянып китә дә тәрәзәгә карый. Вагон тәрәзәсеннән артка йөгереп узган телеграф баганалары, кечкенә станцияләр чагыла. Җирләрнең бу кадәр дә зур, илнең иркен булуына хәйран калып барды Гөлсәйдә түти. Кая карама — урман. Әллә соң чуен юлларны юри шулай урман арасыннан салалар микән? «И, хикмәт,— дип уйлады ул.— Җирнең байлыклары бер дә тигез урнашмаган шул. Безнең якта утынга бармак юанлыгы тал кисеп җәфаланалар. Ә монда бихисап утыннар пычкы көтеп тора. Наратлар нинди эре, гуәрдин кебек кукраеп утыралар. Аудар да өй сал».

Красноярскига дүрт тәүлек бардылар. Юлда үткән бу көннәр Гөлсәйдә түтинең илле биш яшьлек гомерендә иң озын, иң ялыктыргыч көннәр булгандыр. Янында бөтергечтәй бөтерелеп йөрүче Фәүрия булмаса, аңа тагын да кыенрак булыр иде. «Гөлсәйдә түти, газлы су эчмисеңме? Мороженое ашап җибәрсәң тәнеңне бераз салкын алыр»,— дип, кыз станция саен ни дә булса алып менде. Борчулы ананың хәсрәттән тамагына аш үтмәс булса да, кызны рәнҗетәсе килмәде: алып менгән суын йоткалады, конфетларын суыргалады. Моның аңа бөтенләй хәлсезләнмәскә ярдәме тиде.

Поездан төшкәндә аякларын көчкә-көчкә сөйрәп чыккан ананың госпитальгә якынлашкан саен адымнары шәбәйде. Улниндидер эчке сизенү белән улы яткан шифаханәнең юлын тапты. Аяк юллык та русча белмәгән, гомерендә Бөгелмәдән ерак чыкмаган авыл хатыны Красноярскиның зур-зур ташпулатлары арасында адашмыйча бара бирде. Аның артыннан калышмас өчен, Фәүриягә шактый кызуларга туры килде.

Фәнияр яткан госпиталь өч катлы, килешсез итеп салынган бер йорттан гыйбарәт икән. Арудан, дулкынланудан һәм каушаудан дерелдәгән

аякларын көчкә-көчкә өстерәп, икенче катка урнашкан хирургия бүлегенә күтәрелделәр.

Госпитальдә төшке аш вакыты иде, шуңа күрә Фәүрия белән Гөлсәйдә түтигә бераз көтәргә кушылды. Тизрәк улын күрергә теләп ашыкнудан тәмам үзен-үзе тота алмаслык хәлгә килгән ана коридордагы йомшак диванда тыныч кына утыра алмады. Үзләренә халатлар чыгарып биргән сестраның каядыр китеп барганлыгын күрү белән, күләгә шикелле тавышсыз-тынсыз, Фәнияр яткан палатага шуды.

Палатада алты карават тора. Караватларның икесе буш. Ишектән кергәч тә ананың күзе тәрәзә янындагы урынга төште. Улының йөзен әле рәтләп күрмәсә дә, нәкъ менә шушы тәрәзә янындагы карават аныкы булырга тиеш. Фәнияр яктылык, кояш ярата торган бала.

Яктылык!

Син кешеләргә һава кебек кирәк. Бала чакта янып торган учакка кызыгып кайнар күмерләрне тотасың, төнге яшен синең күзләреңне камаштыра. Кеше йокысыннан кояшлы иртәне, алсу таңны сагынып уяна. Төнлә куркыныч, шомлы булып күренгән нәрсәләр иртән ачыклана. Яктылыкта кешене шатландыра, тынычландыра торган көч бар, күрәсең.

Кечкенәдән үк Фәнияр гел яктыга омтылучан бала булып үсте. Хәтта бервакыт өйдәге тәрәзәләрне бүлешкәннәр иде. Алты балага дүрт тәрәзә житмәгәнлектән, Фәнияр белән төпчек кыз тәрәзәсез калган. Фәнияр моңарга бик жәберсенеп елый башлаган. Абыйсы аны үртәп: «Елама, сиңа мунча тәрәзәсе булыр»,— дигәч тә тынычлана алмаган. Аңарга шул бәрәңге бакчасына караган мунча тәрәзәсе түгел, ә өянкеләргә, сыерчык ояларына караган тәрәзә кирәк. Сыерчыкларның жим ташуын, бала очырганын көннәр буе күзәтеп утырырга әзер иде. Ул, шуңа күрә тәрәзәсез калуга риза булмыйча, үзенә тиешле өч көнлек иппен жыеп, апасы белән тәрәзәгә алмашкан. Балалы өйдә бүр ятмый, дигәндәй, бу эш икенче көнне үк Гөлсәйдә түтигә мәгълүм булды...

Ананың сизенүе дөрескә чыкты. Фәнияр тәрәзә янындагы караватта ята, Гөлсәйдә түти килеп кергән чакта олырак яшьтәге бер няня аның авызына кашыклап аш салып тора иде. Фәниярның кул-аяклары яшел одеял белән ябылган. Одеял асты буш кебек түгел, димәк, аяккулы өзелмәгән булырга тиеш. Йөзе дә матур гына күренә. «Болай булгач, аллага шөкер икән әле»,— дип уйлады ана. Чөнки ул малаен тере килеш очратудан өметен өзә башлаган иде инде. Юлда килгәндә поездның пош-пош итеп пошкыруы үлем түшәгендәге кешенең авыр сулыш алуы кебек, тәгәрмәчләрнең тык-тык тыкылдавы ярсып типкән йөрәк шикелле тоелып, ананың тәмам котын алып, саташыр дәрәҗәгә житкерде бит.

Әнисен күргәч, Фәнияр сизелер-сизелмәс кенә елмайды. Ананың «Исәнме, улым!» дип, күрешергә сузган кулы, каршы кул үрелмәгәнлектән, әкрен-әкрен түбәнгә төште. Ана, сыгылып төшкән кулларын артына яшереп, улына иелде, аның маңгаена кипкән иреннәрен тидерде.

Сүз озак кына ялганып китә алмады. Шул вакыт Гөлсәйдә түти:

— И балам, онытып та жибәргәнмен, минем белән Фәүрия дә килде бит,— диде. Аннары палатадан жәһәт кенә чыгып китте дә Фәүрияне ияртеп керде. Кызны күргәч, Фәниярның күзләре очкынланып китте. Караңгы төнгә яктылык сибеп жемелдәгән йолдызлар шикелле, егет күзендәге бу очкыннар Фәүрия күңелен нурландырып жибәрде. Улының жанланып китүенә ана да сөенде: «Ярый әле, Фәүрияне алып килдем»,— дип уйлады ул.

Фәүрия егетнең әнисе шикелле тартынучанлык күрсәтмәде. Палатадагы берничә кешенең кызыксынып карап торуына да, сабыр ананың сүзсез генә карават янынарак елышырга теләвенә дә игътибар итмәс-

тән, Фәниярның иреннәреннән суырып үпте. Одеялын ачып кулларын кысты. Ләкин егетнең куллары моңа җавап бирмәделәр. Бөтен палатаны берьюлы кочаклап алырга җыенган кебек, хисләренә ирек биргән кыз ананы малаеннан читкәрәк кысрыклады. Гөлсәйдә түти, чигенә торгач, улының аяк очына ук барып җитте. Яшьләрне оялтмас өчен аларга карамаска тырышты, әмма улының аксыл, газиз йөзеннән күзләрен ала алмады. Аннары, одеял почмагын сак кына күтәрә төшеп, улының аяк бармакларын тотып карады: салкынаймаганнармы? Тырнаклары үсәме?

Бармаклары җылы иде. Тырнаклары да җиткән, өметле күренәләр. Ләкин нигә соң бер җирен дә кымшатмый ята бу бала? Табан астына юри дә кагылыр хәл юк — кытыкны китерәсең дип, буылып көләргә тотыныр иде, хәзер үзенә тигәнгә, хәбәр-хәтере булмагандай, селкенмичә ята бирә. Кулларын кыймылдатканы да күренми. Битенә чәчләре төшкән, сыпырып артка җибәрергә кирәк иде, күзләренә керүе бар. Әһә, Фәүрия чамалады, тарак алып чәчләрен тарый башлады.

Мондый селкенми ята торган авыруны күргәне юк иде ананың. Карап торуга бөтен әгъзалары исән кебек. Кул-аяклары да имгәнгәнгә охшамый. Тизрәк сорарга, белешергә иде дә бит... Улының шатланып Фәүрия белән сөйләшкәнен күргән ана алып килгән күчтәнәчләрен палатадагы авыруларга өләшеп йөрде. Сестраның кесәсенә дә куш уч-лап кипкән җиләк салды. Гөлсәйдә русча, тегеләре татарча белмәсәләр дә, үзара тылмачсыз аңлаштылар.

Бар да җайга төшеп, күрешү ыгы-зыгысы басылгач, Гөлсәйдә түти Фәүрия белән янәшә утырды һәм телеграмма килгән көннән бирле үзен туктаусыз борчып, йөрәген тәмам алҗытып бетергән сорауны бирде:

— Ни булды, балакаем? Нилектән?

Бу сорау Фәүриянең дә теленнән ычкынып китәргә тора иде, шуңа күрә җавап көтеп икәүләп Фәниярга текәлделәр. Фәнияр, суга чумарга җыенган кеше кебек, тирән итеп сулап куйды. Иреннәрендә газаплы елмаю барлыкка килде. Үзе эшләгән берәр гаеп турында сөйләгәндә аның шулай юмор беләнрәк сөйләү гадәте бар. Ләкин бу юлы елмаю барып чыкмады.

— Шул «тагын бер» дигән нәрсә харап итте мине,— диде Фәнияр.

— Анысы нинди явыз соң? — диде ана, берни аңламыйча.

— Анысымы? Анысы минем комсызлыгым.

Гөлсәйдә түти дә, Фәүрия дә берни аңламадылар. Фәниярга сөйләп бирергә туры килде.

...Фәнияр бервакыт үзләренең өй артларына турник ясады. Моңарчы инде ул мәктәп турнигында уйнап беләкләрен шактый гына калынайткан малай иде. Үзендә көч сизгән саен канатланыбрак уйный башлады ул. Өй артында үз турнигың булгач, теләгән кадәр уйнарга була. «Бу күнегүләргә тотынырга иртәрәк әле сезгә»,— дип, чабуыңнан тартып торучы укытучылар юк. Бөтенесе үз иркеңдә. Озак тартышулардан соң ул сальто ясарга өйрәнде. Сальтоны мәктәптәге бер укучының да ясый алганы юк иде әле. Шунлыктан иртәгесе көнне һәммә малайны шаккатырасы килде. Үзенең ярыйсы гына арыганлыгын сизсә дә, бу күнегүне кабат-кабат эшләп карады. «Тагын бер генә тапкыр әйләнәм дә туктыйм, тагын бер кат...» — дия торгач, ул көнне Фәнияр кулын тайдырып туктады.

Ә икенче бер вакытны су коенганда шундыйрак хәлгә төште. Әллә ни киң булмаган Ык елгасының әле бер ягына, әле икенче ягына туктаусыз йөзде дә йөзде. Шулай ике як ярны дүртме, бишме тапкыр урады. Хәлсезләнде, ләкин туктыйсы килмәде. Арыганлыкны нииндидер үзсүзлелек белән җиңәргә уйлады. «Хәл беткәннән соң тагын бер мәртәбә теге якка чыгып булырмы?» Шуны сынап карыйсы килде. Ярга кулларын тидерег кенә алды да кабат йөзеп китте. Елга уртасына җи-

тәрәк бөтенләй хәлсезләнде, бата-калка башлады. Ә инде арып-талып каршы як ярдагы талларга килеп тотынгач, ул, иситкеч бер зур җиңү яулаган кебек, үз-үзеннән канәгать булып калды.

Ләкин кайвакыт үзеңә артык ышану, башкалардан өскәрәк чыгарга тырышу кешене харап итеп тә ташлый. Үз көчеңне бәяләп бетермәү саксызлыкка китерә.

Фәнияр бу фаҗигасенә дә берդәнбер гаепле кеше итеп үзен санады...

Укчы-радистлар мәктәбендәге спортчылар «Н»чы хәрби часть белән ярышка хәзерләнәләр иде. Спортчыларны бер атнага эштән азат иттеләр. Штангистлар көн саен мунчага йөреп, «артык» авырлыкларыннан арындылар. Йөгерүчеләргә подъемга кадәр үк торырга рөхсәт бирелде. Гимнастлар, спортзалдан чыкмыйча, катлаулы күнегүләр ясадылар. Тренерларның кычкырудан тамаклары карлыгып бетте.

Укчы радистлар мәктәбенең иң зур горурлыгы гимнастлар булганлыктан, өметне аларга багладылар. Ашау-эчү белгечләр төзегән меню белән генә бирелде. Тренер Фәниярга да ышаныч белән карый иде. Фәнияр әле икенче разрядлы гимнаст кына, шулай да ул беренче разрядлар өчен генә рөхсәт ителә торган күнегүләрне дә эшләштергәли иде. Спортчылар телендә «кояш» дип аталган катлаулы, бик авыр бер күнегү бар. Соңгы вакытларда Фәнияр бөтен көчен куеп «кояш» ясарга омтылды. Бу эшне ул тренер юк чактарак башкарырга тырышты, чөнки тренер бик педант нәрсә: һәркем үзенә кушылганнан артыгын эшләмәскә тиеш дип карый. Әмма Фәниярның бер генә дә тренер кушкан белән тукталасы килмәде. Спортзалның буш чагын туры китерде исә үзенең «кояш»ы белән мәшгуль булды. Бердән, ул тренерына сюрприз ясарга теләсә, икенчедән, ел буе икенче разряд белән утыру туйдырган иде.

Тырыша торгач «кояш» ясалды. Фәнияр, шатлыктан нишләргә белмичә, сөялләнеп беткән учларына төкереп, кулларын угалады. Бу минутта спортзалда беркемнең дә булмавы гына аның сөенечен бераз киметте. Күрсеннәр, соклансыннар иде барысы да.

Фәнияр бу күнегү белән озак мавыкты. Бер тапкыр да, ике тапкыр да әйләнде. Һәр уңышы аңарда ышаныч, хәтта бераз һавалану хисе тудырды. Баштарак турникка кулларын бәйләп, сакланып кына менсә, соңыннан бәйләмичә эшли башлады. Куллардагы саклык өчен бәйләнгән каеш хәрәкәтләнергә комачаулый кебек тоелды. «Тагын бер генә әйләнәм дә туктыйм», дип, арыганнан соң да турникка күтәрелде. Һәм шунда соңгы тапкыр «кояш» ясаганда кинәт куллары ычкынып китте...

Иптәшләре аны аңын югалткан хәлдә спортзалдан барып таптылар. Аннары одеялга салып санчастька китерделәр. Фәнияр төнлә генә аңына килде һәм, нәрсә булганлыгын аңламыйча, янында утыручы няняга карады. Икенче көнне аны самолет белән Красноярскидагы хәрби госпитальгә озаттылар.

Менә шуларны сөйләп бирде Фәнияр. Фәүрия егетнең «башсызлыгы» өчен шелтә белдерде. Ә Гөлсәйдә түти нәрсә әйтергә белмичә озак кына торганнан соң:

— Ничек соң, балам, бик сызланмыйсыңмы? Тамагыңа каба аласыңмы? — дип сорады.

— Сызланулар кимеп бара инде, әнкәй,— диде Фәнияр.— Баштарак бер дә түзә алырмын кебек түгел идем. Операциядән соң рәтләнә башладым шикелле. Авыртулар басылды.

— Операцияләре бик авыр булгандыр инде. Алданрак хәбәр иттермәгәнсең бит. Килерием, көне-төне янында булырыем. Бер үзең пычак асларына ничек курыкмый керергә кирәк...

— Әле дә мин телеграмма сугарга кушмаган идем, врач үз белдеге

белән генә эшләгән аны. Терелгәч рәтләп үзем язган булыр идем ничек тә,— диде Фәнияр.

— Егылганыңа күп үттеме соң? — дип сорады Фәүрия. Үзенә килгән соңгы хат исәбенчә, ай ярым чамасы вакыт булырга тиеш иде.

— Ике ай тула,— диде Фәнияр.

— Ике ай буе анага хәбәр иттермә инде,— диде Гөлсәйдә, рәнжеп.— Ана күңеле балада, бала күңеле далада, дип юкка гына әйтмиләр шул. Әллә кайда җәһәннәм астында икән армияң дә. Кешеләр Казанда гына да йөреп кайталар.

— Минем хезмәт урыным моннан өч йөз чакрымнар ары әле. Анда хәрби госпиталь булмаганга Красноярскига китерделәр.

— Врачлар нәрсә әйтә соң? Терелерсең диләрме?

— Ул хакта сорашканым юк, әнкәй. Чөнки терелмәм дигән уйның башыма килеп караганы юк. Минә муенның авыртуы бетәр дә торып китәрмен төсле.

— Чыкмаган җанда өмет бар,— диде ана, нык ышанып.

Гөлсәйдә түти тиз генә өмет өзә торганнардан түгел. Аның иң зур, иң нык таянычы — ышаныч! Ил өстенә дошман ябырылып килгән чакта да, еллар авыр чакта да, ялан болай булмас, рәтләнер әле бер, дип үзүзен юатты. Минә балаларым үсәрләр дә үземә таяныч булырлар, дип көне-төне эшләде. Балалары үсте, ана җилкәсенә өелгән йөкне үз иңнәренә күчереп сала башладылар. Ана яңадан турайды. Ул далада үсеп утырган ялгыз каен шикелле: давыллар аның ботакларын да сындыра, салкын кыраулар яфракларын да саргайта, ләкин зил-зиләләр үтү белән яңадан элекке хәленә кайта каен. Яшенле яңгыр аның тузаннарын юып төшереп каенны ап-ак итә, пакьләндерә.

— Терелерсең, балам, терелерсең,— диде ана, палатадан чыгып киткәндә.— Өметеңне генә өзмә.

Әнкәсе белән Фәүриянең килүе Фәнияргә бик зур куаныч булды. Әйтерсең кыш буе буш торган ояга язын сыерчыклар әйләнеп кайтты да бөтен оя эчен гөрләтеп җибәрделәр. Кеше йөрәге — оя. Буш торуны яратмый. Бушап калдымы — суына, туза, җимерелә.

## III

Фәүрия белән Фәниярнең танышуларына ел ярым чамасы гына әле. Кызның ике еллык китапханәчеләр курсы бетереп, Фәниярлар авылына килгән чагы. Фәниярдан ике яшь чамасы олырак булса да, гәүдәгә кечкенәлектәнме, чәчләрен үсмер кызлар кебек тасмалап үреп йөргәнгәме — чырайга бик яшь күренә.

Авылга килеп, эшли башлаган көнне үк очратты аны Фәнияр. Элекке китапханәче Тәслимә апа аңарга районнан «Анна Каренина» дигән китапны алып кайтырга вәгъдә иткән иде. Шул сәбәпле ишектән керәкерүгә үк: «Тәслимә апа, «Анна Каренина»ны алып кайттыңмы?» — дип кычкырды ул.

Тәслимә апа урынына чәчен ике толымлап үргән, тиен күзе шикелле хәрәкәтчән күзле чибәр генә кызны күргәч: «Менә сиңа Анна Каренина», дип куйды. Кыз аның сүзләреннән буш залны яңгыратып көлеп җибәрде.

— Тәслимә апа эстафетаны яшь кадрга тапшырган икән,— диде Фәнияр, югалып калмыйча.— Яшь кадрның исеме ничек соң?

— Яшь кадрны Анна Каренина дип атамыйлар,— диде кыз.

— Анна Каренина дип атасалар бик җилле булыр иде.

— Ни өчен?

— Менә бүген өемә алып кайтыр идем дә рәхәтләнеп укыр идем.

— «Анна Каренина» бик калын ул, укып чыгарга түземең җитәр микән? — диде кыз.

— Минем түземем Толстойның бөтен китапларыннан да калынрак,— диде егет, шаяртып.

Алар шулай таныштылар. Фәниярның күп китаплар укыган булуы, һәр укыган әсәренә карата үзенчә фикер йөртүе Фәүриягә бик ошады. Берничә көннән кыз шунысын да белеп алды: Фәнияр бик әйбәт китап төпләүче икән. Таралып, һәр бите кесәдәге кулъяулык урынына тауша-лып беткән «Кигәвен»не өр-яңа китап иттереп китергән бит. Әйтерсең тылсымлы сүрә укып өргән.

— Менә монысы шәп булган,— дип мактады ул егетне.

— Булдырабыз инде анысын гына,— дигән булды Фәнияр, ләкин үзе китапханәченең мактавыннан кызарып китте. Һәм: «Һу, сездә бөркү икән», дип кепкасы белән җилләнеп алды. Фәүрия үзе китап төпләп мәшәкатьләнергә яратмый. Артык вак эш дип карый. Аңарга тотынган эше минут эчендә эш булсын, юкса түземе җитми. Башка кызлар кебек тегү-чигү, бәйләү бәйләүгә дә әвәслеге юк. «Хәзер машина заманы, тавык сыман казынып утыру модада түгел»,— дип кенә җибәрә. Калынрак әсәр укый башласа да, ахыры нәрсә белән бетәр икән дип, тизрәк соңгы битен караштырырга тотына.

Фәниярның сүз тыңлаучанлыгы аңа ярап куйды, үзе яратып бетермәгән, эч пошыргыч дип санаган эшләрен егеткә куша башлады. Өстәвенә, Фәниярның башка эшләргә дә осталыгы бар икән: китапханәгә менә дигән иттереп лозунглар язып элде.

Күп вакыт шаярышып сөйләшсәләр дә, аларның бер-берен белергә теләүләре көчәя барды.

Фәүрия беркөнне Фәниярдан болай дип сорады:

— Син, Фәнияр, китапларны бик яратасың, нигә үзең монда эшләргә кермәдең?

— Эш минем теләктә генә түгел шул, Фәүрия. Хәзер бит, үзең беләсең, укымышлылар заманы. Безнең ише укыр-укымас көе мәктәпне ташлаган авыл малае эш рәтен беләмени?

— Син үзеңне артык кимсетеп җибәрмә әле,— диде Фәүрия.

— Беләсеңме, Фәүрия,— дип дәвам итте Фәнияр,— мин әллә нинди тотрыксыз, хыялый кеше. Бер көнне бер һөнәр, икенче көнне икенчесе ошый.

Әле мин бәләкәй чакта ук авылга электр кертергә бермәлне монтерлар килде. Чын-чынлап учларында ут биетә торган егетләр иде алар. Ни арада баганаларын утырттылар да ни арада чыбыгын суздылар. Берәүләре ап-ак чәйнекләрне багана башына меңгереп боралар, икенчеләре өйгә шнур кадаклый, лампа элә. Карап торулары шундый кызык! Без — малайлар — аларның артларыннан бер тотам да калмыйча өйдән өйгә йөрибез, чыбык тартышабыз. Шулчак күзем төште: берсенең сумкасы тулы лампалар. «Шуларның бөтенесен берьюлы яндырып куйсаң, кояш яктылыгы булыр иде микән?» дип, күзләремне сумкадан ала алмый торам. Монтер абый минем кызыгып карап торуымны күргәч, берсен алып җиңе белән әйбәтләп сөртте һәм минем кулга тоттырды. «Бу, энекәш, гади лампалар түгел, Ильич лампалары»,— диде ул.

Бу сүзләр мине әллә нишләтеп җибәрде. Монтер абый ничектер якынаеп, үз булып китте. Аны бөтен кешеләргә яктылык өләшүче юмарт, кайгыртучан кеше итеп күз алдына китерә башладым. Бу бәхетле кешеләрнең һәрбер хәрәкәтенә сокланып, исем китеп карап йөрдем. Тизрәк үсәсем, җилкәләремә «тырнаклар» асып, авыл урамнарыннан үтәсем, ак чыбыкларны зәңгәр һавага сузып өйләрне өйләргә тоташтырасым килде.

Фәнияр, малай чагына кире кайткандай, мавыгып, тәэсирләнеп сөйләде. Фәүрия аны бүлдермичә тыңлады. Тик соңыннан гына:

— Гел шуны сорармын дип йөрим, син кем булып эшлисең соң, Фәнияр? — диде.

Егет, хыял дөньясыннан аерыласы килмәгәндәй, тиз генә җавап бирергә ашыкмады. Кулындагы китабына бармагы белән чиртәләп торды. Аннары:

— Мин монтер булып эшлим,— диде.

— Алайса теләгеңә ирешкәнсең икән.

— Юк, теләккә ирешеп булмады, Фәүрия. Электромонтер түгел, элемтәче генә мин. Унсигез тулмаганнарны электромонтерлыкка алмыйлар иде. Уналтыда районга эш эзләп киттем. Монтерлар әзерли торган курслар районда юк иде. Йөри торгач элемтә конторасына юлыктым. Монда ике егетне армиягә озатканнар икән, шулар урынына кеше кирәк, диделәр. «Багана чокыры казырга ярарсың әле», дип, документларны кадрлар бүлегенә тапшырырга куштылар. Башта чокырын казыдым, аннары өскә менә башладым. Инде разрядым да бар, тик күңел канәгать түгел. Эшем шундый кирәксез, вак нәрсә кебек тоела. Мин телефон куеп чыгып киткән кешеләр теге вакыт безгә электр керткәндәге кебек шатланмыйлар. Киресенчә, идән таптап йөрисең шунда, дигән сыман, син чыгып киткәнче үк эзләреңне сөртә башлыйлар...

Әйе, Фәнияр үз теләген тормышка ашты дип әйтә алмый. Ул һаман саен каядыр ашкына. Бер көнне тракторга утырып җирләр актарасы килсә, икенче көнне күкне ярып үткән самолетка кызыга. Иң кимендә берәр машина уйлап табарга иде аның исәбе. Җилгә канатлар ясап коедан су чыгара торган җайланма да корып куйды инде ул. Тик бу бик аз шул. Күңелне баса алмый.

Болардан башка үзеннән дә яшереп йөри торган тагын бер хыялы бар әле Фәниярның. Ул — язучы булу. Аның инде куен дәфтәрендә яза башлап ташлаган әллә никадәр шигырьләре йөри. Күңеленә матуррак сүз килгән саен Фәнияр аларны кенәгәсенә «төртеп» куя. Әмма берәр вакыт шул «үземнеке» дигән сүзне күптән язылган китапта очрата да кәефе кырыла.

Бер көнне ул үзенең бик әйбәт дип санаган шигырьләрен акка күчереп язды да Фәүриягә күрсәтеп карарга булды. «Фәүрия укыган кыз, нәрсә дияр икән?»

Әмма чишмәләр җырын, өянкеләр моңын тыңламаган, таңнар атканын, офыклар алланганын күзләре арыганчы күзәтмәгән шәһәр кызы Фәниярның шигырьләреннән көлде генә.

— Наивность,— диде ул.— Болар кемгә кирәк? Талларның шаулаганын, чишмәләрнең чылтыраганын син язмасаң да беләләр. Күп шагыйрьләр әйткән ул турыда.

Фәүрия егеткә катырак кагылуын аңлады, ахры, сүзләрен йомшартырга теләп:

— Телисеңме, Фәнияр, мин сиңа бер әкият сөйлим,— диде.

— Я, сөйләп кара,— диде Фәнияр, хәтере калуын сиздермәскә теләп.

Фәүрия чәчләрен төзәткәләп, тамакларын кыргалап куйды. Сәхнәгә чыгып баскандай бераз поза белән сөйләп китте:

— Борын-борын заманда, матур яшел аланда, җәйнең аяз көнендә, шәп куаклык төбендә бер чебеш дөньяга килгән. Чыккан да ул йомыркаңың кабыгын ватып, караган ди бар дөньяга исе китеп, шаклар катып. Бик күп икән иркә урман тавыклары, тиеннәре, куяннары, аюлары һәм урманның бүтән халыклары. Пип-пип, дигән чебеш. Аның тавышын карурман көчәйтеп җибәргән, җилләр еракка илткән. Үз тавышын беренче кат ишеткәнлектән гаҗәп матур, гаҗәп яңгыравык булып тоелган чебешкә. Ул тагын да катырак итеп кычкырган. Яшел урман, син нинди киң, нинди иркен. Бу дөньяга килүемә нибарысы әле бер көн. Ә шулай да яраттым мин сине мәңге. Аланнарың шундый ямьле,

жилэклэрең шундый тэмле. Үлэннэрең йомшак синең келэмнэрдэн, чык суларың — энже-мэржэн...

Хыялый чебешнең бу сүзлэрен ишеткэн дэ бер тилгэн очып якынрак килгэн һэм чебешкэ болай дигэн:

— Дөнья күргэнең юк синең, мескен чебеш. Чык сулары — энже-мэржэн, куаклыклар, чытырманлык матур, имеш. Синең, чебеш, очканың, киңлеклэрне кочканың юк. Канат жилпеп күккэ менсэң, гүзэллекне өстэн күрсэң эйтер идең: кояшны зур алтын диеп, офыкларны ялкын диеп. Без алмаз йолдызлар белэн туенабыз, ак болытка сузылып ятып кызынабыз, ут уйнатып яңгыр яуса — коенабыз. Мин сине, чебешкэем, бер очыртып карар идем, менэ шунда матурлыкны аңлар идең.

— Юк, сөйлэмэ, житэр,— дигэн аңа чебеш,— син мине һавага күтэр, күрим эле бөтенесен, гомерем дэ жэл түгел гүзэллекне күрер өчен.

Тилгэн аны төшеп алган. Күтэргэн ди зэңгэр күккэ, бик биеккэ. Чебешкэйнең болытларга башы тигэн. Чынлап та күк ай-яй матур, зэңгэр икэн. Офыклар киң, сулышлар киң, тынга иркен. Кошларның бик күп төрлесе оча икэн төркем-төркем. Болытлар да ефэк шэлен болгыйлар, ди, кошлар аргач болытларга утырып жил тавышын тыңлыйлар, ди. Бу зурлыкка, хозурлыкка хэйран калып, күкрэгенэ бик күп итеп сулыш алып, очып китмэкче булган, ди, чебеш үзе. Канаты югын онытып бер талпынган, бер кагынган. Тилгэн аны шулчак ялгыш ычкындырган. Чебеш мескен бик эз генэ очып барган. Шуннан түбэнгэ тэгэрэп башын ярган.

— Экиятең бик матур, хикмэтле синең, Фэүрия,— диде Фэнияр.— Шушы чебеш кебек канат чыгармаган килеш очарга кызыкма, диюеңдер инде. Тик синең экиятеңнэн соң минем, киресенчэ, шул чебеш шикелле буласым килэ башлады. Ул, ичмасам, гомере бэрабэрен булса да телэгенэ ирешкэн. Күккэ күтэрелгэн, очу лэззэтен татыган. Жиргэ төшеп башын яруы да шэп, чөнки бер очып караганнан соң тирестэ актарынып яшисе килмэс иде.

Фэүрия үзе сөйлэгэн экиятнең бөтенлэй башкача тээсир итүен күреп куанырга да, ачуланырга да белмэде. Бу егетне аңлап бетерэ алмый ул. Һэрнэрсэгэ тилелэрчэ ышану, сабыйларча беркатлылык һэм үлсэ дэ үзенекен эшлэргэ эзер тору көче бар Фэниярда. Комсомолга керергэ барганда да чак үлми калган ул.

Алтынчы класста укыганда ике кыз, ике малай комсомолга керер өчен районга китэлэр. Тышта апрель. Юллар бозылган. Мэктэпнең кара айгыры юл пычрак дип тормый, шактый житез элдерэ. Бу жилкенчэк йөрэклэргэ башлык итеп быел гына пионервожатый һэм физкультура укытучысы булып эшли башлаган Кэрамны жибэрэлэр.

Район Фэниярлар авылыннан егерме өч-егерме биш чакрымда. Юлның яртысын үткэч, Дим елгасын аркылы чыгарга кирэк. Жырлыйжырлый елга янына килеп житэлэр. Карыйлар: күпер юк. Бозлар алып китмэсен дип сүтеп ташлаганнар. Э елга кузгалган. Теге якка чыгу турында уйларлык та түгел.

Кэрам елгага карап тора да: «Киттек, балалар», ди.

Үзе балалыктан чыгып житмэсэ дэ, шулай бераз эрерэк сөйлэшергэ, үзенең укытучы икэнен күрсэтергэ ярата ул.

Берсенең дэ комсомолга кермичэ кайтып китэсе килми. Шулвакыт мэктэптэ куркаклыгы белэн даны чыккан Һэдия:

— Эйдэгез атны берэрсендэ калдырып, боз өстеннэн чыгабыз,— ди. Дилүсэ дигэн кыз Һэдиянең сүзлэреннэн кычкырып көлэ башлый.

— Идэн астыннан башын чыгарып карап торган тычканны күрсэң дэ котың алына бит синең. Елгага керү турында сөйлэп торган була тагын,— ди.

Һэдиянең сүзе Фэниярга да кыюлык кертеп жибэрэ.— Чынлап та,—

ди,— монда чаклы килгәч кире борылмабыз бит инде, комсомолга керә алмый кайтсак класска ничек күренербез?

Моңарчы сүзгә катнашмаган Гайса:

— Елга гаепле, без түгел,— дип әйтеп куя.

Фикерләр икегә аерыла. Фәнияр белән Һадия — бару ягында, Гайса белән Дилүсә — кайту ягында. Башлык буларак, Кәрам бер сүз дә әйтми. Ләкин ул кыюларны ярата торган кеше. Балалар язмышы өчен борчылса да, елганы кичеп чыгу теләге дә зур үзендә. Укучылары алдында батырлык күрсәтергә уйлап:

— Болай итәбез,— ди ул,— иң башлап мин кичеп карыйм, чыгарлык булса берәм-берәм тәвәккәлләрбез.

Ул җирдән бер казык ала да өелеп торган бозлар өстенә атлый. Боздан бозга сикерә торгач шактый ара китеп өлгерә. Түземе беткән Фәнияр Кәрамның теге якка чыгып җиткәнен көтә алмый, бозга сикерә. Аңарга Һадия дә ияре. Фәнияр белән Һадия елга уртасына якынлашуга шарт-шорт итеп бозлар кузгала башлый. Һадиянең аягы таеп, ике боз арасына егыла. Моны күргән Фәнияр ярдәмгә ашыга: тегенең якасыннан эләктереп үзе артыннан өстери. Ләкин үзе бушлыкка чума. Бу юлы Һадия аны сөйрәп чыгара. Ярның теге ягына чыгып җиткәндә алар манма су булалар. Ләкин яшь чакта моның кебек чылануларга әһәмият бирәсеңмени?! Киемең чыланса, өстә тизрәк кибә, дип салып тормыйсың, тәнең тырналса, ямавы үзендә, дип бәйләп маташмыйсың. Каршылыкларны җиңү шатлыгы үзе генә ни тора! Әгәр алар күңелендә бу минутта туган горур куанычны йолдыз итеп күккә чөйсәң — иң якты йолдыз кабыныр, чәчәкләр итеп җиргә сипсәң — иң матур гөлләр үсәр иде. Яшьлекнең бөтен гүзәллеге — кыюлыкта.

Фәнияр белән Һадия ул көнне комсомолга кереп кайталар. Кәрамга башсызлыгы өчен шелтәнең майлысын чәпиләр чәпәвен, ләкин кешеләрне сөендергән өчен тиргәлү хурлыкмыни ул?!

## IV

Укырга, зур кеше булырга теләге бар иде Фәниярның, әмма тормыш үз шартларын китереп куйды. Абыйсын армиягә алдылар. Апалары бер-бер артлы кияүгә чыгып бетте. Сигез классны тәмамлап, тугызга барырга торганда Фәниярга эшкә керергә туры килде. Әнисенең сәламәтлеге үзе кадәр генә, ә ачык авыз аш сорый. Эшләми хәлең юк. Кичке мәктәптә укуын дәвам итәргә — авылда урта мәктәп һаман ача алмыйлар. Хәер, хәзер мәктәп ачсалар да укып йөрергә туры килмәс, озакламый армиягә китәчәк. Рәтлерәк урынга эләксә, бәлки армиядә укый алыр әле.

Фәниярның бәхете бар икән, армиядә аны авиация мәктәбенә алдылар. Ерак Себернең Канск дип аталган кечкенә һәм тузанлы бер шәһәренә һава укчы радистлары хәзерли торган хәрби мәктәпкә эләкте ул. Малай чагыннан ук спорт белән шөгыльләнүе монда аңарга бик ярап куйды. Башкалар үз гәүдәләрен турникта аякларына кадәр дә күтәрә алмый азапланганда, ул ботактан ботакка сикерүче тиен тизлегендә менеп китә иде. Командирлар аның бу өлгерлеген тиз күреп алдылар. Һәм аңа физик хәзерлекләре начар булган унлап курсантны беркеттеләр. Бу егетләр арасында Ризван исемлесе педагогия училищесы тәмамлаган икән, рус телен яхшы белә. Ә менә Фәниярның ул яктан бер дә мактанырлыгы юк. Килү белән укытучылар: «Кем дә кем һава укчы-радистлар мәктәбен отличнога бетерә, аны очучылар училищесына җибәрәбез»,— дип әйтеп куйганнар иде. Фәниярның очучы буласы бик килә, әмма әлеге дә баягы рус телен начар белүе мәктәптә үтелә

торган фәннәрне яхшы үзләштерергә комачаулый. Менә Ризван ярдәм итсә генә инде.

— Ризван,— диде Фәнияр беркөнне,— синең очучы буласың киләме?

— Һи, тиле, кемнең очучы буласы килми инде,— диде тегесе.

— Алайса, әйдә болай эшлибез: син мине русчага өйрәтәсең, ә мин синнән менә дигән спортсмен ясыйм, килештекме?

— Килештек, малай.

Ризван белән Фәнияр тиз дуслашып киттеләр. Икесенең дә бер максатка омтылулары якынайттымы, хыялыйлыкларымы — әйтүе кыен. Әмма алар уй-теләкләрен бер-берсеннән яшермәс булдылар. Ризванның хыялы Фәниярныкына караганда да зуррак икән. Фәнияр моны соңрак белде.

1957 елның 4 октябрендә җирнең беренче ясалма иярчене орбитага чыгарылуы хакында хәбәр иткәч, Фәниярлар укый торган укчы-радистлар мәктәбендә шатлыклы шау-шу булып алды. Бу хәбәр үзенең шаккатыргыч яңалыгы белән күңелләрне кузгатты. Укуларына вакыт үткәрү дип кенә карап, койрыкта сөйрәлүчеләрдә дә хыял-өмет чаткысы кабынды. Болай булгач тиздән космоска кешеләр дә оча башлар. Галәмгә очарлык яхшы хәзерлекле кешеләр кирәк булыр илгә. Теләк барында үтәп булмаслык эш юк. Өметсез — шайтан, дигәннәр.

Бу кеше дигәнең нәрсәгә генә омтылмый да ниләр турында гына хыялланмый! Һәр эшнең башы — хыял. Кеше күк йөзенә сибелгән алмаз бөртекләредәй ялтыраган йолдызларга сокланып карый-карый да очу турында хыяллана. Серле галәм аның бөтен уйларын били, билгесезлеге үзенә тарта.

Әле самолетка да утырып карамаган, аэродромда бары төнге каравылда гына йөргән курсантлар, йокыларын онытып, космоска очу турында әсәрләнеп йөри башладылар. Әсәрләнгәнгә карап, эчләреннән генә тынсалар бер хәл иде, чарасына да керештеләр. Әлеге дә баягы ике хыялый — Ризван белән Фәнияр — бер көнне спорт залында сөйләшеп киттеләр. Сүз бер хаттан башланды. Ризван ботларын күтәреп турникта селкенеп маташканда кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәге килеп төште. Ул, әйбер урлап тотылган кеше кебек, кызарынып кәгазьне кулына алды.

— Нәрсә, әллә берәр асыл ярдан килгән хатмы, битләреңә ут капты,— диде Фәнияр.

Тегесе ык-мык итте. Шуның белән Фәниярның шиген арттырып җибәрде.

— Болай булгач укып күрсәтми котыла алмассың, малай. Мин синең старшиең. Ә армиядә, үзең беләсең, старшийның сүзе — приказ,— диде Фәнияр, шаяртып.

Ризван, кемгә сөйләргә белмичә эче ачытып йөргәнгә, хатның нәрсә турында икәнлеген Фәниярга сөйләргә булды.

— Дус кеше,— диде ул,— бу хатның әле адресы юк. Язуын яздым, кая җибәрергә белмичә аптырап йөрим.

— Авылга, бабайга, Константин Макаровичка, дип яз,— диде Фәнияр.

— Син шаярма, бу бик җитди хат,— диде Ризван, тирләп чыккан маңгаен майка итәге белән сөртеп.

Алар хатны бергәләп укыдылар.

— Хөрмәтле галимнәр! — дип башланган иде ул.— Җирнең тарту көчен җиңеп космоска чыккан спутник мине бик куандырды. Шатлыгымнан әллә ничә көн йоклый алмый йөрдем. Киләчәктәге очышлар өчен бәлки сезгә кешеләр кирәк булыр. Андый очракта аптырап калмагыз, туры миңа хәбәр итегез. Космоска очарга, яңа ракеталар сынарга мин һәрвакыт хәзер. Әлеге мин һава укчы-радистлар мәктәбендә генә укыйм.

Бөтен предметлардан да отличнога өлгереп барам, тик менә физик хәзерлегем генә шәптән түгел. Әмма бер дә шикләнмәгез, монда да сынатмам. Иң алдынгы курсантларны куып җитәрмен. Радистлар мәктәбен бетергәч, очучылар училищесына китәм. Бу — хәл ителгән инде. Очучы булып чыкканчы чират ала торыйм дип сезгә хат язарга булдым. Берүк мине оныта күрмәгез инде, спутник ясаучы иптәш галимнәр. Космоска кеше җибәрергә уйласагыз, кораблегезнең иң бәләкәй радиосына булса да мине радист итеп утырта күрегез. Морзе әлифбасын шәп беләм. Тиздән парашют белән сикерүләр башлана, анда да сынатмам дип уйлыйм.

Ихтирам белән, булачак радист, хәзергә курсант — Мифтахетдинов Ризван».

Дустының бу хатын укыгач, Фәнияр әллә нишләп китте. Әйтерсең Ризван инде космоска очкан. «Камырбатыр» дигән булып, мыскыл итеп йөр инде аны моннан соң. Борынына чиертте бит Фәниярның. Ярый әле: хатын җибәрергә адресын белмәгән, юкса космоска очарга Фәниярдан алдан чират алып куяр иде. Ә хәзер Фәнияр да йоклап калмас. Ризван хәтле генә яза белер.

— Ах син, Мыштымбай,— диде Фәнияр, хәтере калып.— Дус дигән буласың, якташ дип йөрисең, ә үзең миннән качып космоска очарга маташасың. Юк инде, барып чыкмас. Син очканда «исән бул» дип кул селтәп торырга без дә төшеп калганнардан түгел. Хәзер үк хатыңны ертып ташла. Икәүләп язабыз. Шунсыз бәхиллегем юк.

Ризван дусты әйткәнчә эшләде дә. Хәрефен хәрефкә җиткереп, өтерен-ноктасын тикшереп, бик һәйбәтләп кәгазьнең шомасына гына хат яздылар. Инде кая, кем исеменә җибәрү мәсьәләсен генә хәл итәсе калды. Бу хакта бик күпне белүче, бераз сакаурак Чепановтан сорарга уйлаганнар иде дә, әллә кая бездән алдан аны язып куймагайлары дип, бу исәпләреннән кире кайттылар. Үзара киңәш-табыш кылышканнан соң, хатны СССР Фәннәр Академиясенә адресларга кирәк дигән фикергә килделәр.

Икәүләшеп, сырлый-сырлый, имзаларын куйдылар. Конвертны ябыштырып почтага илттеләр. Аннары, бик олы эш майтарган кешеләр кебек, башка курсантларга өстәнрәк карап, мыек асларыннан гына көлеп йөри башладылар.

Озаклмый парашют белән сикерү көне килеп җитте. Һәр курсант үзенчә дулкынланып, үзенчә җилкенеп көтте бу көнне. Һавада башкалар идарә иткән самолетка утырып, кырык-илле минут җир белән элемтә тотып йөрүнең әллә нәрсәсе юк иде. Артык батырлык та, кыюлык та таләп итми бу эш. Радиостанцияңне бөтән дулкынга көйләсәң, инструкторың янында гына — хәзер әйтеп җибәрә. Морзянкаңны ялгышсаң — аңлашылмады, кабатлагыз, дигән сигналлар кылә. Ә менә парашют белән сикергәндә ялгышырга да, куркып калырга да ярамый. Монда дөнья океаны — зәңгәр күк белән икәүдән-икәү каласың. Язмышың үз кулыңда. Саперлар гомердә бер генә ялгышалар, диләр бит, парашютчылар да шулай.

Фәнияр очып киткән чакта бер дә өркеп калырмын дип уйламаган иде. Әмма самолет тиешле биеклеккә күтәрелеп, «Хәзерләнергә!» дигән команда ишетелгәч, ашкыну каядыр юкка чыккандай булды. Әллә самолет гүләвеннән, әллә яңа хис кичерүдән, әллә куркудан бөтен тәндә калтырану барлыкка килде. Маңгайдан тир бәреп чыкты, аяклар авырайды. Мотор тавышымы, йөрәкме — дөп-дөп типте. Аякларны шудырсаң түбән очасың. Ләкин беленер-беленмәс бусаганы атлап чыгарга көч җитми.

Бусага! Кеше үз гомерендә ничәмә-ничә бусага атлап уза. Башта туган йортының бусагасын атлап ерак җирләргә юл тота. Авыр була. Күнегелгән, һәр нәрсәсе күңелгә якын һәм кадерле булган җылы өйгә

керен китәсе килә. Ләкин юлларда йөрисе, дөньялар күрәсе килү хисе бөтенесен җиңә. Кеше иңнәренә асылган юл капчыгын рәтли дә артына карамаска тырышып алга атлый.

Фәнияр да кыюлыгын тупларга теләп бусагада басып тора.

Менә ул ишек яңакларына куллары белән тотынып түбән карады. Ә аста җир ямь-яшел. Шушы яшел чирәм бик тә йомшак, бик тә якын тоелды аңа. Җирне шулай якында тойгач, кечкенәдән үк аунап үскән яшел чирәмнәрне күргәч, Фәнияр тынычланып китте. Куркуы каядыр юкка чыкты. Аяклары үзләреннән-үзләре бушлыкка атлады. Шартлап парашют ачылып китте, култык астыннан алдырып бәйләгән каешлар тәнне авырттырып тартылып куйдылар. Фәнияр ап-ак парашютында чайкалып, зәңгәр күктә ялгызы калды. Үзен канатлы итеп тою шатлыгыннан ул сул аягының итеге салынып, үзеннән алда җиргә төшеп киткәнен дә, аяк чолгавы сүтелеп җил белән еракка очканын да сизмәде. Гомердә булмаганча рәхәт иде аңа. Шунда ул үзенең бары тик очар өчен генә яратылуын, моңарчы яшәгән егерме еллык гомеренең шушы очыш өчен хәзерлек икәнлеген аңлады. Үзеңне тапкан көн — кеше гомерендә иң бәхетле көннәрнең берседер ул.

Казармага кайтуга аны Фәүриядән килгән хат көтеп тора иде. Дөрес, кызның беренче хаты гына түгел бу. Кайчакта көненә икешәрне дә сызгалап җибәргәли иде Фәүрия. Әмма бүгенге хат бүтәннәренә бөтенләй охшамаган булып чыкты. Элек Фәүрия бераз шаян тонда үзенең нәрсә эшләгәнен, кайсы егет озата барганын, егетнең нәрсәләр дигәнен, үзенең ничек җавап биргәнен бәйнә-бәйнә язып тутыра иде. Бүген кызны алыштырганнар диярсең. Хаты уч төбе хәтле генә, ә һәр сүзе шундый мәгънәле, шигырь итеп күңелдән ятларлык.

Әйе, кызның хаты егет йөрәгенә сарымай булып ята торган мәхәббәт турында иде. Фәүрия аны яратуын, сагынуын язган, синнән башка яшәү күңелсез, дигән.

Фәниярның төшендә еш кына очканы бар. Кулларын канат итеп як-якка җәя дә салмак кына, көчәнмичә генә биеккә-биеккә күтәрелә. Бу очу шул хәтле ләззәт, рәхәтлек, канәгатьләнү китерә, хәтта уянгач та ул шактый вакыт күзләрен ачмыйча ята. Шул хозурлыктан аерыласы килми. Фәүриянең наз һәм иркә тулы хатын укыгач та шуңа ошашлырак хис кичерде. Бөтен тамырлары буйлап рәхәт дулкын агып үтте. Шушы дулкын аны нинди дер бер илаһи тылсым көчедәй сиздермичә һавага күтәрде. Шау-шулы казарма тормышы түбәндә, еракта калды. Бөтен дөнья зәңгәр хыял томанына уралды.

Беренче мәртәбә парашют белән сикерү, беренче мәртәбә «сөям» дигән сүз ишетү егетнең болай да шашкын күңелен бөтенләй тилертеп җибәрде.

Кеше гомерендә күп тә соң бу «беренче мәртәбә»ләр. Беренче мәртәбә «сөям» сүзен әйтә, беренче мәртәбә хыянәт ачысын татый. Беренче мәртәбә шатлыгыннан елый, беренче мәртәбә кайгысы күкрәгенә сыймый.

Фәниярны әйтерсең алыштырдылар. Укулары да әйбәт бара башлады. Китапларны йотылып укый торган булды. Дуслары аның бу хәлен сизеп шаярткалый иделәр.

— Сине, Фәнияр, сикергәндә һавада әллә парилар алыштырды инде. Күзләрең парийнеке төсле карый,— диде арадан берсе.

— Пәри күзләрен күргәнең бармыни синең? — диде Фәнияр да, шаяртып.

— Китапны уку гына түгел, читләрен дә кимерә ул хәзер,— диде икенчесе.

— Китап дисез әле сез,— диде өченче берәү.— Спортзалда үзенә кәләш тапкан әле ул. Беркөн шулай онытылып калган каешымны алырга дип керсәм, шаккаттым, егетләр. Нәрсәгә дисезме? Менә безнең

кияү егете Фәнияр инде, залдагы теге «кәҗә тәкәсен» кочаклаган да чулт-чулт үбеп маташа. Үбешә-үбешә иреннәре канап беткән мескенкәйнең. Вәт тек мәхәббәт!

Курсантлар бар да көлделәр. Аларга кушылып Фәнияр да шаркылдады. Әйе, беркөнне «кәҗә тәкәсе» аша сикергәндә егылып иренен канаткан иде шул. Тегеләр шуннан көлә. Әйдә үртәсеннәр, шаярсыннар. Үртәшмәгәч, шаярмагач — тел нәрсәгә бирелгән. Фәнияр үзе дә ул якка кимен куймый. Сәбәп кенә булсын.

Солдат тормышы шулай кызыклары һәм кыенлыклары белән үтә торды. Фәниярнең һава укчы радистлар мәктәбендә укый башлавына ун ай булды. Тиздән имтиханнар җитә. Ә аннары курсантларга сержант дәрәҗәсе биреп частьларга таратачаклар. Бәхетлеләргә хәрби очучылар училищесына китәргә туры килер бәлки. Кем белә, мондый бәхет Фәниярга тиюе дә бар. Укулары соңгы вакытта бик яхшырды. Үзенә беркетелгән курсантларны әйбәт хәзерләгән өчен командование рәхмәт белдерде. Инде сынауларда гына сынатмаска кирәк.

## V

Ләкин Фәниярга радистлар мәктәбен бетереп имтиханнар тапшырырга туры килмәде. Тормыш аңа башка төрле сынаулар әзерләгән булып чыкты.

...Ул күзләрен түшәмгә текәп больницада ята. Элек бер урында һич кенә дә тик басып тора алмаган аяклары чуеннан коелган шикелле авыраеп хәрәкәтсез катканнар. Авыррак нәрсә күтәргән саен тыгызлана барган беләк мускуллары чүпрәктәй ләшпераеп төшкән. Чибәррәк кызлар күргәндә йөз сиксән градуска әйләнергә әзер торган муен — янында утырган әнкәсенә борылып карарга да ирек бирми. Әйтерсең лә тәндәге һәрбер күзәнәкне җансыз матдә белән алыштырганнар. Бөтен төш хәрәкәтсез, бар нәрсә сүлпәнләнгән. Йөрәк кенә элеккедән катырак тибә.

Фәниярның янында әнкәсе белән Фәурия утыра. Аларның госпитальгә килгәннәренә инде дүртенче көн. Сөйләшер сүзләр сөйләшенгән. Ананың йөзендә арганлык билгеләре. Фәүриянең күзләрендә дә килгәндәге кебек дәрт, ярсу юк. Бөтен өмете, бөтен хыялы, көчле яңгыр утны сүндергән шикелле, врач бүлмәсендә сүнеп чыкты аның.

Врач Николай Сергеевич — оста куллы, үз эшен бик нечкә белә торган нейрохирург. Кандидатлык диссертациясе язып ята. Шуңа күрәме, ул авыруларны ике категориягә бүлеп карый. Бер төрлеләре аның өчен «кызыклы», икенче төрлеләре «кызыксыз» авырулар. Әгәр диссертация темасына туры килсә һәм авыру өметле булса, Николай Сергеевич бөтен көчен куя. Төннәрен дә госпитальдән китми. Ашавын һәм йокысын оныта. Операция ясаган кешесенә үз җанын күчереп куярдай булып хафаланып, борчылып йөри. Ә инде авыру, аның карашынча, өметсез икән, Николай Сергеевичның ачуы чыга. Дөрес, операцияне бик нечкәләп ясый, терелтер өчен вакытын, осталыгын кызганмый. Алай да алга китеш сизелмәсә, Николай Сергеевич үз пациентына чын-чынлап үпкәли.

Фәнияр — Николай Сергеевич каршында «кызыксыз» авыру. Шуңа күрә ул Фәниярлар палатасына сирәк керергә тырыша. Егет тегенди-мондый сораулар бирә башласа, тизрәк чыгып китү ягын карый.

Фәүрияне дә врач салкын каршылады. Әмма кыз андый вак-төяккә игътибар итә торган кешемени?! Үзенекен ярып салды. Мин дөреслекне белергә телим, диде. Врач, Фәүрияне тыңлаганнан соң, егетнең авыру тарихы язылган кәгазьләрне өстәлгә ташлады.

— Менә укып карагыз, кызыксынсагыз снимоклар да бар,— диде.

Фәүрия врач телен аңлап бетермәсә дә, авыру тарихын укып чыкканнан соң Фәниярның гомере буена сузылачак бәлагә тарыганын төшенде, шулай да әле аның бу җансыз кәгазьләргә ышанасы килмәде. Николай Сергеевичның үз авызыннан ишетергә теләп сораулар яудыра башлады.

— Аңлатып бирегезче, зинһар,— диде ул, өзгәләнеп,— нишләп шундый хәрәкәтчән, шундый тиктормас кеше бармакларын да селкетә алмаслык хәлгә килгән? Кешеләрнең куллары сына, сөякләре чәрдәкләнә — тереләләр бит. Муенда да шундый ук сөяк түгелмени?

— Эш монда, сеңелкәй, сөяк сынуда гына түгел,— диде Николай Сергеевич.— Мин аңа үзем операция ясадым. Сөяк кенә сынса, ялгап булыр иде. Хирургия йөрәккә үтеп керә хәзер. Әмма өзелгән нервларны ялгый алучы кеше барын ишеткәнем юк әле минем.

Фәүриягә аның тавышы баздан ишетелгәндәй тонык һәм ямьсез булып тоелды.

— Врач та, вакыт та, авыруның рухи ныклыгы да төзәтә алмасмыни? — дип сорады Фәүрия.

— Әйе. Вакыт күбрәк үткән саен терелергә өмет азая. Әгәр арка миендәге өзеклек булмаса, ике-өч елга кадәр өметне өзмәскә, төрле чаралар белән дәвалап карарга мөмкин булыр иде әле, әмма...

Николай Сергеевич сүзен әйтеп бетермичә туктап калды. Үзенең көчсезлегенә, хәлне берничек тә төзәтә алмавына ачуы чыкты. Фәниярга операция ясаган көннән башлап кәефенә килә алмый йөри инде ул. Фәниярның үзе түгел, авыруы ошамый аңар. Фәнияр — молодец егет. Операцияне дә гомуми наркоздан башка ясатты. Кычкырмаска тырышып ята торгач ике тешен сындырып чыгарган, хәле җиңеләя төшкәч кенә сызлаган тешләрен суыртырга врач чакыртты. Николай Сергеевич мондый авыруларга ихтирам белән караса да, дөреслекне Фәүриядән яшерергә кирәк тапмады. Үзенең көчсезлеге өчен кыздан үч алгандай сүзләрен кисеп-кисеп, төрле ракурста төшерелгән снимокларны күрсәтә-күрсәтә сөйләде. Ул:

— Сез, сеңелкәй, Гатауллинның кәләше булсагыз кирәк, әмма сезгә аның хатыны булырга туры килмәс,— дип сүзен тәмамлады.

Фәүрияне әйтерсең бик авыр әйбер белән бастырып куйдылар: кузгала да, сөйләшә дә алмас хәлгә килде. Кайвакыт куркыныч кинофильмнар караганнан соң шулай саташулы төш күреп интегә иде ул. Юрганына җәһәннәмнең бөтен җен-пәриләре менеп утыргандай авырая, кычкырырга тели — өне чыкмый, кузгалмакчы була — көче җитми. Төшендә саташсаң — иртән аның төш кенә икәнен белеп сөенәсең, ә монда... Фәүрия хирургның: «Су эчеп җибәрегез»,— дигәнен ишеткәч кенә аңына килде һәм стаканлы кулны бар көченә читкә этеп, врач бүлмәсеннән чыгып йөгерде.

Бар да бетте. Бөтенесе җимерелде. Кемгә үпкәләргә, кемнән үч алырга, кемнән ярдәм сорарга? Мең төрле сораулар миен кимерә. Хакыйкать кытыршы теле белән авырттырып-авырттырып йөрәкне ялый. Сулыш урынына үпкәләргә ялкын керә. Кан урынына тамырлардан эрегән кургаш ага. Әллә күктән, әллә күзләрдән аякларга тып-тып кайнар тамчы тама.

Ах, тормышның беренче кайгылары. Бигрәк авыр, бигрәк өшәнгеч икән. Кызның кеп-кечкенә гәүдәсенә шул кадәрле нәрсә өяргә соң? Калын китап укып чыгарга да түземе җитмәгән кешенең сабырлыгын, ныклыгын шул чаклы рәхимсез итеп сыныйлармы? Нигә соң бу тормыш һәркемгә үзе күтәрерлеген генә бирми? Нигә яңа кабынып килә торган мәхәббәт утын рәхимсез җилләр өреп сүндерә? Нигә? Нигә?..

## VI

Фәниярның әнисе Гөлсәйдә түти Фәүрия белгәннәрне белми әле. Аның үз шөгыле шөгыль. Ул Фәниярны үзләре белән алып кайтырга, ничек тә авылга якынрак больницага салырга тели.

— Кызым,— ди ул,— син сөйләшергә оста кеше. Урысчасын да шәп беләсең, берүк хирурлары белән кереп сөйләш инде. Малайны үзебезнең больниска кайтарырга кирәк, диң. Монда ни, тегендә ни — авыру кешене барыбер дәвалыйлар, диң. Ичмасам, үзебезгә якын булса, көн дә килеп йөрербез, диң.

Фәүрия Гөлсәйдә түтинең сүзләрен врачка җиткерде. Врач тегеләйболай каршы килеп маташмады. Фәниярны район больницасына күчерергә ризалыгын белдерде. «Тиешле операциясе ясалган, сынган урын ялганган. Калганын вакыт үзе эшләр. Анасы, туганнары янында чирле кешегә начар булмас. Мондыйларны минут саен карап-тәрбияләп торырга кирәк»,— дип уйлады ул.

Язу-сызу эшләре озакка бармады. Бер көндә һәммәсен әзерләп, җыясын җыеп, төйнәсен төйнәп куйдылар да икенче көнне юлга чыктылар. Озатырга бер медсестра барды.

Вагонда шакы-шокы кайту Фәниярга шактый газап, авырту китерсә дә, аның күңеле шат иде. Ике ай буена беркая да чыкмыйча ап-ак түшәмгә генә карап яткан күзләр өчен горизонт киңәйде. Урманлырак урынга килеп җитә башласалар:

— Сестра, башны бераз калкыт әле,— дип, Фәнияр үзен югарырак күтәртә торган булды. Поезд җиленнән чайкалып калган каеннар да, юлның буеннан-буена сузылган тимер чыбыклар да, еракка-еракка җәелгән зәңгәр офык та шундый сагындырган. Ак каеннарны якын дус итеп кочасы, кара урманнарга кереп көчле тавыш белән кычкырасы, бәбкә үләннәре өстенә ятып ауныйсы килә. Поезд шундый тиз бара, юл буендагы бөтен нәрсә чуар бер тукыма булып күзгә чалына. Их, бераз әкренәйтеп, табигатьнең шул матурлыгын туйганчы карарга иде!

Кеше гомере буена ялан аяк таптап йөргән чирәмнәрен, үзе чапкан печәннәрнең хуш исен онытмый. Таулар — биеклекләре белән горурлык уята. Йөгерек елгалар — йөрәкләргә омтылыш бирә. Карурманнар — дөнья серен пышылдый.

Фәнияр җирдәге һәр нәрсәгә сокланып туймый иде. Госпитальдә яту дәверендә бу тойгы тагын да нечкәргән булып чыкты. Күзләре яшьләнеп китте. Аның Фәүрия белән икәүдән-икәү каласы, табигать хозурлыгына бергәләп шатланасы килә. Ләкин кызга нидер булган. Башына әллә нинди таушалган яулык бөркәнгән. Күзләре талчыккан, кызарган. Гел егеткә карамаска тырыша. Бер дә болай итми иде бит. Берәр нәрсәгә үпкәләсә, минем үпкәләвемне күр, дигән шикелле иреннәрен турсайтып тырт-пырт йөрер иде. Бөтен эшне сыдырып эшләр, тырышлык күрсәтер иде. Бүген янда бөтенләй башка Фәүрия утыра. Борешкән, бетерешкән. Дөньядан суынган.

Ниһаять, Гөлсәйдә түти белән сестра купедан чыгып киттеләр.

— Фәүрия, яныма утыр әле,— диде егет.— Кулларым исән чакта мин сине кочаклый да алмый калдым. Яратышуыбызны да мин армиягә киткәч кенә белдек бит. Ну, ничево, Фәүрия. Тазарырмын да, кабыргаларың шытырдаганчы кочакламын әле үзеңне.

Кайда гына булмый, ниләр күрми
Ир егеткәй белән ат башы,—

дип җырлыйлар бит башкортлар.

Кыз мышкылдап елап җибәрде. Нинди чиргә тарыганын белми шул Фәнияр.

Фэнияр кеше юата белми иде, кызның елаганын күреп аптырап калды. Янына утырып, иңнәреннән алыр иде — куллар тыңламый. Чәченнән сыйпар, бер дә булмаса муенын кытыклар иде. Фәурия шулай кәефсезләнгән чакта үлән белән муенын кытыклый башласаң, һич түзә алмый шаркылдый башлый. Фэнияр аны, янадан турсаймам, дигәнче көлдерә иде. Ә хәзер:

Уф димәс, уфтанмас идем,
Ялкынланып янмасам,—

дип жырларга гына кала.

Фэнияр теләгән сөйләшү барып чыкмады. Поезд Уфага якынлашып килә иде. Фэниярларга Уфада төшеп, башка поездга утырырга кирәк булганга, купеда жыену ыгы-зыгысы башланды. Әйберләр тутырылган чемоданнар кабат-кабат тотып каралды.

Уфа вокзалын Фэнияр күрә дә алмый калды. Килеп туктау белән ике санитар кереп егетне икенче поездга күчереп тә куйдылар. Поезд Уфада озак тормады. «Тизрәк, тизрәк!» дигән тесле, кыска-кыска гудоклар биреп китеп тә барды. Поезд кузгалгач кына үзләре арасында Фәуриянең юклыгы беленде. Барсыннан да бигрәк Фэнияр пошынды:

— Әнкәй, сестра! Фәурия утыра алмый калган бит,— диде ул, ачыргаланып.— Әллә проводникка әйтеп поездны туктатыргамы? Нишләп соң берегез дә жавап бирмисез? Ашыгырга кирәк ләбаса.

— Балам, без нишләек соң? — диде ана.— Поездның киткәнен абайламагандыр. Сабыррак бул, сабыррак. Бүтән вагонга утыруы да бар. Менәтерә күрми дә калырсың, куып та житәр әле.

— Ай, әнкәй, башка поездга утырып адашып йөрмәсә генә ярар иде. Юл йөргән кешемени ул!

Ана улын төрлечә юатырга теләде. Сүзләрнең иң йомшагын, иң үтемлесен сайларга тырышты. Әмма улыннан да ким хафаланмаган ана теленә кирәкле сүзләр килмәде. Ул ана сизгерлеге белән Фәуриянең поездлан болай гына төшеп калмавын сизенә иде. Госпитальгә килгәннең өченче көнендә үк кызның канатлары салынды. Ул янган урман өстеннән очканда канатларына ут капкан кош шикелле баргәләнде, ачыргаланды. Дөрләгән ялкынны кызулык белән сүндереп ташларга теләде, тик кабаланган саен утка ныграк чорнала барды. Менә хәзер инде аның очарга көче житмичә жиргә килеп төшүе бик ихтимал.

Моның шулай икәнлеген сестра гына белде, чөнки киткән чакта Фәурия сестрага ачыктан-ачык сөйләде. Сез Фэниярга үзегез жайлап әйтерсез, аның өчен мин башка берни дә эшли алмыйм, диде. Күзләренә карарга батырчылыгым житми, чәчләреннән сыйпарга кулларым күтәрелми, сөйләшергә телем әйләнми, диде. Сестра, үзе дә бала анасы, үзе дә кайчандыр якын кешесен югалту ачысын татыган хатын булганлыктан, Фэниярга да, әнисенә дә хакыйкатьне ачып сала алмады. Әйдә, өметләнсеннәр, көтсеннәр. Килер диеп ышансыннар. Өметләнү алар файдасына. Әллә ничә тәүлек рәтләп йокы күрмәгән ана һәм бала болай да йончыганнар. Болай да әрнегән күңелне әрнетү кирәкмәс. Сестраның бит әле авыруны исән-имин килеш район больницасына кайтарып тапшырасы да бар.

## VII

Фэнияр Фәуриянең бөтенләй ташлап китүенә бик озак ышанмый яшәде. Поездда барганда һәр тукталыш саен, менә-менә утырып, дип көтте. Ләкин кыз күренмәде. Поезд ажгырып алга барды. Фәурия төшеп калган шәһәр томаннарга, поезд төтеннәренә уралып, торган саен

ераклашты, артта калды. Фәнияр соныннан гына ишетте: Фәурия документларын алырга да авылга кайтып тормаган, почта белән генә соратып җибәргән.

Район больницасында егет өчен иң авыр, иң газаплы көннәр башланды. Ашауның тәме, яшәүнең яме бетте. Больницадагы сестралар, врачларның индидер шәүләләр шикелле күренде аңа. Ул шәүләләр вакытвакыт аның янына килделәр, авызына кайнар аш салдылар. Йотасыңмы, чәйнисеңме — анысын тикшереп тормадылар. Ашаттылар, әйләндереп яткырдылар, яшәтергә теләделәр. Егет ябыкты, суырылды. Әйтерсең лә әкияттәге убырлы карчык һәр көн килеп аның канын эчте. Түгәрәк гәүдәсе үсмер малайларныкы кебек кечерәйде, чандырланды. Элегрәк урыннарын алыштырып җәйгәндә ике санитарка аны көчкә күтәрә иде, хәзер карт нянялар ялгыз килеш тә бер урыннан икенче урынга күчереп йөртәләр. Ваннага алып барырга да, перевязка ясарга да җиңеллек туды.

Озак, бик озак ятты егет тормыштан суынып. Башка вакытта кешеләрнең исемен бер ишетүдә отып кала торган Фәнияр, район больницасында бер еллап ятуга карамастан, һичкемнең диярлек исемен белмәде. Авызына салмасалар — ашамады, дару бирмәсәләр — йокламады. Монда аның иң беренче ачылып сөйләшкән кешесе Хәтерсез Нәсимә булды.

Яңа гына медучилище бетереп килгән яшь, ямьсезрәк бер кыз иде Нәсимә. Ак яулыгын маңгаена чаклы төшереп бәйләр, яулык астыннан бер генә чәч бөртеге дә күренмәс. Ябык булгангамы, җилкәләре калкыбрак торыр. Йөзе озынча, аксыл. Әмма шунсы әйбәт — куллары искиткеч йомшак. Массаж ясый башласа, тырпаеп торган сөякләрең эреп юкка чыккандай була. Бөрешкән тәннәрең языла, авырткан төшең басыла, оешкан каннарың тарала.

Мондый матур, мондый йомшак куллар тагын кемдә генә бар икән?! Гадәттә, кайбер кызлар үзләренең чибәрлекләрен күрсәтергә тырышалар. Елмаюлары сөйкемле икән — ешрак елмаерга, гәүдәләре сылу икән — басыбрак торырга карыйлар. Ә Нәсимә, ямьсез кешегә мондый матур куллар бирелгәнгә оялгандай, аларны күп вакыт халат кесәсенә яшереп йөртә.

Бик хәтерсез иде шул Нәсимә. Массаж ясаганда талькасын берәр палатада онытып калдыра да менә эзли аннары. Кайвакыт Фәниярга иртән массаж ясап китә дә смена бетәр алдыннан тагын кереп ясарга тотына. Егет: «Миңа иртән ясаган идең бит», дисә, Нәсимә кызарып, оялып аска карый. «И, онытып җибәргәнмен икән, бер башлагач ташламыйм инде»,— дип ахырга хәтле эшли. Яки берәр авыру янына кереп утыра да тегенең хәл-әхвәлләрен сорашып, төшке ашын да ашарга оныта. Башка сестралар аның бу хәленнән көләләр. Шуңа күрә кызга Хәтерсез кушаматын тагып өлгергәннәр. Көлсәләр дә хәтере калмый үзенең, башкаларга кушылып бер көлә дә бетә.

Беркөнне Нәсимә Фәниярлар палатасына халатсыз-нисез атылып керде. Битләре кышкы суыктан кызарган. Маңгаена төшеп торган чәчләренә бәс кунган. Үзе еш-еш сулый. Әйтерсең кемдер артыннан куа килгән.

— И шул хәтерсезлекләрем аркасында бөтенләй онытып җибәрә язганмын бит,— диде ул.

— Нәрсәне? — дип сорады Фәнияр.— Бүген синең эш көнең түгел иде бугай.

— Эш көне түгел, анысын беләм. Синең туган көнең бит бүген, Фәнияр. Котлыйм үзеңне!

Фәнияр әллә нишләп китте. Тамагына кайнар төер утырды. Ә Нәсимә кечкенә сумкасыннан үзенең бите кебек кызыл алмалар чыгарып куйды. Фәнияр күчтәнәчләргә карата ризасызлык белдергәч:

— Үзебезнең бакчаныкы алар, сатып алмадым,— дип акланырга керешге. Палатадагы авыруларга конфетлар өләште. Палата бәйрәм төсен алды: шаулаштылар, көлештеләр. Һәркемнең тумбочкасыннан нинди дә булса тәмле әйбер чыкты. Иң ахырдан Нәсимә, бармактан чак кына зуррак итеп ясалган бронза бюст алып:

— Ә менә моны таныйсынмы, Фәнияр? — дип, бюстны егетнең күкрәгенә куйды.

— Ничек инде танымаска! Бу Николай Островский бюсты бит! — дип кычкырып җибәрде Фәнияр.— Кара инде, мин мондый кечкенә итеп эшләнгән бюстлар күргәнем юк иде. Һәйкәлләрне зур итеп урамнарга гына куялардыр дип белә идем. Рәхмәт, Нәсимә!

Фәнияр күзләрен тутырып кызга карады. Нәсимә аның карашыннан уңайсызланып түшендәге төймәләренә үрелде. Шунда гына ул үзенең халатсыз икәнен аңлады.

— И ходаем, халат кияргә дә онытканмын икән, врач килеп керсә кирәкне бирер. Тизрәк халат алып керим әле.

— Кирәкми, Нәсимә. Халат кимә, хәзер, үзең беләсең, врачлар йөри торган вакыт түгел. Ә синең мондый чагыңны күргәнем юк иде минем. Бүген әллә нишләгәнсең, матурайгансың. Чәчләреңне дә күргәнем юк иде, карлыгач канатларыдай кара икән. Нигә син аларны гел яшереп йөрисең? Толымнарыңны чыгарып сал.

— Мин эштә бит,— диде кыз, уңайсызланып.

Шулай да ул яңадан маңгай чәчләренең беразын яулык астыннан чыгарып калдыра торган булды.

Нәсимә китергән бюст Фәнияр тумбочкасы өстенә озакка менеп кунаклады. Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты»сын укып, Павка Корчагинның батырлыкларына сокланып үскән малай бит ул. Павка кебек кыю булырга, буржуйларны кырырга ашкынып йөргән чаклар артта калды. Ә хәзер Фәниярны Павка түгел, китап авторы үзе ныграк кызыксындырды. Островскийның: «Кешенең иң кадерле нәрсәсе — гомере. Гомер аңа бары бер генә мәртәбә бирелә, һәм аны шундый итеп үткәрергә кирәк: үлгән вакытта, бөтен гомерем, бөтен көчем дөньядагы иң матур нәрсә — кешелекне азат итү өчен көрәшкә бирелде, дип әйтерлек булсын»,— дигән сүзләре колак төбендә яңгырагандай булды. Мәктәптә ирекле сочинение язган вакытта да Фәнияр шул теманы сайлаган иде бит.

Ул бу китапны тагын соратып алды. Кечкенәдән таныш геройларың белән очрашу, алар тормышына яңача карау, башкалар язмышын үзеңнеке белән чагыштыру — гыйбрәтле хәл икән.

Әмма Островский белән мавыгу озакка бармады. «Ул кем дә мин кем? — дип фикер йөртте Фәнияр.— Ул искиткеч зур көрәш елларында туган, үз каны белән тарихны язышкан, киләчәккә юллар салып калдыру өчен җилкәләрендә шпаллар ташыган, башкалар бәхете өчен сәламәтлеген дә, гомерен дә кызганмаган. Ә мин әзер ипине сумкага тутырып сигез ел мәктәп сукмагын таптап йөрдем дә әзрәк эшләп алдым. Аннары — армия. Нәрсә күрдем дә нәрсә белдем соң мин? Кешеләрне я белемен, я тормышын, я батырлыгын белән сокландырырлык булмагач, ни турында язмак кирәк?! Язучылык таланты һәркемгә дә бирелмәгән. Островский кебек сукыраючылар, түшәккә егылучылар күптер, шуларның башкасын тагын кем белә? Ах, бигрәк гади шул минем тормыш. Дошман белән бугазга бугаз килеп көрәшкәндә яраланган булсам, үкенмәс идем»...

Фәнияр Корчагин турындагы уйлардан арынырга теләи. Тик тумбочка өстендәге кечкенә бюст күзне йомсаң да күз алдыннан китми. Бер генә кулы эшләсә дә үзенә шөгыль табар иде әле Фәнияр.

Куллар, куллар!

Сездән дә кирәкле, сездән дә кадерле әгъза бармы икән? Кешенең гап-гади таякны эш коралы итеп, шуның белән үзенә ризык табып, шуның белән дошманнарыннан сакланып яши башлавына ничәмә миллион еллар үткән. Кеше куллары остарганнан-остара барган. Куллар, агач сука ясап, иген үстергән, куллар, ташны ташка бәреп, ут чыгарган. Куллар җир астындагы яшерен байлыкларны өскә калкыткан. Кеше кулларында корыч эрегән, ташлар уалган. Җир йөзендәге барлык гүзәл нәрсәне кеше кулы тудырган. Дустыңны сыйпарга да, дошманны кыйнарга да кул кирәк. Кешене кеше иткән дә, кешене көчле иткән дә — кул.

Ә Фәнияр кулы белән кашык та тота алмый. Шундый хәлдә нәрсә дә булса эшләргә хыялланып яту көлке түгелмени? Юк-бар уйларны баштан чыгарып ташларга! Күңелне ымсындырып, үз-үзеңне нигә пошаманга салырга?!

Ләкин уйлар абзардагы тирес түгел шул. Кирәкми дип, аларны көрәп чыгарып булмый. Егет тормыш турында, киләчәк турында уйламаска дип күңеленә беркетсә дә, һаман уйлады, һаман борчылды.

Ә беркөнне аның тормышына яктылык сирпегән бер хәл булды. Шулай гадәттәгечә Нәсимә массаж ясый иде. Фәнияр сул кулында ниндидер хәрәкәт барлыкка килүен сизде. Шатланырга да, кешеләргә әйтергә дә куркып янә кулын күтәрде. Көчәнүдән маңгаена тир бәреп чыкты, йөрәге кысылды, сулышы ешайды. Менә нинди сөенеч: сул кул иякка кадәр күтәрелде. Фәнияр бөтен палатаны яңгыратып:

— Урра, егетләр, бер кулым селкенә башлады,— дип кычкырып җибәрде.

Палатадагы авырулар аның тирәсенә җыелдылар. Хәтерсез Нәсимә, күзләрен халат почмагы белән сөртеп, палатадан чыгып китте. Врачлар һәм сестралар өерелеп керделәр. Һәммәсе куанышты. Шаянрак телле авырулар:

— Кулың авызыңа кадәр күтәрелгәч, ачтан үлмисең икән, Фәнияр,— дип, шаяртып та алдылар.

Бераз селкенә башлагач, Фәнияр кулына һич тынгылык бирмәде. Я терсәге белән стенадагы кнопкага китереп басты, я янына килгән сестраларга, няняларга кулын сузды. Берничә айдан кул шактый көчәйде. Хәзер инде Фәнияр борынына килеп кунган чебенне элекке кебек өреп кенә куркытмый, ә аюга селтәнгән шикелле нык селтәнеп куа башлады.

Бармаклары эшләмәсә дә, кулның күтәрелүе зур файда булды. Фәнияр ашлы тәлинкәне түшенә куеп үзе ашарга өйрәнде, моның өчен кашыкның сабын тиштереп резин тактырды. Кашыкка тагылган резинны кулга кидерәләр дә — рәхәтләнеп аша гына. Дөрес, кул калтырап китеп кайнар аш муенга да түгелә, өскә ябынган одеалларны да чылата. Әмма анысы гына зур бәла түгел. Үз кулларың белән ашаган ашның тәме бөтенесен оныттыра.

Фәнияргдагы алга китешкә Нәсимә бөтен кешедән дә ныграк шатлангандыр. Ул егеткә һич тә тынгылык бирмәде. Массажын ясап, физкультурасын ясатып, җан тирләрен чыгартты.

— Әйдә, озак ялкауланып яттың, хәзер шуны кайтарырга кирәк,— дип, яңадан-яңа күнегүләр уйлап тапты.

Фәнияр йөри торган кулы белән икенчесен дә кузгаткаларга керешге. Ләкин уң кул, гел күтәреп йөртергә өйрәткән баладай, эшләп китәргә ашыкмады. Тик Фәнияр, булмады инде, дип кул селти торганнардан түгел шул. Аның күңеленә өмет кенә ояласын. Бер шырпы белән учак кабызасың, учак бөтен өйне җылыта. Йөрәктәге өмет тә шулай.

Көндез генә вакыты җитмәгәч, Фәнияр төннәрен дә төрле күнегүләр ясый башлады. Арып-талып йоклап китсә, җилкәсендә әллә нинди

авыр бүрәнәләр ташыганын күреп, шабыр тиргә батып уянды. Әгәр бер кулын йөртер өчен агызган тирләрен бергә жыйсаң, күл булыр иде.

Кайларга гына таммый маңгай тире!

Тырышлыгы бушка китмәде егетнең, икенче кулга да жан керде. Хәрәкәте арткан саен, мәшәкате дә артты Фәниярның: хәзер ул кешеләргә күрсәтми генә язарга өйрәнә. Ике бармак арасына карандаш кыстырып куя да икенче кулы белән этеп кәгазь өстеннән шудырып йөртә.

Беренче класста Фәнияр ничек язарга өйрәнде икән? Хәзергедән күп тапкыр жиңелрәк булгандыр, мөгаен. Көч түкмичә, жайлы башкарылган эш тиз онытыла бит. Сәламәт кеше үзе дә сизми торган гади бер хәрәкәт ясау өчен Фәниярга тау кадәр ихтыяр һәм көч кирәк.

Язарга өйрәнү авыр булды. Баштарак хәрефләр кайсы зур, кайсы кечкенә, кайсы яткан, кайсы утырган булалар иде. Кызу-кызу язсаң, сүзгә охшаган нәрсәләр килеп чыга чыгуын, әмма кызуларга кулларның хәле юк. Хәрефне әкрен генә матурлап ясыйм дисәң, кул сикереп китә дә карандаш түшкә килеп төшә. Аннары түш түш инде ул, язу өстәле түгел. Дәфтәр куярга, тәлинкә утыртырга жайланып эшләнмәгән. Чыгып торган сөякләр язарга комачаулый. Ә шулай да азаплану бушка китмәс сыман тоела.

Беренче мәртәбә шигырь язып карау теләге кайчан тугандыр — Фәнияр тәгаен үзе дә әйтә алмас. Шагыйрьне мәхәббәт тудыра, диләр, тик егет йөрәгендә мәхәббәт юк. Ул изге хисне таптадылар. Шагыйрьне нәфрәт тудыра, диләр, анысы Фәниярда житәрлек. Гомумән, усалланды ул. Кешеләргә ышанмау, һәрнәрсәгә шикләнеп карау торган саен арта бара. Больницадагы һәр житешсезлеккә ачуы кабара, врачларның үз авыруы каршындагы көчсезлеге ярсыта. Алар урынында үзе булса, бөтенесе кулыннан килер кебек.

Менә шушы ярсу, ачу аның күңеленнән шигырь булып чыга башлады. Ул берәр кеше исемен сайлап ала да шуны арыганчы кабатлый, охшаш сүзләр, рифмалар эзли. Талип сүзенең табипка якын булуы ошап китте аңа.

> Талип, Талип, начар табип,
> Эшкә килә спирт «кабып».

— Шома гына килеп чыкты шикелле. Житмәсә, нәкъ өстенә басылды: хирургия бүлегенен мөдире Талип Таһировичның эчүдән кызарып, бүртенеп йөрүен кем белми?..

Санитарка Хафиза апага берәр куплет чыгарсаң, шәп булыр иде. Бик йокы ярата торган бәндә. Төнге дежур вакытында йокламыйча калганы бар микән? Басса — баскан килеш, утырса — утырган килеш, ятса — яткан килеш йоклый. Дөрестерме, түгелдерме — бер заман төнге сменадан кайтканда йоклап киткән дә авылның икенче башына барып чыккан, имеш. Аяк астындагы тышаулы кәжәгә абынып уянмаса, һаман барасы икән, диләр.

Сүзләрне солдатлардай тезеп күңеленнән үткәрә торгач, Хафизага карата да бер куплет нәрсә оешты:

> Хафизага йоклар өчен
> Кирәк түгел түшәк тә.
> Йоклап ашый, йоклап кайта,
> Йоклап йөри эшләп тә.

Уйланылган такмакларын кәкре-бөкре хәрефләр белән дәфтәргә теркәп куйгач, янә бер кат куанды Фәнияр. Болай булгач эшләр бара бит.

Больницадагы бөтен кешегә карата шундый шигырьләр чыгара торгач, Фәниярның калын дәфтәре тулып китте. Хәзер аның шигырь

язуын авырулар да белә. Дәфтәр кулдан кулга йөри. Укыйлар, көләләр. Фәниярны шаярып шагыйрь дип атыйлар. Нинди шагыйрь инде ул? Белеме күпме дә тормышта күргәне күпме?! Кеше исеменә кушып чыгарган такмаклар белән генә шагыйрь булып буламыни? Их, менә үзеңнең хыялларыңны, омтылышларыңны, шатлыкларыңны, борчуларыңны шигырь юлларына сыйдырып булсын иде. Юк шул, кулдан килми. Яза башлаганда шундый шәп, шундый тәэсирле әйбер чыгар төсле тоела да, язганнарыңны укып карасаң, беренче класс укучысына да таныш гап-гади фикер була. Тирләп-пешеп язган нәрсәңне кешегә күрсәтергә оялып, тизрәк ертып ташларга ашыгасың. Матур-матур уйлар башка килә, әйтеп бирергә тел җитми. Гаҗәп икән бу тел дигән нәрсә. Элек Фәниярның андый хәлне сизгәне юк иде. Ни сөйләргә тотынсаң да сүзе табыла, сүз җитмәгән җирләрдә куллар хәрәкәтләнә, алар гына да аз тоелса, авыз, йөз, күз карашы ярдәмгә килә иде. Шигырьдә кулларыңны селтәп тә, авызыңны турсайтып та, кашларыңны сикертеп тә күрсәтә алмыйсың. Барысын да сүз белән аңлатырга кирәк. Боларның һәммәсенә сүзне каян табарга икән?

Фәнияр китаплар дөньясына чумды. Беркөнне аңа Муса Җәлилнең өч томлыгы килеп эләкте. Фәниярның бу зур шагыйрьне элек тә укыганы бар иде. Әмма кабат укып бөтенләй яңа хисләр, яңа тойгылар кичерде. Моабит төрмәсендә язылган әсәрләр аның тын күңелендә бомбадай шартладылар. Менә ул кичерешләр, омтылышлар кайда! Менә ул йөрәкнең кимсетелүләргә түзә алмыйча чаң кагуы! Менә көрәшергә, җиңәргә, бирешмәскә өндәгән авазлар! Сүзләр никадәр көчле, никадәр дәһшәтле була ала икән!

Язган әсәрләре генә түгел, Җәлилнең тормышы, дошман өнендә алып барган тиңсез көрәше дә сокландырды егетне. Ул Муса Җәлил язмышында үзенең язмышы белән ниндидер уртаклык күрде. Җәлилне, кул-аякларын богаулап, караңгы зинданга ташлаганнар, җәзалаганнар. Ә Фәниярның кул-аякларын чир богаулаган. Җәлил тәнендә кыйналу эзләре булса, Фәниярныкында пычак һәм инә эзләре. Ничәмә тапкыр операциягә генә керде, инде тамырларында үз каны да калмагандыр. Яткан урының ап-ак җәймә булса да, үз организмыңа үзең хуҗа була алмагач, барыбер хокуклардан мәхрүм ителгән тоткын хәлендә син.

Җәлил барлык кимсетелүләрне җиңеп чыккан, дошманы алдында тез чүкмәгән. Фәнияр үзен урынга кадаклаган авырудан өстен була алырмы? Бөтенесен җиңәрлек көчне каян табарга?

Вакыт дигәнең үтә дә үтә. Вакыт агышын күреп булмый, диләр. Дөрес түгел. Вакыт үзе узган җирдә ташпулатлар, гөл бакчалары, яңа калалар калдырып китә. Вакыт — яңа язылган әсәрләр, яңа ачылган йолдызлар булып күз алдына килеп баса.

Түшәк өстендә ятып, Фәнияр өченче язын каршылый инде. Көче кими, ә көрәшә башлаганы юк әле. Куллары башта эшләп китәрдәйрәк күренгән иде, тик әллә нәрсә майтарырлык йөри алмадылар. Бармаклары, хәрәкәтләнергә кирәклекне гел оныткандай, матурлык өчен генә тагылган әйбер шикелле тик торалар.

Шулай пошынып ятканда беркөнне алар палатасына бер көтү сестра һәм нянялар ияртеп Талип Таһирович килеп керде. Кыяфәте махмырга аракы таба алмаган кешенеке төсле. Халат җиңнәрен сызганган, түшләре ачык. Күкрәгендәге йоннары кабарып тора. Аның артына яшеренеп Хафиза апа кергән, йокысы ачылган күренә.

Исәнлек-саулык та сорашып тормыйча, туры Фәнияр янына үттеләр. Шул чак Талип Таһировичның кулында Фәнияр үзенең шигырьләр дәфтәрен күрде. Врач аның таушалып беткән дәфтәрен борын төбенә үк китереп болгый-болгый:

— Нәрсә бу? — дип акырып җибәрде. Бәләкәй генә гәүдәдән шул хәтле тавыш каян чыга диген?!

— Нәрсә икәнен күрмисезмени? Дәфтәр бит,— диде Фәнияр.

— Ни язып тутырдың син монда? Бәлки, без ялгышабыздыр, яле үзең укып күрсәт, акыллы баш.

Башкаларны этә-төртә, Хафиза апа алгарак чыкты. Фәниярның күкрәге өстенә үк килеп төшкән дәфтәрне алды да үзе турында язылган битне бик тиз табып укып җибәрде.

— Адәм көлкесенә калдырган бит, Талип Таһирович. Йоклар өчен түшәк тә кирәкми, эштә йоклый диген. Аш белән атканга таш белән ату шушы буладыр инде.

Хафиза апа, сүзләре үтемлерәк чыксын дипме, елап ук җибәрде. Еш-еш сөртүдән күз һәм борын кызарып та киткәч, кызганыч кыяфәткә керде. Фәнияр аны үзе дә кызганып куйды.

Хафиза апаның елап бетерүен дә көтмичә, нәзек тавышлы слесарь чәрелдәп җибәрде:

— Та-лип Таһ-рыч, мин-нем турда ул мен-нә нәмәстә диган. Батарейгә пар килми, мон-ның өчен слесарьның үзен тотып парласы бар диган. Вәт җүнсез, вәт әкәмәт.

Слесарь тагын нидер әйтмәкче иде бугай, ләкин палатада шау-шу купты. Кемнәрдер Фәниярны яклап сөйләде, тик төрле тавышлар арасыннан кемнең аклаганын, кемнең таплаганын белерлек түгел иде.

Фәнияр өчен бар да бетте. Дөнья караңгыланды. Әйтерсең кемдер алама бишмәт белән кояшны каплап төште. Күзне ачып карыйсы, авызны ачып сөйләшәсе килмәде.

Палатадан кешеләр чыгып беткәч, Фәнияр баш очындагы бер блокнотын алды. Ул блокнотның тышы бумажник кебек итеп эшләнгән, төрле әйберләр салып куярга җайлы иде. Фәниярның шунда яшерен склады бар. Даруларын җыеп бара ул анда. Төннәрен начар йоклагач, аңа люминал, барбамель ише йокы дарулары бирә башлаганнар иде. Ничектер бервакыт шаярган булып Фәнияр сестрага әйтеп куйды:

— Эчүен эчәм инде мин бу йоклаткыч нәрсәләрне, бөтенләйгә үк йоклап китмәмме соң?

— И,— диде сестра,— кешене бөтенләй йоклатыр өчен илле таблетка кирәк.

Илле таблетка сүзе аның күңеленә кереп утырды гына бит. Бигрәк тә кәефе начар, дөньядан туйган көннәрдә бу сүз хәтергә еш килә башлады. Һәм Фәнияр үзенә төнгелеккә биргән даруларны кешегә сиздермичә генә блокнотының яшерен кесәсенә җыярга кереште. Кай көннәрне сестралар таблетканы үзләре эчерәләр, ә кай көннәрне кулына салып чыгып китәләр. Шул кадәр таблетканы җыяр өчен күп көн кирәк. Ә инде шигырьләр белән мавыгып яши башлагач, бу эшне бөтенләй туктаткан иде. Ярый әле, җыелганнарын юләрләнеп кире биреп чыгармаган.

Фәниярның исәбенчә, барлыгы утызлап таблетка булырга тиеш. Аның кебек күләгәгә шунысы да бик җиткән инде. Йокларга! Мәңгегә күзләрне йомарга! Тәрәзәләргә кагылып, тормыш матурлыгы турында пышылдаган чаган агачлары, хушыгыз. Таң җилләренә кушылып никадәр пышылдасагыз да, Фәниярны уята алмассыз. Әй, болытлар, бер генә минутка кояшны капламагыз. Соңгы мәртәбә күздән яшь чыккан-чы кояшка карасын. Җилләр! Палатага кырлардан арыш исе алып килегез. Хуш, тормыш! Газапларыңны Фәниярның иңнәренә ныграк өй, үзе белән бөтенесен алып китсен.

Ул даруларын җәймә өстенә бушатып салды. Алар борчак шикелле ап-аклар. Кечкенә вакытта куырган борчакны бик ярата торган иде Фәнияр. Табадан алу белән кесәгә тутырасың да урамга атыласың.

Кесәдәге кайнар борчаклар ботны пешерә. Суынып өлгергәнче бер кәтү малай кесәне бушатып та куя.

Таблеткалар кайнар түгел, әмма алар да Фәниярның кулын пешерә. Ул аларны берәм-берәм авызына сала һәм салган берен шытырдатып чәйни. Боларны бу кадәр дә ачыдыр дип белми иде ул. Әйтерсең кайгылы кешенең күз яшеннән ясаганнар. Телне, аңкауны өтеп ала. Сусыз берсен дә йотып булмый. Су кирәк, су!

Больницада көндезге йокы вакыты, шуңа күрә палатадагы авырулар һәммәсе йоклый. Сестралар һәм нянялар да кереп комачауламый. Иң уңайлы чак. Ә тумбочкада графин белән су тора.

Фәнияр калтыранган куллары белән графинга үрелде. Моңа кадәр бер тәлинкә ашны да түшеннән алып куя алмаган кеше, ни хикмәттер, графинны шактый җиңел күтәрде. Шулай да чәч төпләренең юешләнүен сизде. Дөньядан аерылу җиңел түгел икән. Бөтен тәне дер-дер калтырый. Тагын бер генә минут булса да якты дөньяда яшәп каласы килә. Әмма вакытны сузарга ярамый: китәргә булгач китәргә!

Егет карават читенә утырткан графинга үрелде, әмма бу юлы кулы кинәт кенә хәлсезләнде. Әйтерсең тамырларыннан ниндидер кайнар агым үтеп китте. Бармаклар үзләреннән-үзләре язылдылар. Һәм сулы графин паркет идәнгә төшеп чәлпәрәмә килде. Фәнияр үзе дә аңын югалтып башы белән караватка барып бәрелде. Тавышка йоклап ятучы авырулар уянды. Сестра алып керергә чыгып чаптылар.

Сестра белән яңарак эшли башлаган врач Зарипов килеп керде. Ул авыруның пульсын тыңлап карады. Аннары сестраларга ашыгыч рәвештә күрсәтмәләр бирә башлады. Сестра укол ясар өчен Фәниярның одеалын ачып җибәрде. Шулвакыт борчактай ап-ак дарулар идәнгә сибелделәр.

— Бу нәрсә? — дип сорады Зарипов.

— Белмим,— диде сестра.— Безнең авырулар кулына бервакытта да дару биргәнебез юк. Каян алгандыр...

— Хәзер үк идәннән җыеп алыгыз. Нәрсә икәнен ачыкларга кирәк.

Озакламый Фәнияр аңына килде. Ул нервлары артык киеренке хәлгә килүдән һушын җуйган иде.

— Нәрсә эчтең? — дип сорады аңардан врач.

— Йокы даруы,— диде Фәнияр, көчкә генә тынын алып.— Сез борчылмагыз, мин аны эчеп өлгерә алмадым. Сусыз андый нәрсәләрне йота алмыйм мин.

— Кем бирде сиңа аларны?

— Беркем дә бирмәде, үзем таптым.

Зариповның бик нык ачуы килсә дә, Фәниярның хәле авыр булганга, тиргәргә теле бармады.

— Ярар, бу турыда соңыннан сөйләшербез,— дип чыгып китте.

## VIII

Икенче көнне врачларның һәм сестраларның «пятиминутка» дип атала торган иртәнге җыелышлары шактый озакка сузылды. Сүз Фәнияр турында барды. Талип Таһирович кызып:

— Без аны карыйбыз, дәвалыйбыз. Ә ул үләргә маташа, понимаешь. Кайтарып җибәрергә кирәк үзен өенә. И вәссәлам. Барыбер аякка бастыра алмыйбыз бит без аны,— диде.

Врач Зарипов аңа каршы:

— Әйе, аякка бастыра алмыйбыз,— диде,— әмма аны ул килеш ничек өенә озатасың? Ята-ята аркасы, янбашлары тишелеп беткән. Көн саен перевязкаларын алыштырырга кирәк. Ә бит үзегез беләсез, перевязкаларны стерилизовать иткән нәрсәләр белән генә ясыйлар. Гади крестьян йортында аны карарлык шартлар юк.

— Һәр авылда фельдшер бар, перевязкаларны фельдшер да ясый ала,— диде Талип Таһирович.

— Рөхсәт итсәгез, өйләренә мин барып йөрермен,— диде Нәсимә. Үзе кыюланып китүеннән оялып аска карады.— Аңарга массаж да кирәк.

— Без сиңа анда барып йөргән өчен аерым эш хакы түли алмыйбыз, кызый,— диде Талип Таһирович.

Нәсимәнең аның сүзләренә хәтере калды.

— Эш акчадамыни!

Шул вакыт бер няня кереп:

— Гатауллинның әнисе килгән, кертергәме? — дип сорады.

— Монда алып кер әле син аны,— диделәр врачлар.

Гөлсәйдә түти кыенсынып кына боларның бүлмәсенә узды. Керү белән аңа өлкән сестра урындык тәкъдим итте. Талип Таһирович бераз арлы-бирле йөргәннән соң:

— Апа, сезгә сүз бар иде,— диде.

— Нинди сүз? — диде Гөлсәйдә түти сагаеп.

— Улыгыз турында инде. Аны без дәваламадык түгел, дәваладык. Яшереп маташу кирәкмәс, үзегез дә күреп торасыз, рәтләнү ягына бармый бит. Әллә өегезгә алып китеп карыйсызмы? Карт кешегә район тикле җиргә килеп йөрүе дә кыендыр.

Гөлсәйдә түти ни әйтергә белмәде. Фәнниярны өйгә алып кайтып, каен себеркеләре белән чаба-чаба парлы мунчаларда юындырасы, яраларына пешкән юкә яфраклары ябып карыйсы, кыскасы, үзенчә дәвалыйсы бик килә иде аның. Ләкин карый алуына гына шикләнә. Ни әйтсәң дә, тоткан-ниткән эш түгел бит.

— Өйдә тагын да начарланып китмәс микән соң? — диде Гөлсәйдә түти.— Кара эшләрен мин башкарып та чыгармын ди. Ә бит...

Ананың ни әйтергә теләгәнен бар да аңладылар.

— Анысы өчен борчылмагыз, менә Нәсимә үзем барам дип тора. Карар, бөтен кирәген эшләр,— диде врач.— Кирәкле материалларын да биреп җибәрербез.— Талип Таһирович теге вакытта Фәнниярга катырак кагылганы өчен бераз үкенә иде бугай, шунлыктан әнисе белән йомшаграк булырга тырышты.

— Әле мин капыл гына бер нәрсә дә әйтә алмаем,— диде Гөлсәйдә түти.— Балалар белән дә, Фәнниярның үзе белән дә киңәш-табыш итешик. Көчебез җитәрдәй күренсә, баланы больниста тилмертеп яткырмабыз.

Гөлсәйдә түти врачлар бүлмәсеннән чыккач Фәнияр янына керде. Улы аны һәрвакыттагыча ачык чырай белән каршылады. Бераз сөйләшеп утырганнан соң, Гөлсәйдә түти:

— Больниста ята-ята да туйгансыңдыр инде,— дип сүз башлады.— Өйгә кайтасың килмиме?

— И әнкәй,— диде Фәнияр көрсенеп,— бездә бит сынган сарык сыйрагын бәйләрлек тә кеше юк. Анда мине кем карасын?

— Башыңа төшсә, башмакчы буласың, диләр. Карарга өйрәнербез әле. Мунчасына-ниенә абыең күтәреп алып барыр, бүтән йомышларыңны мин йомышлармын.

Гөлсәйдә түти врачлар белән булган сүз турында әйтмәде. Авыру кеше шикчелгә әйләнә, миннән җайлы гына котылырга, больницадан озатырга уйлыйлар икән, дияе бар. Дөрес, Фәнниярның үзенең дә өйгә кайтасы килә, ләкин туганнарына уңайсызлык китерүдән курка иде. Аннары, абыйсы өйләнергә исәпли, әгәр Фәнияр авылга кайтса, туйлары өзелеп куймасмы? Авылда йортлар әллә ничә бүлмәле түгел, һәммәсенә бергә яшәргә туры киләчәк. Авырулы йортка беркемнең дә килен булып төшәсе килмәс.

Ана, үзе дә бу хакта уйланганлыктан, башта улы Заһид белән сөйләшергә булды. Заһид механизаторлар мәктәбен бетереп, авылда тракторда эшли иде. Әнисе ул көнне аның кайтуын көтеп алды. Ә кайтып кергәч:

— Улым,— диде йомшак кына.— Фәниярны өйгә апкайтсак, карый алырбыз микән? Таба ашлары ашатырыек үзенә...

— Бик әйбәт булыр,— диде Заһид.— Алып кайтыйк. Карарбыз. Кирәк җирдә үзем күтәреп йөрермен.

— Анысы син карамассың дип әйтмим, тик ни бит...

Гөлсәйдә түти улының өйләнәсе барлыгын әйтмәкче иде, әмма ничек итеп әйтергә белмәде. Сүз эзләп шактый җәфалангач кына:

— Синең башлы-күзле буласың бар, чирле кешесе бар йортка килен килерме диюем.

— Һи, әнкәй, юкка аптырама, яратса төшәр. Яратмаса — бүтәннәрен табарбыз. Синең малаең төшеп калганнардан түгел бит әле. Сынатмабыз, Фәниярны да алып кайтырбыз, киленен дә төшерербез. Туйга энекәшне алып кайтырга үземнең дә исәп бар иде. Шәп була бу, әнкәй. Фәниярның әзрәк күңеле күтәрелер. Кыерсытмабыз...

Ананың өстеннән тау төште диярсең, җиңеләеп, тынычланып калды. Ә бераздан алар Фәниярны алып кайтырга хәзерләнә башладылар. Гөлсәйдә түти бик тырышып мичен акшарлады, Фәниярның армиягә киткәнче киеп йөргән күлмәкләрен, чалбарларын сандыктан чыгарып җилләтергә элде. Таушалганракларын юып үтүкләде. Кияүдәге кызлары үзләренең бала-чагалары белән килеп, өйнең стеналарын, идәнтүшәмнәрен сап-сары итеп кырып юдылар. Бәйрәмнәрдә генә эленә торган кашагалар, чигүле чыбылдыклар эленде.

Фәниярлар барлыгы алты бала үстеләр. Дүртесе кыз, икесе малай. Кызлар инде барчасы үз ояларын кордылар. Шулай да, Фәниярны алып кайтасы булгач, бөтенесе, сүз куешкандай, җыйналып төп йортка килделәр. Гөлсәйдә түтинең олы кызы Васимә:

— Беләсезме, туганнар,— диде.— Фәнияр кайтуга бирәр бүләк әзерләргә иде безгә.

— Нәрсә бүләк итәргә соң аңарга? — диештеләр башкалар.

— Телевизор алсак шәп булыр, минемчә,— диде Заһид. Барысы да Заһидка борылдылар. Мондый зур әйберлек акча берсендә дә юк иде.

— Акча дисезме? — диде Заһид.— Акча бар ул.

— Кайда? Кемдә?

— Соң мин бит өйләнергә җыенып йөрим түгелме? Шулай булгач, туйлык акча бар. Телевизорга җитәр дип уйлыйм.

— Ә туй? — диде Гөлсәйдә түти.

— Соң, әнкәй, анысын бераз соңлатып та була бит инде. Әзрәк баш-күз алгач, мая туплагачрак өйләнермен.

— Фәнияр үзенә мондый корбан бирүне белсә, беребезне дә кичермәс,— диде уртанчы кыз.— Ул бик горур кеше. Иң яхшысы — без болай итик: бөтенебез җыйнаулашып алыйк. Биш семьядан бер телевизорлык кына байлык табылмый калмас. Туй да кичектерелмәс, Фәнияр да шатланыр.

Чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыга, дигәннәр бит картлар. Туганнары тәки бер телевизорлык акча җыйдылар, хәтта бурычка да кермәделәр.

Фәнияр кайтканда өй курчак өедәй җыештырылган, ә почмакта «Енисей» дигән телевизор тора иде. Фәнияр моңарга барыннан да ныграк сөенде. Район больницасында аның ише нәрсә булмаганлыктан, дөньясы киңәеп киткәндәй булды. Гомумән, аның әле телевизорны беренче күрүе иде. Армиягә киткәндә авылда, күрсәтә торган радиолар бар икән хәзер, дип сөйләнәләр генә иде. Телевизорны ул «хикмәтле тәрәзә» дип атады. Тапшырулар башланыр вакыт җитте исә: «Әнкәй,

теге хикмәтле тәрәзәне ачып җибәр әле»,— дип әйтә торган булды. Бу тәрәзәдән ишегалдын, урамны гына түгел, бөтен дөньяны күрәсең. Мәскәү урамнары буйлап сәяхәт итәсең, Африка джунглиларына барып чыгасың, диңгез дулкыннарының ярларны кыйнавын күзәтәсең.

...Фәнияр кайтып озак та үтмәде, Заһид абыйсы өйләнеп җибәрде. Киленне озата килүче кызлар Фәниярлар өендәге бөтен әйберләрне алып үзләренекен элделәр. Иң матур чәчәкле чыбылдык белән Фәнияр караватын әйләндереп алдылар. Туйлар күңелле үтте. Җиңги тиешле кеше киң күңелле һәм тыныч табигатьле кеше иде. Беренче көннән үк кирәк очракта Фәниярны караудан тартынып тормады. Әмма Фәнияр үзе генә җиңгәсенә эш кушарга ояла иде.

## IX

Фәнияр өйдә карый алмаслар дип курыккан иде. Яраларын бәйләргә Нәсимә килеп йөри йөрүен. Ләкин кеше дигәнең никадәр авыр ятмасын, һичнинди хәрәкәтсез тора алмый: кыймшана, селкенгәли. Шул кыймшанган арада Нәсимәнең яңа гына ябыштырып киткән марлялары да кубып төшкәли. Аның өчен генә авылның икенче очындагы фельдшерга бармассың бит. Тота да ана үзе бәйли.

Баштарак Гөлсәйдә түти мондый очракларда аптырабрак кала иде. Ләкин тормыш батырайтты аны. Тегендә — больницада чакта врачлар, сестралар, «инфекция эләкмәсен» дип, ярага яба торган салфеткаларны пинцет белән генә тотып маташалар иде. Гөлсәйдә түти авыл хатыннарына гына хас беркатлылык белән: «Судан да чиста нәмәстә юк», дип, кулын сабынлап юып җибәрә дә рәхәтләнеп тотып ябыштыра да куя. Мунчага алып барсалар, ләүкәгә яткырып, йомшак итеп пешерелгән каен себеркесе белән бөтен җирен бик каты чаба. «Тиреңчыксын, тиреңбелән чиреңдә чыгар»,— ди ул. Фәниярның янбашындагы яралары кайвакыт канап чыга. Монда да ана аптырап калмый: «Бозык каның акса, тизрәк савыгырсың»,— ди.

Фәнияр көзән җыерулардан бик нык җәфалана иде. Кискенрәк хәрәкәт ясаса да, көчәнебрәк әйбер күтәрсә дә, кинәт бөтен тәнен куырып алгандай итеп көзән җыера башлый. Кайвакыт өстенә ябынган юрганы шуып төшә дә, шуны тартып алыйм дип кыймшанды исә, куырыла да ката. Врачлар телендә моны «спастика» диләр. Больницада ятканда тартышуларны басар өчен Фәниярга еш кына дару бирәләр иде. Ләкин алар да вакытлыча гына тынычландыра.

Өйдә Гөлсәйдә түти моңа каршы үзенчә эшләп карарга ниятләде. Көннең иң озын вакытларында ул һәр елны дару үләннәре җыеп, чормада киптерә иде. Шул үләннәрне кайнар суда парландырып, Фәниярны көн аралаш суга кертә башлады. Моның өчен Заһид агачтан улак ясап бирде. Фәнияр әнкәсенең бу мәшәкатьләнеп йөрүләренә каршы:

— Юкка маташасың, әнкәй, мин аның ише ырымнарга ышанмыйм,— диде.

— Сине анаң ырымларга да, сихерләргә дә җыенмый, үлән белән борын-борыннан дәвалаганнар,— диде Голсәйдә түти ачуланып. Һәм авылда фәлән кешенең шулардан файда күрүен, хәзер җен кебек эшләп йөрүен сөйләп алды. Фәниярның мондый эшләргә күңеле ятмаса да, җанын бирергә йөргән әнкәсен рәнҗетәсе килмәде. Сыкрап-сыктап ризалашты.

Гөлсәйдә түти үз белдеге белән:нме, кешеләрдән ишетепме, улын күбрәк акбаш суына кертте. Ананың мәшәкатьләре бушка китмәде: Фәниярның көзән җыерулары кимеде. Ни хикмәттер, янбаштагы өч ел чиләнеп интектергән яралары да бетә төште. Гөлсәйдә түти улы ваннадан чыгу белән яраларына бал сөртеп куя торган булды. Больницада Вишневский мазы дип аталган начар исле бер дару сөртеп бәйлиләр

иде. Озак вакыт аның исен иснәү Фәниярны шул тикле туйдырды, исе борынына керсә дә, күңелен болгата башлады. Аннары аның исе бөтен өйгә тарала, янына кергән кешеләрнең борыннарын тотып утырулары кемнең кәефен кырмасын?! Балның, ичмасам, исе тәмле. Чәчәкләр арасында яткандай тоясың үзеңне.

Еш әйләндереп яткырулар файда иткәндерме, әнкәсенең мунчалары-үләннәредерме, әллә балмы — Фәниярның яралары төзәлде. Яра урыннарында, пешкән төш шикелле, шома кызыллык кына калды. Егетнең яралары беткәч, Нәсимә хәтта күңелсезләнгәндәй күренде.

— Хәзер миңа эш тә калмады инде,— диде ул, төшенке генә.

— Эшләргә генә димәгән, син кунакка кил, Нәсимә,— диде Гөлсәйдә түти, кызның аркасыннан сөеп.

— Әйе,— дип өстәде Фәнияр да,— кунакка кил.

Ә беркөнне боларга врач Зарипов килеп керде. Аңа Нәсимә Фәниярның яралары ябылуын әйткән икән. Врач шулар белән кызыксынды.

— Нәрсәләр кулландыгыз? Ничә көн саен перевязка ясадыгыз? Кыен булмаса, барсын да сөйләгез әле,— диде ул Гөлсәйдә түтигә.— Дөресен әйтим, мин шундый яраларның ябылуына ышанмаган идем.

Врач Фәниярны баштанаяк карап чыкты. Гөлсәйдә түти эшкә оста булса да, сөйләргә дигәч, авызын яулык чите белән каплап сүзсез калды.

— Аны кем сәгатьләп-көнләп караган инде,— диде ул бераз торгач.— Акбаш белән бергә әреме, кычытканы да кереп киткәндер. Бәйләвен дә көнләп түгел, купкан саен ябыштыра тордык. Шуларның кайсысы шифалы булгандыр, алла белсен.

Врач үзе белән бераз дарулар һәм башка кирәк-яраклар алып килгән икән, аларны калдырды. Саубуллашканда:

— Хәзер бик нык саклагыз инде, тәннәре яңадан тишелмәсен. Ә син, Фәнияр, күбрәк кырын яки йөзтүбән ятарга тырыш,— диде.

...Яз җитеп, тәрәзәдән җилләр өрми башлагач, Фәнияр үзенең элеккке яраткан тәрәзәсе янына ятты. Моннан өянкедәге сыерчык оясы да, бакча да яхшы күренә. Күзләрең талганчы карарга, арыганчы сыерчык сайравын тыңларга мөмкин. Хәзер барлык кошларның да оя корып, тормышларын көйләргә җан-фәрман тырышып йөргән чаклары.

Тышта апрель. Шатлыктан чыккан күз яшьләре кебек, түбәдән көмеш тамчылар тама. Ерактан тонык кына ишетелгән музыка тавышын хәтерләтеп, кар астыннан чылтырап сулар агып ята. Ачылмый утырган агач бөреләрен кошлар чукып ача, таулар изүләрен чишеп җибәргәннәр: күкләр, аңа күңеленнән тукылган тукыма кебек, саф һәм пакь.

Әллә яз, әллә бала чактан якын урыннарны яңадан күрү Фәниярның күңелен кузгатып җибәрде. Әле салкын булса да, тәрәзәләрне ачып җибәрергә кушты ул. Тыштан төрле тавышлар ургылып керде. Язның исерткеч музыкасын тыңлап туйганнан соң, ул үзенең кечкенә транзисторын ачып җибәрде. Эфирда Левитанның тантаналы, дулкынландыргыч көр тавышы яңгырый иде. Тукта, чү!.. Космоска кеше очырганнар! Дөньяда беренче тапкыр космоска кеше җибәргәннәр, ул батыр — безнең совет кешесе! Искиткеч, шаклар каткыч вакыйга бу!

Шушындый дөнья шаулаткыч яңалыкларны ишетер өчен генә дә яшәрсең. Андый вакыйгаларның шаһиты булу өчен генә дә әллә ни бирерсең.

Фәниярның күңелен галәмгә очкан батыр белән горурлану хисләре биләп алды. Бөтен дөньяның исен китәрерлек мондый тиңдәшсез батырлык турында ишеткәч, үзенең уңышсызлыклары, борчылулары бик кечкенә тоелды аңа. Космоска очкан геройның исемен ишеткәнче, армиядәге дусты Ризван түгелме дип, өметләнебрәк торган иде, ул булып чыкмады. Беренче тапкыр очмаса, икенчесендә очар. Ризван — телә-

гәнен булдыра торган егет. Хәзер инде очучылар мәктәбенә укырга кергәндер. Ни әйтсәң дә, безнең заман кешесе өчен өч ел вакыт бик күп бит ул. Көн саен дөньяны таң калдырган яңа ачышлар, яңа уңышлар турында радиолар сөйләп, газеталар язып тора.

Бу көнне Фәниярга тагын бер сөенечле хәбәр китерделәр. Бусын радиодан да сөйләмәделәр, телеграмма белән дә җибәрмәделәр. Җиңү булса да, бу Фәнияр өчен генә җиңү иде. Фәниярга шатлык алып килүче — Нәсимә булды. Аның инде Фәниярларга килмәгәенә бер-ике атналап бар иде. Кыз бик дулкынланган, шатланган. Шатлыгын никадәр яшерергә тырышса да, иреннәре үзләреннән-үзләре елмая иде.

— Космоска очканнарын ишеткәнсеңдер инде, Фәнияр. Башта сине шул зур җиңү белән котлыйм,— диде ул һәм егетнең кулын кысты.

— Рәхмәт,— диде егет. Кызның үзен дә тәбрикләде.

Нәсимәнең тагын нидер әйтергә теләве кояш төшкән тамчыдай ялтыраган күзләреннән үк күренеп тора иде.

— Бусын,— диде ул,— биесәң генә әйтәм. Шунсыз котыла алмассың.

— Бии ала башлау белән, иң беренче сиңа биеп күрсәтермен, Нәсимә.

— Алайса, җырла, мин анысына да риза.

— Уйнама әле, Нәсимә, җырлый-җырлый шатланырлык нинди шатлыгым булсын соң минем?!.

— Бар икән шул менә...

Фәниярның сабырсызлана башлавын күреп, Нәсимә урындыкка куйган сумкасыннан бер газета чыгарды. Бу — районда чыга торган «Байрак» газетасы иде.

— Менә укы, шатлан. Синең шигырьләреңне басканнар.

Фәнияр, кабаланып, сузылган газетаны алды. Куллары калтырады, күзләре томаланды. Шулай да күзенә иң беренче чалынган нәрсә — үзенең шигырьләре булды. Чынлап бит, Фәнияр Гатауллин шигырьләре, дигәннәр. Башка кеше белән бутау мөмкин түгел. Фәниярның авыру егет икәнлеген, язмышына буйсынмыйча, Островский кебек язарга керешүен әйткәннәр. Шуннан соң Фәниярның ике шигыре бирелгән.

Каян алганнар? Бу шигырьләр язылган дәфтәрен беркемнең дә күргәне юк иде бит. Ул больницада матрац астында калган иде. Кайткан вакытта исендә булса да, Фәнияр ул дәфтәрен алдырмады, нигә кирәге бар дип уйлады. Ә менә бүген озак уйланулар, күп тырышулар аркасында туган, шундый якын, шундый үз булып, һәр сүзе хәтергә сеңгән таныш шигырьләрен газетадан укыгач, егетнең күзләреннән яшь атылып чыкты. Янында Нәсимә утырганлыгын да, кулында газета барлыгын да онытып, шатлыктан мөлдерәгән яшьләренә ирек бирде. Күңеле моңа кадәр кичермәгән әллә нинди татлы, газаплы хисләр кичерде.

Җиңү! Кечкенә генә җиңү! Үз-үзен югалта башлаган, көченә ышанычы кимегән, сабырсызлыктан гасабиланып тормыштан туеп барган кешенең беренче җиңүе. Менә нинди ләззәтле син. Ширбәттәй башны әйләндерәсең, йөрәкне җилкендерәсең. Сусаган кеше иреннәрен чишмәдән аера алмаган кук, җиңү куанычыннан аерыласы килми. Аның бервакытта да мондый татлы күз яшьләрен татыганы юк иде.

Үзен бераз кулга алгач, дулкынлануы басыла төшкәч, Фәнияр Нәсимә барын хәтерләде. Йомшап китүеннән оялып:

— Нәсимә, син көлмә инде, минем күңел әллә нишләгән: бер карыйсың — таштай катып китә, икенче карыйсың — тулып түгелә,— диде.— Йөрәк дигән нәрсәнең кайсы якта икәнен дә белми идем, ул да, йомырка кабыгын тишеп чыгарга азапланган чебидәй, тибенеп тора башлады.

Нәсимә аңа якынрак килеп утырды. Бу коңгырт күзле, озак ятуга карамастан бер дә төс куймаган чибәр егетне никтер беренче көннән

үк якын итте ул. Шуңарга нинди дә булса бер яхшылык эшлисе килеп кенә тора. Фәниярның матрац астындагы дәфтәрен дә ул табып алды. Тапты да, кешегә-нигә сөйләп тормыйча, редакциягә китте. Моңа кадәр газета белән алыш-биреше булмаса да, редакторын табып, бөтенесен сөйләп бирде. Менә, диде, бездә шундый-шундый егет ятты. Кулларына рәтләп каләм дә тота алмаган килеш язарга өйрәнде, матур-матур шигырьләрен больницадагы авырулар ятлап йөриләр хәзер, диде.

— Карале, Нәсимә,— диде Фәнияр,— минем бу шигырьләрне редакциягә кем җибәргән дә, авыру икәнлегемне каян белгәннәр?

Нәсимә бер сүз дә әйтмәде, башын аска иде. Әгәр Фәнияр кызга төбәп караган булса, аның йөзендәге үзгәрешне күреп, бу эштә Нәсимәнең катнашы барлыгын аңлар иде. Ләкин Фәниярның уйлары еракта, хыяллары биектә иде шул, ул кат-кат төпченеп маташмады. Кем җибәрсә дә барыбер түгелмени?

## X

Шигырьләре газетада басылып берничә көн үткәч, Фәниярга хатлар килә башлады. Күбесен кызлар яза. Кызлар күңеле кылдан нечкә, кылычтан үткен шул: ни кирәген хәзер тоеп ала. Юатырга ашыга. Егетнең батырлыгына соклана.

Батырлык! Нәрсә соң ул батырлык? Газинурлар, Матросовлар шикелле күкрәгең белән дошман амбразурасын каплаумы, әллә үзең ач чакта соңгы сынык икмәгең белән бүлешүме? Кешеләр төрле-төрле булган кебек, батырлык та күп төрле шул.

Берәүләрне тормыш гомергә бер тапкыр сыный. Кеше дөнья зилзиләләренә каршы үзенең кечкенәдән үк җыеп килгән бөтен гайрәтен, ана сөте белән кереп тамырларына таралган көчен куя. Куя да өстенә ябырылып килгән бөтен авырлыкны бер селтәнүдә юкка чыгара. Шул мизгелдә каушап калмаганны батыр диләр.

Икенчеләрне тормыш көн саен, сәгать саен сыный. Алар күкрәкләре белән дошманның ялкын чәчеп торган дзотларын япмыйлар, галәм биеклекләренә күтәрелеп, дөньядагы барлык кешеләрнең карашларын үзләренә юнәлтмиләр. Туктаусыз тамып торган тамчыдай, сиздерми генә, шау-шусыз гына эшлиләр. Беренче тамган тамчыны һичкем игътибарга алмый. Тама-тама ташны тишеп чыккач кына тамчыга сокланалар. Ә ташны тишеп чыкканчы ай-яй озак тамасы бар. Ничә язлар көтәсе бар, ничә кышлар үтәсе бар.

Фәнияр әле ташны тишә алдымы соң? Моны батырлык дип атап буламы? Язылган хатларның эшләнмәгән эшкә әйтелгән рәхмәт кенә икәнен яхшы белә ул. Әле бу күкрәгең белән дулкыннар ярып диңгездә йөзү түгел, яр читендәге талларга тотынып аяк чапылдату гына. Хәзер эшкә чын-чынлап тотынырга, аңа ышаныч белән караучыларның ышанычын акларга кирәк.

Ул кечкенәдән үк төрле мәзәк уйлап чыгарырга оста иде. Берьюлы ике шигыре басылып чыккач, егетнең хыяллары уйнап китте. Дөньясын онытып, тагын әллә ничә шигырь язып ташлады. Шигырьләрнең күпчелеге балалар өчен язылган иде. Үзенә ошаган байтак әсәрен аерым дәфтәргә туплап, балалар газетасына җибәрде. Фәнияр газетадан җавап болай тиз килер дип уйламаган иде. Атна-ун көн үткәндерме-юкмы, тышына пионер значогы һәм кызыл галстуклы балалар сурәте төшкән зур конвертта озын итеп язылган хат килде. Хатны Илдус Гаделшин дигән кеше язган. Бу кешенең шигырьләрен Фәниярның газета-журналларда укыганы бар иде. Республика газеталарының берсендә эшләүче, шигырьләрен калын журналларда бастыручы шагыйрьнең хатын тыныч кына укый алмады Фәнияр.

Шагыйрь кешедән алган беренче хат иде бу. Күз алдыннан үткән көннәр чагылып узды. Фәнияр кечкенә чакта су буенда комга бармагы белән сызып рәсем ясарга ярата иде: чабып барган куяннар, үрмәләүче ташбакалар, шар сугучы малайлар. Хыялына нәрсә килсә — шуны ясый. Дөрес, аның рәсемнәрендәге куяннар кәҗә бәтиенә, ташбакалар кырмыска түмгәгенә охшашлы булып чыгалар. Әмма зыян юк, үзе таный ич ул аларны. Барыбер ул рәсемнәрне дулкын юып китә. Матуррак чыкканнарын кайвакыт озаграк саклыйсы, бүтән малайларга күрсәтәсе килә. Тик рәхимсез дулкын әллә каян гына тәгәрәп чыга да комны тигезли дә ташлый. Фәнияр елгага йодрык яный, үзсүзләнеп тагын рәсемне ясамакчы була, ләкин яңадан ясаганда элеккесе кебек шәп чыкмый.

Фәниярның язган шигырьләре дә, кечкенә вакытта комга ясаган рәсемнәре төсле, үзенә генә аңлаешлы булмасмы? Дулкыннар бик тиз юып китмәсме? Шагыйрь кеше аның әсәрләренә карата ни дигән?

Әллә ничә мәртәбә укыгач кына, шигырьләреңнең берничәсен ошаттык, бер-ике атнадан басылып чыгар, газеталарны караштырып бар, дигән сүзләрне укый алды Фәнияр. Илдус Гаделшин хатының ахырында Фәниярның кем булуы, укучы булса ничәнче класста укуы турында сорашкан.

Фәнияр аңа үзенең авыру кеше икәнен, шигырьләр язарга бик яратуын, әмма шигырьләренең бер дә шәп чыкмавын әйтеп язды.

Илдус Гаделшин Фәнияр язмышына битараф калырга теләмәде. Гомерендә бер тапкыр да күрмәгән, ләкин берничә хаты аша шактый якын булып өлгергән Фәнияр йоклаганда да аның уеннан чыкмады.

Ниндирәк кеше икән? Акыл утырган картмы, әллә тормышның беренче ялкыннарына канаты өтелгән яшь җилкенчәкме? Шигырьләрендә дөнья күргән кешеләрнең генә башына килердәй фикерләр белән сабыйларча беркатлылык янәшә тора. Янына барырга, күрергә кирәк!

Илдус Гаделшин редакциядән өч көнлек командировка алып Фәнияр яшәгән якка юл тотты. Фәниярның туган авылы Кызыл Кыяга килү кыен булмады. Бөгелмәгә хәтле самолет белән очты, аннары типтигез асфальт юлдан йөрүче автобус өч-дүрт сәгать эчендә китереп тә җиткерде.

Үзе балалар яраткан кеше булгангамы, кая гына барса да Илдус Гаделшинга кызыклы бала-чага очрап тора. Кызыл Кыя авылына килеп кергәч тә, үзенә юл күрсәтүче итеп бер малайны сайлады. Малай авылы белән горурлангандай:

— Безнең авыл бик зур, абый. Гатауллиннар да күп, сиңа кайсысы кирәктер? — диде.

— Миңа шагыйрь Фәнияр Гатауллин кирәк,— диде Илдус.

— Син, абдый, шутник икәнсең, безнең авылда нинди шагыйрь булсын, ди.

Малай шулай «з» урынына «д» әйтеп сөйләшә. Илдуска үзенең туган ягы Минзәләдәге малайларны хәтерләтте ул. Әллә кечкенәдән таныш сөйләм ишеткәнгә, әллә ут борчасыдай тере малайны ошатканга, ныклабрак сорашырга тотынды:

— Син ничәнчедә укыйсың, дус кеше?

— Миңа дус кеше диярга, бед синең белән бодау көтмәдек бит әле,— диде малай. Күренеп тора: сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел.— Безнең укытучы апа әйтә: олы кеше сораганда җавап бирергә кирәк, ди. Әйтәем инде дус кешең булмасам да, дүртенчедә укыем.

— Исемең дә бардыр инде синең? — диде Илдус.

— Барые, сине күргәч истән чыкты әле. Бу абдыйның исеме ничек микән дип барадырыем үдем дә.

— Мин Илдус булам.

— Ә мин — Шәвәли. Шәүкәт Галиев абдый ядган Шәвәли түгел түлке. Аның безнең авылга килеп караганы да юк әле.

— Син шагыйрь Фәнияр Гатауллинны белмисең, алайса? Классыгыз белән янына барганыгыз да юкмыни?

— Булмаган шагыйрь янына ничек барасың инде, абдый?

Шәвәлинең бу сүзләреннән соң артык сорашып маташуның кирәге юк иде. Ул:

— Авырып ятучы Фәниярларны беләсеңме соң? — дип сорады.

— Анысын беләм, абдый,— диде Шәвәли.— Алар теге баштук, типтәрдүк торалар. Шушы урам белән бар да бар.

— Әйдә, мине шуларга чаклы илтеш әле,— диде Илдус.

— И абдый, баргач кайтасы була бит. Безнең авылда әлегә трамвайлар йөрми. Мин аларның өйләрен сиңа болай да үрәтә алам. Шулай бар-бар да, бара торгач, түбәсе салам белән ябылган бер өй күрерсең. Салам башлы өй авылда шул гына. Ул өйнең ишегалдында бик җилле бура булыр. Вәт шул өйдән соң бер шифер түбә үтәсең, шиферлан соң өч түл түбә рәттән китә. Уртадагысына керсәң, Фәнияр абдыйларныкы булыр.

Илдус Гаделшин Шәвәлинең өйрәтүе буенча килеп, Фәниярларның өен җайлы тапты. Шәвәли бик күзәтүчән малай икән: һәммәсен дөрес тасвирлаган.

Илдус килеп кергәндә, Фәнияр укып ята иде. Ят кешене күргәч, китабын караватка куйды. Ике таныш түгел кеше бик кыска гына вакыт эчендә бер-берләренең күзләренә карашып алдылар. Фәниярның күзләре искиткеч тере, әйтерсең бөтен хәрәкәте күзләренә күчкән. Ябык кулларын күрмәсәң, Фәниярны ял итәргә генә яткандыр дип уйларга мөмкин. Фәнияр, үзе янына Казан тикле җирдән шагыйрь килүенә ышанып җитмәгәндәй, күзләрен Илдус Гаделшиннан алмады. Илдус Гаделшин бик гади. Сөйләшүе дә мәзәгрәк: «р» авазын әйтеп бетерә алмый. Яшькә Фәниярдан биш яшькә генә зур икән. Шулай булса да чәчләре шактый сирәкләнгән, чалара башлаган урыннары да күренгәли. Күрәсең, шигырь язу бик җиңел түгелдер. Чәчләренә чал керсә дә, ачык чырайлы булгангамы — йөзгә яшь.

Алар, бер-берләрен күптән белгән кешеләр кебек, «син» дип сөйләштеләр. Илдусның кулында шома папка. Сөйләшеп, хәл-әхвәл сорашулар беткәч, шул папкасындагы кәгазьләр арасыннан «Яшь ленинчы» газетасын табып алды.

— Көткән кешегә озак тоелгандыр, бер-ике атнадан шигырьләреңне басарбыз дигән идек. Менә ташка басылгач ничегрәк булган, укып кара,— дип, газетаны Фәниярга бирде.— Мин элегрәк тә килергә уйлаган идем, шигырьләрең басылсын инде дидем. Коры кул белән киләсе килмәде.

— Ә мин, Илдус абый, син безгә килерсең дип башыма да кертеп карамадым. Язучы кешеләрне бөтенләй башка төслеләрдер дип уйлый идем.

Илдус аның сүзләренә каршы:

— Язучылар да безнең кебек кешеләр, ләкин мин үземне хәзергә язучы дип саный алмыйм әле. Бик зур исем ул, туганкай...

Илдусның Казан каласыннан үзенең улы янына килгән олы кунак икәнен белгәч, Гөлсәйдә түти дә бик куанды. Кабаланып өстәл әзерләргә керește. Ул арада Фәниярның абыйсы Заһид кибеткә барып кайткан икән: күкәйләп кыздырылган балык янына ак түбәтәйле, нәзкәй билле шешә килеп кунаклады. Илдус чишенеп өстәл янына килеп утыргач:

— Сез, агай-энеләр, минем өчен генә булса моны ачып маташмагыз, андый нәрсәләр белән дуслыгым юк,— дип, шешәне ачтырмады.

— Син юлдан килгән кеше бит, жылынырсың, әз-мәз генә мишәйт итмәс,— дип кыстасалар да, Гаделшин нык торды. Кыстаулар күпкә китә башлагач, ул тамак астындагы бизләрен тотып:

— Минем ангина бизләре бар, әчкелтем нәрсәләрне бер дә яратмыйлар,— диде.— Ә жылыну ягына килгәндә, ачык йөзегезне күргәч үк өшүләрем онытылды.

Шуннан соң аны кыстаучы булмады.

Чәй янынннан кузгалгач, Илдус Гаделшин Фәниярның шигырь дәфтәрләрен сорап алды. Ул бик туры сүзле кеше икән, начар язылган шигырьләрне күрсә, синең дәфтәреңдә ята бирсеннәр, аларны кешеләр укымаганнан һични югалтмаслар дип, ул битләрне тизрәк актарып үтәргә тырышты. Ә инде матур әйтелгән ике генә юл очратса да, түш кесәсендәге бармак буе карандашын чыгарып, шул юлларның астына калын итеп сызды. «Менә монысы шәп, ичмасам, Фәниярча әйтелгән», дип, ул сүзләрне үзе уйлап тапканнан ким куанмады.

Күңеленә ошаган шигырьләрне Илдус Гаделшин күчереп ала барды. «Кайткач өлкәнрәк агайларга күрсәтеп карармын, әлегә вәгъдә бирә алмыйм,— диде ул.— Син бик өметләнеп ятма. Казаннан корреспондент килде дә, хәзер ни язсам, шул басылыр дип. Зур эшкә тотынгансың икән, барысына да түзәргә кирәк. Мин сиңа турысын әйтәм: яза аласың, сәләтең бары күренеп тора. Әмма шигырь язар өчен ул гына житми: тырышлык, белем, үз өстеңдә туктаусыз эшләү, кимчелекләрне күрә белү һәм тагын әллә нәрсәләр. Яза-яза үзең дә төшенерсең әле. Ә хәзергә сиңа иң кирәге — системалы белем. Шунысыз син ерак китә алмассың. Яшьлегең турында, сөйгән ярларың турында берничә дистә бер-беренә охшаган әйберләр язарсың да туктарсың. Аннары учагыңда күмер сүнәр».

Илдус Гаделшин шагыйрь булуның бик жаваплы эш икәнлеге турында сөйләде. Ул Фәниярга үгет-нәсихәт тә укымады, менә болайрак яз, тегеләйрәк эшлә дип күрсәтмәләр дә бирмәде. Язарына темалар да сайлашмады. Аның сөйләгән сүзләре бер Фәнияр өчен генә түгел, ә үзе өчен дә иде. «Без хәзер бер тәртәгә жигелгән атлар» дип, Фәниярны үзе белән тиңләштерде. Антын яңартучы солдат кебек тойды ул үзен яшь шагыйрь янында.

## XI

Илдус Гаделшин, килдем-киттем, эшем бетте, дия торган кеше булып чыкмады. «Мәктәптә минем бераз йомышым бар иде»,— дип чыгып китте. Мәктәптә дирекция һәм укытучылар белән егетне шефка алу хакында сөйләште. Фәниярны укыту турында сүз кузгаткан иде, әмма Кызыл Кыя авылында урта мәктәп киләсе елларда гына ачылырга тиешлеген әйттеләр. Илдус укытучылар белән сөйләшкәннән соң:

— Әгәр мөмкин булса, мин укучыларга берничә сүз әйтер идем,— диде.

— Бик әйбәт,— диде директор.— Озын тәнәфес вакытында жыярбыз үзләрен.

Тәнәфестә укучыларны коридорга жыйдылар. Директор сүз алып:

— Менә Казаннан килгән корреспондент иптәш сезгә сүзем бар, ди. Шауламыйча гына тыңлагыз,— дип, балаларны кисәтеп куйды. Илдус тегe папкасыннан пионерлар газетасы чыгарып:

— Бу газетаны беләсездер инде, кайсыларыгыз ала? — диде.

Берничә тавышның: мин алам, мин язылдым, дигәне ишетелде.

— Бүгенге санда сезнең авыл шагыйре Фәнияр Гатауллинның шигырьләре басылган. Бу газета сезгә килеп житмәгәндер әле. Мин ул шигырьләрне сезгә укып күрсәтәм.

Балалар шым булдылар. Илдус ашыкмыйча гына укыды. Шигырьләр кызыклы иде, көлешкән тавышлар ишетелә башлады. Укып туктагач, Илдус, балаларга карап:

— Авылыгызда шагыйрь барын беләидегезме? — дип сорады.

Беркем дә җавап бирмәде. Кайберәүләр аның шигырьләрен район газетасыннан укыган булсалар да, газетадан килгән кеше алдында батырланасылары килмәде. Әллә нинди сорау биреп, төп башына утыртып куяр я. Дәшмәүдән шәбе юк. Илдус иелгән башларга карап:

— Ә бит аның турында район газетасында «Районыбызның Островские» дип язып чыкканнар. Берничә тапкыр шигырьләре басылган. Ә сез авылыгызда шундый кеше яшәвен дә белмисез. Әйбәт түгел, дуслар.

Укучыларның башлары тагын да түбәнрәк иелде. Гаделшин Фәнияр турында озак сөйләде. Каләмне бик авырлык белән тотуы, уйлаган әсәрләрен кәгазьгә күчерү өчен әллә ни чаклы көч түгүен әйтте.

— Без аның янына барып йөрербез, абый,— диештеләр балалар чын күңелдән.— Шигырьләрен дә күчереп язарбыз.

Газетадан килгән кеше алдында укытучыларга да шактый кызарырга туры килде. Бигрәк тә түгәрәк йөзле, тәбәнәк буйлы яшь пионервожатый кыз үзе таккан галстугы шикелле булды.

— И, Илдус абый,— диде ул, балаларча галстук очын кабып,— моннан болай барырбыз, моңынчы кайда идегез дип куып чыгармаса.

— Кумас. Фәнияр — кешеләрне бик ярата торган егет.— Илдус: — Минә синең кебекләр аңа бигрәк тә ошар,— димәкче булган иде, болай да кабынып китәргә торган кызны оялтасы килмәде.

Мәктәптә эшне бетергәч, Гаделшин комсомол райкомына китте. Фәнияр Гатауллинның өч ел инде бернинди оешмага теркәлмәвен, хәтта взнос алырга да янына кешеләр килмәвен сөйләп бирде. Секретарь хатаны төзәтергә, иртәгәдән үк егетнең янына үзе барырга сүз биреп калды.

Комсомол оешмалары һәм мәктәпләр белән сөйләшеп, кайбер кузгалырга исәбе юкларны үзенең «каләм очына» алып, кабат Фәнияр янына кайтты Илдус. Ә Казанга киткәндә янә бер кат:

— Син, Фәнияр туган, бу кеше газетада эшләгәч, бөтенесен булдырыр дип уйлама,— диде.— Бернигә карамыйча яз, каләмеңне шомарта тор. Кыенлыклар очраган саен йокы дарулары җыя башлама. Безнең эштә зур түземлелек кирәк. Ә синең өчен бу икеләтә шулай.

Зур вәгъдәләр биреп китмәгәч, Фәнияр бу абый китәр дә онытыр дип уйлаган иде. Әмма атна-ун көн уздымы икән,— яшьләр газетасында да, балалар газетасында да Гаделшинның мәкаләләре басылып чыкты. Ул мәкаләләр Фәниярның язмышы, киләчәге өчен чын-чынлап борчылып һәм кешеләрне үз тирәсендәге ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә карата игътибарлырак булырга чакырып язылган. Шунда ук Фәниярның фотосын һәм шигырьләрен биргәннәр иде.

Фәнияр өчен бөтенләй яңа, шау-шулы тормыш башланды.

Моңарчы Фәниярга бары авыру дип кенә карauчылар, Казаннан килгән корреспондентның сүзләреннән соң, Фәнияр янына агыла башладылар. Ялгызлыктан иза чигеп, иркенләп сөйләшергә сусаган, язган шигырьләрен кемгә укып күрсәтергә белмичә йөдәгән егет бер генә сәгатькә дә кешесез калмады. Я балалайкаларын күтәреп пионерлар килә, я стена газетасына бирәр шигырь эмәллэп бирмәссеңме дип, авыл яшьләре кереп тула иде. Фәнияр озак вакытлар караңгыда торып, кинәт яктыга чыккан кешедәй хис итте үзен. Карады — тирәюнендәге кешеләрне аермады, тыңлады — сүзләрен аңламады. Язган бер шигырен иң элек өйләрендәге ала мәчегә укып күрсәтә торган иде, Фәнияр тирәсендә ят кешеләр кайнаша башлагач, ала мәче мич башы-

нарак күчендә һәм: «Ярар, мин дә кирәк булырмын әле», дигәндәй, еракта гына күзләрен елтыратып ята башлады.

Егетнең бу уңышлардан башы да әйләнеп алды. Ул язган әйберләренә карата таләпчәнлеген югалтты. Төрле редакцияләргә чиле-пешле шигырьләр җибәреп, басылып чыгуларын көтте. Редакциядән әсәрләренең кимчелеген күрсәткән хатлар килсә — турсайды. Ачуы килде. Газета-журналларда йомшаграк шигырьләр укыса, болар да минекеннән артык түгел, аларныкын басканнар, дип үпкәләп ятты. Үзе йөри алып, әсәрләрен үз кулллары белән илтеп бирсә, һичшиксез, басарлар шикелле тоелды. Кайчак кешегә бераз ташламалар да ясап була бит инде, дип уйлады.

Бу чир, бәлки, озаккарак та сузылган булыр иде. Илдус Гаделшин каты гына итеп Фәниярга хат язып җибәрде. Ул әдәбиятта беркемгә дә ташлама ясалмагын, яшьме яки картмы, тазамы яки чирлеме — аны-сы укучы өчен әһәмиятле түгеллеген әйткән һәм укучыларның язган әсәрләргә карап фикер йөртүен, үзең авыру булсаң да, «сәламәт» әсәрләр язарга кирәклеген төшендергән иде. Башкаларга бик тиз хәтерә калса да, Илдуска үпкәләмәде Фәнияр. Фәниярның һәр уңышлы сүзе өчен чын-чынлап шатланучы бу әчкерсез абыйга ничек ышанмаска кирәк? Әле бит һаман да Фәнияр турында кайгыртудан туктамый. Синс Казан больницаларының берсенә алдыру турында да Язучылар союзындагы өлкән агайлар белән сөйләшеп, исләренә тагын бер кат төшердем, дигән. Бәлки, шушы көннәрдә синең белән Казанда очрашырбыз, дигән.

Казан больницаларының берсендә дәвалану, зуррак профессорларга күренеп карау Фәниярның күптәнге хыялы иде. Районда ятканда әллә ничә мәртәбә әйтеп карады Фәнияр Талип Таһировичка. Тыңларга да теләмәде тегесе. Бездә бөтен больницаларда да бер үк метод белән дәвалыйлар, диде. Ә инде үзе турындагы шигырьләрне укыгач, бу турыда авыз ачып карарга да мөмкин булмады. Ләкин Фәниярның өмете киселеп бетмәгән иде әле. Өмет дигәнең җиргә күмелгән орлык шикелле бит ул: уңайлы вакытны көтеп кенә ята.

Фәнияр да өч ел ятуга карамастан, терелүдән өметен өзгәне юк. Аңа калса бик белдекле, бик оста врач кулына гына эләгергә кирәк. Кабат операциясен дә ясар, тиешле даруларын да табар. Нәп-нәзек нервларны ялгау нәрсә ул! Заманасы нинди бит, заманасы! Өметләнмәслекмени? Космоска очалар, тавыш тизлегеннән дә җитезрәк оча торган самолетлар уйлап табалар, элек еллар буе бораулап та төшеп җитә алмаган девон катламнарына ун көндә торба сузалар. Шундый заманда ничек инде өметенне өзәсең!

Ә көннәрдән бер көнне Фәниярга телеграмма китереп тоттырдылар. Анда, шушы араларда Фәниярны Казан больницасына алып китәр өчен самолет җибәрәчәкләрен әйтеп, хәзер булып торырга кушылган иде. Фәнияр бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ничек инде бер кеше өчен самолет тикле самолет җибәрсеннәр?!

Әзерләнергә кушылгач, берни эшләр хәлең юк, ышанмасаң да юл капчыгыңны төйнәп куярга туры килә. Гөлсәйдә түти аналарга гына хас өлгерлек белән юлга җыена башлады. Чемоданга әллә никадәр әйбер тутырганын күргәч, Фәнияр аңа:

— Мин бит, әнкәй, кунакка җыенмыйм, больницага барам, нигә шул хәтле тутырасың? — диде.— Күчтәнәчләп бармасам да, кире бормаслар.

— Син генә түгел, мин дә барам,— диде әнисе.

— Син анда кайда тормакчы буласың? Әллә үзеңне бик көтеп торалардыр дип беләсеңме?

— Көткән җиргә кем дә бара,— диде Гөлсәйдә түти.— Бер башы-

ма кайда да урын табармын. Синең караватың янына урындыклар куеп булса да йокlармын. Җан биргәнгә — җүн бирер, дигәннәр бит.

Фәнияр берничек тә әнисен калырга күндерә алмады.

Ике көннән авыл башына самолет килеп төште. Анда очучыдан башка бер сестра да бар иде. Элек председательне йөрткән, идарәгә җиңел машина бирелгәч эшсез калган кара айгырны җигеп, Фәниярны алырга килделәр. Арбага салам түшәп, өстенә матрац салдылар.

Каян күреп, каян ишетеп өлгергәннәрдер, самолет тирәсен олысы-кечесе сарып алган. Барабаннар, быргылар күтәреп пионерлар да килеп җиткәннәр. Алар бөтенесе бертавыштан:

— Фәнияр абый, терелеп кайт,— дип кычкырдылар. Быргычы быргысын уйнатып салют бирде. Барабанчы барабанын какты. Карт-корылар да, бала-чагалар да, этә-төртә, Фәнияр янынарак үтәргә тырыштылар. Һәркем шул бер үк сүзне кабатлады: терелеп, үз аякларың белән кайт! Фәниярның мондый хөрмәткә күңеле нечкәреп китте. Кешеләргә сиздермәскә тырышып, күзләрен кул аркасы белән сыпырып алды. Ләкин шатлык яшьләрен сөртеп кенә бетерерлек түгел иде. Сестра һәм очучы, җыелган халыкны читкәрәк куалап, самолеттан носилка алып төштеләр. Нәкъ шул вакыт, озак йөгерүдән сулуы кабып, Нәсимә килеп житте. Әллә аның артык кабалануын, әллә ак халатын күреп, халык юл бирде. Нәсимә саубуллашып Фәниярның кулын кысты. Гөлсәйдә түтинең дә улы белән китүен белгәч:

— Гөлсәйдә апа, алайса, мин сиңа бер адрес язып бирим әле, Казанда безнең җизниләр бар,— дип, кесәләрен кармаштыра башлады. Ләкин кесәсендә кәгазь-каләм табылмады. Шул вакыт кешеләр төркеме арасыннан берәү каләм, икенчесе кәгазь сузды. Кыз ашыга-ашыга адрес язып Гөлсәйдә түтинең кесәсенә салды.

— Алар Савинка поселогында, үз йортларында торалар. Нәсимә җибәрде дисәң, кертерләр,— диде.

Озак сөйләшеп торырга вакыт булмады. Самолетка Фәнияр белән Гөлсәйдә түтине утырттылар да очып та киттеләр.

## XII

Казан гомер-гомергә шагыйрьләрне үзенә тарткан. Ул яшьләрне вузлары, нәшриятлары, редакцияләре белән кызыктырып китерә. Дөнья матурлыгына сокланып беренче шигырен язган яшь шагыйрь, курка-курка, редакция ишекләрен ача. Фән биеклекләренә үрмәләргә теләүче хыялый егет-кызлар иң беренче вуз баскычларын атлап менәләр. Авыл сәхнәләрендә уйнап, үзләрен чын актерга санаучылар Казанга килеп өч-дүрт ел буе студент шулпасы чөмерәләр. Казан беркемне дә кире какмый. Кайчандыр вуз баскычларын биек тау дип исәпләүче ябык студентлар, үзләре галим булып, вузларда укыта башлыйлар. Казан берәүләрне сәхнә йолдызы итеп күккә чөя, икенчеләрне яктылык өләшүче итеп авылларына кайтара.

Казанга Фәниярның үз гомерендә икенче килүе. Беренче тапкыр моннан дүрт ел элек, армиягә киткәндә булды. Татвоенкоматта биш көн буе яткан иде ул. Шул вакыт аның хәтереннән бер күңелле вакыйга калкып чыкты. Таныш җирләргә килгәч, таныш хатирәләр искә төшүчән була. Ә бу хатирәне Фәниярның бөтенләй онытып бетергәне дә юк.

...Татвоенкомат ишегалды. Үзе шикелле йөзләгән такырбашлар арасында Фәнияр да бар. Һәрвакыт кая булса да чабарга, йөгерергә күнеккән аяклар тик кенә торырга теләмиләр. Капканың теге ягына чыгып китәсе, арып егылганчы шәһәр урамнарында йөрисе килә. Ләкин капкада сакчы тора: кертми дә, чыгармый да. Их, кайчан соң инде Фәниярлар шул солдат шикелле кулларына карабин алырлар. Күңелләре сабан туйларында чабышырга әзерләнгән ат сыман ярсына, билге-

сезлек интектерә. Яшь каннары кайный. Ә кайчан китәселәрен һичкем белми.

Военкоматның коймасы артында бер кран, озын муенын әле бер якка, әле икенче якка борып, тәпиләренә чебеш элэктергән тилгәндәй, югарыга кирпеч күтәрә. Кран кабинасындагы кызның яшел яулыгы гына күренә. Бер төркем такырбашлар койманың бу ягыннан кранның эшләвен күзәтәләр. Фәнияр кранчы кызга кул изи, төрле ишарәләр ясый. Бүреген салып түбәсенә бәргәләп күрсәтә: янәсе, монда төш, монда төш. Кыз әллә аңламый, әллә аңламаганга салыша. Шулай да уңайлы вакыт туры китереп, тәрәзәсендәге тузаннарын бияләе белән ышкып ала. Эшчеләрнең төшке ял вакытлары җитә. Кайсы кая таралыша. Тик кранчы кыз гына урынында кала. Ул, тәхеткә менеп утырган королева шикелле, түбәндәгеләргә горур караш ташлый. Шул чак егетләр кычкыра башлыйлар:

— Давай, чибәркәй, краның белән безне теге якка күтәреп ташла әле.

— Армиядән кайткач, бушлай киногa йөртербез.

Бәләкәй буйлы, чәрелдек тавышлы берсе:

— Үзеңне кәләшлеккә алырмын,— дип кычкыргач, төркемдәгеләр шаулашып көлешеп алдылар.

— Кеше көлдермә әле, кырмыска. Шәһәр кызлары синең кебек авыл кырмыскасына тормышка чыгарга торалар, ди. Тот капчыгыңны! — диләр аңа.

Кранчы кыз якын-тирәдә прораб, бригадир ише кешеләрнең юклыгын күргәч, кранның сиртмәсен военкомат ишегалдына борды да кирпечләр төйи торган кечкенә мәйданчыкка төшерде. Бер көтү такырбаш төялеп өскә менеп китте. Койманың теге ягына килеп төшү белән һәммәсе, суга җибәрелгән балыклар кебек, таралышып та беттеләр. Бары Фәнияр гына кая барырга белмичә басып калды. Үзенә каты кисәтү эләгәчәген белгәне хәлдә, шушындый шуклык эшләргә батырчылыгы җиткән кызны якыннанрак күрәсе килә аның.

Кранчы кызның үзенең дә түбәндә эше булган икән, озакламый, җиргә төште. Аның буе үсмер балаларныкы хәтле генә. Чырае яшь. Үз күзең белән күрмәсәң, эшләп йөрүче дип тә уйламассың. Фәниярга кызның песинеке төсле яшькелт күзләре ошады. Хәер, ул аның башка җирен күрмәде дә. Чөнки кыз яулыгын шундый итеп бәйләгән: бер кечкенә генә яулык чәчен дә, ияген дә, битен дә капларга җиткән.

— Бу эшеңне белсәләр, ну эләгер инде сиңа, кызый,— диде Фәнияр, кыз белән ничек сүз башларга белмичә.

— Өстән караганда бигрәк читлеккә тутырылган чебешләр кебек күренәдегез, кызгандым инде үзегезне,— диде кыз һәм көлеп җибәрде. Ана кушылып Фәнияр да көлә башлады. Ике тиле һичнинди сәбәпсез бөтен төзелеш мәйданын яңгыратып шаркылдаштылар. Шундый кызык!

Кызның исемен дә белмәде Фәнияр. Исемен сорагач:

— Минем исем сиңа нәрсәгә кирәк? — диде кыз.— Я хат яза башларсың. Ә мин хат язарга бер дә яратмыйм. Солдатның аның хат язудан бүтән эше бармыни?

— Нигә алай дисең? — диде Фәнияр.— Солдатта булып караганың юктыр бит?

— Солдатта булмасам да, өч ел хезмәт итеп кайтканнардан күбрәк беләм,— диде кыз.

— Кайдан?

— Анысы секрет.

Шулай дисә дә, кыз үзенең «секрет»ын саклап торырга теләмәде, сөйләп китте. Ул гаҗәеп кызу сөйли. Һәр сүзе артыннан кычкырып көлә. Гомерендә бары бер мәртәбә күреп, яңадан мәңге очратмаячак

кешегә һәммәсен сөйләргә мөмкин. Ул сине, син аны белмисең. Ә күңелдәген түгү ярый.

— Минә безнең төзелештә,— дип башлады кыз,— бер юаш малай эшли иде. Сигез сәгатькә сигез сүз дә әйтмәс. Кызлар янына килсә, учак каршысында утыргандай, кызарыр иде. Шул армиягә китте дә бишәр километрлы хатлар язып җибәрергә тотынды бит. Укып та өлгерә алмассың, какой җавап язу. Кай көнне яргышар потлы икешәр хат килеп төшә. Иртән ничек күзен ачкан, кайчан торган, кайчан ашаган — берсен дә калдырмый. Тәмам туйдырды үзенең казарма тормышы белән. Телеграммаларын, открыткаларын чутламыйча да бер вагон кәгазь җыелды инде.

— Алайса, сине яраткан инде ул,— диде Фәнияр.

— Фи, подумаешь,— диде кыз,— яраткан кешене шулай чүп-чар язып интектермиләр. Аның ничә секундта киенүе миңа нигә кирәк?!

Фәнияр һәм кранчы кыз яраткан кешең белән нәрсә сөйләшергә яраганлыгы, нәрсә ярамаганлыгы хакында бәхәсләшеп киттеләр. Ни егет, ни кыз бу турыда ачык белмәгәнлектән, аларның бәхәсләре берберсенең сүзен кире кагудан гыйбарәт булды. Төшкелекне ашап килүче төзүчеләр эш урынына җыела башлагач кына, Фәнияр шәһәр карарга чыгуын исенә төшерде.

— Һи, яшел күз,— диде ул,— мин бит Казан урамнарында йөрергә дип чыккан идем. Кызлар күрсәм, онытылам да китәм. Башым әйләнә башлый. Юл күрсәтмәссең микән миңа, ә? Бер әби әйткән, имеш, минем кызым кияү күргән кешемени, дип. Шуның кызы сыман, мин шәһәр күргән кешемени?

— Казан урман түгел, адашмассың,— диде кыз.— Адашсаң — сорарсың, телең бик шома күренә.

— Үзең Казан кызыдырсың әле, шәһәрегез белән мактанырга теләмисең.

— Авылдан бер такырбаш килгән дип, бөтен эшемне ташлап йөгерергә торам бик! — диде кыз, мыскыллап елмайды да кранына менеп китте...

## XIII

Казанда Фәниярләр палатасының врачы яшь кенә бер кыз иде. Үзе бик яшь булуга карамастан, өлкәннәрнең ихтирамын казанып өлгергән: һәркем аны, олылап, Галина Измайловна дип кенә дәшә. Авыруларның караңгы чырайлары, Галина Измайловна килеп керсә, яктырып китә. Ләкин нәкъ менә шушы яшьлеге өчен Фәниярга ошамады ул. «Яңа гына институт бетереп килгән кыз нәрсә белә инде»,— дип уйлады Фәнияр. Өлкәнрәк яшьтәге, тәҗрибә туплаганрак кешегә эләкмәвенә ачырганды. Шактый вакыт врач белән Фәнияр арасында салкын мөнәсәбәт сакланды.

Галина Измайловна төскә-биткә татар кешесенә бик охшаган. Чемкара күзләр, түгәрәгрәк йөз һәм түбәгә өелгән кара толымнар барысы да татарныкы. Фәнияр аны: институт бетергәч, исемен алыштырган, мөгаен, Галина да, Измайловна да түгел, берәр Галия Исмәгыйловнадыр дип уйлап ятты. Ә беркөнне ул Галина Измайловнаның сорауларына татарча җавап биреп, врачны аптыратып бетерде. Галина Измайловна чыгып киткәч, палатадагы авырулар Фәниярны моның өчен бик шәпләп кыздырып алдылар. Биш-алты шигырь язып бастырдым дигәч тә, үзеңне генийга саныйсың, кеше белән сөйләшергә иренәсең, диделәр. Шуннан соң гына Фәниярның кикриге шиңде. Ул үзенең кыланышлары өчен Галина Измайловнадан гафу үтенде. Гафу үтенмәскә дә тарткалашкан иде, авырулар: гафу үтенмәсәң, синең белән беребез дә сөйләшмәячәкбез, диделәр. Фәнияр мәҗбүр булды.

Галина Измайловна Фәниярдан бөтенесен төпченде. Ул үз авыруы турында кешеләргә сөйләп туеп беткән иде инде. Чөнки яңа больницага күчсәң дә, палатага башка бер авыру кертсәләр дә, һәммәсенә бер үк әйберләрне кабатларга кирәк. Ләкин Галина Измайловна белән сөйләшү ничектер җинел булып чыкты. Ул Фәниярга тиешсез сораулар биреп алҗытып бетермәде: әкренләп-әкренләп, җайлап сөйләште. Фәниярның шигырьләре белән кызыксынды.

— Татарча белсәм, шигырьләрегезне укыр идем,— диде.— Ә шулай да укып карагыз әле, татарча шигырь ничегрәк яңгырый икән.

— Сезгә мине тыңлау бик күңелсез булыр,— диде Фәнияр.— Мин матур итеп укый да белмим.

Фәнияр үзенең берничә шигырен укып күрсәтте. Бу шигырьләр яз һәм мәхәббәт турында иде. Шигырьләрне, сүзен-сүзгә тәрҗемә итеп, соңыннан Галина Измайловнага төшендерделәр. Фәнияр үзе генә сүз таба алмый торса, палатадагы башка авырулар ярдәмгә килде. Галина Измайловнага бу шигырьләр бик ошады.

— Боларны русчага тәрҗемә иттерергә иде,— диде ул.— Сәләтем булса, үзем үк тотыныр идем. Ә беләсезме, минем бер танышым бар, филология факультетында укый, кача-поса үзе дә язгалый бугай. Берничә шигырецне аңа бирсәк, тәрҗемә итмәсме икән? Ул татарча да ярыйсы гына сукалый.

— И, Галина Измайловна,— диде Фәнияр оялып,— кая әле миңа тәрҗемә турында уйлау. Татарчасын язып бастыра алсам, бик шөкер инде.

Шулай дигәч, врач аны кабат кыстамады.

Менә шушы сөйләшүдән соң Галина Измайловна Фәниярга якынайды да китте. Ул аңа үзенең бөтен тормышын, кичерешләрен, борчыуларын сөйләде. Ә беркөнне Фәнияр:

— Галина Измайловна, сез ничек уйлыйсыз: минем хәлдәге кешегә нинди дә булса алга китеш турында уйларга өмет бармы? — дип сорады.

— Сез үзегезнең авыру тарихыгызны беләсездер дип уйлыйм,— диде врач.

— Укырга туры килде. Ул нәрсә безнең кулга бирелмәсә дә, җаен табасың инде,— диде Фәнияр.

— Әйе,— диде Галина Измайловна, үз-үзенә әйткәндәй,— сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшсәк, икебез өчен дә файдалы булыр. Госпитальдән җибәрелгән авыру тарихында дүртенче-бишенче муен умырткаларының кушылган урынында арка мие өзелгән, диелә. Хәзер мин сезгә карыйм да бу диагнозның дөреслегенә шикләнеп куям. Ул турыдан арка мие өзелгән булса, кулларда хәрәкәт башланмас иде.

— Димәк, өмет бетмәгән әле? — диде Фәнияр кабаланып.

— Ашыкмагыз,— диде врач,— мин сезне юк-бар нәрсәләр белән юатырга теләмим. Бу әле минем уем гына. Ә мин, күреп торасыз, яңа эшли башлаган тәҗрибәсез врач. Зуррак, тәҗрибәлерәк белгечләр белән киңәшеп карау кирәк булыр. Безнең үзебезнең больницаның профессоры Рәшит Шамилович — мондый авыруларны бик нечкәләп тикшергән кеше. Ләкин әле ул үзе авырып ята. Аның өенә барып булса да консилиум җыйганда, ачык фикергә килеп булыр иде. Мин бу мәсьәләне үзем генә хәл итә алмыйм, баш врач һәм башкалар белән киңәшербез. Ә хәзергә мин сезгә менә нәрсә әйтергә телим: мөмкин кадәр физик күнегүләр эшләргә, хәрәкәтләнергә кирәк.

— Өзелгән нервларга хәрәкәтләнү генә нәрсә бирер соң? — диде Фәнияр төшенкеләнеп.

— Хәрәкәттән туктау мондый авыруларга иң куркынычы,— диде врач.— Күңеленнән бертуктаусыз йөрергә омтылырга, безнеңчә әйтсәк, баш миеннән импульслар җибәреп торырга кирәк. Менә шул вакытта

исән калган бер нерв күзәнәге ике күзәнәк башкарган кадәр эш эшли ала. Кулга гер күтәреп, маңгайдан тир тамызуны гына физик эшкә санамагыз, менә шушы импульсларның сезгә ныграк ярдәме тиюе мөмкин.

Врач чыгып киткәч, Фәнияр чынлап та шулай эшләп карады: бармакларын хәрәкәтләндерергә тырышып, тирләп чыкты. Әмма өзелгән чыбык аша электр тогы үтмәгән кебек, өзелгән нервлар аркылы да баш җибәргән сигналлар аякларга барып җитмәде. Шулай да Фәнияр мондый күнегүләрне үзенең көндәлек режимына кертте.

Галина Измайловна Фәниярның язмышы өчен нык борчылды. Шәһәрдәге танылган белгечләр һәм нейрохирурглар белән киңәште. Башка больницада эшли торган Шубин фамилияле бер нейрохирургны Фәнияр кызыксындырды, һәм ул егетне килеп карарга булды. Озак та үтмәде, ул Галина Измайловна белән Фәнияр янына килеп тә житте.

Бик ныклап, җентекләп тикшерде Шубин. Ниһаять, ул да, арка мие бөтенләй өзелеп чыкмаган булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килде.

Ә берничә көннән врачлар профессор Рәшит Шамиловичның өенә җыелдылар. Аларның кулында Фәниярның авыру тарихы да, госпитальдә һәм монда төшерелгән снимоклар да бар иде. Профессор аларны күңелсез каршылады. Дөрес, ул инде Фәнияр турында ишеткән иде, врачларны бергәләшеп өенә килергә дә үзе чакырды. Ләкин соңгы вакытларда үзенең гел яклап килгән дәвалау методына шикләнеп карый башлаган иде ул.

— Сез, коллегалар, миннән нинди дә булса яңа сүз көтәсездер инде,— диде ул, авыру тарихы белән танышканнан соң.— Күрәсез, күпме хезмәтләр язылган.— Ул китап киштәләренә күрсәтте,— диссертацияләр якланган. Мондый авыруларны дәвалауга аерым метод тудырдык: аларны клиникага китерү белән бөтен төрле хәрәкәтләрдән тыябыз. Янәсе, сынган умырткалар урыныннан кузгалмасын. Сөяк ялганганчы авыру кеше битараф хәлдә ята, ул арада исән калган нерв күзәнәкләре дә үзләренең функцияләрен оныта башлыйлар. Пассивлашалар яки бөтенләй үләләр. Минемчә, мондый авыруларга беренче көннән үк тынгылык бирергә ярамый. Актив хәрәкәт ясый алмый икән, пассивларын ясатырга кирәк. Исән калган бер генә күзәнәк тә эшсез ятмасын.

Профессор кемгәдер ачулангандай кызып-кызып сөйләде. Аның сүзе беткәннән соң, Галина Измайловна:

— Гатауллин белән хәзер нишләргә киңәш итәсез соң? — дип сорады.

Рәшит Шамилович озак кына уйланып торды. Сорауны ишетмәде, ахры, дип, Галина Измайловна кабатлап сорады. Шул вакыт нейрохирург Шубин түземсезләнеп сикереп торды:

— Мин аңа кабат операция ясау ягында. Арка миен басып торган кимерчәкләрне кырып ташларга һәм исән калган җепселләрне кысанлыктан коткарырга кирәк.

— Операция дисезме? — диде Рәшит Шамилович.— Миңа күптән түгел Мәскәүдә профессор Вишневский янында булырга туры килде. Беләсезме, коллегалар, ул яңа нәрсә уйлап тапкан. Арка мие зарарланган урынга биш тиен акча зурлыгындагы пластинка куела. Батареялардан килгән ток пластинкага җибәрелә һәм шуның нәтиҗәсендә ясалма импульслар барлыкка килә...

— Искиткеч шәп бит бу! — диде Шубин.

— Ләкин,— дип дәвам итте профессор,— шуны онытмаска кирәк. Операция тылсым ярдәмендә түгел, пычак белән ясала. Пычакның нервларны кисү ихтималы бар. Сез Гатауллинның куллары эшли башлаган дисез. Безгә аның кулларын сакларга кирәк. Вишневскийның тәҗрибәләре шактый уңышлы чыга, ләкин операцияне имгәнгәннең

икенче көнендә үк ясаган очракта гына. Вакыт күбрәк үткән саен, үзәк нерв системасы үз эшчәнлеген оныта бара. Ясалма импульсларның да файдасы тими башлый. Ә Гатауллин күпме ята инде?

— Дүрт ел,— диде Галина Измайловна төшенке тавыш белән.

— Күп шул,— диде профессор,— операция көткән нәтиҗәне бирмәс дип куркам. Аннары бик ябык дисез. Гадәттә, мондый авырулар симезлектән җәфаланалар. Аның эчке әгъзаларында үзгәреш юкмы икән? Ничек кеше шул кадәр ябыгырга мөмкин?!

— Имгәнгәннән соң аның бөтен тәне шешенгән һәм тишелеп ага башлаган,— диде Галина Измайловна.— Эчке органнарының паралич-лануы нәтиҗәсендә, бүленеп чыгарга тиешле сыекчалар тире аркылы чыгып, тукымаларны таркатканнар. Аннары госпитальдә ятканда үпкәләре шешкән...

— Мөмкин хәл түгел,— диде Рәшит Шамилович.— Ничек инде больницада моңа юл куйсыннар.

— Булган инде,— диде Галина Измайловна,— мунчага ике санитарка алып төшкән, ә анда су юк икән. Егетне душ астындагы эскәмиягә салганнар да үзләре котельныйга су белешергә киткәннәр. Алар чыгып китүгә үк, душтан салкын су Гатауллинның күкрәгенә коя башлаган. Санитаркалар килеп җиткәнче салкын тидереп өлгергән.

Моңа профессорның исе китте. Чөнки үзәк нервлары зарарланган кешеләрнең тәннәре салкынга да, җылыга да тиз бирешүчән була. Ул арлы-бирле йөренгәләде. Ләкин хәзер Гатауллинга нинди дәва кулланып карарга белмәде.

— Санаторийга, курортка җибәрергә кирәк, күкертле сулар, ләмнәр, бәлки, файда бирер,— диде ул соңыннан.— Ә хәзергә менә бу күнегүләрне эшләргә тырышсын.

Ул үзе төзегән күнегүләр комплексын бирде.

Икенче көнне Галина Измайловна Фәниярга профессор белән булган әңгәмәне сөйләде.

— Арка мие өзелеп чыкмаган, ниндидер җепселләр калган,— диде ул.— Моны снимоклар да раслый һәм профессор да шундый фикердә. Ләкин имгәнгәннән соң озак вакыт үткән, шунлыктан исән калган нерв күзәнәкләрен кабат эшләтә башлау өчен күп тырышлык куярга кирәк булачак.

— Әгәр дә тырышлык һәм сез биргән күнегүләр белән генә аякка басып булса, мин төн йокламаска әзер,— диде Фәнияр.

— Аякка басар дәрәҗәгә килеп җитәрсез дип гарантия биреп булмый, әлбәттә. Шулай да хәлегез бераз яхшырыр. Әкренләп утырып тора башларсыз,— диде врач.— Шушы кулларыгыз белән язарга, үз эшләрегезне эшләргә өйрәнгәнсез бит. Утырып тору өчен дә шундый ук тырышлык куярга кирәк. Көненә бер-ике генә сәгать утыра алсагыз да сезгә файда булыр. Коляска белән урамга, бакчага чыгарсыз. Шагыйрь кешегә яфраклар лепердәшкәнен тыңлап керү дә куаныч китерер.

Фәнияр көрсенеп куйды. Аның көрсенүенә каршы Галина Измайловна:

— Нишлисең бит,— диде,— хәзергә безнең көч җитмәгән нәрсәләр күп шул әле.

Ә бер атнадан Рәшит Шамилович Фәниярны үзе килеп карады. Ләкин яңа берни дә әйтә алмады. Ул Фәниярның ябык, әмма бик хәрәкәтчән кулларына карап исе китте. Фәниярдан язу яздырып карады, төрлечә күтәртте, төшертте. Энәсе белән баштанаяк төрткәләп чыкты. Аркадагы яра эзләренә әледән-әле камфаралы спирт сөртергә кушты. Курортка путевка юлларга киңәш бирде.

Фәниярны әкренләп утырткалый башладылар. Башта аның күз аллары караңгыланды, башы әйләнде. Ике-өч минуттан артык түзә алмады. Ләкин тора-бара хәл бераз үзгәрде, баш әйләнү кимеде, ул

инде яртышар сәгать утыра башлады. Аны коляскага утыртып һава суларга чыгаргаладылар. Әмма Фәнияр бу коляска дигән нәрсәне беренче көннән үк яратмады. Ул аның кешелек горурлыгын кимсетәдер кебек тоелды. Бер бармагын да өзелмәгән килеш, ниндидер күзгә күренмәгән нерв җепләренең чыдамсызлыгы аркасында, ике адым ара үтәр өчен дә артыннан кемнеңдер килеп этүен көтәргә кирәк. Урамга чыкса, читлеккә ябылган маймылга карагандай, бар да аңа карыйлар кебек. «Урынында кузгалмый ятудан да яхшысы юк», дип уйлады ул. Һәм утырып торудан, гомумән, баш тартты. Врач аның белән ничек сөйләшергә белмәде. Фәнияр Галина Измайловнаның дәлилләренә каршы:

— Үзең йөри алмагач, карачкыдай урамга чыгып утыруның ни файдасы бар? — дип җавап бирде.— Урында ятканда кимчелекләрең әзрәк күренә. Урын өстендә бар кеше дә бер төсле була. Мин дә үземне кешечәрәк сизәм, яныма килүчеләргә дә артык кызганыч күренмим. Тирене төртеп торган сөякләремне тырпайтып ишегалдына чыгасым юк, кыстамагыз.

Кешеләр бөтен нәрсәгә күнегә, ләкин үзләренең физик кимчелекләренә күнегә алмыйлар. Чөнки ул минут саен үзен сиздереп тора. Башкалар күзендә чагылган кызгану билгесен дә, саксыз әйтелгән сүзне дә алар үзләренә әйтелгән дип кабул итәләр.

Фәнияр өчен мескен булып күренүдән дә хурлыклырак нәрсә юк. Ул үзенең ябык beләкләрен яшерер өчен гел озын җиңле күлмәк кия. Мөмкин кадәр пөхтәрәк ятарга тырыша. Ике көннең берендә кырына. Дүрт-биш көн саен юындыруларын таләп итеп, ваннада эшләүче санитаркаларның теңкәләренә тия. Һичбер вакыт аның өстендә таушалган яки керләнгән кием күрмәссең. Аның һәр җире, кунак көтүче хуҗа кешенекедәй, җыйнак һәм пөхтә булыр.

## XIV

Гөлсәйдә түти Нәсимә биргән адрес белән әллә кайдагы Савинка поселогында яшәүчеләрне эзләп йөрмәде. Больница коридорындагы диванда йоклады. Врачлар:

— Апа, сез кайтып китегез, йончып бетәсез бит,— дип карасалар да, ул аларның сүзен тыңламады.

— Монда чирлеләр әллә ничә, ә караучылар әз, ничек барсына да житешсеннәр алар. Үз малаемны үзем караем мин,— дип җавап бирде. Төннәрен аяк очларына гына басып улы янына кереп чыкты: юрганы шуып төшеп, өшеп ятмыймы? Әйләндерергә кирәкмиме? Урыны җайсыз җәелеп, йоклап китә алмыйча газапланмыймы?

Гөлсәйдә түти бу палатада ятучы башка авырулардан да чиркәнеп тормады. Һәрберсенә кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышты. Иртән җыештыручылар кергәнче ялт иттереп палатаны юып чыгарды, тәрәзә төпләренең, тумбочкаларның тузанын сөртте. Графинадагы суларны алыштырды. Түгәсе нәрсәләр булса — чыгарып түкте. Авырулар да, нянялар да аны бик тиз үз иттеләр, яраттылар. Кайбер нянялар үзләренә кунарга барырга кыстадылар, әмма ана, башкага тыңлаучан булса да, монда нык торды. Улын ташлап китәргә теләмәде.

Беркөнне һич көтмәгәндә Фәниярлар палатасына берсеннән-берсе чибәр өч кыз килеп керде.

— Без житен комбинатыннан. Таныш булыйк: мин — Ләбибә, менә бу ак йөзлесе — Рәҗибә, ә теге сөйкемле сөяк — Хаҗия булыр.

Кызлар өчесе бер бүлмәдә яшиләр, өчесе бер цехта эшлиләр икән.

— Мине сез каян белдегез соң? — диде Фәнияр гаҗәпләнеп.

— О, хәзер сезне белмәгән кеше юк,— диде Ләбибә.

— Портретыгыз белән шигырьләрегез газетада басылгач, киосклдрда бер газетаны калдырмыйча сатып алып бетердек,— диде Хаҗия.

— Тулай торактагы бөтен кызлар сезгә гашыйк,— диде Рәҗибә.

— Шаяртмагыз инде, мин кемгә хаҗәт? — диде Фәнияр.

— Хаҗәт булмасагыз, әллә кайлардан эзләп килмәс идек,— диештеләр кызлар.

Алар Фәниярның кайда яшәгәнлеген сорап газетага хат язганнар икән. Редакция аның шушы көннәрдә генә Казанга китерелүен һәм кайсы больницада ятуын хәбәр иткән. Кызлар, озак уйлап тормастан, тотканнар да килгәннәр.

— Сезнең янга безнең тулай торактан тагын бик күп кызлар килмәкчеләр иде, барыбызны берьюлы кертмәсләр дип, тегеләрдән качып кына килдек,— диделәр кызлар.

Егет боларга нинди рәхмәтләр укырга да белмәде. Кызлар шундый ачыклар, әйтерсең Фәнияр белән бергә уйнап үскәннәр. Чәчрәнләп торалар. Нәрсә ашыйсың килә, ни китерик дип, Фәниярны аптыратып бетерделәр.

— Берни дә кирәкми,— диде Фәнияр.— Безне монда начар ашатмыйлар. Аннары минем әни дә бирелә. Кирәк-яракны ул чыгып ала.

— Әниегез кайда соң әле? — диде кызлар, бер-берсен бүлеп.

— Әнә ич, ишек төбендә.

— Ак халатлы булгач, без аны няня дип торабыз тагын.

Кызлар Гөлсәйдә түтине сырып алдылар һәм коридорга алып чыгып киттеләр.

— Малаең нәрсә ярата, апа? Компот, варенье ише нәрсәләргә әвәслеге бармы? Бәлки, аның язарына кәгазь-каләм кирәктер? Укырга китаплары җитәрлекме?

Ана бу сорауларның кайсына җавап бирергә дә белмәде. Тегеләр бик нык лап сорашкач, Фәниярның өчпочмак яратуын әйтте. Кызлар, ананың авызыннан шул сүз чыгу белән, ишеккә йөгерделәр.

Бераздан алар кайтып та җиттеләр, шатлыкларыннан балкып. Фәнияр янына килеп керделәр.

— Менә өчпочмаклар алып килгән идек, кайнар килеш ашап җибәрегез әле, Фәнияр,— дип, кызарып пешкән өчпочмак тоткан өч кул Фәниярга сузылды.

Фәнияр кемнекен алырга белмәде. Берсен дә үпкәләтәсе килми, әмма бер өчпочмактан артыгын ашап та булмый.

— Мин барыгызныкын да ашармын, кызлар, пычак кына кирәк,— диде ул.— Ә хәзер,— диде егет, пычак китергәч,— һәрберегезнекеннән берәр почмак кисеп алабыз да, миңа тулы өчпочмак була.

Кызларның һаркайсы зуррак итеп кисеп бирергә теләде. Фәниярның әнисенә дә шундый ук ризыклар сузылды.

— Үзегез дә безнең белән ашарга тиеш инде,— диде Фәнияр.

— Үз күчтәнәчен ашаган кешенең гомере озын була,— диде Гөлсәйдә түти.

Кызлар соңыннан Гөлсәйдә түтинең кайда кунып йөрүен сораштылар. Шушында больницада йоклавын белгәч, үзләренә кайтырга кыстый башладылар. Фәнияр да әнисенә ял кирәген аңлый, ләкин чарасын гына тапмый иде. Кызлар үзләре чакырып торгач, әнисенә:

— Чынлап та, әнкәй, син гел мине саклап ятарга димәгән бит инде, кайт кызлар белән. Бер рәхәтләнеп йомшак урында йокларсың,— диде.

— Әйе, әйе,— диделәр кызлар,— без сезгә үзебезнең караватны бирербез. Комендантка, әниебез килде, диярбез.

— Сезне тыгызлап кайтып йөрмәм инде, балалар,— диде ана.

— Фәниярны төнлә няньлар да карарлар, без бит сезне төнгә генә чакырабыз. Иртән үзебез больницага илтеп куярбыз, әкичләрен барып алырбыз,— диде Рәҗибә.

Кызларның бу кадәр кыстауларына каршы тора алмады ана. «Берәр кичкә булса да кайтаем, алайса», дип, тегеләр белән китте. Гөлсәйдә түтине кызлар үз әниләре кебек кунак иттеләр. Хаҗия белән Рәҗибә коймак пешерделәр. Ләбибәнең авылга әнисенә алып кайтырга дигән самовары бар икән, авыл кешесе самовар чәен ярата төшә дип, шуңарда чәй кайнатты. Озак кына кич утырып, гөрләшеп чәй эчтеләр.

Бер кичкә генә дип килгән ана, шулай итеп, бу киң күңелле, кунакчыл кызларда атнага якын торды. Ә улын больницада карый алуларына ышангач, авылына кайтып китте.

— Үзебез барып йөрербез, борчылмагыз,— дип калдылар кызлар. Һәм сүзләрендә тордылар. Соңгы вакытта Фәнияр янына барырга теләүчеләр күбәеп киткәнлектән, аларга хәтта исемлек төзергә дә туры килде.

## XV

Фәнияр авылда чагында ук Казанның бер эшче-яшьләр мәктәбендә укый торган Илсөя исемле кыз белән хат алыша иде. Илсөя аның больницага килүен ишеткәч, янына барырга уйлады, ләкин ялгызы гына баруны яхшысынмады. Рус теле укытучысы Марина Викторовнаны кыстый башлады. Марина Викторовна белән Илсөя бер урамда яшәгәнлектән, мәктәптән еш кына бергә кайталар. Төннәрен шулай бергә йөрү аркасындамы, әллә башка сәбәптәнме — укытучы белән укучы дуслашып киткәннәр иде. Илсөянең Марина Викторовнага Фәнияр турында да сөйләгәне бар иде. Шунлыктан Марина Викторовна Илсөянең тәкъдименә бик риза булды.

Палатага алар икесенә бер халат бөркәнеп керделәр. Илсөя кечкенә гәүдәле, нәзек кенә кыз икән. Ә Марина Викторовна бик таза, төз һәм озын буйлы, бер-бер беләге Илсөянең биле юанлыгында.

— Халатлар биреп торучы няня икебезне берьюлы кертмәскә маташа,— диде Марина Викторовна.— Халат берәү генә, ди. Ә мин әйтәм, берәү булгач бик җиткән инде, бу чебеш минем кесәмә дә сыя, дим. Шуннан соң уздырып җибәрде тагын.

Марина Викторовна шат күңелле, сүзчән кеше икән. Шаярып сөйләшергә ярата. Илсөя, киресенчә, оялып утыра. Үзе турында сүз чыккан саен бите алланып китә.

— Бу минем иң яхшы укучым,— диде Марина Викторовна.— Газета-журналларда чыккан шигырьләрегезне җыеп бара.

— Җитәр инде, Марина Викторовна,— диде Илсөя һәм кыенсынып башын аска иде. Чәчләре яулык астыннан чыгып битенә төште. Кызның чәче сүс төсле. Фәниярның әнисе элек киндер суга торган иде. Сүсне кабага бәйләр, тәрәш тарагы белән яхшылап тарар. Тараганнан соң сүс йомшап, кабарып китәр. Фәнияр шул сүсләр арасына бармакларын тыгып уйнарга, әнкәсенең әйбәтләп тараган сүсләрен чуалтырга ярата иде. Әле дә, әнкәсенең сүсен чуалткан кебек, Илсөянең чәчләре белән уйныйсы килеп китте. Әгәр кыз шул вакыт күтәрелеп карамаган булса, бәлки, Фәнияр аның башыннан сыйпап та алган булыр иде. Ләкин кыз башын күтәрде. Фәниярга карады. Фәнияр сихерләнгән кебек аның күзләренә текәлде. Бу күзләр таныш төсле тоелды аңа. Илсөянең күзләре яшел-соргылт сызыклар белән чуарланган. Ул сызыклар, көзгегә төшеп таралган нурлар шикелле, күз карасыннан читкә сибелгәннәр. Кайда күргәне бар иде соң Фәниярның бу күзләрне?

Ул берничек тә исенә төшерә алмады. Ә Марина Викторовна бертуктаусыз сөйләнә. Фикер тупларга ирек бирми. Фәниярдан ул:

— Карагыз әле, сез ничә класс тәмамладыгыз? — дип сорады.

— Сигезне генә,— диде Фәнияр, уңайсызланып. Белем турында сорашсалар, ул әйтергә кыенсына. Сигез класс белемең белән шигырь язып маташасың, диярләр кебек тоела.

— Укуыгызны дәвам итәргә исәбегез юкмы соң? — диде Марина Викторовна.

— Кая инде хәзер миңа уку! — диде Фәнияр.— Үзең больницада ят, өч-дүрт куплетлы шигырьне язганчы да тирләп чык, ничек укымак кирәк. Аннары мин теләгәнгә карап кына барып чыга торган эш түгел бит ул. Үзегез күрәсез ич: мәктәпкә бара алмыйм.

— Теләк булганда мәктәпкә бармыйча да укырга мөмкин,— диде Марина Викторовна.— Бара алмасагыз, укытучылар үзләре килер.

— Белмим шул,— диде Фәнияр,— кем генә больницага йөреп дәрес бирергә ашкынып торыр икән.

— Менә мин рус телен укытырмын,— диде Марина Викторовна.— Онытылганнарны искә төшерергә Илсөя ярдәм итәр. Шулай бит, Илсөя?

— Сорап торасыз тагы,— диде кыз, ризалыгын белгертеп.

— Менә хәзер үк икәү булдык. Калганнарын да табарбыз.

Укытучылар килсә укырга исәбе барлыгын әйткәч, Илсөя дә, Марина Викторовна да шатланып куйдылар. Әйтерсең алар Фәниярга түгел, ә Фәнияр аларга яхшылык эшләргә җыена.

...Марина Викторовна бу мәсьәләне мәктәп дирекциясе каршында күтәреп чыкты. Моның өчен укытучыларга акча түләнмәячәген дә, дәрес бирергә эштән соң әллә кайдагы больницага барып йөрергә тиеш булачагын да һәркем белә иде. Шулай да татар теле һәм әдәбияты укытучысы Хаҗи Галиевич, физикадан — Нәзирә, математикадан — Фирүзә һәм башкалар аның янына барырга әзер икәнлекләрен белдерделәр. Пенсиягә чыгарга әзерләнеп йөрүче тарих укытучысы Рамазанов та каршы килмәде. Бары тик чит тел укытучысы гына тапмадылар. Бу мәктәптә чит телдән күптән түгел институт бетереп килгән яшь кыз укыта иде. Больницада ятучы авыру кешегә дәресләр бирергә дигәч аның коты очты.

— Авырулардан, врачлардан куркам мин,— диде ул.— Дару исе дә ярамый миңа. Бервакыт тешемне алдырырга баргач та һушым китеп егылганмын.

Шулай дигәч, аңа кабат ялынып тормадылар. «Чит телсез дә ярар әле», диделәр. Барлык укытучы үзара килешеп расписание төзеделәр. Кемгә кайсы көнне бару уңайлы, аны белештеләр. Атнаның һәр көнендә бер укытучы килергә тиеш булды.

Фәниярны дәресләкләр белән күмеп ташладылар. Палатага укытучылардан башка кешеләрне кертмәскә кушылды. Ишек төбендә торучы швейцар карчык гаять зур тугрылык белән Фәниярның тынычлыгын саклады. Халат сорап бик йөдәтә башласалар:

— Берүк мишәйтләп йөрмәгез, егетебез укый, китаплардан башын да калкытмый. Укытучылардан башкаларын кертергә главныйның рөхсәте юк,— дип борып җибәрергә тырыша. Ләкин килүчеләрне кызгана да: барыгыз инде, бер-ике минутка гына кереп чыгыгыз, дип халатын бирә иде.

Егеткә уку җиңел бирелмәде. Күбесе онытылып беткән. Математика, геометрия, химияише фәннәр гомергә укып карамаган шикелле тоела. Физикага армиядә укуның ярдәме тидеме, анысы, карлы юлга чыккан чанадай, җиңел шуып китте. Укытучысы Нәзирә бик аңлаешлы итеп сөйли. Гади. Килгән саен тәмле-тәмле нәрсәләр пешереп алып килә. Үзе әле Фәниярдан бернычә яшькә генә өлкәндер. Кияүгә дә чыкмаган. Портфеле аның бик калын була.

— Нәрсәдән башлыйбыз? — ди ул Фәниярга.— Сез сөйлисезме, әллә мин генә сөйлимме?

— Башта мине тыңлап карагыз,— ди Фәнияр.

Тел фәннәренә Фәниярның элек-электән мәхәббәте зур булганлыктан, боларын уку үзенә бер төрле рәхәтлек бирә иде. Татар теле һәм

әдәбияты укытучысы Хажи Галиевич үз эшенә шундый бирелгән, бер сөйли башласа, вакыт узганын да сизмисең. Күп кенә язучыларны күреп белә. Шуңа күрә Фәнияр, ул сөйли башласа, әкият дөньясына кереп киткән сабый хәленә төшә. Больницада икәнен дә, янында ыңгырашып ятучы авырулар барын да оныта. Үзен ул укытучы тасвирлаган геройлар арасында хис итә. Шул сихри дөнья кешеләренең кылган эшләрен ишетеп тәэсирләнә, рухы ныгый, күңеле байый. Һәр әсәрдән пакьләнеп, сафланып калгандай була.

— Сезнең Муса Җәлилне күргәнегез булдымы? — дип сорады аңардан Фәнияр бервакыт.

— Әйе,— диде Хажи Галиевич.— Очратырга туры килгәләде. Мин үзем дә яшь чакта шигырьләр язгалап караган кеше. Берничәсе хәтта басылып та чыкты. Уңышлардан куанып, бер бик озын поэма да әвәләп ташладым. Ләкин ул минем поэма дигән нәрсәм либреттога охшашрак булып чыккан. Язучылар союзындагы әдәби консультация бүлеге мине Муса Җәлилгә җибәрде. Утыз сигезенче ел иде бу. Муса Җәлилнең яңа Мәскәүдән кайткан чагы. Шундый танылган язучы минем белән сөйләшеп тә тормас дип курка-курка гына бардым. Җәлил опера һәм балет театрының әдәби бүлек җитәкчесе иде.

Куркуым юкка булган икән. Кабинетына керү белән янына утыртты. Минем либретто китерүемне белгәч:

— Әйе, туганкай, безгә либреттолар бик кирәк. Укырбыз, озакламабыз,— диде. Кайда торуымны, кем булып эшләвемне сорады. Мин студент икәнлегемне әйттем.

— Монысы әйбәт, әдәбиятка укыган кешеләр килә, шөкер,— дип сөенеп куйды.

Мин аның яныннан канатланып чыктым. Әйтерсең либреттом сәхнәгә куелган. Әмма шатлануым озакка булмады. Беркөн Муса Җәлил мине институтта очратты да: «Либреттогызны укыдык, куандыра алмыйм, начар»,— диде. Башкалар начар әйберләрне укысалар кыеклап, читләтеп әйтә торгачнар иде. Муса Җәлилнең турыдан-туры: «Либреттогыз начар» дигәе минем бик нык хәтеремне калдырды... «Сездән башка да язучылар бетмәгән» дип, тагын әллә нинә кешегә күрсәтеп карадым. Тик өметле сүз ишетмәдем. Кешегә үз вакытында турысын ярып әйтү дә зур файда икән. Әгәр шунда минем пешеп җитмәгән либреттомны алып, үзләре эшкәртә-эшкәртә дөньяга чыгарсалар, мин үземне даһига санап йөриячәк идем. Андый язучылар да юк түгел бит әле бездә...

Әллә ничә кештән либреттомның начар икәнен ишетсәм дә, ышанасы килми генә бит, каһәр. «Тукта әле, мин әйтәм, председательнең үзенә барыйм, шундый шәп әсәрне хурлаганга Җәлилнең кирәген бирсен». Таушалып беткән папкамны култык астына кыстырдым да Язучылар союзына киттем. Председатель кабинетына керсәм, күзләрем шар булды: өстәл артында Муса Җәлил утыра. Әйе, утыз тугызынчы елда язучылар аны үзләренең җитәкчесе итеп сайлаганнар икән. Ә мин аңардан хәбәрдар түгел идем.

— Ә, иске таныш икән, утырыгыз,— диде Җәлил.— Әллә яңа әсәрләр китердегезме?

— Юк, яңа түгел, теге вакытта сезгә күрсәткән либретто. Әйтегез әле, зинһар, кай җире начар, төзәтеп китерәм,— дим.

— Сез педагогия институтында укыйсыз бит әле, әйеме? — диде ул.

— Әйе, киләсе елда бетерәм инде,— дим.

— Алайса, практикаларда булганыгыз бардыр, ничек соң, эшегезне яратасызмы?

Әле ныклап укыта башламасам да, мәктәпне, балаларны яратып өлгергән идем. Практиканы отличнога үтүем, беренче дәресләрем ту-

рында кайнарланып сөйләп киттем. Ул мине бүлдермичә тыңлады. Ә соңыннан болай дип сорады:

— Әйтегез әле, сезнең яхшы укытучы буласыгыз киләме, әллә начар язучымы?

Мондый сорауны көтмәгән идем. Маңгаем тирләп чыкты. Үземдә язучылык сәләте юклыгына шунда гына ышандым. Билгеле, моны аңлау бик авыр булды. Теге либретто салынган папкамны яратып өлгергән идем, тиз генә аерыласым килмәде.

Фәнияр аның сүзләрен тыңлаганнан соң:

— Сез һәр әдәби әсәрне шундый нечкәләп аңлата аласыз. Кимчелекләрен, уңышлы якларын табасыз. Миңа калса, сез яхшы итеп яза да алыр идегез,— диде.

— Әсәрләрне анализлау, үзеңчә бәя бирү бер нәрсә, ә иҗат итү бөтенләй башка эш ул, Фәнияр туган. Муса Җәлил миңа нәкъ шуны төшендерде дә инде. Рәхмәт аңа. Ул мине озатканда: «Сездән әйбәт укытучы чыгар. Укытучылык эшен бит теләсә кем булдыра алмый. Мәсәлән, мин үземдә укытучылык сәләте күрмим».— диде.

Хажи Галиевичның бу сүзләре уйландырды Фәниярны. Чынлап та, үзеңнең нәрсәгә сәләтле икәнеңне белү читен эш. Армиядә вакытта беренче мәртәбә самолетка утырулары, парашют белән сикерүләре исенә төште. Сикерү рәхәтен татыганнан соң ул үзен я парашютчы, я очучы итеп күз алдына китерә башлаган иде. Ризван белән космос турында хыялланып йөрделәр... Хәзер кайда икән ул? Ник бер дә хат язмый? Әллә дуслыгы шуның кадәр генә булдымы?

Фәнияр Ризван белән рус теле өйрәнеп йөргәен исенә төшереп елмаеп куйды. Ризван бер җирдән дә хат алмый иде. «Әйдә, малай, без синең белән хат язышабыз»,— диде ул Фәниярга. Хатларны бары тик русча гына язарга дигән шарт куйды ул. Бер-берсе белән янәшә караватта яткан ике солдат хат язышa башладылар. Фәнияр бөтен күргәнбелгәннәрен русчалап тезә-тезә дә хатлар куела торган тактага илтеп сала. Ризван укып, хаталарын төзәтә һәм кызыл кара белән кагыйдәләрен аңлатып яза. Хат, төзәтелгәннән соң, кире Фәнияр кулына килеп керә. Болай язу Фәниярга үз хаталарыннан арынырга ярдәм итсә, детдомда үскән туган-тумачасыз Ризванга юаныч булды.

Соңгы вакытларда Ризванны сагына башлады Фәнияр. «Кемне уйласаң, шуннардан хәбәр алырсың»,— ди Фәниярның әнисе. Чынлап та, бер көнне аңа Ризваннан хат китерделәр. Ризван хатны редакциягә язган иде.

«Фәнияр дускай! Озак язмый торуыма ачуланганыңны беләм, әмма язуымның үзенә күрә сәбәбе бар: без бит синең белән очучы булырга хыялландык. Теләкләр тормышка ашарга торганда гына синең белән шундый хәл килеп чыкты. Сине госпитальгә озаткач, икебезнең хыялны тормышка ашырырга мин үз-үземә ант иттем. Мин дә очучы була алмасам, син мине гафу итмәссең кебек тоелды. Укчы-радистлар мәктәбен бетергәч, полк командирына кердем дә бөтенесен сөйләп бирдем.

Очучылар училищесына җибәрделәр. Инде өч ел уку артта калды. Мин тулы хокуклы очучы булдым. Шулай да минем теләк тормышка ашып җитмәгән иде әле. Хәтереңдәдер, космонавтлыкка алуларын сорап без бер хат язган идек. Училищены тәмамлагач, тагын яздым. Чакыру кәгазе килде. Медицина комиссиясе анда бик таләпчән икән. Теләсә нинди самолетта оча аласың, ләкин космоска ярамыйсың, диделәр. Командование мине яңа самолетлар сынарга билгеләде. Очкан сәгатьләремнең яртысын синең исәпкә язып барам. Сиңа да шактый җыелды инде. Син шигырьләр яза башлагансың икән. Бик шәп, малай. Әйдә, безнең хыялларны шигырьгә сал. Шигырьләрең сине самолеттан да биек күтәрсен. Ә иртәгә, дускай, минем особой көн булачак. Мин үз гомеремдә иң җаваплы эшкә китәм. Хәзергә хуш. Озак язмаганга

ачуланма, теләккә ирешми торып язасы килмәде. Сәлам белән — хезмәттәш дустың Ризван».

Фәнияр бу хатны укыды да озак кына уйланып ятты. Аннары аны кире конвертка тыгып куймакчы иде, ләкин әчтә тагын бер кәгазь кисәге күрде. Бусы бөтенләй икенче кул белән язылган бернечә генә сүздән тора иде: «Сезнең дустыгыз Ризван җаваплы задание үтәгәндә һәлак булды. Сезгә язган хатын кәгазьләре арасыннан табып алдым. Аны сезгә җибәрәм. Ризванның дусты Коля».

Фәниярның йөрәген кинәт ниндидер кайнар кыршау китереп кыскандай булды. Тын алуы авырайды. Күз аллары карангыланып китте. Няня йөгереп сестраны, сестра врачны алып керде. Ашыгыч рәвештә кофеин уколы кададылар.

Аның белән бернечә мәртәбә шундый хәл булды инде. Торган саен йөрәге начарлана бара. Кичерешләр, йокысыз төннәр үзенекен итәдер шул. Кеше бер түзә, ике түзә — өченчесендә өзелеп куя.

## XVI

Фәнияр Казан больницасында ярты ел ята инде. Сәламәтлегендә әллә ни үзгәреш булмаса да, бирегә килү зыян итмәде. Күп кенә язучылар белән танышты. Ә иң әһәмиятлесе — шушы ярты ел эчендә тугызынчы класс программасын тулаем үзләштерде. Укытучылар: «Хәзер иркенләп ял ит, ә киләсе елда без тагын килербез. Урта мәктәпне тәмамларсың»,— дигәннәр иде, ләкин Фәнияр вакытны әрәм үткәрергә теләмәде, унбиш көнлек каникул ясап алганнан соң, тагын укырга керешә.

Аңарга шул ук укытучылар дәрес бирде.

Илсөя дә больницага еш килеп йөри хәзер. Үзе дә унынчы класста укыганлыктан, күп вакыт дәресләрен Фәнияр белән бергә хәзерлиләр. Фәниярга аның белән рәхәт. Ничектер егет күңеленә тиз кереп урнашты Илсөя. Була бит шулай: хәтта гомереңдә бер тапкыр күрмәгән кешене дә хыялыңда тудырасың. Төсен-битен, холкын-фигылен, сөйләшүенкөлүен күз алдына китерәсең. Хыял тарафыннан тудырылган бу кешенең кайчан да булса очраячагына ышана башлыйсың. Сиңа очраган, бигрәк тә авыр чакта дуслык кулы сузган кешеләрдән хыялың тудырган кешенең билгеләрен эзлисең.

Ә Илсөянең күңеле сизгер. Егетнең үзен көтеп алганлыгын аңлый. Ярдәм итәргә, ничек тә бер яхшылык эшләргә тели. Ул беркөнне Фәниярларның врачы Галина Измайловна янына кереп:

— Миңа Фәнияр турында сөйләгез әле,— диде.— Аңарга нинди ярдәм кирәк?

— Сезнең килеп йөрүегез аның өчен зур ярдәм инде,— диде Галина Измайловна.— Ул бирегә килгәндә ничектер кешеләргә ышанмыйчарак карый иде. Баштарак мин аның белән рәтләп сөйләшә дә алмадым. Ә хәзер бөтенләй башка, шундый хиреслек белән укып ята. Киләчәккә өмете уянган. Менә шуны сүндермәскә кирәк безгә.

— Аңарга кан җибәреп булмыймы? — дип сорады Илсөя.— Мин аңа үземнең канымны бирер идем. Бәлки, файдасы тияр...

Ачынып-ачынып кеше язмышын кайгыртып йөрүче бу кызга яратып, ягымлы итеп карады врач. Фәниярга ярдәм итәргә теләүчеләр көннән-көн арта, димәк, аның сәләтенә, көченә ышаналар. Кан җибәреп кенә аякка бастырып булса, врач үз канын да жәлләмәс иде. Шулай да Илсөянең күңелен төшерәсе килмәде аның.

— Аңарга язучылар курортка путевка юллап йөри бугай. Бәлки, курортларның файдасы тияр әле,— диде.

Илсөя әллә кайчан барасы курортны көтеп торырга теләмичә:

— Хәзер бит космоска кеше очыралар, йөрәкне алмаштыралар, нервларны да күчереп куеп булмыймы соң? — диде.— Мин бер газетада ул турыда укыган идем. Ниндидер бер профессор этләргә тимер нерв куйган, ди. Бәлки, хәзер кешеләргә дә куя башлаганнардыр. Тимерне куймасалар, мин үземнекеләрен дә бирер идем.

— Әйе, фән бер урында тормый, бер заман кешеләргә дә тимер нервлар куя башларлар әле...— диде Галина Измайловна, кызны юатырга теләгәндәй.

Әмма Илсөянең егеткә үзеннән нәрсә дә булса бирәсе килә. Кеше гомере гасырлар белән исәпләнми, һәр көн кадерле. Тизрәк Фәниярны аякка бастырырга иде. Моны ничек эшләргә? Шул сорауга җавап бирсен иде врач.

— Бәлки, аны Мәскәү, Ленинград кебек зур шәһәрләргә алып барып күрсәтергә кирәктер.

— Бик теләгән очракта Мәскәүгә алып барырга да мөмкин, әлбәттә. Тик...

Илсөя аның тел төбен яхшы аңлады. Артык сорашып тору файдасыз иде. Күңелсезләнеп, врач янынннан чыгып китте. Фәниярга да ул Галина Измайловна белән сөйләшүен әйтеп тормады. Палатага һәрвакыттагыча ачык чырай белән керде. Фәнияр бүген бик озак эзләнүләрдән соң ачыш ясаган кешедәй шат иде.

— Янымарак утыр әле, Илсөя,— диде ул түземсезләнеп.— Ә хәзер кулыңны бир, язмышыңны багып карыйм.

Илсөя кыяр-кыймас кына аңа кулын бирде. Егет, кулдагы сызыкларга караган булып, сөйләп китте:

— Исемең Илсөя инде, анысын кулыңа язылмаса да беләм. Эшең бик югарыда икән, шуңа күрә егетләргә бераз өстәнрәк карарга өйрәнгәнсең...

— Мин чынлап дип торам тагын,— диде Илсөя.

— Шаярып сөйләмим, мин сине күптәннән беләм икән, Илсөя. Кайда күргәнем бар икән бу кызны дип әллә ничә көн баш ваттым. Тәки искә төште бит. Мин сине армиягә киткәнче күргәнмен.

Һәм Фәнияр Татвоенкомат ишегалдыннан ничек итеп кранга утырып чыкканын кызга сөйләде. Илсөя дә ул вакыйганы онытмаган икән, чөнки шул шуклыгы өчен беренче мәртәбә эшендә шелтә алган. Кранына бер төркем кеше утыртып койма аша чыгарганын хәтерләсә дә, ул чактагы Фәниярны исенә төшерә алмады Илсөя. Ә бит еш кына исенә алгалый иде ул егетне.

Илсөянең шул вакытта очраткан кыз икәнен белгәч, ни өчендер Фәнияр бик шатланды. Кыз аңа тагын да якынаебрак китте. Больницага Илсөя килмәгән көннәрне ничек үткәрергә белмәде. Егет йөрәгендә зур бер хис кабынып килә иде.

Ул хис үтеп керә алмаган бер генә стена да юк. Төрмәләрнең тимер ишекләре дә, больницаларның таш стеналары да, юлларны бүлеп торган биек кыялар да, ургып-ургып аккан елгалар да киртә була алмый аңа. Кешеләр диңгезләр кичеп, карурманнар гизеп бер-берсен табыша. Аны мәхәббәт диләр.

Мәхәббәт бер яклы гына икән, сүндерергә дә мөмкин әле. Бер йөрәк — ут, икенчесе — су булганда ялкын бар дөньяны чолгап ала алмый. Ләкин Илсөянең дә күңеле тыныч түгел. Элегрәк мендәргә башын төртү белән йоклап китә иде, хәзер сәгать икеләргә кадәр урыны өстендә әйләнә. Күздән йокы, күңелдән тынычлык качты. Йокласаң төшкә керә, күзне йомсаң, күз алдына килә, эштән туктасаң, уйларны биләп ала Фәнияр. Нәрсәгә шулай якын соң ул? Чибәр-чибәр егетләр артыннан өерләре белән йөргәндә дә, сөйләшеп тормыйча кереп китә иде Илсөя. Ә Фәнияр...

Аның дулкынланып торган кара чәчләрен сыйпыйсы, хәрәкәтчән коңгырт күзләренә туйганчы карыйсы килә. Ул күзләр Илсөя килеп керү белән шул кадәр җанлана, ялкынланалар, әйтерсең әйбәтләп шомартылган алмаз бөртегенә төрле яктан нур төшерәләр. Илсөя, гадәттә, Фәнияр янына кичләрен килә. Шуңа күрә беркөнне Фәнияр шаярып болай диде:

— Минем хәзер ике кояшым бар, Илсөя. Берсе аның иртәнге алтыларда тәрәзәдән төшә, икенчесе кичке алтыларда ишектән керә.

— Ишектән кергән кояшны күргәнем юк әле минем,— диде Илсөя.— Хәзер кичке алты бит инде, кая соң ул кояшың?

— Менә ич, янымда утыра,— диде егет, Илсөянең кулларын үзенең битендә йөртеп.

Фәниярның сүзләреннән Илсөя кызарды. Битендәге ялкын чәченә кабар төсле тоелды.

— Алай әйтмә, Фәнияр,— диде ул.— Мин нинди кояш булыйм. Төзелештә эшләүче бер кранчы кисәге генә бит мин. Әле дә инде иптәш кызларым үртәп туймыйлар, сина шагыйрь ошап китте, больницадан кайтып та кермисең, диләр. Җитмәсә, химия китабына шигырь язып җибәргәнсең. Аны үземә чаклы иптәш кызларым күреп алганнар. «Химия китабы дигән идек, әдәбият икән бу, әнә шигырьләр язылган», диләр. Ачып карасам исем китте.

Әйе, Фәнияр ул шигырьне яхшы хәтерли.

> Чокырлы ияккәем,
> Сөйкемле сөяккәем,
> Сине бер көн күрми торсам,
> Өзелә үзәккәем,—

диелгән иде анда.

Нишлисең бит, яхшымы, яманмы — Фәнияр шагыйрь кисәге. Күңелендәген дә шигырьләр белән аңлатырга тырыша. Тазамы син, авырумы — яшьлек үзенекен итә. Үбешү тәмен татып карамаган иреннәр назга сусаган. Кызлар кулы сарылмаган иңнәр — шул кулларның йомшаклыгын тоярга тели. Татлы мәхәббәт сүзләре ишетмәгән колаклар — шул сихри сүзләрне ишетергә зарыккан.

## XVII

Тагын яз житте. Кояш нуры өй түбәләрендә асылынып торган боз сөңгеләрендә уйный. Чыпчыклар, песнәкләр дәртләнебрәк сайрыйлар. Алар салкын кышны исән-сау чыгуларына куаналардыр, күрәсең. Күк йөзе зәп-зәңгәр, палата әчләре дә яктырып китте. Фәнияргә моңсу да, күңелле дә бу яз. Моңсу — чөнки урамнарны, якты кояшны тәрәзә аша гына күрә. Күңелле — чөнки йөрәген татлы бер хис ашкындыра. Шигырьләр дә җиңелрәк туа. Кар астында күмелеп калган яшел уҗымны яз җилләре килеп ачкан кебек, яз — хәтердә томанланып яткан истәлекләрне өскә калкытып чыгара. Тагын бер язны күрә алуыңа куанасың.

Фәнияр хәзер бөтен көчен куеп имтиханнарга әзерләнеп ята. Урта мәктәпне тәмамларга җыена. Ләкин күңеле моңа ышанып җитми. Сынауларын бирә алмыйча хур булыр төсле тоела. Әйе, аңа сынатырга ярамый. Ел буе, шәһәрнең бер башыннан икенче башына кадәр аңа дәрес бирергә килеп йөргән укытучыларның йөзләрен кызартмас өчен генә дә яхшы хәзерләнергә тиеш ул. Имтиханын тапшыра алмаса, дәресләрен әзерләргә комачауламаска тырышып, бик авыртынган чакларда да ыңгырашуларын тыеп яткан палатадаш дусларының йөзенә ничек карар. Аның тынычлыгын саклап, аяк очларына гына басып йөргән сестралар, няняларның күзләренә ничек күренер?..

Галина Измайловна Фәниярнын артык тырышуын күреп:

— Сез үзегезнең сәламәтлегегез турында да уйлагыз,— дип кисәтте.— Соңгы вакытларда бик ябыгып киттегез.

Фәнияр врачның сүзләрен шаяруга борды:

— Безнең әни әйтә: тәндәге ит кунак кына, ди. Аннары, тазарып китсәм, нянялар ничек күтәрер? Шунысы да бар бит.

— Берсенең генә көче житмәсә, икәүләп күтәрерләр, эшчеләр житәрлек бездә,— диде Галина Измайловна.— Мин сезгә менә нәрсә әйтергә телим: авыру кешеләрне экзаменнардан азат итәргә мөмкин. Без больницадан мәктәбегезгә справка жибәрербез. Аттестатны экзаменсыз гына бирәләр.

— Мин авыру түгел ич,— диде Фәнияр.— Башым эшли, йөрәгем әйбәт, нервларым тыныч. Эш аякларда гына. Алары өчен дә кайгырган юк: бер яктан караганда аларның булмавы шәбрәк тә әле. Чөнки укытучылар үзләре килә, аякларым йөрсә, үземә барырга туры килер иде.

Фәниярның күңеле күтәренке чакта җитди сөйләшеп булмаслыгын белгәнгә, врач кул селтәп чыгып китте. Справкага каршы киләсен дә белде ул. Чөнки Фәнияр үзенә ташлама ясаганнарын яратмый. Башка укучыларга нинди таләпләр куелса, аңарга да шундый ук таләпләр куелсын. Юкса чын-чынлап үпкәли, алай гына да түгел, хәтта кимсенә. «Больницадан справка алып мәктәпкә җибәр, имтиханнардан азат итәрбез»,— дип, Марина Викторовна да әйткән иде аңарга.

— Мин болай да көне буе бер эшсез бит, мине түгел, эшләп тә, укып та йөрүчеләрне азат итәргә кирәк,— дип җавап бирде Фәнияр.

— Ничек эшсез булсын? — диде Марина Викторовна.— Шигырь язуны эшкә санамыйсызмыни?

Кешеләрнең үгет-нәсихәтләренә бирелмичә әзерләнүендә булды Фәнияр.

Менә имтиханнар көне дә килеп җитте. Иң беренчесе — рус теленнән иншa иде. Мәктәптә барлык укучылар язып бетергәч, имтихан алу комиссиясе Фәнияр янына килде. Моннан берничә көн генә элек, тынычлап укый алсын өчен, Фәниярны бер үзен бер палатага салганнар иде. Палата кечкенә, ләкин әзерләнер өчен тыныч һәм уңайлы иде.

Иншаның темасы «Рус әдәбиятында синең яраткан героең» дип атала иде. Теманы ишетүгә, Фәнияр үзенең тумбочкасындагы Нәсимә бүләк иткән Островский бюстына карап куйды. Ниндидер тылсымлы көчкә буйсынгандай, егет тагын Павел Корчагин турында яза башлады.

Уйлар бер-бер артлы кәгазьгә агыла. Павка кичергән давыллы еллар күз алдына килә. Корчагинның омтылышларында, хыялларында Фәнияр үз омтылышларын, үз хыялларын күрә. Шуңа күрә язу рәхәт аңа. Бер сәгать үткәндерме-юкмы, ул иншасын тәмамлап та бирде. Комиссия аның эшен шунда ук тикшереп чыкты да «яхшы» билгесе куйды.

Башка имтиханнарын да әйбәт тапшырды ул. Ә аттестат алган көн аның өчен зур бәйрәм булды. Укытучылар һәм укучылар олы-олы чәчәк бәйләмнәре күтәреп килделәр. Һәркайсы Фәниярны котлады. Тәбрикләргә килүче укучылар арасында берничә егет тә бар иде. Алар, кай җирләренәдер яшереп, шампанское алып кергәннәр икән. Тавышын чыгармый гына ачтылар. Әмма беркемдә дә рюмка яки стакан ише нәрсә табылмады. Илсөя сестралардан бер мензурка сорап торды. Шуңарга шампанское салып Фәниярга суздылар. Фәнияр, монда миннән өлкәннәр бар, менә укытучыларыбыз башласын дигән иде, һәммәсе: без бүген синең кунагың, иң беренче хуҗа эчеп күрсәтсен, диделәр.

— Алайса мин бу тостны, ару-талуны белмәүче укытучыларыбыз, сезнең хөрмәткә күтәрәм,— диде Фәнияр.— Сез вакытыгызны да, көчегезне дә кызганмыйча һәрвакыт яныма килеп йөрдегез. Укытучыларым гына түгел, якын дусларым да булдыгыз. Рәхмәт сезгә!

Фәнияр бик күп матур сүзләр әйтмәкче иде, ләкин үзенә төбәлгән сөйкемле күзләр, ел буе күреп ияләшенгән ягымлы йөзләр аның күңелен дулкынландырып, әйтергә теләгән сүзләрен оныттырып җибәрделәр. Ул тагын бер кат рәхмәт әйтте дә эчеп җибәрде.

Мензурка кулдан-кулга йөрде. Физика укытучысы Нәзирәнең сумкасыннан кабартма һәм пәрәмәчләр чыгып өстәлгә тезелде. Марина Викторовна шаярып:

— Хәзер өлгергәнлек аттестаты алдың инде, Фәнияр, шигырьләрең дә «өлгергән», «җитлеккән» булсын,— диде.

Хажи Галиевич дәресләрен бик матур аңлатса да, тантаналы речь сөйли белми иде. Бүген бераз таркаурак та күренә ул. Утыз гына грамм сыешлы мензуркадагы эчемлекне дә бетерә алмыйча азапланды. Ахырдан ул Фәнияр янына килеп болай диде:

— Менә монда, синең больницаң белән янәшә генә, университет, Фәнияр туган. Шунда кереп, зур галимнәрдән белем алуыңны телим.

— Рәхмәт, Хаҗи Галиевич.

Палатада тавышлар кубәеп киткәч кенә ишектә тагын бер кеше күренде. Ул — Хәтерсез Нәсимә иде. Фәнияр Казанга киткәч, кыз еш кына хатлар язып, егетнең хәлен белешеп торды. Фәнияр да Нәсимәнең хатларын җавапсыз калдырмады. Ләкин әллә кайдагы ерак районда эшләүче кеше монда килеп чыгар дип уйламый иде. Фәнияр палатадагы дуслары белән Нәсимәне таныштырды.

— Менә бу кара кыз Нәсимә була. Безнең больницасының иң әйбәт шәфкать туташы.

Нәсимә аның сүзләреннән оялып читкә карады. Шул вакыт бер генә мизгелгә Илсөя белән Нәсимәнең күзләре очрашты. Фәнияр Илсөя турында һәр хаты саен диярлек яза иде. Бу исемнең торган саен ешрак кабатлануы тикмәгә генә түгеллеген аңлый иде Нәсимә. Гомерендә күрмәгән Илсөяне ул күз алдына китерергә тырышты. Нинди рәк кыз икән? Ничек Фәниярның күңелен шулай тиз яулый алган? Күп төрле сораулар Нәсимәне борчый, тынычлыгын ала башлады. Моңарчы Илсөяне күргәне булмаса да, Фәниярның бу кызга ниндидер бер җылылык һәм ярату белән каравыннан Нәсимә аның Илсөя икәнлеген абайлады. Нәсимәнең йөрәгеп нидер чеметеп-чеметеп алды. Палата эче бөркүләнеп китте. Шулай да ул үз хәлен сиздермәскә тырышты. Фәниярны котларга дип алып килгән бүләген кеше-карага сиздермичә генә одеял астына тыкты. Аннары игътибарны читкә юнәлтү өчен:

— Ник тәрәзәгезне ачмыйсыз? Бөркү бит,— дип, тәрәзәне киереп ачып җибәрде. Һәммәсе иркенләп сулыш алдылар. Тәрәзәнең ачылуын гына көткәндәй тышкы яктан өч баш күренде. Болар җитен комбинаты кызлары: Ләбибә, Хаҗия һәм Рәҗибә иде. «Сездән башка да анда кеше күп», дип, аларны кертмәгәннәр икән. Бүлмәдәге кешеләргә сәлам биргәч, алар:

— Молодец, Фәнияр, булдыргансың,— дип дәррәү кычкырдылар һәм ачык тәрәзәдән чәчәк бәйләмнәре суздылар. Егет аларга рәхмәт әйтергә дә өлгерә алмады.

— Без киттек, хушыгыз,— диделәр дә юк булдылар.

Башкалар да, сине ардырдык бугай дип, кузгалыша башладылар. Фәнияр яшертен генә Илсөягә карады. Нәсимәнең дә Фәнияр янында иркенләп сөйләшеп утырасы килә иде. Озакламый бүлмәдә Нәсимә белән Илсөя генә калды.

Тынлык урнашты. Бераздан Илсөя:

— Мин мондагы кеше әле, еректан килгән кунак белән сөйләшегез,— дип, урыныннан торды.

— Юк, юк, утырыгыз,— диде Нәсимә.— Мин озакка килмәдем. Мине җизниләр чакырып җибәргәннәр, юл уңаеннан Фәнияр янына да сугылып үтим дидем. Сез утырыгыз, Илсөя.

— Минем исемемне беләсезмени? — диде Илсөя, гаҗәпләнеп.

— Әйе, әйе, мин барысын да беләм,— диде Нәсимә һәм кызу-кызу атлап чыгып китте. Аны туктатмаганы өчен Илсөя Фәниярны битәрләп калды. Фәнияр кыенсынудан иренен тешләп түбән карады.

Нәсимә җизнәләре чакыруы буенча килмәгән иде. Фәниярны, анардан да бигрәк, Илсөяне күрәсе килде аның. Җилбәзәк кыз түгелме? Егет күңелен ымсындырып кына йөрмиме?

Нәсимә үзен кая куярга белмичә больница каршында йөренде. Ул Илсөяне күтәргә, сөйләшергә карар итте. Шунсыз йөрәге басылмаячагын аңлады. Илсөя Фәнияр янында шактый озак тоткарланды. Ә урамга чыгу белән каршысында Нәсимә пәйда булгач, гаҗәпсенеп туктады.

— Мин сезне көттем, Илсөя,— диде Нәсимә, ерактан йөгереп килгән кешедәй, сулышын еш-еш алып.— Ашыкмасагыз, менә бу эскәмиягә утырыйк әле...

Утырдылар.

Үзе генә чакта батыраеп, бөтенесен ярып салырга теләгән Нәсимә Илсөя янында югалып калды. Әйтергә теләгән сүзләре тел очында торса да, башлап китү кыен иде. Бер уйлаганда, Илсөядән Фәнияр турында сорашырга аның хакы да юк бит. Әмма йөрәк хак-хокуклар белән исәпләшергә теләми.

— Илсөя,— диде Нәсимә, ниһаять, үзен кулга алып,— сез Фәниярны... яратасызмы?

Илсөя үзенә мондый сорау бирерләр дип уйламаган иде. Аның тупас итеп: «Сезнең миннән сорау алырга ни хакыгыз бар?» — диясе килде. Тик Нәсимәнең үз-үзен тотышы, кыенсынып, кызарып көч-хәл белән сорашуы аны тыеп калды. Чынлап та Фәниярны яратамы соң Илсөя? Аның күз алдыннан Фәниярның елмаюлы йөзе, Илсөя килеп кергәч шатлыктан балкыган күзләре чагылып үтте. Егет турында уйлап йоклый алмый ятулары исенә төште. Бу сорау артык катлаулы шул.

— Фәнияр яратмаслык егет түгел,— диде Илсөя, туры җавап бирмичә.

— Сез Фәниярны күптәннән беләсезме?

— Армиягә киткәндә танышкан идек.

Нәсимә бу кадәресен көтмәгән иде. Ул кинәт эскәмиягә сеңде. Аннан соң ашыгып-ашыгып сөйли башлады:

— Әйе, Фәнияр да сезне ярата. Мин аңа карап тордым: ул күзләрен гел сездән алмады. Минем аның бервакытта да шундый өмет, ышаныч белән каравын күргәнем юк иде. Ә миңа аның һичкайчан да алай караганы булмады. Әйе, ул сезне ярата. Сез генә аны бәхетле итә аласыз. Мин аңа бары шәфкать туташы гына идем.

Нәсимә үз янәшәсендә сүзсез утырган Илсөя барлыгын да онытты. Ә бит ул юләрләнеп Казанга эшкә күчәргә, Фәниярга якынрак булырга теләгән иде. Фәнияр аның ярдәменә мохтаҗдыр, көтәдер, сагынадыр дип уйлаган иде. Барысы да буш хыял. Нәсимә үзе уйлап чыгарган нәрсә генә булган икән. Фәнияр янында кешеләр кайнап тора. Укый, яза, сөя, сөелә. Тормышы бөтен, бәхете түгәрәк. Нәсимәнең комачаулап йөрүе кирәкми.

Ул: «Ах, җизниләр мине көтеп арыгандыр», дип, ашыгып китеп барды. Якындагы киосктан конверт һәм кәгазь алып Фәниярга кыска гына хат язды: «Фәнияр, мин тормышка чыгам, кешеләр алдында әйтә алмадым. Миңа хат язма. Киявем чит кешеләр белән язышуны теләми. Хуш. Сәламәтлән. Хатерсез Нәсимә».

Тик шулай да, уйлагач, күңелен җәрәхәтлисе килмичә, хатны салмыйча калдырды.

## XVIII

Фәниярның дуслары аңа күптәннән курортка путевка юллап йөрделәр. Егетнең инде төшләренә диңгез, җимештән сыгылып төшкән агачлар керә. Аның беркайчан да көньякны күргәне юк. Җырларда җырланган кипарислар нинди була икән? Ык буенда үскән талларга, зирекләргә охшаш микән? Диңгезнең шаулавын ишетү күңелдә, бәлки, яңа хисләр уятыр. Яңа шигырьләр туар. Курортта дәвалану ягына килгәндә, Фәнияр зур файда өмет итми. Дүрт ел урын өстенә ятып, хәрәкәтләнергә тиешлеген оныткан әгъзаларны нинди дер күкертле су, кайнар ләмнәр генә дәвалый алмас. Хәзер калган сәламәтлекне югалтмаска һәм әз генә хәрәкәтләнә торган төшне дә ныклап эшкә җигәргә кирәк. Ә иң мөһиме: уйлаудан, эзләнүдән, язудан туктамаска! Тәнең өчен акылың хәрәкәт итсен, аяклар урынына хыял йөрсен. Башка чара юк.

Көньякка китәргә өметләнеп ятса да, Фәниярга путевканы анда бирмәделәр. «Ерак җиргә җибәрү куркыныч. Беренчедән, озаклап утырып тора алмыйсың, икенчедән, бик кызу вакыт, климат ярамас», диделәр. Көньяктагы кебек күкертле сулар белән дәвалый торган курорт Татарстанның үзендә дә бар икән. Фәниярны шунда җибәрделәр.

Бар яктан да татар авыллары белән чолганып алынган «Күкертле күл» курортын Фәнияр бик ошатты. Табигать, саф һава, яшел чирәм шундый сагындырган. Утырган коляскана әйләнеп тә карамыйча, ялан аяк яшел чирәмнән йөгерәсе килә. Нишләптер Фәниярда йөрисе килү теләге табигать белән икәүдән-икәү калган очракта көчәя. Ул кечкенә чакта күккә ак юл сызып узган самолетларга, урамдагы каз бәбкәләрен куркытып, выжлап үткән машиналарга соклана иде. Ә хәзер җиргә дөп-дөп басып йөргән кешеләргә кызыга. Бу кызыгу элекке шикелле хыялый, ашкындыргыч түгел, бәлки йөрәкне кыса, әрнетә торган кызыгу. Сабый чакта синең бөтен тормышың алда була. Шуңа күрә һәрбер теләгәнеңнең тормышка ашачагына ышанасың. Ә хәзер ул ак каеннар тезелеп утырган аллеялар буйлап йөри дә, елга дулкыннарын кыйный-кыйный йөзә дә алмаячагын белә. Шул нәрсә аның бәгырен үтмәс пычак белән туктаусыз кискәләп тора.

Шулай да Фәниярга монда больницадагыдан күңеллерәк иде. Килгәненең икенче көнендә үк анализлар алдылар һәм егетне яңача дәвалый башладылар. Беркөнне күкертле ваннага чумдыралар, икенче көнне ләмгә күмәләр. Әзрәк хәл алып өлгерүгә, массажы, физкультурасы көтеп тора. Тын алырга да вакыт бирмиләр. Дәвалау физкультурасы белән шөгыльләнүче кыз Асия Фәниярга бигрәк ныклап тотынды. Физкультура кабинетына күтәреп кертеп сала да:

— Әйдә шуыш, үрмәлә. Җиде кат тирең чыксын. Бүтәнгә файдасы тимәсә, ашау үтәргә әйбәтрәк булыр, юкса ашавыңның рәте-чираты юк. Чыпчык хәтле дә ашамыйсың,— ди.

— Ә беләсезме? — ди Фәнияр,— чыпчыклар көненә үз авырлыкларыннан күбрәк азык ашыйлар икән.

Физкабинетның бөтен идәненә калын матрац җәелгән. Бер башында үлчәү тора. Фәнияр шул үлчәүне немец танкысы итеп күз алдына китерә, үзенчә шуны «шартлатырга» тырыша. Ләкин дүрт-биш адым озынлыгындагы идәннең бер башыннан икенче башына шуышыр өчен көне буе таш кискән кадәр көч сарыф итә. Алай да үлчәүгә барып җитә алмый. Аякларыннан меңләгән җен-пәриләр тарта диярсең, шул кадәр авыр. Ә Асия ял бирергә уйламый да. Идәнгә бер кап шырпы таратып ташлый һәм шуларны берәмләп җыярга куша. Һәркөн шулай дәвам итә.

...Фәниярның шигырьләр язуын, курортта дәваланып ятуын каян ишеткәннәрдер, бер көнне аның янына укучылар килде.

— Фәнияр энем,— диде укытучылары,— без сезнең хәлегезне белер-

гә, яраса эзрәк концерт күрсәтергә килдек. Ләкин без бик күп, бүлмәгезгә генә сыймабыз.

— Ә мин үзем чыгармын,— диде Фәнияр, шатланып.

Няняләр аны киендереп колясками утырттылар һәм тышка чыгардылар.

Балалар Фәниярнең газета-журналларда басылган шигырьләрен ятлап килгәннәр икән. Һәрберсе сөйләп күрсәтте. Аннары бер малай баянын тартып жибәрде. Ул үзе дә баян кадәр генә. Ләкин бармаклары төймәләр өстендә тигез йөгерә. Гармунчы бию көен уйный башлауга, ике кыз тупырдашып биергә тотынды. Сәхнәдәге кебек, алдан кемнең ни башкарачагын әйтеп торучы да булмады. Һәммәсе бик табигый һәм күңелле чыкты. Соңыннан хор белән жырладылар. Пионерларның «ду» кубарып, бер кешегә концерт куюларын күреп, курорттагы башка авырулар да шул төбәккә жыелдылар.

— Ни өчен бу егеткә шундый почет? Кем ул? — диештеләр. Аларның сорауларына жавап биргәндәй, укучылар бертавыштан:

— Фәнияр абый, безгә яңа шигырьләрегезне укыгыз әле,— диделәр. Фәнияр ялындырып тормады. Тамагы карлыкканчы шигырь укыды. Пионерларның сораулары бик күп иде, тиз генә таралырга теләмәделәр. Сорау арты сорау яудырдылар.

— Шигырь ничек языла ул? — дип сорады бер кыюы.

Шау-шу тынып калды. Күрәсең, бу сорау барчасын кызыксындыра иде.

— Бик кыен сорау бирдегез әле сез, дуслар,— диде Фәнияр.— Башка шагыйрьләр ничектер, мин үзем шигырьне язарга кулга каләм алганчы озак уйланып ятам. Менә әле мин сезгә «Кечкенәдән калган гадәт» дигән шигырь укыдым. Яхшымы ул, начармы — анысын сез әйтерсез. Ә ул шигырь болай туды...

Кечкенә чакта әнкәй миңа бер пальто сатып алды. Кулларны тыгып йөрергә ике ягында тирән-тирән кесәләре бар. Якасы да бик шома. Гажәп шәп инде. Жәй көне булуга карамастан, пальтоны кидем дә урамга йөгердем. Анда мине малайлар сырып алдылар. Минем пальтома алар да сөенделәр. Безнең якта яңа нәрсәне котлау гадәте бар. Мин дә күрше-тирәләргә кереп, пальтоны котлатып йөри башладым. Кергәне берсе:

— И, кем малае бу? — дип, миңа гажәпләнеп карыйлар һәм аркамнан сөеп:— Яңа пальто кигәч, танымый да торам үзеңне, Фәнияр икәнсең,— дип, кесәгә конфет-прәннек яки пешкән йомырка салалар. Аларның конфетларына караганда минем пальтомны мактаулары, аның өчен сөенүләре күңелемне куандыра. Кергән бер кешедән үсеп, канатланып чыгам. Күбрәк кешегә күрсәткән саен шатлыгым арта. Ә соңыннан кесәдәге конфет-прәннекләрне, йомыркаларны бөтен малай жыелышып ашыйбыз. Тәмлерәк күчтәнәчләрне малайларга бирергә тырышам. Алар минем пальтоны мактый-мактый кесәне бушаталар. Ә мин ашамасам да шат.

Менә шушы шатлыгымны кешеләргә сөйлисе килү элеге шигыремне язарга ярдәм итте. Уйлый торгач, мин кечкенә вакыттагы гадәтемнең үзгәрмәгәнен белдем. Хәзер инде мин яңа киемнәремне түгел, яңа шигырьләремне кешеләргә күрсәтергә ашыгам. Кечкенә генә шатлыгымны да кешеләргә сөйлисем, үзем белән аларны да сөендерәсем килә. Кешеләргә сөйләгән саен сөенечләрем арта сыман...

## XIX

Фәниярнең курорттан китәр көннәре дә якынлашып килә. Ләкин кая барырга? Казанда торыр урыны юк. Ел буе ятып, тәмам туйдырган больницаны исенә төшерсә дә калтырана башлый. Больницада терелүгә

таба барган кешене генә яраталар. Фәнияр ишеләргә «урын биләүче» дип кенә карыйлар. Авылга китсә — бөтенесе юкка чыга. Ә бит аның хыяллары зур: югары мәктәп тәмамлап, кешеләр алдында кызармаслык әсәрләр иҗат итү. Авылда институт та, язучылар да юк.

Ул Казан больницасына килү белән шәһәрдән үзенә берәр бүлмә бирүләрен сорап гариза язган иде. Аннан соң бер ел вакыт үтте. Ә бүлмә һаман булырга охшамый. Нишләргә? Кемнән киңәш сорарга? Илдус Гаделшинны да туйдырып бетергәндер инде. Алар үзләре дә бер бүлмәдә дүртәү яшиләр. Гомер буе шәһәрдә торган кешеләр дә шундый кысан фатирларда яшәгәч, авылдан килгән исемсез-эшсез малайга кем квартира тоттырсын?

Күп уйлый торгач, «кая кайтыйм» дип, Язучылар союзына телеграмма суктырды. Ана бер-ике айдан квартира вәгъдә итүләрен, шуңарчы больницада ятып торырга туры киләчәген әйтеп җавап бирделәр. Бүлмә дигән нәрсәнең чынлап булачагына ышанып җитмәсә дә, тагын больницага кайтты ул. Хәзер аны дәваламадылар. Фәнияр Илсөягә хәбәр җибәрде. Ә кыз килгәч:

— Илсөя, миңа китаплар кирәк. Университетка әзерләнә башларга иде исәп,— диде.— Шушы бер ай эчендә әзерләнмәсәм, бер елым юкка чыгачак.

— Сиңа ял итәргә иде,— диде Илсөя.

Кыз Фәниярны курорттан терелеп кайтыр дип көткән иде, өмете акланмады. Тормыш рәхимсез шул. Эш сорап куллары кычыткан, яңа юллар ярыр өчен йөрәге атлыгып торган кешеләрне шәфкатьсез рәвештә ега да ташлый. Ә эшкә кулларын тыгарга чирканып, җинел кәсеп эзләүче кайберәүләр сәламәт йөриләр. Яшен агачның биеген суга. Җил искән саен бөгелеп, яшенле яңгырлар вакытында зур агачлар ышыгына яшеренгән сыек үсентеләргә берни тими. Ә Фәнияр, авыруына уч иткәндәй, бернигә карамыйча, алдына куйган максатына баруын дәвам итә. Тормышка ул теше-тырнагы белән ябышкан. Кешеләр ярдәменнән башка әйләнеп тә ята алмаган килеш университетта уку турында хыяллана. Булдыра алырмы? Хәлсезләнеп, түземе җитмичә кире сыгылып төшмәсме?

Университетка керү имтиханнарын больницада тапшырырга туры килер дип ята иде Фәнияр. Көтмәгәндә Илдус Гаделшин аңа шатлыклы хәбәр китерде.

— Давай, Фәнияр туган, миңа паспортыңны бир, ышаныч кәгазе яз, бүлмәңә ордер алырга барам,— диде ул.

Фәнияр шатлыгыннан сикереп торырдай булды. Ләкин иртәрәк сөенгән икән. Паспорты юклыгы исенә төште.

— Ә минем паспорт юк, Илдус абый. Армиягә киткәндә военкоматта алып калганнар иде.

— Паспортыңны тапшырганда берәр справка биргәннәрдер бит.

— Биргәннәр иде. Югалмаган булса, авылдадыр.

— Алайса хәзер үк авылга телеграмма сугарга кирәк. Бөтен документларыңны җыеп әниең килсен. Квартирада син ялгызың гына яши алмыйсың бит инде.

Шул ук көнне хәлне аңлатып авылга телеграмма җибәрделәр. «Улым кайда — урыным шунда» дип өйрәнгән Гөлсәйдә түти ике көннән килеп тә җитте. Ләкин көтелгән документлар гына булмады. Белешмә каядыр юкка чыккан. Гомер буе авылда көн күргән Гөлсәйдә түтинең дә бернинди документы юк иде. Улы белән икесенә Фәниярның метрикасыннан башка һичнинди язу-фәлән тапмадылар. Илдус, ни булса булыр дип, Фәниярдан ышаныч кәгазе яздырып алып, больницада раслатты да үз паспортын тотып шәһәр башкарма комитетына китте. Анда артык төпченмәделәр тагын, ордерны биреп җибәрделәр. Кулына

ордер һәм квартира ачкычы бирелгәч. Фәниярның бер генә көн дә больницада ятасы килмәде...

— Әйдә, алып кайтыгыз мине,— диде ул энисенә.

— Анда берни дә юк бит әле, балам,— диде Гөлсәйдә түти.

— Миңа бернәрсә дә кирәкми, бер карават, бер мендәр булса җитә. Кухнясына газ кермәгән, туалетына ванна куелмаган. Анда кайтып нишләмәкче буласың? — диде Илсөя дә, ананы яклап.— Юасы, җыештырасы бар.

— Яңа йортның нәрсәсен юасың, нәрсәсен җыештырасың аның? — диде Фәнияр.

— Без апа белән барып карадык инде,— диде Илсөя.— Түшәме алакола. Тәрәзәләренә буяу каткан.

Фәниярны тагын берничә көн түзәргә күндерделәр.

Илсөя үзенең ике иптәш кызы белән яңа квартираны җыештырырга килде. Алар тизелештә эшләп, һәммәсен өйрәнеп беткәннәр. Гөлсәйдә түтинең кулына чүпрәк тә тоттырмадылар. Кырдылар. Юдылар. Агарттылар. Ә Гөлсәйдә түти кулына эш тапмыйча:

— Тәуфыйкларыгыз арткыры, мин ни эшләем соң? — дип, кызларга карады. Иләшкән авыл өендә булса һәммәсен белеп сыдырып эшләр иде, әмма монда су краның ачарга да курка ул. Ә үзе эченнән генә: «Ходайга шөкер, газы юк. Анысына ничек тотынырыең», дип йөри.

— Син алайса безгә квас алып кайт,— диделәр кызлар.

Илсөя юлны өйрәтте:

— Юл буенда олы арбага салынган чан булыр. Чанга сары хәрефләр белән «квас» дип язылып куелган.

Гөлсәйдә түтинең андый чан салынган арбаларны күргәне бар иде. Илсөя алып килгән бидонны күтәреп җәһәт-җәһәт чыгып китте. Кызлар кызу эшләп сусаганнар иде, Гөлсәйдә түтине түземсезлек белән көтеп алдылар. Илсөя хәтта пошынып та өлгерде:

— Әллә адашты микән?

— Адашмас, алай бик төшеп калганга охшамый,— диделәр кызлар.

Ниһаять, Гөлсәйдә түти тирләп-пешеп кайтып керде:

— Кеше шундый күп. Бөтенесе ир-ат. Эчәләр дә китәләр, эчәләр дә китәләр. Анда ике арба икән. Берсендә кеше-фәлән югые. Бусыныкы тәмлерәктер дип, кешеләр алган җирдән алдым,— дип сөйләнде ул.

Өйдә чынаяк ише нәрсә булмаганлыктан, күтәреп кенә эчәргә калды. Иң беренче булып Илсөя эчте.

— Әчәч! Әллә нинди тәмсез квас бу! — дип кычкырды ул бар көченә.

Тегe кызлар да эчеп карадылар һәм икесе берьюлы:

— Квас түгел, сыра бит бу,— диделәр.

Өчәүләп идәнгә тәгәри-тәгәри көлделәр.

— Вәт молодец, апа, өмәдә квас эчеп тормыйлар, сыра апкайтуың әйбәт булган.

— Китер әле бидонны, тагын берне күтәрик.

— Сыйлангач сыйланыйк инде.

Кызлар уйный-көлә сыраны эчтеләр. Гөлсәйдә түти генә уңайсызланып торды. Аның һәр әйберне кешеләр чират торган җирдән алу гадәте бар иде. Бервакыт Октябрьск шәһәренә катык сатарга баргач, чиратта кагылып-сугылып камыш себерке алып кайткан иде. Нәрсәгә безгә себерке, үзебездә дә почмак саен бит, дигәч, кешеләр ала бит, дип җавап бирде.

Кызларга сыра ошады. Эчкәч кызарыштылар, сүзчәнләнделәр. Берсе җыр сузып җибәрде. Аңа башкалар кушылды. Тегеләрнең кәефе күтәрелгәнен күргәч, Гөлсәйдә түти дә җиңел сулап куйды.

Бүлмәне кызлар әйбәтләп тазарттылар. Илсөя Гөлсәйдә түтине

узләренә кунарга алып китте. Гөлсәйдә түти, идәндә дә йоклармын, бармам инде, дип матәшкән иде, әмма Илсөя аның ай-ваена карамады:

— Синең идәндә йоклар чагың үткән инде,— диде.

Фәниярга кайбер нәрсәләр алырга Язучылар союзыннан йөз сум акча бирделәр. Гөлсәйдә түти белән Гаделшин йорт җиһазлары сатыла торган кибеттән ул акчага бер өстәл, ике тимер карават һәм берничә урындык сатып алдылар. Гөлсәйдә түтинең үзенең дә бераз байлыгы бар икән: аңарга түшәк-ястык, бераз савыт-саба юнәттеләр. Шуннан соң Фәниярны больницадан алып кайттылар. Кысан больница палаталарында ятарга күнеккәнлектән, унсигез квадрат метрлы бүлмә Фәниярга искиткеч зур булып тоелды.

— Ниһаять, әнкәй, безнең дә үз куышыбыз булды.

— Яңа йортта яңа бәхетләр насыйп булсын, балам...

...Университетка имтихан тотар вакыт та житте. Фәнияр шундый зур уку йортына керә алырмын дип уйламаган иде. Тырышкан табар, ташка кадак кагар, диләр бит. Әзерләнде, тырышты егет. Ә кабул итү имтиханнарын алырга аның өенә килделәр.

Университетта уку Фәниярга ялгызлыктан котылу өчен дә әйбәт чара иде.

Тормыш бераз эзгә төште. Күңел басылды. Иркенләп язарга, укырга мөмкинлек туды. Больницадагы кебек, янында ыңгырашып ятучылар юк. Теләгән вакытта торасың, теләгәндә ятасың. Башыңа берәр матур уй килсә — язып куясың. Ут яндырганга, кәгазь-каләм кыштырдатканга сыкрап-сыктап ятучылар юк. Карарга әнисе бар...

Аналарның бөтен мәхәббәте, бөтен җылысы ярдәмгә мохтаж балаларга тиючән. Фәнияр да бу хакта белә: язмыш нык кыерсыткан саен әнкәсенең якынлыгын күбрәк тоя ул. Ананы дөньяда һични алыштыра алмый. Ул — кешелекне тотып торучы алтын багана.

Әмма яшьлек ярсуыннан тау чишмәседәй ургып торган йөрәккә ана назы гына аз, ана кайгыртуы гына житми. Күңел үзенең ишен эзли. Куанычларын булганда бергә куанырлык, кайгы-хәсрәт килгәндә — юатырлык, егылганда кул сузарлык, ялгышканда төзәтерлек, эшләп арганда иркәләрлек, назга сусаганда кочагында эретерлек кеше табасы килә. Ә Фәнияр кебек кешеләргә мондый иш табу кыен эш. Шуңа күрә ул үзенең авыруын капларлык эшләр башкарырга, тормышта яшьтәшләреннән бер як белән дә калышмаска теләп, туктаусыз көрәшә.

Көрәш ул сабан туйларында кулыңа тастымал урап, кемнәрнеңдер биленнән алу гына түгел. Тормыш өзлексез көрәштән гыйбарәт: көчлеләр ега, көчсезләр егыла.

Фәниярга бер генә җиңүнең дә көрәшсез килгәне юк әле. Кулларына каләм тотып бер юл шигырь язар өчен дә, замандашларыннан артта калмаска теләп тырышып-тырышып уку да, хәтта мәхәббәт өчен дә көрәшергә, язмыш куйган ятьмәләрне ертырга кирәк. Фәнияр яшендәге кешеләргә мәхәббәт күп вакыт үзеннән-үзе бирелә. Кыз һәм егет очрашалар, танышалар, кавышалар. Дини карашлар да, миллэт аермасы да — берни дә киртә була алмый. Кешеләр йөрәгенә табигать тарафыннан салынган байлык — мәхәббәт — башкалар өчен вакыты җиткәч киләргә тиешле нәрсә булса, Фәниярга яулап алынасы, көрәштә табыласы бәхет. Бары үзенә генә кагылган эштә Фәниярнын сынатканы юк, ләкин мәхәббәттә ике кеше катнаша. Монда инде һәр ике якның тигез тартылуы кирәк. Шунсыз көчәнү файдасыз.

Фәниярның Илсөя белән ныклап сөйләшәсе, мөнәсәбәтләренә ачыклык кертәсе килә. Билгесезлектә яшәү тәмам туйдырды: тәгәрәп үләрлек булса да ачык белсен. Яшисе көн, башланмаган гомер бар. Һаман

саен ялгызын тору кыен. Дөрес, бер караганда Фәниярның мәхәббәткә, семья бәхетенә хакы юк кебек. Ул укыган китапларда аның язмышына тарыган кешеләр үзләренең яраткан ярларын яннарыннан куалар, аларны бәхетле итәргә телиләр. Ләкин Фәнияр алай эшли алмый. Беренчедән, эштә генә түгел, шәхси тормышта да башкаларга тиңләшәсе килә, икенчедән, янында якын кешесе булганда гына көчле ул. Фәнияр үзен күп тапкырлар сынады инде: ялгыз калдымы — үзенә булган ышанычын югалта, авырайган башын кая куярга белми, газаплана, бөргәләнә, авыртмаган җирләре авырта башлый.

Кеше күңеле корыч булса — ялгызлык тутык булып ябышырга әзер. Фәниярнең курыккан дошманы — ялгызлык. Бер караганда үзе ялгыз калмас өчен башка кеше тормышын бозу эгоистлык кебек. Ләкин Илсөя дә Фәниярны яратса, нигә ике яратушкан йөрәк аерым сызарга тиеш? Мәхәббәтнең бит тылсымлы көче бар: ул һәркемне тигезли. Картларны яшәртә, ямьсезне матурлый, көчсезгә көч бирә. Яраткан кешең синең күзеңә иң яшь, иң таза һәм иң матур булып күренә. Күңелеңне аннан да яхшы кеше юклыгына ышандырсаң, һичнинди кимлек тоймыйсын.

Фәнияр бәхетне шулай күз алдына китерә: яратышкан кешеләрнең гел янәшә барулары. Кеше бәхеткә комсыз ул. Әле кайчан гына Фәнияр үзем язган шигырьләрне газетада күрсәм, үлсәм дә үкенмәс идем дип ята иде. Хәзер аңа ул гына җитми. Инде иңгә терәп баручы гомер юлдашы кирәк.

Илсөя Фәнияр янына еш килә. Китапханәләрдән китаплар алып кайта, университетка контроль эшләр илтә. Машинкада басарга да өйрәнеп өйрәнеп маташа. Шулай үзеннән-үзе Фәниярның секретарена әйләнеп китте ул. Соңгы вакытларда Фәнияргә хатлар да күп килә башлады. Кайсы үзенең шигырьләрен җибәрә, кимчелекләрен күрсәтүне сорый, кайсы киңәш-табыш итешә, кайсы — кирәк очракта ярдәм кулы сузарга әзер икәнен белгертә. Барысына да җавапны Фәнияр үзе язып өлгертә алмый. Илсөягә нәрсә язарга икәнен әйтеп торасы юк, үзе белә.

Беркөнне, һич уйламаганда, Фәүриядән хат килеп төште. Хат шактый калын, озак йөреп конверты таушала башлаган. Чөнки Фәүрия Фәниярның адресын белмәгәнлектән, аны Язучылар союзына җибәргән. Бераз Союзда аунап ятканнан соң гына Фәнияр кулына килеп керде ул.

«Фәнияр, мин бу хатны бик күп уйланулардан соң язарга булдым,— дип башланып китә хат.— Бервакыт районнан яңа китап-журналлар алып кайттым. Казанда чыга торган журналның яңа санын ачып карасам, синең рәсемеңне күреп исем китте. Шигырьләреңне һәм синең турыда язылган очеркны тын да алмыйча укып чыктым. Аннары журналга капландым да үксеп еларга тотындым. Күңел әллә нинди үкенүле, әрнүле хисләр кичерде. Мин бит синең хыялларыңны, омтылышларыңны вакытлы бер юләрлеккә санап йөрдем. Турникта «кояш» ясарга теләп егылып төшкәч, кайчандыр сиңа сөйләгән экиятемдәге «хыялый чебеш» кебек булып күрендең. Ә бит син үзеңнең «кояш»ыңны барыбер ясагансың, Фәнияр. Син егылып түбәнгә төшмәгәнсең, югарыга күтәрелгәнсең».

Фәүрия үзенең тормышы турында озын итеп һәм тәфсилләп язган. Иргә чыгуын, иптәшенең укытучы булуын һәм бик семья җанлы кеше икәнлеген әйткән. Үзе башкорт авылларының берсендә китапханәче булып эшли икән. Хатын ул болай тәмамлаган: «Мин үземне бәхетле дип тә, бәхетсез дип тә саный алмыйм. Бер караганда бөтенесе дә бар төсле: семья, бала, эшем. Ләкин миндә ашкыну юк: өйдә булсам, эшкә дип атлыгып тормыйм, эштә икәнмен — өйгә тиз генә кайтасым килми. Бөтен нәрсә эчпошыргыч. Күрәсең, матур итеп хыяллану, ашкына белү сирәк кешеләргә генә бирелә торган талант шикеллерәк нәрсәдер. Хәзерге вакытта синең янәшәңдә булсам да, таянычыңа, көч бирүчеңә әйләнә алмас идем. Шигырьләреңә караганда, син үзеңә тиң кешене

тапкансың бугай. Кавышмаган булсагыз, кавышып, бәхетле яшәвегезне телим. Син бәхеткә лаек кеше, Фәнияр. Сәлам белән Фәүрия».

Илсөягә Фәниярның Фәүрия турында сөйләгәне бар иде. Хатны бергәләшеп укыдылар. Бу хатны укыгач, сүз үзеннән-үзе мәхәббәт хакында башланды. Фәнияр уңай чак туры килүгәме — кыюланып китте һәм әллә кайчаннан бирле үзен тынычсызлаган сорауны бирде:

— Илсөя, синнән шуны күптәннән сорарга җыенам. Син мине кызганып кына килеп йөрисеңме, әллә...— Фәнияр сүзен тәгәлли алмады, Илсөя аңа шундый итеп карады, егет ачылган авызын ябарга онытты.

— Кызганыч кешеләрне вообще мин яратмыйм,— диде Илсөя.— Кызганыч кеше янында яшь түгәләр, ах-ух килеп утыралар. Ә синең өйдә тормыш кайный. Больницаларга йөргәндә синең палатага керергә чиратка баса идек. Әллә син үзеңне кызганудан шулай булгандыр дип уйлыйсыңмы? Мескеннәр больницада азмыни? Берсенә дә үз туганнарыннан башкалар килми. Мин хәтта синең янында озак утыручылардан көнләшә идем. Әчкә үтәргә ак халат эләктерсәм, әллә нинди байлык тапкандай куана идем...

Илсөя шулай кызып сөйләп китүенә кыенсынып туктап калды. Ләкин әле ул күбесен әйтми калды. Фәнияр янына керергә уңай булсын өчен ак халат тектерүен, сәламәтлек хакында язылган барлык газета-журналларны укып баруын, зур профессорларга консультацияләргә йөрүен, Мәскәүләргә хат язуын сөйләп тормады. Медицинага кагылышлы китаплар укып, профессорлар белән киңәшеп йөри торгач, үзе медикка әйләнеп бара инде. Фәниярнын нинди бәлага тарыганын да яхшы белә ул хәзер.

Кызып-кызып үзен яклавын күргәч, Фәнияр сөенеп куйды.

— Алайса, Илсөя, син мине башка кешеләрдән кимгә санамыйсың? — дип сорады ул.

— Сәламәт кешеләрнең дә бик әзләре генә эшли торган эш эшләүче, шуның өстәвенә, иң зур вузларның берсендә укып ятучы кешенең кай җире ким булыр икән? — диде Илсөя.

— Тормыш бит әле эштән генә тормый, Илсөя. Һәркемнең әчке дөньясы, семья бәхете булырга тиеш. Әгәр мин берәрсенә: икебез бер тәртәгә җигелеп, тормыш йөген парлап тартыйк дисәм, ул кеше кимсенмәсме? Менә бит тормышның кай яклары бар. Мин әзгә генә риза түгел, Илсөя. Корбан теләмим, үзем кебек көчле яратуларын телим. Минем белән яшәгән кешегә икеләтә авыр булачак. Кешеләр төрле-төрле бит. Гайбәт ишеттерүләре мөмкин, нахак сүзләр дә. «Их, мескенкәем, башка кеше тапмадыммыни, әллә берәр гөнаһың бар идеме?» диючеләр дә очрамый калмас.

— Минемчә,— диде Илсөя,— тормыш корырга ризалык биргән кеше аларына түзәргә тиештер.

Бу әңгәмәнең юкка гына башланмавын белә Илсөя. Үзенең дә ул хакта күп тапкырлар уйлап караганы бар. Җавап кына таба алганы юк.

— Әгәр, Илсөя, мин сиңа, гомерлеккә яныма кил дисәм, нәрсә әйтер идең?

Иң зур сүз телдән ычкынгач, Фәнияр тын да алмый туктап калды. Йөрәге бөтен өйгә ишетелерлек булып типте. Күзләр өмет, ялвару, ышаныч, икеләнү белән Илсөягә текәлде. Бу минутта ул соңгы шырпысын сызган юлчыга охшаш иде.

Илсөянең җавабын түземсезләнеп көтте Фәнияр.

— Эш миндә генә түгел бит, Фәнияр,— диде Илсөя, ниһаять.

Кыз ни дияргә үзе дә белми. Фәнияр аңа якын, ягымлы. Аның янына килмәгән көннәрне үткәреп җибәреп булмый: озын, күңелсез. Эштә әз генә уңышы булса да Фәниярга тизрәк сөйләргә ашыга. Борчуларын да яшерми Илсөя. Мондый чакта Фәнияр үзенең я берәр шигырен укып җибәрә, я тормыштагы шуңа охшашлы вакыйганы сөйләп ала. Юату

сүзләре әйтмичә, үзеннән-үзе тынычландырып куя. Илсөя беркем янында да болай ачылып сөйләшә алмый. Бәлки, ярату шулдыр? Яраткан кешеңнең кимчелекләрен күрмисең, диләр. Фәнияр Илсөя өчен барлык таза кешеләрдән тазарак, барлык көчлеләрдән көчлерәк. Илсөя Фәнияр белән яши алыр кебек. Гомер буе икеләнеп, кайсы агачка арка сөяргә белмичә йөри алмас. Әнисе дә күптән: үзем дөнья куйганчы сине башлыкүзле итәргә иде, дип тукый. Төзелештә эшләүче яшь инженер Котдус та артыннан калмый йөдәтә. Инде әллә ничә тапкыр Илсөяләрнең өйләренә килде. Әнисенә Котдус бик охшый. Илсөя эштән кайтып керде исә: «Кызым, өс-башыңны алышыбрак куй, кеше-кара килүе бар. Син гел чыгып югаласың, әзрәк өйдә торырга иде»,— дип, кызының кола‑ гына киртеп куя. Ә Илсөя әнисе әзерләгән ризыкларны аннан-моннан капкалый да чыгып китә. Әнисе, туганнары Фәниярга чыгуга риза булмаслар, билгеле. Ләкин аларга әйтми эшләп булмый. Ана фатихасы белән яшәү җиңелрәк. Үзеңне тудырып үстергән кешене рәнҗетәсе, кайгыга саласы килми.

Ә беркөнне әнисе тормышка чыгарга вакыт чкәненә ишарәләгәч, Илсөя үзенең дә моны уйлавын, әнисенә әйтергә генә кыймавын белдерде.

— И кызым,— диде әнисе,— оят эш түгел инде ул. Егерме өч белән барасың. Ялгыз кыз — даладагы каз, диләр.

Ана кешенең күз алдында торганы инженер Котдус булганлыктан, егетне мактый ук башлады.

— Бик әдәпле, бик игелекле бала күренә, бәхетсез булмассың. Саран бәндәгә дә охшамаган. Килгән саен кучтәнәчен-ниен кыстырып алып килә.

— Кемне әйтәсең син, әни? — диде Илсөя, аңламаган сыман.

— Һи, кемне дип сорап торган буласың. Үзегез белән эшләүче инженер Котдусны әйтәм. Шул бит инде ике сүзнең берендә Илсөя дип тора. Үзегез сөйләшкәндерсез инде, миннән генә яшереп маташуыңдыр.

Илсөя әнисенең хәтерен калдырмаслык сүзләр эзләде. Кызының Фәнияр янына больницага барып йөрүен белә иде ана белүен. Әмма янына йөрү бер нәрсә, тормышка чыгу бөтенләй башка бит. Әнисенең йөрәге бик начар, шатлыклы хәбәрне кинәтрәк ишетсә дә, егылып китәргә тора. Моны күтәрә алырмы?

— Әни, мин Котдуска чыгарга җыенмыйм бит әле,— диде кыз.

— Кемгә соң?

— Фәниярга.

— Аның кем тагын?

— Соң, әни, сөйләгәнем бар бит инде, шундый-шундый авыру шагыйрь янына барып йөрим дип. Әнисен бервакыт кунарга да алып кайткан идем.

Ананың әйтерсең көтмәгәндә тез астына китереп типтеләр. Чайкалып китте. Хәлсезләнеп идәнгә чүкте. Илсөя тотып калмаса, егылып ук китәр иде.

— И балакаем,— диде ана һәм елап җибәрде.

Нинди кыен чакларда да яшьле күзләрен яшереп йөрткән әнисенең тәгәрәп-тәгәрәп төшкән яшьләрен күргәч, Илсөя аны кызганды. Юатасы, тынычландырасы килде. Ләкин ничек итеп тынычландырырга? Монда юату сүзенең файдасы юк. Бары тик: «Әни, мин шаярдым бит, берниндн Фәниярга да чыкмыйм», дисә генә әнисе тынычланыр. Ләкин Илсөя алай итә алмый. Бер яктан, Фәниярның мәхәббәте, икенче яктан, әнисенең хәсрәте уйга салды кызны. Ул Фәниярны якларга теләп:

— Әни, син аны күргәнең юк әле, күрсәң үзең дә яратырсың,— дип сөйләнде.— Инженер Котдусларыңнан болайрак кеше ул. Заманында космоска очарга хыялланган. Таза булса, бәлки, Титовлар урынына ул очкан булыр иде. Хәзер дә аның һәр көне батырлык.

— Шулайдыр да бит,— диде бераз хәлләнә төшкән ана.— Батырлыкны култыклап йөреп тә, кочаклап ятып та булмый шул. Тормышта бөтенесе дә кирәк: гомерең буе парлашып урамга чыга, кешегә бара алмассыз. Гелән-гелән ялгызың йөрү туйдырыр, бикләнеп өйдә ятасың да килмәс. Ирләр имән булырга тиеш: яңгыр яуса — ышыкласын, кояш көйдерсә — күләгәсенә кертсен.

— Анысы шулай,— диде Илсөя, әнисе белән килешкәндәй итеп.— Ләкин мин, әни, Фәниярны нәкъ менә шундый имән итеп күз алдына китерәм дә. Хәтта аннан да артыграк. Бер агач төбендә бернечә кеше генә ышык тапса, Фәнияр меңләгән кешеләрне ныклыкка өйрәтә. Аңарга килгән хатларны укып карасаң иде син, кемнәр генә язмый аңарга. Берәүләр аның шигырьләрен укып зур шатлык кичерүләрен, икенчеләр рухи яктан ныгып китүләрен әйтәләр. Өченчеләр Фәниярдан ярдәм сорап язалар. Ә бит көчсез кешеләрдән ярдәм сорамыйлар. Әйе, без аның белән култыклашып кино-театрларга йөри алмабыз. Эш анда гынамыни, әни!

Фәнияр көчле кеше, әмма көч бетми торган нәрсә түгел. Менә шушы көчен киметмәс өчен генә булса да аңа терәк кирәк. Ә мин аңарга шундый кеше була алырмын дип уйлыйм. Аннары, сиңа гаҗәп тоелса да, мин аны яратам. Үз шигырьләре белән меңләгән кешеләрнең күңелен табучы, юатучы, рухландыручы, яшәргә өйрәтүче кеше миңа таяныч була алмасмыни?

Илсөя әнисен ышандырдым дип уйлаган иде, ләкин әнисе хәсрәтеннән түшәккә үк егылды.

— Үзеңнең дурацкий выходкаларың белән әнине кабергә тыгасың, кызый,— диде Илсөянең абыйсы. Авыру карыйсың килгәние, әллә каян эзләп йөрергә дә кирәкмәде. Кара әнә әнине. Янадан шул Фәниярларга барганыңны ишетсәм, җаныңны суырып алырмын...

Кыз ике ут арасында калды. Фәнияр якын, әнисе кызганыч. Фәнияр җавап көтәдер. Урын өстендәге әнисен ташлап аның янына бара алмый Илсөя. Бәлки Фәниярны онытып булыр?!.

Әйе, Фәнияр Илсөядән үзенең соравына җавап көтте. Әмма кыз юкка чыкты. Аның килмәвен Фәнияр үзенчә аңлады. Димәк, ул аны яратмаган. Кызганып кына йөргән. Ах, шул кызгану дигән нәрсә! Никадәр хурлый, кимсетә, түбәнсетә кешене! Хәер, яраткан очракта да Фәнияр кебек кеше белән кем инде тормышын бәйләсен?!

Бу язмыш дигәнең торган саен мәрхәмәтсез кылана. Сабый баланың кулына уенчык тоттырып, сабый шул уенчыкка күнеккәч, ярата башлагач кына тартып алган шикелле, Фәниярның иң кадерле нәрсәләрен йолкып ала. Җир өстенә бастырып, буразналарның йомшаклыгын, юл йөрүнең рәхәтлеген күрсәтте дә — ике аяксыз калдырды. Күкләргә күтәреп очу ләззәтен татытты да — зәңгәр күктән мәхрүм кылды. Сөю шәрабын эчерде дә сагыш диңгезенә ыргытты.

Кайгы егетне эчтән кимерде. Кемгә сөйләсен, энкәсенәме? Ул болай да барсын белеп тора. Мендәренә капланып бер үксер иде, күзләреннән яше чыкмый. Яшь түгеп үкси-үкси елый алу да бәхет, ахры. Кеше кайгы-хәсрәтне төрлечә китерә. Берәүләр аңардан, чабылган үләндәй, кинәт егылалар, икенчеләр яшен суккан агач кебек дөрләп яналар.

Кемгә дә булса хәтерең калса, җәберләсәләр — ул кешене авыз тутырып сүгәр идең. Монда сине җәберләүче дә юк. Барысына да үзең гаепле. Тормыштагы бер ялгышың гомер буе кара елан булып артыңнан сөйрәлеп бара. Аңардан һичничек котылырга мөмкин түгел.

Ярый әле — дөньяда эш бар. Ансыз кеше — сансыз кеше. Фәнияр да борчуларын эш белән куарга тырыша. Эшләре аның йокыдан уянуын көтеп кенә торалар. Зачетка, имтиханнарга әзерләнәсе, контроль һәм курс эшләре язасы, конспектлар төзисе бар. Шулар өстәвенә, бөтен тырышлыгын куеп имтиханнарга әзерләнеп ятканда башына берәр яңа

фикер килә дә һич тынгылык бирми башлый. Фәнияр укуын ташлап, күңелендә шытып килгән шул шигырь турында уйлана башлый. Кирәкле формасын, тиешле рифмасын табып ул шигырьне кәгазьгә төшерми торып, бүтән эшкә кулы бармый.

Ул йокыдан бик иртә уяна. Авылдагы гадәтләрен һаман ташлый алмый. Кечкенә чакта әнкәсе аны: «Тор, балам, тор, озак йокласаң, бәхетең ким булыр», дип уята иде. «Озак йоклаганга нишләп бәхет кимесен инде», дип уйлый Фәнияр. Шулай да әнисе кушкач тора. Йөгереп тышка чыга, ә анда тау артыннан тәгәрәп зур, якты кояш күтәрелеп килә. Кояш чыгуын күргәч, малай сөенә. Кояш бераз күтәрелә дә аларның өянке башларына утырып ял итә. «Шушыдыр инде ул бәхет», дип фикер йөртә малай.

Хәзер әнкәсенең шушы сүзләре исенә төшә. Чынлап та Фәниярның йокылы күзләрен уа-уа, таңнарны, җирне алтынга манучы кояшны күзәтүе, чык сулары кипкәнче үләннәрдә йөгерүе зур бәхет булган икән. Яшьтән иртә торырга, эш тәмен белергә, җир сулышын тоярга өйрәнмәсә, анарга шигърият каян килер иде.

Бер генә минутка да тынгылык бирми ул үзенә. Туктап тордыңмы — артка каласың. Болай да бөтенесен эшләп җитешә алмый. Язган шигырьләрен кат-кат күчереп тә арып бетә. Бармаклары эшләсә, машинкада басарга өйрәнер иде. Әллә соң берәр җайланма уйлап карарга мы? Шушы куллары белән кашык тотып ашарга, каләм тотып язарга өйрәнде бит. Башта кәгазьне күкрәгенә куеп яза иде. Соңыннан караватына куярга кыйгач өстәл ясатты.

Фәнияр үз алдына ничек кенә булса да машинкада язарга өйрәнергә максат куйды. Моның өчен ул «Т» хәрефенә охшаш ике таякчык ясатты. Таякчыкларны кулына резина белән бәйләтте. Башта ул коляскасына утырып эшләп карарга уйлады. Әмма утырып барып чыкмады. Беренчедән, коляска өстәлнең аяк араларына сыймый (ә Фәнияр мондый гади урындыкта утыра алмый иде), икенчедән, машинка клавишларына басарга дип үрелгән саен тәгәрмәчләр урыннарыннан кымшаналар да таякчыклар кирәкмәгән хәрефкә барып төртеләләр. Аннары Фәнияр көненә бер-ике сәгатьтән артык утыра да алмый. Димәк, яткан килеш язарга кирәк.

Үзенең кыйгач өстәленә машинка шуып төшмәсен өчен бер такта кадаклатып, урын өстендә язарга өйрәнә башлады ул. Аның маңгаеннан бәреп чыккан тирләрен күреп, әнкәсе:

— Улым, көчең житмәстәй эшкә тотынма,— дип кисәтте.— Нигә үзеңне җәфалыйсың?

— Бу барып чыкса, минем эшләр җиңеләергә тиеш, әнкәй. Мин бит һәр уйланган шигырьне унар кат язам. Башта дәфтәргә, редакциягә язарга дип күчерәм, нәшрият өчен яңадан әзерлим. Бер үк әйберне күчерә-күчерә дә ничаклы вакыт әрәм итәм. Ә машинкада теләсәң ничә катлап язарга була. Бәлки әле кул белән язуга караганда җиңелрәк булыр.

— Ай-һай. Бер дә булырга охшамый.

— Булыр, булыр, әнкәй. Мәскәү дә тиз генә салынмаган.

Шул кадәр үзсүзлелек, түземлек каян киләдер аның улына. Бу эш минем кулдан килми дип уйламый, мин моны эшләргә тиеш дип тотына. «Көчле белән көрәшмә, телчән белән сүзләшмә» диләр иде элек. Ә аның малае бөтенләй бүтәнне әйтә.

— Көрәшсәң көчле белән көрәш. Егылсаң да хурлык түгел,— ди.

Азаплана торгач машинкада басарга өйрәнеп килә бит тәки. Кәгазьне дә үзе кыстыра. Таякчыкларына да бераз үзгәреш керттерде. Аларның башы каты булганлыктан, клавишлардагы хәрефләрдән таеп-таеп китәләр, шуның өстенә хәрефләрне чокыталар иде. Таякчык башларына тимер кыршау кидертеп, кыршау эченә бетергечтән кисеп алынган

резинка тыгып куйгач, ике бәладән берьюлы котылды. Хәзе́р кызурак эшләргә өйрәнәсе генә калды. Яза-яза кызуланыр да әле. «Биючегә сүз әйтмәгез, бии-бии остара», диләр бит. Осталык, өлгерлек эштә килә.

— Син бу тырышлыгың белән тырышсаң, аягыңа да басарыең,— диде әнисе беркөнне.— Физкультураларыңны, хәрәкәтләнүләреңне бөтенләй ташладың.

— Алар белән маташырга вакыт юк бит, әнкәй. Аннары менә бу машинкада басу үзе физкультура инде. Файдасызга көч сарыф иткәнче, болай, ичмасам, ике эш берьюлы башкарыла.

Машинкада басарга өйрәнү Фәниягә зур уңайлык тудырды. Ул элек гел чалкан ятып кына яза иде. Ә аркасы белән озак яттымы — элекке яралары ачыла башлый. Хәзер ул машинкасын урындыкка куеп, кырын яткан килеш тә төрткәли. Эш тә бара, арка да ял итә.

Илсөянең килмәве генә эчне пошыра. Һич югында, соңгы сүзен әйтсен иде. Билгесезлектән дә авыр нәрсә юк. Кеше гел эш белән генә яши алмый бит. Тормышың шатлыклардан гына торганда да, шатлыкларыңны сөйләр кеше кирәк. Кешеләргә сөйләмәсәң, сөенечләр дә төссезләнә. Ә Фәниярнең тормышында шатлыкка караганда кайгы күбрәк. Каткан күңелен ул ничек эретсен соң? Фәнияр — янына килеп йөрүчеләргә шат күңелле, шаян сүзле булып күренә. Ләкин бит кешеләр аның ялгыз калган вакытын, төннәрен йоклый алмыйча башын мендәр асларына тыгуын күрмиләр. Кешеләр киләләр дә китәләр. Ә ул үзенең язмышы белән тагын ялгыз кала. Кайчан да булса моның ахыры чыгачагын белсә, көннәрне уздыруы җиңелрәк булыр иде. Шуңарга Фәнияр кыйнасалар да, тиргәсәләр дә риза, бары тик бөтенләй ташлап кына китмәсеннәр. Ә Илсөя, күрәсең, бөтенләй онытты. Хәтта Фәниярнең хатларына да җавап бирми.

Шундый еш килеп йөргән кызның кинәт кенә күзгә-башка күренми башлавы ананы да уйга салды. Улының Илсөясез яши алмавын, көннәнкөн сула баруын күреп, борчылуы икеләтә артты. Гөлсәйдә түти әллә ничә мәртәбә Илсөяләргә барып, ныклап сөйләшергә дип өйләреннән чыгып китте. Ләкин аларның ишек төбенә килеп җиткәч, ниндидер көч аны эчкә керүдән тыеп калды. Улына Илсөянең кирәклеген никадәр нык белсә дә, кызны үгетләргә, аңа нинди дә булса киңәш бирергә көче җитмәячәген аңлады.

Гөлсәйдә түти соңгы вакытларда үзендә ниндидер хәлсезлек, баш әйләнү сизә башлады. Элекке чагы булса мондый хәленә игътибар да итеп тормас иде, ләкин бер уй аның миен туктаусыз кимерә: миңа алай-болай булса, Фәнияр нишләр? Фәнияр үзе яратмаган кеше белән яши алмый. Моны ана яхшы белә. Юкса Фәнияр белән тормыш корырга теләүчеләр булмады түгел. Бу хакта бервакыт сүз чыккач: «Тормышта мин я үз теләгемә ирешергә тиеш, яки бөтенләй яшәмәскә»,— дип җавап биргән иде ул. Теләкләре артык зур шул. Буе җитмәслеккә үрелми микән? Шигырьләр язуы да үзенә гел борчу китереп тора. Я күңелсез хат язып җибәрәләр, я язучылар үзләре өйгә килеп тәнкыйтьләп китәләр. Үпкәләми тагын үзе. Бәләкәй чакта турсаерга гына тора иде. Холкы да үзгәреп бара. Хәзер Фәнияр йомарланган йодрык кебек. Эчендәген тышка чыгарырга ашыкмый. Борчымаска теләведер инде. Шулай да таяныр кеше тапмыйча йөдәгән, үзен кая куярга белмәгән чаклары күп була.

## XXII

Тормыш Фәниярны яңагына сугып аягыннан екса, чәченнән сыйпап кире торгызды. Илсөяне уйлап, газаплы уйлар дәрьясында тотынырга тал тапмый ятканда аңа сөенечле хәбәр китерделәр. Бу юлы да сөенеч хәбәрчесе Илдус иде. Ул алтын тавы тапкан геологтай куанып:

— Фәнияр туган, чыгып җитте бит көткән китабың,— дип, егеткә шигырьләр җыентыгын китереп тоттырды. Чүлләрдә сусаган кеше чишмәгә ташлангандай, Фәнияр китапка ташланды.

Беренче китап! Утыз биш-кырык шигырьне эченә алган, коймак калынлыгы гына җыентык. Күпме хезмәт, күпме тырышлык, күпме икеләнүләр кергән моңарга!

Игенче дә бит үз коймагын пешереп табынга куйганчы җирне никадәр кадерли: сөрә, тырмалый, чәчә. Яңгырлар яумый торса да, көннәр суытып җибәрсә дә кайгыра. Икмәге өлгерсә — җил екмасын дип тә, бөртекләр коелмасын дип тә пошына. Иген җыелып, табынга коймак булып килгәч кенә игенче борчылудан туктый.

Ә шагыйрь? Шагыйрь кулга китап кергәч тә тынычлана алмый әле. Укучылар ничек кабул итәрләр, китапның гомере озын булырмы? Әсәрләр кешеләр күңеленә хуш килерме?

Фәниярның шушы уйларын белгән кебек, Илдус:

— Китап, минемчә, матур чыккан,— диде.— Шигырьләр көчәнеп, бармактан суырып язылмаган. Уйландыра, тәэсирләндерә.

— Илдус абый, чынлапмы? — диде Фәнияр, куанычыннан нишләргә белмичә. Илдусның мактарга юмарт булмавын белгәнгә, аның сүзләре икеләтә кыйммәт иде.

— Шигырь сөючеләргә әйбәт бүләк булыр дип уйлыйм,— диде Илдус.

Ике шагыйрь ул көнне озак сөйләштеләр. Илдус Гаделшин, язган әсәрләргә карата һаман саен таләпчәнрәк булырга, канәгатьләнеп калмаска кирәклеген кабат-кабат әйтте:

— Син инде хәзер сигез класс бетереп килгән авыл малае түгел. Белемең, тәҗрибәң артты. Университетта укыйсың. Беренче китапка яраган таләп икенчесе өчен кечкенә була. Үскәнең, белемең артканлыгы шигырьләреңдә дә күренсен. Бездә күп вакыт үз-үзебезгә таләпчәнлек җитми. Урта кул шигырьләр язабыз да сөенеп йөрибез. Дөрес, Пушкиннар, Тукайлар сирәк туа...

— Мин Тукай була алмам инде анысы,— диде Фәнияр.

— Сиңа Тукай булу кирәкми дә,— диде Гаделшин.— Син Гатауллин бул. Кешеләргә үз тавышыңны, үз җырыңны ишеттер. Шунсы кыйммәт. Поэзиядә үзеңне табу, ай-һай, кыен. Хәтерләгәнең бардыр: дөньяда кешеләр һич тә бер-берсенә охшамаганнар. Сөйләшүләре, йөрешләре, тышкы кыяфәтләре, холык-фигыльләре, кыскасы, бөтен яктан аерылалар. Минемчә, шагыйрьләр дә шулай аерылып торырга тиешләр. Авторының исемен укымастан ук, менә бу шигырь нәкъ шул шагыйрьнеке диярлек булсын.

Илдус Гаделшин сүз тапмый утыра торган кеше түгел. Бигрәк тә әңгәмә әдәбиятка кагылышлы булса, шундый мавыгып китә, кеше бары үзенең бик якын дусты турында гына шулай бирелеп сөйләргә мөмкин. Югары белемле, берничә китап чыгарып шактый тәҗрибә тупларга өлгергән бу шагыйрь Фәнияр өчен чын-чынлап табыш булды. Аның барча сүзе, комга төшкән яңгыр тамчыларыдай, Фәнияр күңеленә сеңә барды.

Кайберәүләр бик белемле, оста булсалар да, белгәннәрен аңлата алмыйлар. Бер балта остасыннан сораганнар: син ничек һәр нәрсәне шулай уңайлы, матур итеп ясыйсың, серен аңлат әле, дигәннәр. Ә оста: мин лутчы сезгә ясап кына күрсәтим, дигән, имеш. Әгәр бөтен кешеләр дә шушы балта остасы кебек ясап кына күрсәтә торган булсалар, дөньяның алга китеше, үсеше әкрен барыр иде. Әшләгәнен сөйләп тә бирә алучылар икеләтә бәхетле. Илдусны Фәнияр шундый, сөйләп тә бирә белүчеләрдән саный.

Бик күп төрле ризыкны бала алдына тезеп куйсаң, кайсын ашарга белмичә аптырап кала. Фәниярның укырга кергәндәге хәле шуңарга

охшаш иде. Китапларны ул йотылып укыды. Кайвакыт кайсын укырга белмичә, әле берсен, әле икенчесен актарды. Бөтенесен берьюлы укып була торган булса, Фәнияр шулай эшләр иде.

Университетта уку кызыклы да, авыр да иде Фәниярга. Бер мәртәбә дә профессорларның лекцияләрен үз авызларыннан ишетмәгән кешегә бөтенесен китаплардан гына алу, ай-һай, күп көч сорый шул. Әллә ни әһәмияте булмаган бер зачет өчен дә Фәнияр дөнья кадәр китап укыды. Конспектлар язды.

Ятып уку, ятып язу өчен күп көч сарыф ителә. Кайвакыт Фәниярның китап күтәрерлек тә хәле калмый, озак укудан күзләре яшьләнә, ләкин ул туктамый. Авырып ятып болай да замандашларыннан артта калган. Ә Фәнияр кайбер студентлар кебек «ничек тә ерып чыгармын әле» дип, экзаменнар якынлашканны көтеп ятмый. Киресенчә, барлык предметларны башка студентларга караганда алданрак әзерләп куярга тырыша. Моның үзенә күрә сәбәбе дә бар: университетта имтиханнар вакытында укытучыларның вакытлары бик тыгыз була. Шунлыктан, Фәнияр чакырган чакта гына килә алмыйлар. Фәнияр тынычсызлана, имтиханын бирә алмас кебек тоела башлый. Инде тәмам әзерләнеп беткән булса да, кабат-кабат укый. Шушындый борчулы хәлгә калмас өчен ул бөтенесен алдан әзерләнеп, укытучыларны эшләре бушрак вакытта чакыртырга тырыша.

Фәниярга рус совет әдәбиятын бирү кыен булды. Юк, фәнне белмәүдән түгел, Балалайкин дигән укытучының ниндидер кирелеге аркасында. Имтиханга хәзерләнеп бетү белән Фәнияр аңарга хәбәр итте. Балалайкин: «Мин озакламый ялга китәм, шуннан кайткач яныңа килермен, ныклап әзерләнеп тор», дип язды. Фәнияр программада күрсәтелгән әдәбиятны укып чыккан иде инде, программадан тышларын да укый башлады. Чөнки студентларның сөйләүләренә караганда, Балалайкин күп вакыт программадан тыш материалларны сорап теңкәгә тия икән.

Бер айдан соң Балалайкин ялдан кайтты. Фәнияр аны көтүен белгертеп тагын хат салды. Бу юлы Балалайкин: «Минем лекцияләрне укымый торып, экзамен алмаячакмын»,— дип, студентлар аркылы әйттерде. Фәнияр аның лекцияләрен тапмый аптырады. Студентлар үзләренекен бирергә теләмәделәр, чөнки төн йокыларын йокламыйча шул предметны әзерләнеп яталар. Инде Фәниярга аларның имтихан биргәннәрен көтәргә калды. Студентларның имтиханнары бетеп, инде килер дип торганда Балалайкинның теше сызлый башлады. Фәнияр башка укытучы җибәрүләрен сорап мөрәҗәгать иткәч: «Ул минем группа студенты, үзем барам»,— дип, аңарга да каршы төште. Өч ай дигәндә, ниһаять, ул Фәнияр янына килде. Өстен дә салып тормыйча түргә үтте.

— Мин сездән әллә ни сорап маташмам, мондый хәлдәге кешегә әзерләнү кыендыр, бирегез зачеткагызны,— диде ул.— Фәнияр аптырап калды, чөнки аның янына килгән һәрбер укытучы хәтта зачет кына булганда да бик күп сорый торган иде.

— Юк инде,— диде Фәнияр, хәтере калып.— Мин андый ташлама теләмим. Башкаларга нинди таләпләр куйсагыз, миңа да шундый студент итеп карагыз.

Балалайкин Фәниярга сәер караш ташлады. Моңа кадәр әле аның сорамый гына билге куйдырудан баш тарткан студент очратканы юк иде. Студентларның «күп сорамаса ярар иде» дип, үзе алдында кан калтырап торулары аңа ниндидер ләззәт бирә иде.

— Теләсәгез сорарга да була,— диде ул.— Мин билетлар алып килмәдем, сораулар гына бирермен.

Балалайкин Фәниярны сорау белән күмеп ташлады. Леоновның «Рус урманы»ндагы Грацианский образын сөйләтте. Утызынчы еллардагы

рус совет поэзиясенең үзенчәлекләрен әйтергә кушты. Бөек Ватан сугышы чорында нинди жанрларның өстенлек алуын сорады. Фәнияр аның сорауларына тулы һәм дөрес җавап биргәч, Балалайкин йомшарып китте. «Болары экзамен өчен түгел, ничек җавап бирсәгез дә ярый» дип, тагын әллә ниләр сөйләтте. Зачеткага рәхәтләнеп «отлично» билгесе куйгач, өстен чишенеп керде. Фәниярның шигырьләр язуы турында ишеткәне бар икән, тәрҗемәләре юкмы дип кызыксынды. Фәнияр берничә шигырь укып күрсәтте. Тәрҗемәләр шактый йомшак эшләнгән иде, шуңа күрә Фәнияр кайбер образларның оригиналда ничек булуын әйтте. Әңгәмә үзеннән-үзе әдәби тәрҗемәләр темасына күчте.

Тиз генә чыгып китәргә җыенган Балалайкин Фәнияр янында өч сәгатьтән артык утырды.

Фәнияр, көчле гипнозга ия булган кеше шикелле, үзенә килүчеләрне тиз генә җибәрми. Ул чын-чынлап кешеләргә сусап тора. Үзендәге ашкынуны, тынгысызлыкны ул әңгәмәчесенә дә йоктыра.

Фәниярның ни өчен университетта укуын күпләр аңлый алмадылар. «Сиңа, түшәк өстендә ятучы кешегә, диплом нәрсәгә кирәк, җәзалама үзеңне», диючеләр шактый очрады. Бигрәк тә күрше Сабира апа, кергән саен Фәниярны кызганган булып: «И, бичаракай, бигрәк ябыккансың инде, күз төпләрең күгәреп чыккан», дип сөйләнергә тотына. Фәнияр диплом өчен түгел, белем өчен укыганын шундыйларның һәрберсенә аңлатырга мәҗбүр. Ләкин Сабира апа кебекләрне болай дип кенә ышандыру кыен.

— Диплом алгач я пенсияне арттыралардыр, я язган шигырьләреңә хакны күбрәк түлиләрдер, юкка азапланмас идең,— ди ул.— Минем бер белгән укытучым бар, шул, өченче курстан соң безнең зарплатаны арттыралар, дип әйтә иде. Алты ел интегеп, заочныйның өченче курсын тәмамлады да шуннан соң институтка ике аягының берсен дә атламады.

Гөлсәйдә түти дә улының контроль эшләр, конспектлар һәм шулар өстенә шигырьләр язып, кашык та күтәрә алмаслык булып арыганын күрә, борчыла.

— Әллә соң, ташлыйсыңмы, балам? — ди.— Шигырьләрне әлек тә язадырыең бит әле, язучыларның бөтенесенә дә унбирситет бетерергә димәгәндер.

— И әнкәй,— ди Фәнияр,— син дә аңламыйсыңмыни мине? Шигырьне аны ничек язсаң булмый. Өченче класс укучылары да шигырь яза хәзер. Мена шул өченче класс укучысы язган кебек әсәрләр белән генә канәгатьләнәсем килми минем. Гомер яңа башлана гына. Нәрсә эшләп үткәрим мин аны? Элеккечә түшәмдәге ярыкларны санапмы?

— Сәламәтлегең бик беткәнгә генә әйтәм,— ди ана, аклангандай итеп.

— Тазалыкны саклап тик ятудан ни файда? Алты ел университетта уку, әйдә, өч ел гомерне кыскартсын, ди. Бу әле зур бәла түгел. Ә бөтен гомер бушка үтсә — кызганыч. Ул чакта үзең үк куралмый башлар идең. Мин бит синең холкыңны яхшы беләм: үзең дә тик торырга яратмыйсың, башкаларның кул кушырып утыруларына да түзә алмыйсың. Тынгысызлык синнән күчкән миңа.

Фәнияр укуны да, шигырьләр язуны да көн үтсенгә генә эшләми. Көнне телевизор карап, мавыгулы китаплар укып та уздырып була. Ләкин аннан ни үзеңә, ни кешеләргә файда юк. Ә Фәнияр көннең бер генә минутын да әрәм үткәрергә теләми. Кемнәргәдер файдалы эш башкарганда гына күңелендә чын сөенеч һәм горурлык туа.

Шулай да кайвакытларда Фәнияр шикләнеп тә куйгалый. Университетта уку аңа нәрсә дә булса бирерме? Юкка гына тотынмадымы? Бәлки аның бернинди таланты юктыр. Ул вакытта бер түгел, ике инсти-

тут бетерсәң дә, һични чыкмаячак. Бары тик дипломлы инвалид кына булырсың.

Ләкин егет мондый уйларын күңеленнән тизрәк куарга тырыша. Газета-журналларда басылып чыккан шигырьләрен күрү һәммәсен оныттыра. Күптән түгел яшьләр газетасында бер тәнкыйть мәкаләсе басылган иде, анда Фәниярны үсүче шагыйрьләр рәтенә керткәннәр.

Әйе, университетта укуының юкка гына түгеллеген үзе дә белә ул. Хәзер дә инде ул күп нәрсә алды. Әдәбиятны рәтләп аңламаган чакта үз шигырьләренә гашыйк булып ята иде. Зур шагыйрьләрне күбрәк укыган саен үзенең кимчелекләрен күбрәк күрә. Хәтта бу шагыйрьләрдән соң кәгазь пычратып язып торасы да юк дип, атналар буе һични язмый ята. Әмма канат чыгарган кошны очудан тыеп булмаган кебек, аны да хәзер язудан аерып булмый. Кошлар арыгач җиргә төшеп ял итәләр дә кабат очып китәләр. Шагыйрьләрнең күңелләре төшкән очракларда каләмнәрен атып бәрәләр дә уймак хәтле берәр яңа фикер тапсалар — каләмнәрен кире эзләп алалар. Шагыйрьләрне иң юмарт, иң ашыгучан кешеләр диярга була. Күңелләрендәге байлыкларын тизрәк әйләндереп салмасалар, аларның йокылары кача, тынгылыклары югала.

## XXIII

Нинди карарга килергә белмичә озак йөрде Илсөя. Әнисенең һаман да ныклап савыгып җитә алганы юк. Абыйсы һәр адымын күзәтеп тора. Кыз да бирешергә теләми, җае чыккан саен Фәниярны якларга тырыша. Газетада Фәниярның шигырьләре чыкса, ул газетаны башкалар күрердәй төшкәрәк куя. Ә инде Фәниярның китабын кибеттә күргәч, сөенеченнән берьюлы унны сатып алды. Ләкин китаплар икенче көнне үк юкка чыкты. Илсөя аларны әнисенә дә күрсәтә алмый калды. Моның абыйсы эше икәнен белгәнгә, үч итеп тагын алып кайтты. Китаплар тагын юкка чыкты. Шулай берничә мәртәбә кабатланды. Ниһаять, абыйсы болай итеп кенә Илсөяне җиңә алмаячагын аңлады һәм бөтенесенә кул селтәде.

Кызының үз эченә йомылуын әнисе дә күрә. Элек Илсөя бернинди сәбәпсез кычкырып көлә, кемдер кытыклаган шикелле туктаусыз шаркылдый иде.

— Шул балалыгыңны ташларга вакыт,— ди иде әнисе.

Хәзер Илсөяне көлдерер өчен әллә ни бирер иде, булдыра алмый ана. Кайвакыт ул: «Әллә соң фатихамны бирим микән?» дип уйлап куйгалый. Ләкин кызының Фәнияр белән бәхетле булачагын берничек тә күз алдына китерә алмаганлыктан, ул сүзне әйтергә теле әйләнми.

Ә Илсөянең Фәнияр янына бармаганына байтак булды инде. Бөтенләй онытырга, күңелдән сызып ташларга кирәк тә бит... Тик онытырга теләгән саен ныграк уйландыра. Нәрсәсе белән тарта соң аны үзенә Фәнияр? Башка егетләр кебек, әллә нинди тәмле сүзләр дә әйтми, яратуы һәрбер хәрәкәтеннән, һәрбер кыланышыннан күренеп торса да, «сөям» сүзен дә ишетмәссең анардан. Фәниярның йөрәгендә Илсөя белеп бетерми торган ниндидер тарту көче бардыр, күрәсең.

Илсөя шундый хәл кичерде. Фәнияр янына гел барып йөргәндә, мәхәббәт җепләренә болай нык чолгангандыр дип уйламый иде, ычкынып китәргә теләгәч бу җепләрнең искиткеч нык икәнен белде. Илсөя кичергән бу хисне мәхәббәт дип кенә дә булмый. Кыз Фәниярда ачылмаган талант яшеренеп ятуын сизә. Гөлләр дә бит чәчәккә бөреләнәләр дә, вакытында яңгыр яумаса, ачыла алмыйча бик озак утыралар. Дым көтәләр. Ә инде көтеп-көтеп тә яңгыр яумый икән — бөредә килеш көяләр. Бөренең кабыгын ярып чыгарга көч тапканнары да зәгыйфь була. Фәниярны да суга сусаган чәчәк итеп күз алдына китерә Илсөя.

Тормышны рәтләп күрергә дә өлгермәгән килеш имгәнеп, озак еллар больница палаталарында аунау егеткә сәләтен күрсәтергә, ташып торган көчен эштә кулланырга мөмкинлек бирмәгән. Аның шушы бөреләнеп килгән талантын ачышырга, көченә ышандырырга кирәк. Коры юату сүзләре биредә ярдәм итмәячәк, чөнки Фәниярның гөнаһсыз сөю хисләрен бер мәртәбә пычратканнар. Аның күңелендә яңадан ышаныч кабызу өчен бары бер нәрсә эшләргә кирәк: янына гомерлеккә барырга!

Фәнияр бит Илсөянең килүеннән әллә никадәр көч алып кала иде. Илсөя юри кызыксынып Фәниярның шигырьләре астына язылган числоларны карый иде. Шигырьләрнең иң матурлары ул килеп киткәннән соң язылган була. Кыз озаграк килми йөрсә, дәфтәрдә бушлык күбәя.

Янында ныклы терәк сизгәндә, Фәниярның кешеләр яратырлык матур әсәрләр иҗат итәчәгенә тамчы да шикләнми Илсөя. Бәлки аны мәхәббәт сукырайткандыр? Мәхәббәт сукыр диләр бит. Ләкин ул бу сүзләр белән килешми. Киресенчә, мәхәббәтнең күзе очлы. Яраткан кешеңдәге күркәм сыйфатларны, матур якларны бөтен кешедән дә алда күрәсең. Фәниярга иң кирәкле кешенең үзе икәнен яхшы төшенә Илсөя. Төшенә, ләкин күңелендәге киртәне сикереп чыга алмый. Нәрсәдер өркетә, тыеп тора.

Икеләнүләр, газапланулар белән яшәп ятканда, беркөнне радиодан Фәнияр иҗатына багышланган тапшыру бирделәр. Фәниярның күп кенә яңа шигырьләрен укыдылар, университетта укуын әйттеләр. Соңыннан бер танылган композиторның Фәнияр сүзләренә язган җырын тапшырдылар. Җырның көе дә, сүзләре дә күңел тетрәтердәй сагышлы иде. Радиодан Фәнияр турында сөйли башлау белән әнисе урыныннан торып утырды. Фәниярның шигырьләре бик нык тәэсир итте аңа. Бу шигырьләрдә әллә нинди нечкә сагыш та, тормышны өзелеп ярату да, матурлыкка соклану да, үз мәхәббәте өчен көрәшкә әзер тору да бар иде. Ананың хәтерендә бигрәк тә бер шигырь уелып калды. Бу шигырь Фәниярның сөйгәненә багышлап язылган. Ярының йөрәге таш булса — хисләрнең тамчы булып тамачагын, боз икән — утка әйләнәчәген, кыя тау кебек горур булса — тау астыннан чишмәгә әйләнеп бәреп чыгачагын сөйли иде шагыйрь. Менә ул кеше күңелен әйтеп биргән сүзләр. Мондый кеше сөелергә хаклы түгелмени?

Ананың күзләреннән яшь тәгәрәде. Әй язмыш, нигә син шундый ихтыярлы кешеләрнең юлына баз казыйсың икән?! Җирдә барча кеше сау-сәламәт яшәсә нәрсә була? И кодрәтле алла, бернигә ярамаган бөҗәкләргә канат та, аяк та биргәнсең, кешеләрне дә ник канатлы яратмадың? Аяклары сынса — канатлары калыр иде.

Шул чак ананың күңеленә Фәниярның тагын бер шигыре килеп төште. Ул шигырендә Фәнияр кешенең канатлы булуы турында сөйли түгелме? Кешенең канатлары мәхәббәт, ди. Шул канатларда үзенең югары күтәрелүен, кояшка якынаюын сөйли.

Ананың бервакытта да шигырьләрне болай тиз отып кала алганы юк иде әле. Ул яңа гына ишеткән шигырь юлларын күңеленнән кабатлады:

«...Язмышларын болай булырын
Сизмәгән шул бер дә күңелем.
Егылганда катырак төшәр өчен
Булган икән биек менүем.»

Илсөянең әнисе — әдәбиятны ярата һәм үзенчә аңлый торган кеше. Академия театрында барган яңа спектакльләрнең берсен дә калдырмый. Ләкин ахыры кавышу белән бетмәсә, канәгатьсезлек белдерә. «Шуларны нигә инде бергә калдырмаска», дип авторны тирги. Яңадан мондый спектакльләргә бармаска ант итә. Тик икенче атнада ул әкрен-әкрен кызы Илсөядән сораштыра башлый. Фәлән кешенең фәлән пьесасын куялар икән, нәрсә турында икән, ахырын ничек беткәнен белмисеңме?

дип йөдәтеп бетерә. Илсөя әнисенең зәвыгын белгәнгә, кайчак юри дә: «Кавышалар, әни» дип, тегене театрга җибәрә.

Кешеләргә гел бәхет һәм кавышу гына теләгән ананың үз алдына тормыш шундый сорау китереп куйгач, аптыраудан гаҗиз калды ул. Фәнияр кызганыч, ләкин үз баласы якынрак. Фәниярның канатын сындырмыйм дип, үз балаңны бәхетсез итәсе килми. Кызын ышанычлырак, яхшырак кулга тапшырасы иде дә бит...

Башы катты ананың. Тегеләй дә, болай да уйлап карады. Ахырдан ул түзмәде, фатихасын бирде, ләкин Фәниярларга бара алмаячагын белдерде. Илсөя әнисенең күкрәгенә капланды. Йөрәген албастыдай басып торган авыр таш юкка чыкты. Ул бары тик: «Рәхмәт, әнкәй» дип кенә әйтә алды ул.

Үзе егылган еламас дип, Илсөягә үз юлын үзе сайларга калды.

Юллар! Ай-һай, төрле, ай-һай, үзгә сез. Кар өстеннән ергаланып киткән сукыр тычкан эзеннән башлап, космоска кадәр сузылган юллар. Кеше үз гомерендә бик күп юл чатларына килеп чыга. Әкиятләрдәге шикелле, берсендә — үлем, икенчесендә — бәхет дип язылмаган, ә шулай да кайсыннан китсә кая барып чыгачагын аңлый кеше. Нәкъ менә үзе сайлаган юлның авыр, чытырманлы булуын да белә, ләкин борчылмый. Ешкынлыклар аның битләрен тырный, сазлыклар тәнен пычрата, урләр хәлен бетерә, ә кеше аның саен үҗәтләнә.

Илсөя Фәниярны шатландырырга, әнисенең ризалыгын әйтергә ашыкты. Тилмереп, тилереп көткән Илсөя үзләренә килеп кергәч, Фәнияр урыныннан кубарылып, сикереп торырга җитеште. Кызга таба омтылып шундый кискен хәрәкәт ясады, хәтта тимер караватт ыңгырашып куйды. Әгәр сагыну көче хәрәкәткә, йөрәктәге мәхәббәт — канатларга әверелсә, бу минутта Фәниярдан да көчле кешене табып булыр идеме икән?

Әйтерсең өйнең бөтен стеналарын алып ташладылар, Фәниярга иркен, рәхәт, җиңел булып китте. Бүлмә саф һава һәм яктылык белән тулды. Арып-талып тау башына менгәч, йөзеңне җилгә борып еш-еш сулыш алулары нинди рәхәтлек бирсә — Илсөянең килүе дә шулай рәхәтлек бирде.

— Илсөя,— диде Фәнияр, ят тавыш белән.

Кыз, озак килми йөрүенә гафу үтенгәндәй, башын бераз аска иеп, егетнең караватына якынлашты.

— Бөтенләйгә килдем,— дип пышылдады ул.

Аның килүенә улыннан да битәр ана шатланды. Гөлсәйдә түти улының бу кызны ничек көтүен яхшы белә. Берәрсе килеп ишек шакыса, әнкәй, тизрәк ач әле, Илсөя түгелме? дип, гел ашыктыра башлый иде. Кибетләргә, базарларга барганда ишекне бикләтми калдыра. Илсөя керә алмый китүдән курка.

Илсөянең улы янына бөтенләйгә килүен белгәч, Гөлсәйдә түти куанычыннан телен йотты. Бик озак торгач кына күзләрен алъяпкыч белән сөртеп, Илсөянең аркасыннан какты:

— Рәхмәт, кызым. Тәүфыйкларың, сөенечләрең белән кил. Безне шатландырган өчен, ходай сине унлата шатландырсын.

Ана кухняга чыгып китте. Озакламый анда таба чыжлаганы ишетелә башлады. Ә Фәнияр Илсөягә карап туя алмый. Күңелендә төрле уйлар бутала. Шул чак аның хәтереннән күптән түгел булып узган бер вакыйга чагылып үтте.

Кышның салкын гына көнендә, ачык форточкадан песнәк очып керде. Фәнияр кош-кортларны бик ярата иде, песнәккә чиксез шатланды. Песнәк тә җылы өйгә эләгүенә һәм куркытучы кеше булмаганга өйдән тиз генә чыгып китәргә ашыкмады. Ә әнисе кайтып кергәч, Фәнияр форточканы яптырып куйдырды. Песнәкне бик тә өендә калдырасы килде аның. Ә песнәк өйгә ияләшергә теләмәде. Биргән ризыкларга да

кагылмады. Тәрәзәгә канатларын бәрә-бәрә тышка, иркенгә омтылды. Фәнияр аны читлеккә яптырды. Ләкин ирек кошы тар читлекне үз итмәде. Боекты, саргайды. Ничектер тынып калды. Тәрәзәнең тышкы ягында чагында чырык-чырык сайрап туймаган кош өйгә кергәч тавышын да чыгармады. Шуннан соң Фәнияр тәрәзәне ачтырып аны тышка чыгарып җибәртте.

Илсөя дә менә шулай ялгышлык белән очып кергән кош кебек боега, күңелсезләнә башламасмы?

## XXIV

Алар шау-шусыз, туй-сыйларсыз гына язылышып куймакчылар иде, ләкин Гөлсәйдә түти киңәш-табыш кылгандай сабыр гына:

— Алай килешеп бетмәс бит, балалар,— диде.— Еллар күркәм, табыннар сыйлы — нигә гөрләтеп туй итмәскә?! Күзгә кырып салырлык он булмаган ярлы елларда да кешеләр туй ясашып өйләнештеләр.

— Соң, әнкәй, алар...

Гөлсәйдә түти улының тел төбен аңлады. Гомумән, ул аның һәр фикерен ярты җөмләдән аңларга өйрәнде.

Гомергә бер тапкыр килә торган шундый куанычлы эшне кешегә әйтмиләр димени? Ләбибәләрне, Рәҗибәләрне чакырабыз. Алар иң кыен чакларда килеп йөрделәр, тыгын димәделәр, үзләре янына мине сыендырдылар. Алардан яшерү гөнаһ булыр.

— Болай булгач, мин дә иптәш кызларымны алып килермен,— диде Илсөя.— Алар бу квартираны юарга килгәч үк: «Туена чакырырсыңмы?» дип, мине үрти башлаганнар иде инде.

Туй ясаргамы-юкмы дип киңәшләшеп торганда хатыны Миләүшә белән Илдус Гаделшин килеп керде. Чит кешеләрдән иң беренче серне аларга чиштеләр. Илдус бу хәбәрне ишеткәч, үз малаен өйләндерергә җыенган ата кешедәй шатланып:

— Һай, дуслар, бик шәп эшлисез! Рәзе мондый эшне кешедән яшерәләр! — дип, тегеләрне кызартып алды. Иптәше Миләүшә табын әзерләшергә, туй күлмәге сайлашырга җиң сызганып торуын белдерде.

— Минем хатын пилмәнне бик оста бөгә, апага кияү пилмәне ясашыр,— диде Илдус.

— Булдырабыз аны,— диде Миләүшә,— туе гына булсын, сыеннан эш калмас.

— Мин иртәгә бу хәбәрне Язучылар союзына ирештерәчәкмен,— диде Илдус.

— Шту син, Илдус абый,— диделәр Илсөя белән Фәнияр парлашып.— Анда әйтә-әйтә туй ясарга без кемнәр соң? Олы кешеләрне мәшәкатьләп йөрергә!

— Нинди мәшәкать булсын,— диде Илдус.— Фәниярның хәзер язучылардан яшерен эше булырга тиеш түгел. Бүген-иртәгә член итеп алынырга тора. Ә бәлки идарә моны хәл дә иткәндер инде.

Шагыйрьләр секциясе берничә ай элек Фәниярның иҗатын тикшереп, Союзга тәкъдим иткән иде. Эш идарәдә калды.

Дус-ишләрен, туган-тумачаларын барлый торгач, кырык-илле кеше җыелды. Бу кадәр кешенең бер бүлмәгә сыймасын белсәләр дә, исемлектән һичкемне сызасылары килмәде. Һәркайсы якын, һәркайсы кадерле. Гөлсәйдә түтинең дә, Фәниярның да, Илсөянең дә күз алдында торган тагын бер кешеләре бар: Ул Илсөянең әнисе Бибинур. Теге вакытта: «Сеагә барып йөри алмам» дисә дә, ана күңеле эрүчән бит. Бәлки, килер.

— Мин кодагый янына барып кайтаем әле,— диде Гөлсәйдә тути, балаларының кем турында уйлануларын төшенеп.

Гөлсәйдә килеп кергәндә Бибинур урын өстендә ята иде. Исәнлек-саулык сорашкач, ул торып утырды. Кухня ягына чыгып, чәй куеп җибәрде. Гөлсәйдә аның борчылып йөрүен күргәч:

— Кодагый, берүк минем өчен генә булса мәшәкатьләнә күрмә. Өйдә тамакны туйдырып кына килдем,— диде.

Бибинур Гөлсәйдәгә ниндидер талчыккан бер караш ташлады. Үзенә кодагый диюләрен беренче кат ишеткәнгәме, бу сүз аңа сәеррәк тоелды. Гөлсәйдә тизрәк сүзне башларга теләде:

— Мин, кодагый, сине туйга чакырырга килгәнием,— диде ул, гади һәм сабыр гына.

— Кәефем бик начар шул,— диде Бибинур, бераз көттереп.

— Син килмәсәң, балаларның күңелләре бик төшәр инде,— диде Гөлсәйдә.— Әйе, һәркемгә үз баласы газиз. Минем улымның да күкрәк киереп йөргән чаклары барые. Язмыштан узмыш юктыр, күрәсең.

Бибинурның: «Синең улыңның алай булуына минем кызым гаепле-мени?» диясе килгән иде дә, хәсрәт чиккән ананы җәберсетәсе килмәде. Узган эшкә салават дигәндәй, Илсөя киткәч кычкырышып йөрүдә ни файда?

Ике ана бер-берен аңладылар. Әллә ничә кат чәй кайнатылды. Бибинур туйга килергә ризалыгын биргәч, Гөлсәйдә тутинең күзләре яшьләнде. Бер-берсенә күрсәтмәскә тырышып ике ана яулык почмаклары белән күзләрен сөрттеләр. Икесенә дә ничектер җиңел һәм рәхәт булып китте. Уртак хәсрәт аларны якынайтты.

— Уйларымны кемгә чишәргә белми йөдәп беткән идем, килүең әйбәт булды әле, кодагый,— диде Бибинур.

Ул үзенең кызы, ә Гөлсәйдә улы турында сөйләде. Һәр ике ана балаларына бәхет-тәүфыйк теләделәр.

Туй көне килеп җитте.

Загстан бер апа кәгазьләрен, печатьләрен күтәреп Фәниярларга килде. Аны өй тулы кунак каршылады.

Илдус Гаделшин чынлап та Язучылар союзында Фәниярның өйләнүе турында әйткән икән. Туйга бер төркем язучылар, шагыйрьләр килде. Араларында газетадан бер корреспондент та, танылып өлгергән яшь бер композитор да бар иде. Корреспондент ялт-йолт фотога төшерде, Фәнияр белән Илсөянең кайчан һәм ничек танышулары турында сорашырга да, җавапларын үзенең блокнотына сызгаларга да җаен тапты. Композитор үзенең бер яңа көен уйнап күрсәтте һәм бу көйне яңа өйләнешүчеләргә бүләк итүен белдерде. Ә шагыйрьләргә көй генә булсын, сүзләре телләрендә — шул арада берсе композиторның яңа көенә сүзләр язып ташлады. Мәҗлестәгеләр яңа җыр өйрәнергә тотындылар.

— Яңа семья белән яңа җыр да туды бит әле, иптәшләр. Бу бик хикмәтле нәрсә. Һәрбер туйда яңа җыр туып тормый,— дип сөйләде бер өлкән язучы.

Яңа җыр хөрмәтенә, яңа семья хөрмәтенә дә тостлар күтәрелде. Шампанское бөкеләре шартлап түшәмгә очты. Бөкеләр күбрәк атылган саен «ачы!», «ачы!» сүзләре ешрак кабатланды. Өстәл өстендәге шешәләр аска төшеп ятты, кухнядан кияү пилмәнен ташучыларның табаннары шомарды. Бокаллардагы шәрабләр кимегән саен кешеләр йөзендә кызыллык артты. Табыннар такырайды, йөзләр матурайды. Җырлар көчәйде. Тавышлар ишәйде.

Бөтенесе дә матур, күңелле булды. Кунаклар да өйгә сыйдылар. Тыгын дип зарланмадылар. Туй үпкәсез булмый дисәләр дә, үпкәсен белдерүче ишетелмәде. Һәммәсе канәгатьләнешеп таралдылар.

Фәнияр белән Илсөя өчен яңа тормыш башланды. Аларның юлында шатлыклар да, кайгылар да күп очрар, әле юлның башы гына. Үрләрнең әле беренчесе яуланды. Үр артында үр, офык артында офык бар. Әйе, хәзер Фәниярга бирешергә ярамый: ике якта ике ишкәкчесе — Илсөя белән әнкәсе бар.

Язмыш синең тез астыңа китереп сукса — егылмас өчен якасына ябыш. Утларга салса — үзең аннан да көчле ян, шул вакыт аның кызуын сизмәссең. Суларга ташласа, күбек булып өскә күтәрелмә — асылташ булып төпкә бат, ялтыравыгыңны күреп чумып алырлар. Тузан итеп һавага күтәрсә — яңгыр тамчыларына кушылып җиреңә төш. Карурманнарда адаштырса — кояшка карап юл сайла. Ташлар белән бастырса — чишмәгә әверелеп ирекә ургы. Җиргә күмсә — орлык шикелле тишелеп чык. Җилкәнеңне җилләр екса — йөрәгеңне җилкән итеп күтәр. Нинди генә очракта да җиңәргә өйрән. Көчле рухлылар гына максатларына ирешә алалар. Түземнәр генә бәхеткә лаек,— диде алар туенда бер өлкән шагыйрь.

Фәнияр, ерак диңгезләрдә йөзүче диңгезче төсле, шигырь дөньясында йөзә дә йөзә. Әйе, ул караватка куелган кыйгач өстәлгә беркетелгән кәгазьгә шигырь юллары тезә. Шигырь юллары бик үк туры килеп чыкмый, аның каравы, тормыштагы юлы туры аның.

Авыр булды минем язмышым,
Мин әле дә һәркөн сыналам;
Диңгезләрне кичеп чыгам да,
Утрауларга басып тын алам,—

дип язып куйды ул. Әйе, тормыш аны һәр көн, һәр сәгать сынап тора. Ә алда сынаулар әле хисапсыз күп.

1970—71

## Илдар Юзеев

# Карурман

Тавыш тизлегендә самолетта
Очкан чакта,
Идел ярыннан
Яңрап куйды еракларда калган,
Онытыла язган «Карурман».
Бабам тавышы белән әйтә гүя:
«Бик ашыгып, ай-һай, барасың...
Югарыдан гына булса да бер
Бәлки, балам, борылып карарсың?»
Ә мин әйттем: «Киләчәккә барам,
Тукталырга вакытым юк әле.
Сезнең җирле микрохисегездән
Безнең уйлар бик-бик югары!»
Очтым, очтым,
Мин оныттым инде
Карурманнар биргән сагышны,
Узганнардан түгел,
Киләчәктән
Ишетерсез минем тавышны.
Карурманнан атың чыккан чакта,
Йолдызларга, бабам, карарсың.
Онытыңны җирдән эзләмә син,
Галәм юлларында табарсың.
Сиңа юлдаш — озын салмак көйләр,
Ат кешнәве, кошлар сайравы.
Оныкларың бүтән юл сайлады...
Ай, йолдызлар — урман,
Җир — туган йорт...
Син һаман шул: ат та дилбегә.
Җир дә башка хәзер, җыр да башка.
Үзгәрмәдең бары син генә.
Күңелең булсын, иске җырларыңа
Минем исемне дә куш, бабам.
Тукталырга һич тә вакытым юк,
Син аңларлык түгел...
                    хуш, бабам.
Карурманда калган юлларыңа
Бик биектән карап үтәбез.

. . . . . . . . . . . .

Өйдә мине хәбәр көтеп торган:
«Бабаң дөнья куйды... Көтәбез...»
...Тәрәзәгә карап өметләнгән
Кайтмасмы дип урман ягыннан.

Ахыр сулышында өзгәләнгән:
«Сандугачлар... Чишмә... Карурман...
Васыятем аңа тапшырыгыз:
Түбән күрсә әгәр бабасын,
Егылып төшмәгәе югарыдан...
Кайтсын... астан өскә карасын»...
Кабереңдәге салкын ташны кочып,
Җылы туфрагыңа тезләндем.
Мәгънәләрен эзлим, мәгънәләрен
Син калдырган серле сүзләрнең.
Шушы серле, җырлы дөньяны ул
Оныгына — миңа калдырган.
Тормыш агымына кереп китәм
Әкрен генә кабер яныннан.
Күңелемдә — бабам васыяте...
Рәнҗеттемме әллә аны мин?..
Туган авыл. Эне-сеңелләрем,
Кичерегез, сезне танымыйм.
Килен бәхетен күрәлмәгән әнкәм
Колонкадан әнә су ала.
Өе җылы, чәе кайнап тора,
Балам кайтты диеп юана.
Хәтереңдәме, яшьтәш, ат көтүләр,
Печән салган чаклар улакка?
Әнә үзе... яңа «Волга»сында
Түбән очка бара кунакка.
Хәтереңдәме, туган, чана белән
Әрәмәдән утын ташулар?
Әнә үзе... таудай бульдозерда
Җир тетрәтеп килә басудан.
Хәтереңдәме, энем, елый-елый,
Ата каздан куркып йөгергән?
Әнә үзе... тыйнак кыйгакларга
Карап тора вышка үреннән.
Күңелем тулы җылы хисләр минем
Машинага, «кара алтын»га,
Мәдхияләр сорый табигатем
Авылым матурлыгы хакында.
Кыр да башка хәзер, җыр да башка,—
Танымаслык булып үзгәргән.
Хәйран калып узам асфальтларга
Күмелеп калган иске эзләрдән.
Бар да бәхетлеләр, канәгатьләр,
Ә бабамның гомере өзелгән.
Нидер эзли күңел... Тапмый... Киттем
Аның васыяте эзеннән.
Ник йөрәгем сыза? Сәбәбе ни?
Белмим, нәрсә җитми, ни җитми?
Бабам васыяте... Тукта... Ә нигә мин
Сандугачлар тавышын ишетмим?
Соңгы төсе итеп иркәләдем
Сөйгән кашкасының ялларын.
Мең ат кечен җиңә алган егет
Бер бахбайны җигә алмадым.
Мин оялып калдым,
Аксакаллар

Хәлне аңладылар,—
Җиктеләр.
Тәгәрмәчләр,
Әлли-бәлли итеп,
Сабый чакка алып киттеләр.
Төнгә каршы кая юнәлгән дип,
Юлчыларның исе китмәсен.
Мин табарга тиеш бабаемның
Васыятен — урман, чишмәсен.
Онытылган, узганнарда калган
Хатирәгә таба юл алдым.
Эзләмәгез мине,
Бала чакның
Томанында эреп югалдым.
Туктатмагыз мине, авылдашлар,
Эзләп барам бабам мирасын.
Нигә, кашкам, мине тыңламыйсың,
Сабан туйга таба борасың?
...Мәйдан. Көрәш. Сөлге тоттырдылар
«Күктән җиргә кайткан кунак»ка.
«Эһ!» дигәнче, заман тизлегендә
Килеп төштем... туган туфракка.
Агайларның серле күзләрендә
Тойдым шул чак бабам карашын:
«Ешрак кайтып шулай туган якка,
Астан өскә таба карасын...»
...Ат та башын игән.
Мин дә — уйда.
Гамьсезлекнең теге чигеннән
Мин илемә кайтып барам бугай,
Мин чигенәм бугай, чигенәм.
Ат адымы белән узган юллар
Бераз истә, бераз онытылган.
...Чалкан ятып барган уйчан малай
Ерак йолдызларга омтылган.
Күңелем минем гаҗәп бер җыр эзли...
Ул ягымлы барлык көйләрдән,
Бала чакта
Әллә былбыллардан,
Әллә әниемнән өйрәнгән.
Якынайган саен васыятькә,
Тамырлана шул көй күңелдә.
Өздереп лә бер җырларсың әле
Карурманга кереп күмел дә...
Бабамнардан мирас булып калган
Изге нигезем син, өем син,
Таңнарымда үбеп уяткан да,
Йоклаткан да иркә көем син.
Кара урман...
Качкын егетләргә оя корган,
Бунтарь йөрәкләрне яшергән,
Табигатем нигә ярсу дисез...
Шәрук беглый[1] безнең нәселдән.

[1] Шәрук беглый — алпавыт утарларын туздырган, халык җырларында җырланган легендар качкын.

Күңелемә нидер җитмәс иде
Тукаеңны җырга кушмасам,
Шүрәлеңне тапкан егетеңне
Бер сагыныйм әле ичмасам.
Былтыр[1] сыман алдап дошманнарны
Җәлилчеләр сиңа кайткандыр,
Батыр егетләрне ил чишмәсе,
Ил урманы үзенә тарткандыр.
Мин тын гына сиңа баш иярмен,
Сүзсез аңларсың син барыбер.
Бар кошларың миңа кушылырлар,
Сәйдәшеңне көйлим әле бер.
Һәлакәткә алып барган чакта
Мәхәббәттә тирән ялгышым,
Туры юлга борып хәл иттең син
Дилбегәсез яшьлек язмышын.
Мин бик озак сезгә кайтмый тордым,
Былбылларым гаеп итмәсен.
Күрсәтегез миңа яшьлегемнең
Кайнап торган татлы чишмәсен.
Сандугачым, тыңла, күкрәгемнән
Син өйрәткән көйләр ургыла,
Алып китче мине бу малайның
Үлеп гашыйк булган урнына.
Табигатем, холкым — кара урман...
Һаман сабый, һаман нарасый.
Кәкүкләрең белән алда мине,
Борма юлларыңда адашыйм.
Шәһәр гөрелтесе шау-шуыннан
Тынып тору өчен ни кирәк?
Кара урман...
Бар ямьнәрең белән кил каршыма
Көйләп,
назлап,
сайрап,
чылтырап.
Кара урман...
Күккә карап хыялланып яткан
Малайларның серен яшергән.
Бала чакка кайтып аваз салам!
Ау-у!
. . . . . . . . . . . . .
Дәш, урман!
Мин ни күрәм: бабам васыять иткән
Чишмә тынган, сулар кипкәннәр...
Сандугачлар кайда? Сандугачлар?..
Алар... безне... ташлап киткәннәр.
Сандугачлар эзлим... Чылтыравыклар...
Басып узам салкын ташларга.
Кара урман...
Мәхәббәттә алданган кыз сыман,
Онытылган,
сулган,
ташланган,

[1] Былтыр — Тукай поэмасындагы тапкыр егет.

Сандугачлар кайда? Сандугачлар
Соңгы ядкарь миңа бабамнан.
Ракетага менеп утырсам да,
Мин табалмам сезне, табалмам.
Уем-хисем белән бабаемның
Васыятенә килеп орындым.
Сандугачлар эзлим... Сандугачлар...
Авылыма таба борылдым.
«Сайра, сандугачым, сайра» диеп
Урам урый яшьләр-якташлар,
Соңладыгыз инде, алар киткән,
Алар киткән, бәлкем, кайтмаслар.
Гашыйкларның җыры нигә сүрән,
Гармунчыдан әллә уңмаган?
Басып сайрар өчен каешына
Сандугачлар килеп кунмаган.
Радиолар, мотор тавышлары,
Машиналар шавы эчендә
Сандугачлар эзлим, челтерәүләр...
Авылымның нурлы кичендә.
Әнкәм бүген матур бер төш күргән:
Очып килеп әллә кайлардан,
Чишмә буендагы талга басып,
Өзелеп-өзелеп кошлар сайраган.
Мин сискәнеп киттем узган чакта
Клуб тәрәзәсе яныннан,
Сандугачның тавышын кемдер берәү
Тасмаларга язып калдырган.
Ике яшьнең туйларында булдым:
Баш әйләнде. Әллә нишләдем.
Өстәл сыгылырлык муллык. Шәраб.
Тоймадым тик чәчәк исләрен.
...Мин төн буе йөрдем урамнарда
Бабам мирасына юл эзләп.
Матур киләчәгем ашыктыра,
Күз кысалар күктә йолдызлар.
...Кеше серләр эзли күк йөзеннән,
Җир астыннан, диңгез төбеннән.
Йолдызларга оча, атомнарның
Кара урманына күмелә.
Яңа Матурлыкны иҗат итә,
Булмаганны таба. Гали зат.
Әмма табигатьсез яши алмый.
Ансыз яши ала табигать.
Шәфкать көтми кеше табигатьтән,
Теләгәнен ала көч белән.
Ә ул,
Шомырт кара күзен мөлдерәтеп,
Рәхим-шәфкать көтә кешедән.
Ләкин кеше, ашыгып барган чакта,
Туар матурлыгы хакына,
Сандугачлы кара урманнарны
Күпер итә аяк астына.
Саксыз куллар килеп табигатьнең
Нечкә кылларына кагыла.
Машиналар тоймый. Ә йөрәкләр
Сандугачлы төнне сагына.

Юллар тузанында күмелеп калган
Онытылган борма юл ята.
Кеше шулай булмаганны таба,
Ә булганны кайчак югалта.
Киләчәгем миңа нәрсә әйтер
Бабам васыятен онытсам,
Кан юлларым буйлап челтерәгән
Чишмә агышларын корытсам.
Юк, югалмас җирдә карурманың,
Эзелерлек түгел тамырлар,
Ерак-ерак киләчәктән килеп
Оныкларың сине танырлар.
Тау буеннан кайтып килгән чакта,
Әле генә күрдем үзләрен,
Минем кебек алар эзли иде
Йомылып калган чишмә күзләрен.
Бораулаучы көрәк тоткан... Сәер...
Куллар машинага өйрәнгән.
Бабаемның шатлык яше сыман,
Чишмә суы атылыр тирәннән.
Тавыш тизлегендә самолетта
Очкан чакта,
Идел ярыннан
Ишетермен сайрау, челтерәүләр...
Онытылмас бер көй: «Карурман».
Көйдән, сүздән, сайрау, нәкышләрдән
Һәйкәл коям.
Кемгә?
Бабама.
Кашкасының ялларыннан сыйпап,
Карап торсын балкыр таңнарга.
...Лирик чигенүгә нокта куеп,
Сикереп төшәм кашка атымнан.
Заман тизлегенә кушылам да
Китәм яңа җырлар артыннан.
Сүзләреңнең мәгънәләрен таптым.
Тыныч йокла.
Китәм.
Хуш, бабам.
Күпме генә биек менсәм дә мин,
Юк, егылмам хәзер,
ышанам!

Мәскәү, 1971

**Шакир Янбаев,**
башкорт язучысы

# ИКЕ БҮЛӘК

хикәя

## 1

Мәрхәбә апа Уфадагы кызы янына барып кайткач, сумкасын чоландагы иске-москы арасына чыгарып ташлады. «Һаман, элеккене куып, сине тотам да янына барам да керәм. Иптәшләре алдында оялгандыр». «Әни, шушы иске нәрсәне күтәреп йөрмә инде. Туган көнеңә яңаны алып биргән идем бит. Минем яныма шул сумкаң белән кил»,— диде. Үсте бит инде Нәфисәбез, ФЗӨда укып йөргән чагы түгел. Хәзер менә дигән тегүче, өстәвенә, эшен ташламый, кичке техникумда да укып йөри...» — дип, күңелен тынычландырырга тырышты Мәрхәбә апа.

Озак еллар буе файдасын күргән әйбердән аерылу, кадерле кешеңне югалткан сыман, авыр була икән. Чыгарып ташлавын ташлады да, ары үтсә дә, бире үтсә дә, күзенә чалынып, иске сумка йөрәген сызлатып тик торды. Әллә ни затлы да, бәяле дә түгел, кирзадан тегелгән гади генә кара сумка. Хәзер аның ишеләрне берәүнең дә кулында күрмәссең. Заманында да арзанлысы гына иде. Шулай да киштә астындагы агач чөйдә эленеп тормагач, өй ятим калгандай булды. Ахырда, бер чыкканда, Мәрхәбә апа иске сумкасын кире алып кереп, элекке урынына элеп куйды.

Кырыйлары искереп тишелә башлаган, авыр күтәрүдән бавы сузылып озынайган сумка, гыйнвар суыгыннан җылы өйгә алып кергәч, тирләп эреде. Су бөртекләре юл-юл эз калдырып агып төшкән чакта, ул өнсез генә елый төсле иде. Мәрхәбә апага гына шулай күренгәндер. Бу сумка аның өчен бик тә кадерле, истәлекле — өйләнешкән елны Ибәтулласы алып биргән тәүге бүләге иде.

Мәрхәбә апа аны ничәмә еллар инде эленеп торган агач чөйгә яңадан элеп куйды да, гафу үтенгәндәй, иске сумкага озак текәлеп утырды, җан дустына эч серләрен чишкәндәй, үз алдына сөйләнде. Әгәр теле булса, сумка да апаның сүзләренә кушылыр, бергәләп серләшер-гәрләшер иде. Әйберләрнең җаны да, теле дә юк шул.

Бу кара сумканың да әр-яңа чагы бар иде. Аны сатып алганда Мәрхәбә апа үзе дә яшь иде, күз тирәсе дә хәзергедәй җыерчыклар белән чуарланмаган иде. Янында, гарип булса да, ире Ибәтулла бар

иде. Мәрхәбә ананың үз гомерендә иң бәхетле минутлар кичергән чагы иде бит ул. Нигә шулай булмасын, сөйгән егете ут-сулар кичеп, тәненә ерак җирләр тузанын, авыр яу исен сеңдереп кайтып килгән иде. Мондый бәхет сирәк кыз-хатынга гына эләкте ул заманда.

Сугыштан кайтып килгән солдатны Мәрхәбә үзе ат җигеп станциягә каршы алырга төште. Авыл белән станция арасы ике чакрымнан артык түгел, дөньяның яртысын урап кайтып килгән солдат, өзелеп сагынган тугайларын, яланнарын карый-карый, сөйгән кызы белән җәяүләп җитәкләшеп кенә үтсә дә була иде. Мәрхәбә ат җигеп станциягә каршы алырга килде. Җилдереп кенә алып кайтыр өчен түгел, ике аягын да төптән сугышта калдырган Ибәтулласын утыртып алып кайтыр өчен җиккән иде атны.

«Күрәләтә башыңны кайгыга салма, гарипкә кияүгә чыгып гомерлеккә имгәк кенә алырсың. Мөгаен, кияү табылыр, хәзер сирәк кенә булса да егетләр кайта башлады бит инде»,— дип, Мәрхәбәнең юлына каршы төшүчеләр дә булды. Ибәтулланың әнисе Газизә әби, хәзер мәрхүмә инде, үзе арбага ястык чыгарып сала, үзе Мәрхәбәдән күзен алмый, аның һәрбер хәрәкәтен күзәтә. Менә Мәрхәбә ирләр сымак аягын терәп камытның чөелдереген ныгытып тартып бәйләде, аркалыкны күтәрде. Газизә әби алып килгән юкә дилбегәнең ике очын йөгәнгә ныгытып бәйләп куйды. Арбага сикереп менеп утыргач, инде дилбегә кагып атны кузгатам дигәндә генә, Газизә әби туктатты. Күңелемдә шикле төен булып калмасын, дип уйлагандыр инде, Мәрхәбәнең кулын кысып тотты да:

— Кызым, мин үз баламнан нинди генә гарип булса да бизмәм, бәгыремә басармын... Син соң яхшылап уйладыңмы? Соңыннан үкенмәссеңме? — дип ялварып сорады. Карт ананың газаплы карашында алмаш-тилмәш өмет белән өметсезлек нурлана иде.

— Минем аяк-кулларым бар бит, исән булсам, кеше алдында тилмертеп утыртмам,— дип җавап бирде Мәрхәбә, үзе кып-кызыл булды. Шушы минутта ул Ибәтулланы ташламаска күңеленнән генә ант итте. Станциягә кадәр озата килгән медсестра Мәрхәбәнең күзләренә сораулы караган чакта, биргән антын ул эченнән тагы кабатлады.

Ибәтулланы беренче тапкыр вагоннан күтәреп алып, арбага күчереп утырткан чакта, Мәрхәбәнең маңгаена кара кургаш сымак бөрчек-бөрчек тир бәреп чыкты. Көче җитмәгәннән түгел иде бу тир. Сугыш елларында ул юан-юан бүрәнәләрне дә күтәрде, алтышар потлы капчыкларны да җилкәсенә салып ташыды. Ир-ат көче бар иде аның йөрәгендә. Ибәтулланы күтәргән иде, аяк-кул буыны калтырады да төште. Җир селкетеп бит иде бит Ибәтулла! Аның аяк тавышы үзенә башка була торган иде. Шул аякларның җитезлегенә карап туя алмаган сөекле егетен кинәт сабый хәлендә күреп югалып калды Мәрхәбә. Ибәтулла, Мәрхәбәнең муеныннан кочаклап асылынган килеш, гаепле елмаеп, арбага килеп җиткәнче тын да алмый барды. Ястык өстенә җайлап утыргач кына:

— Фашист, каһәр, ярты гәүдәне өзсә дә, үзем ярыйсы гына авырмын, ахры,— дип шаярткан булды. Үзе моңсу күзләрен Мәрхәбәдән алмады.

Әйе, гәүдәне урталай өзсәләр дә, мәхәббәтне кылыч белән дә, утлы снаряд ярчыгы белән дә кыеп, көйдереп, өзеп-йолкып имгәтү һич мөмкин түгел икән. Мәрхәбә сугыш гарипләндергән егетенең күзләрендә мөлдерәмә тулы сөю җылысын тойды. «Гарип солдатка бәйләнеп, яшь гомереңне әрәм итмә»,— дип, акыл бирүче адәмнәр шушы минутта бик мескен булып күренделәр. Мәрхәбәнең беләкләрендә көч-куәт артты, йөрәге сөю дәрте белән ярсып типте. Ул станциядән кайтышлый ук, үзләренең йортына сугылып, урын-җир

әйберләрен алып чыгып тәяде дә, кешеләрне гаҗәпләндереп, Газизә әбинең йортына килеп булып төште.

Авыл халкы сугыштан кайткан солдат белән күрешергә килә башлады. Олысы да килде, кечесе дә килде. Ә араларында: «Ике аягы да төптән өзелгән кеше нинди икән?» — дип кызыксынып килүчеләр дә юк түгел иде. Түрдә ястыкка сөялеп утырган Ибәтулла мондый кешеләрнең нинди ният белән килүләрен күз карашларыннан ук сизеп ала, юрганны ачып, үзенең буш чалбар балакларын күрсәтә.

Атна буе ишек ябылмады. Килгән бер кешегә яшь киленнең самовары пар бөркеп кайнап торды, ул йөгереп йөреп сәкегә ашъяулык җәйде. Газизә әби улы алып кайткан ипине шикәр урынына шакмаклап бүлеп, һәркемгә авыз иттерде. Чынаякны каплап, кунакчыл йорттан чыгып киту белән төрле кеше төрлечә фикер йөртте, төрлечә кызганды.

— Ничек кенә кочаклап ятар икән Мәрхәбә ул месkenне? — дип гаҗәпкә калганнар да булды.

— Ибәтулла нинди пәһлеван егет иде, сабый бала хөкемендә генә торып калган икән шул...

— Сәкедән идәнгә дә үзе төшә алмый бит, күтәреп төшерәләр.

— Газизә әби үз гәүдәсен үзе чак йөртә, монда иң авыры Мәрхәбәгә төшә...

— Кирәк ташның авыры юк, дигәннәр. Беркем дә көчләп кушмады, үзе теләп тәрбияләргә алды...

— Әйе шул, үзе егылган — еламас, диләр бит...

Ташка уеп язган язулар да еллар үтү белән юыла. Ибәтулла кайтып төшкән көндә, аннан соң да, авылдашларының шушылай кызганып, гаҗәпкә калып сөйләгән һәрбер сүзе Мәрхәбәнең күңелендә әле дә булса онытылмый саклана. Баштарак кешеләрнең шушылай сөйләнүләренә бик рәнҗегән иде, «Безне чәйнәмәсәләр, эчләре поша микән?» — дип җаны көя иде. Уйласаң, гайбәт булмаган икән аларның сөйләгәне.

Бөгелеп төшәрлек чаклары бик күп булды Мәрхәбә апаның. Төннәрен Ибәтулланың сабый бала кебек буылып-буылып елаганын ишетмәмешкә салышып ятуы, аның кургаштай авыр гәүдәсен әллә ничә тапкыр күтәреп өйдән тышка, тыштан өйгә йөртүдән газаплырак иде. Иртән торуга Ибәтулланың төнге күз яше кызу мунча ташына салынган су кебек эзсез кипкән була. Шушындый вакытларда Мәрхәбә дә бирешсә, Ибәтулланың талчыккан күз карашында яшәүгә өмет нуры яңадан кабынып иде микән?..

...Ибәтулла, кайтып, дүрт ай чамасы торгач, аны Уфага протез алырга чакырдылар.

— Агач булса да, аяк аяк булыр әле, ишек алдында кыбырдап йөрергә булса да ярар. Болай бит синең ике аягыңа бик авырга туры килә,— дип, чиксез сөенде Ибәтулла.

Менә шул чакта, Уфага барганда, Ибәтулла үзенең яшь кәләшенә беренче бүләге итеп алып биргән иде шушы кара сумканы. Үзен бәләкәй арбага утыртып, вокзалдан тау өстендәге шәһәргә тартып алып менгән, урамнар буйлап йөрткән Мәрхәбәсенә әллә нинди эсыл-затлы бүләкләр алса да, аз сыман иде дә бит, тик сугыштан соң кибет киштәләре буш иде. Кара кирзадан тегелгән сумка да чиратсыз эләкми иде.

— Кирәкмәс лә, тотып чыксаң, авылда кеше көләр. Шәһәр бичәләренә генә килешә торган нәрсәне алмыйкчы,— дип тә әйткән иде Мәрхәбә. Ибәтулла учына йомарлаган акчасын сатучыга тоттырды.

— Бик тә җайлы нәрсә ул сумка дигәннәре, шәһәр халкы белмичә егылып алмый аны. Еллар тынычланып китсә, чәй-шикәр, прән-

нек-конфетлар чыга башлар. Менә шул вакытта шәһәр бичәләренә генә түгел, сезгә дә сумка бик килешер,— дип, яхшысын үзе сайлап алды.

Ибәтулланың шул чакта әйткәннәре дөрескә килде. Еллар имингә утырып китте. Газизә әбинең тау битләвендә утырган өенә дә ямь керде. Йорт хуҗасы агач аяклы инвалидмын дип нигез буенда тик утырып гомерен уздырмады. Елга буеннан сары тал кисеп китереп, ишек алдын читән белән уратып алды. Авылда беренче булып ул челтәрле капкалар да ясап утырткан иде. Үзенең йортында гына түгел, колхоз умарталыгында да Ибәтулланың оста куллары ясаган умарталар бал кортлары белән гүләп, дөньяны дәртле зыңлауга күмеп утырдылар. Ибәтулланың үзенең гомере кыска булды. Ярны ишеп ашаган су сыман түзәлмәс сугыш җәрәхәте аның саулыгын аяусыз кимерде. Корган дөньясын, өч баласы белән Мәрхәбәкәен ятим калдырып, бик иртә үлде Ибәтулла...

## 2

Ирсез калып, ялгызы гына балалар үстергән хатыннарның да шатланган чаклары була. Тик аларның куанычы ирле хатыннар шатлыгына охшамый. Мәрхәбә апа станциягә барып кайтсынмы, калага барып әйләнсенме, кулындагы сумкасы авыр булган чакта бигрәк сөенә иде. Станциядән авылга кадәр байтак җәяү атлыйсы бар. Өйгә кайтып җиткәнне көтмичә, Мәрхәбә апага балалары каршы йөгереп килерләр иде. Тау итәгенә ин алдан чәчен җилфердәтеп Нәфисәсе, аңа иярә Мидхәтне җитәкләгән Газизҗаны куш мунчак шикелле тәгәри. Бала бала инде. «Әни, юлың уң булдымы? Ни хәлдә кайтып киләсең? Армадыңмы?» — дип сорау кайда! Өчесе дә килеп җиту белән иң алдан кара сумкага килеп ябышалар иде. Шунда ук яшел чирәм өстенә утырып, балаларының шәһәр күчтәнәчен ашаганнарын карап, Мәрхәбә апа үзе дә куана, арып-талуларын көне буена авызына тәгам ризык капмаганын да оныта иде. Ибәтулла да бик бала җанлы иде. Нәфисәне биш яшеннән үзе укырга өйрәтте. «Кара инде, биш яшьлек бала да укуның кадерен белә. Алдагы көнендә илнең бер өметле кешесе булып чыксыннар, балаларны ничек тә укытырга тырышыйк!» дип, васыять әйткән шикелле текърарлар иде. Шушы теләге Мәрхәбәнең күңеленә сеңеп калсын дигәндер инде.

Балалар бик әирәк булып үстеләр. Нәфисә авыл мәктәбендә сигезенче классны тәмамлагач, кешеләр: «Үзеңә ярдәмче булыр, фермага эшкә бир»,— дип киңәш иткәннәр иде, Мәрхәбә аларны тыңламады. Бала үзе дә Уфага барып тегүче һөнәренә өйрәнергә диг омтылды. Бала газиз бит. Нәфисә ФЗӨ да укып йөргән чагында Мәрхәбә апа ай саен дигәндәй, маен, кортын, бәрәңгесен күтәреп, Уфага йөри башлады. Монда да, ишектән килеп керүе була, Нәфисә иң әүвәл шул авыр кара сумкага тотынып иде. Олы хәзинә сыман күреп, сумканы актара, күчтәнәчләрне өстәлгә чыгарып тезеп куя да иптәш кызларын сыйлый, түбәсе күккә тиярдәй булып шатлана иде бала.

Авызыннан өзеп, чебешләренә җим ташыган ана сыерчыктай ару-талуны белмәде Мәрхәбә. Икешәр пот бәрәңге булсынмы, сөтле авыр бидон булсынмы, иңбашына салыр да станциягә сатарга йөгерер иде. Кешеләр татлы йокыларыннан әле уянганда, ул инде сатарын саткан, балаларына кием-салыммы, чәй-шикәрме алып өлгергән була. Тизрәк кайтып балаларының тамагын туйдыра да колхозның корт бакчасына эшкә китә. Анда да Ибәтулласы башлаган эшне башкарыр өчен, бал кортларын карауучысыз калдырмас өчен җан

атып ашыга. Өч баланы иптәшләре арасында ким-хур йөртмәс, ятим күрсәтмәс өчен, шулай үңәче өзелә язып тырышты Мәрхәбә апа. Кайда гына барса да, кулыннан кара сумкасын төшермәде, Ибәтулласының төсе итеп, кадерләп йөретте. Авыр йөкне иңбашына салган чакта, сумка һәрвакыт күкрәге өстендә булды. Шушы кадерле бүләкне кочаклап атласа, әллә нинди авыр йөк тә җиңел тоела иде Мәрхәбә апага.

«Әй, бала! Энисенең иске сумка тотып килүен ошатмады. Шәһәрнең матур-матур киенеп йөргән кешеләре арасында ямьсез күренгәнмендер шул. Кабат сине оялтып, янына еш барып йөрмәм, балам, үстең бит инде, һөнәрле кеше булдың...» — дип, Мәрхәбә апа, агач чөйдә эленеп торган кара сумкадан моңсу күзләрен алмыйча, үз алдына сөйләнде.

### 3

Дөньяда баладан аерылудан да авыр нәрсә юктыр. Мәрхәбә апа бик сагынды Нәфисәсен. Элекке сыман күчтәнәчләр алып янына барып кайтырга әллә ничә тапкыр әзерләнеп тә беткән иде, әлеге шул сумкага тотынуы була, юлга чыгудан күңеле кайта. Ниһаять, түзмәде, «Хат аша сөйләшеп утырмыйм әле, Нәфисәмне күреп килим» дип, Мәрхәбә апа юлга әзерләнә башлады. Нәфисә өчен саклаган казны, майны, йомыркаларны келәттән алып керде. Мидхәт белән Газизҗан да тик тормады. Берсе иске китап битен ертып биреп торды, икенчесе күчтәнәчкә дигән йомыркаларны шул кәгазь битенә төрә барды.

— Мидхәт, Газизҗан, кирәк китабыгызны ерта күрмәгез!

Мәрхәбә апа балаларының үскән саен әтиләренә охшый баруына гаҗәпләнеп, җитез кулларына сокланып карап торды.

Малайлар әниләрен станциягә кадәр озата бардылар. Авыр гына күчтәнәч салынган яңа сумканы алар, алмаш-тилмәш күтәреп, Мәрхәбә апаның кулына тидермәделәр дә.

— Минем муенымнан да йөк төште лэбаса! — дип, ана ике кулын селтәп, кинәнә-кинәнә атлады. Улларының ялан тәпиләре сырлаган юлдан күзен алмый барды. «Җылы бөркеп яткан шушы аяк эзләрен Ибәтулла күрсә, нинди шатланыр иде. Үзем аяксыз булсам да, җирдә эзем җуелмас, балаларым дәвам иттерер минем юлымны, дип әйтә торган иде бит ул. Нинди алдан күреп әйткән. Әнә бит, бер түгел, ике Ибәтулла атлый бүген»,— дигән уй ана йөрәген горурлык хисләре белән җилкендерде.

Кызлар тулай торагына якынлашкан саен Мәрхәбә апа күрешү шатлыгын алдан тоеп, ашкынып атлады. Әллә беренче баласы булганга, әллә читтә яшәгәнгә, Нәфисәсен аерата якын күрә, сагына шул Мәрхәбә апа. Менә хәзер кызым йөгереп каршыма килеп чыгар, үзе бүләк итеп биргән яңа сумканы тотып килгәнемне күреп, бигрәк тә сөенер бала,— дип уйлый. Башка кешеләр сыман төз басып, кулыча өр-яңа матур сумка тотып, шәһәр урамнарыннан атлавы рәхәт анага. Шәһәр кешеләре генә түгел, моннан күп еллар элек ике аяксыз ирен бәләкәй арбага утыртып тартып барган яшь кенә Мәрхәбә дә, сөт, бәрәңге сатып өй борынча йөргән өч балалы тол Мәрхәбә дә бүгенге Мәрхәбәгә карап калалар төсле. «Иске сумканы өйдә калдырганга күңелең борчылмасын, яңа сумкаң менә нинди килешә үзеңә! Башыңны горур тот, син бит барлык авырлыкларны җиңгән кеше!» дип, әллә алар кычкырды, әллә Мәрхәбә апаның үз йөрәгендә шул шатлыклы аваз яңгырап ишетелде.

## Гамил Афзал

### Сабан туе

Күңеллләрдә горурлык
Тоеп йөрде бу яклар.
Өебез киң, табын мул,
Түргә узың, кунаклар!
Миллиард тонна алтынны
Коеп бирде бу яклар.

Иске уңыш искерде,
Яңа уңыш китерде.
Яңа уңыш шатлыгы
Өйгә кунак китерде,
Илгә бәйрәм китерде.

Каршы чыгып ал икән,
Өйдә ачы бал икән,
Кунак килә, кунак китә;
Үзең өйдә кал икән,
Өең тулы мал икән.

Дуслар сөйләр бер төрле,
Дуслар сүзе җанга үз,
Дошман сөйләр бер төрле,
Дошман сүзе — канга тоз,
Дуслар сүзе әйбәттер,
Дошман сүзе гайбәттер.

Типсәң тимер өзәсең,
Тимер чыңы үзеңдә.
Бассаң бакыр өзәсең,
Бакыр төсе йөзеңдә.

Балкып торган илеңдә
Җәен таңнар ал икән,
Кышын юллар кар икән...
Илен ташлап киткәннәр
Бер кайтырга зар икән.
Җирдә бәхет бар икән,
Безгә бәхет бар икән.

Илле бул да, җирле бул,
Җире юкның аты юк.
Атлы бул да, затлы бул,
Аты юкның заты юк,
Көче юкның хакы юк.

Җил җилләтеп килгәндә
Җилфердәсен тасмалар.
Җитен-ефәк үләндә
Тупырдашсын кашкалар,
Көч сынашсын башкалар.

Дәрәҗәң зур, эшең зур
Нефть чыккан якларда,
Алышларда Алыптай
Билең бирмә ятларга,
Серең бирмә ятларга.

Колгаларда сөлгеләр,
Сөлгеләрнең аклыгы!
Киленнәрнең күз нуры,
Күңелләрнең сафлыгы,
Җиңүләрнең шатлыгы.

Улың булса илгә бир,
Илең белән иш булсын,
Улың — имән тамыры.
Кызың булса иргә бир,
Ире белән иш булсын,
Кызың — бодай камыры.

Җирән атың ефәк ял,
Әкрен басып күп ала,
Яшь үләндә биеп кал,
Бәйрәм үткәч моң кала,
Киң аланнар тын кала.

Аяз күкләр зәңгәрдер,
Күк зәңгәре күзләрдә,
Аяз таңнар алсудыр,
Таң алсуы йөзләрдә,
Рәхмәт инде сезләргә!

Без кадаган байраклар
Җилфердәсен җилләрдә!
Нефть чыккан бу яклар
Куәт бирсен илләргә
Тыныч, якты көннәргә!

## Кояшка гимн

Ана кулы сөеп үстергән дә,
Киткән кеше тормыш юлыннан.
Бар гаделлек ана сөтеннән дә,
Бар яхшылык кояш нурыннан.

Хаоста бер тәртип булсын диеп,
Куркытып һәм алдап торсын диеп,
Уйлап чыгарганнар алланы;
Ә аллалар бик күп алдады да,
Ышанырлык алла калмады.

Ә син, Кояш, бөекләрдән бөек,
Алдаламый торган алла син,
Без зурлыйбыз сине башлар иеп,
Безнең җанда, безнең канда син.

Тереклеккә син сөйкемле ата,
Шәфкатең тиң газиз анага.
Карашыңнан гөлләр чәчәк ата,
Көлүеңнән җаннар ярала.

Синең алда Галәм — зәңгәр алан,
Күңеле киң күге биекнең.
Арыслан да синең газиз балаң,
Амеба да синең сөеклең.

Һәр күзәнәк хәлен хәлəл аңлап,
Һәр яралгы җанын тыңлыйсың.
Хәйлә корып,
Адвокатлар яллап,
Үз-үзеңне мактаттырмыйсың.

Ә син, Кояш, бөекләрдән бөек,
Алдаламый торган алла син.
Без зурлыйбыз сине башлар иеп,
Безнең җанда, безнең канда син,
Һәр вакытта безнең алда син.

## Үзем булып калдым

Гувернантлар карап үстермәде,
Француз телен өйрәтмәделәр.
Дугаларга кыңгыраулар тагып,
Ярминкәгә ияртмәделәр.

Бәхет юктыр диеп торган чакта,
Ярминкәдән кайткан җирән атта
Прәнникләр кайтты бер кесә,—
Бәхетләр бар икән югыйсә.

Хыял булып төшләремә керде
Кепка белән ялтыр күн итек.
Тәти чалбар өмет иткән җирне
Киндер ыштан белән хур иттек.

Чабатага салам олт ырак салып,
Арыш урып йөргән басулар
Күңел түрләрендә калды янып,
Ә таңнары нинди алсулар!

Даһи уйлар килмәделәр агып
Күнегү һәм үсү юлында.
Ярты гомер үтте хыялланып
Бәрәңге һәм ипи турында.

Ватан миңа йолдыз юрамады,
Тугрылык һәм бурыч хакында
Стенага терәп сорамады;
Күп эшләргә кушты вакытында.

Урап-урап Уралларда йөрдем,
Ерак калды инде Уральлар.
Гомер буе күз алдында күрдем,
Гомер буе уйларымда йөрде
Малай чагымдагы хыяллар,
Үсмер чагымдагы хыяллар.

Җәлү чаптым, элдертмәдем атта,
Гайрәт эчкә сыймый йөрмәдем,
Штраф та түләмәдем хәтта,
Суд ишеген ачып кермәдем.

Көйдермәде җәйнең эсселәре,
Өшетмәде кышның салкыны;
Офыгымда кыйблам көч өстәде,
Баш очымда йолдыз балкыды.

Кызыл нурга манып шәфәкъ янды,
Сары диңгез булды басулар.
Ак тастымал булып юлым калды,
Ә таңнары нинди алсулар!

## Болгар төне

Мин Болгарга килеп учак яктым,
Балык тоттым Идел суларыннан.
Яшь чирәмгә сузылып чалкан яттым,
Чал гасырлар узды уйларымнан.

Тимер дага белән илне таптап
Кемнәр үтте моннан, дала җиле?

Йолдызларга кара болыт каплап,
Ни сөйлисең миңа, Болгар төне?

Кара күктән кара болыт ага,
Болыт арасында көмеш тоткын.
Ярсый-ярсый Идел ярга кага,
Гөрс, гөрс итеп ярга бәрә дулкын.

Камышлар пышылдый яр читеннән,
Кипкән әрем кыштыр-кыштыр итә.
Иксез-чиксез каберләр өстеннән
Җилләр исә.

Вавилон да калган комга чумып,
Карфаген да үлгән кан-яшь елап.
Заман җилләренә сыртын куеп,
Җиргә сеңеп үкси Кара-пулат.

Изге ташлар ауный уңда-сулда,
Шәһәр булган җирдә буш далада
Бөкре карчык булып басып тора
Сыңар бармак кебек бер манара.

Вәйран булып ята үткән гомер —
Ничек бара моңа адәм кулы!
Нәрсә кирәк сиңа, Булат-Тимер,
Ни җитмәде сиңа, Чынгыз улы!

Бүреләрне канлы туйга дәшеп,
Барлык тере җанга ләгънәт укып,
Кылычларын, сөякләрен чәчеп,
Баскынчылар үткән агу йотып.

Ташлар арасыннан бер өн килде:
— Кадерләгез һәрбер гөлчәчәкне.
Үткәннәрне таптадылар инде,
Таптатмагыз асыл киләчәкне!

## Юл буйлап

Юл буе, болыттай тузаннар.
Тузанда кырыклап өй тора.
— Ни дигән авыл бу, оланнар?
— Колчура бу, абый, Колчура.

Басулар читендә урманнар
Тирбәлә офыкта күгәреп.
— Ни дигән авыл бу, туганнар?
— Колшәрип бу, энем, Колшәрип.

Бормалы су буйлап үтә юл,
Су буйлап утырган зур авыл.
— Ни дигән авыл бу, бабакай?
— Каракол бу, улым, Каракол.

Баш иеп, бил бөгеп, бик тирән,
Татарга кол кереп утырган...
Бу якты көннәргә китергән
Тарихның юллары чытырман.

## Шигырь

Син — йөрәктән янып чыккан очкын
Гимн булып илгә атылдың,
Син дөньяга дога булып чыктың,
Утка кердең,
Яуга чакырдың.

Син — йолдызлы кич һәм серле иртә,
Таң җилләре сине иркәләр;
Чын шагыйрьләр сине байрак итә,
Кәсепчеләр ыштыр итәләр.

## Кичке этюд

Көн сүрелде.
Яшькелт һава җиләс,
Иренеп кенә эңгер таралыр,
Тупыл башларына тияр-тимәс
Күк болытлар ага каядыр.

Яфрак шавын сөйләп тирә-якка
Төн буена җилләр йөрерләр.
Тәрәзәне кага шундый чакта
Киткән дуслар,
Үткән гомерләр.

●

Бер-берсенә теләп үлем, газап,
Тозак-аулар ясап,
«Кеше» дигән хәшәрәтләр яши
Берсен-берсе ашап.

Кулы белән күккә йолдыз чөеп,
Пәйгамбәрдән бөек,
Кеше дигән гали затлар яши
Берсен-берсе сөеп.

## Тынлык

Уйный-көлә, күңел ача яшьләр
ямьле чаклар кебек.
Көтмәгәндә ярып яшен яшьнәр,
дөнья чатнар кебек.
Таң җилене уҗым дулкыннары
гөжли, кайный кебек,
Күңел сизә дөнья сулкылдавын,
тынлык алдый кебек.

## Туктама

— Алга бар,
Кыю бар,
Кызу бар! — диләр,—
Бик сүлпән киләсең син йоклап.
— Иптәшләр,— димен,— мин машина түгел бит,
Тын гына алыймчы бер туктап!

Әйтәләр иптәшләр:— Туктасаң пост кала,
Бу сафта урының буш кала,
Көрәштән туктаган — көрәшче түгел ул,
Туктама!
Туктама!
Туктама!

## Эч пошканда үзтәнкыйть

Үз җанымны тентеп, теге-бусын
Карап чыктым шырпы яндырып;
Ник бер генә юньле фикер булсын
Каләм белән чукып алырлык!

Күңел ята тук сыердай пошмас,
Кибәк-фәлән иснәп пошкыра,
Ми сырына кысылып, төшәр-төшмәс,
«Ахмак» диган бөек сүз тора.

●

Ерак карап,
Упкын чите буйлап
Барасың син, юллар ярасың да,
Халкыңа бер эш эшләргә уйлап,
Кыя белән упкын арасында.

Курку бетә анда,
Хәвеф үлә,
Йөрәктә дәрт-дәрман табасың да,
Күкрәк киереп бер җырлыйсы килә
Әҗәл белән тормыш арасында.

●

Матур залда
Шигырь сөйләгәндә
Шатлыгыңны меңнәр бүләдер;
Ачы җилләр искән шомлы төндә
Йолдыз булсаң иде кемгәдер.

Аяз күкле гомер бакчасында
Күбәләктәй көннәр көләдер;
Убылганда,
Упкын якасында
Терәк булсаң иде кемгәдер.

≈≈≈≈≈≈

Мөхәммәт Мәһдиев

# ФРОНТОВИКЛАР

РОМАН

Мәктәп ишек алдыннан чыкканда гына ул каршысына директорның килгәнен күрде. Димәк, мәктәптә кичен нишлиләр дип, тикшеренеп йөри. Тукта! Беренче танышканда ук директор нәрсә дигән иде?

— Аракы эчәсеңме? Ә хатыннар мәсьәләсе ничек? Тол хатыннар монда буа буарлык!

Менә жылы көе генә эләгүең кайда буласы икән! Секундлык каушау моментында үзеңне кулга ала алмасаң — беттем диген. Рушад караңгы урамның бер читендә койма буенда басып калды. Директор, әлбәттә, аны күрмәде.

...Язның чынысы каникул беткәч башланды. Ике-өч көн туңдырып торды да каникулның соңгы көнендә кинәт жылы яңгыр явып дөньяны су басты. Шәмсетдинов каникулны ашыгыбрак ясаганын белде — ләкин эш үткән иде инде. Иртәгә уку дигән көнне Казаннан Нәркис кайтып төште, мәктәпкә, авылга ямь керде. Нәркиснең битен язгы җил ашаган, борын очына асылташ тузаны кебек ике-өч бөртек вак сипкел төшкән. Аның дәресләре күбрәк мәктәпнең икенче катында була иде, кояшлы көндә ул берөзлексез су буена карап дәрес алып барды.

Су буенда ул көнне боз кузгалган иде.

Дәресләр беткәч, мәктәптә беркем калмады. Бөтен халык тегермән буасына китте. Бозлар чатнавыннан, аларның гөрселдәп субайларга килеп бәрелүеннән кешене кеше ишетерлек түгел. Зур боз кисәкләре өстендә район үзәгеннән килгән шартлату командасының солдатлары чабышалар, алар янында яланбаш, гимнастеркадан Хәкимҗан кайнаша. Дөнья тетрәтеп һавага зәңгәр боз кисәкләре оча, су баганасы күтәрелә, шул гарасатка сискәнеп авыл өстеннән каргалар, чәүкәләр өере очып китә, сыерлар кычкыра.

Нәркис буа кырыенда, кешеләрдән читтәрәк басып торды. Аның өстендә затлы кыска куртка, аягында озын кунычлы ботылар иде. Субайлар арасында ватылган боз кисәкләре буадан агып чыгалар да иркен болында мәһабәт кыяфәттә борыла-борыла еракка юл алалар. Нәркис монланып аларга карап кала.

---

Дәвамы. Башы 1, 2 саннарда.

— Их, нигә мин кеше булып туганмын, нигә әнә шул боз кисәге түгел,— дип шаярып, янына килгән Нәсимәгә ул сүз катты.

— Абау, ни сөйлисез сез, Нәркис апа,— дип, беркатлы Нәсимә күзләрен зур итеп карады.— Боз эри дә бетә бит ул! Ә сезнең әле иң бәхетле, иң рәхәт чагыгыз!

— Бәхетле? Һай, сеңелем! Бигрәк яшь инде үзен... Бигрәк саф. Әнә шул бозларга башны салып агып китәргә иде. Еракка-еракка агарга иде...

Нәсимә бүтәнчә сорау бирмәде. Чөнки Нәркиснең күзләренә карады — аның күзләре дымлы иде.

Бу дөньяны белмәссен! Нәсимә семьяда иң өлкәне, бердәнбер акча табучы. Быел җәй ул читтән торып укырга институтка керергә уйлый, насыйп булса, бәлки, башлангычка укытучы итеп тә алырлар. Аның өстендә күн якалы зәңгәр сырма, яшел бумази чалбарының балакларын лыпылдатып кыска ботылар киеп куйган. Аның өчен Нәркис — принцесса, хан кызы. Шул кеше дә язгы бозлар белән агам дип сөйләгәч, Нәсимә нинди бозлар белән, кая таба агарга тиеш?

Кичке салкын сизелгәч кенә буа яныннан таралыштылар. Авыл урамнарыннан чурлап гөрләвек ага, тополь башларында томшыкларын суыра-суыра сыерчыклар сайрый иде. Сыерчык бер тыңласаң чут-чут итә, икенче тыңласаң бака булып бакылдый, үрдәк булып кычкыра. Тагын томшыгын суыра-суыра сайрый. Сыерчык — язның патшасы, гөрләвек аккан атнаның бөтен музыкасы, бөтен матурлыгы, бизәге — сыерчык томшыгында була. Менә карлар эреп бетәр, сыерчыклар балага утыра башлар, ул вакытта кошлар җитдиләнеп китәләр, мондый концертлар сирәкләнә. Сайра, сыерчык, сайра! Син — дөньяда иң серле итеп сайраучы кош! Халык хәтта сине үзенең җырларында да телгә алмый. Чөнки сине аңлавы кыен. Син шатланасыңмы? Кайгырасыңмы? Тополь башыннан каһкаһа белән көлгән тавыш ишетелде.

— Каһ-каһ-каһ-каһ...

Бу — сыерчык. Ул Нәркистән көлә. Нәркиснен хәле көлке. Кичә ул Казан белән саубуллашып килде. Ихтимал, мәңгегә. Нәркис анда торырга кайтмаячак. Тик паспортта гына никахның билгесе калды. Көлке бит! Кияү куенына кермәгән көе кияүгә чыккан дигән печать сугылган. Көл, сыерчык, көл! Нәркиснең яшьтәшләре фронтта кырылып беттеләр. Алар белән бергә мәктәп тәмамлаган егетләрне дөнья пыран-заран китерде. Университетны тәмамлаганда да аудиториядә егетләр саны гадәттән тыш аз иде. Тегенди-мондый авырулар, сугыш инвалидлары. Нәркис үзенә иш тапмады, шәһәрдән китәсе килмәде, шуңа күрә ОРС базасында эшли торган көмеш тешле Җәүдәт белән таныштыргач, каршы килмәде, беткән баш беткән дигәндәй, язылыштылар. Ләкин язылышып кына куйды, егет белән кыз шикелле киноga йөрделәр, аерым яшәделәр. Җәүдәт киноны бик ярата иде — анда килгәч ул, һичшиксез, буфетына керә, Нәркискә мороженое ала, аны култыклап кына йөртә. Җәүдәт надан егет тә түгел: бөтен яратканы — детектив әдәбият. Бу мәсьәләдә ул университетта диплом язып йөргән Нәркисне төп башына утырта ала. Шулай. Җәүдәтләр бай яшиләр, өйләреннән борылып чыгарлык түгел — барысы да бар. Нәркис бу байлыкны күреп йөрде, аңа дигән алтын әйберләр, аерым бүлмә, көмеш кашыклар барысы да киленне көтә иде. Барысы да бар, тик мәхәббәт кенә юк иде. Нәркис бер елдан кайтырмын дип тимер юлга якын авылга җибәрүләрен сорады. Министрлыкта югары белемле рус теле укытучысы алтын бәясенә йөрерлек чор иде, кадрлар бүлеге мөдире аның алдына Татарстан картасын куйды.

— Җаныгыз теләгән урта мәктәпне сайлагыз, үзем телеграмма бирәм, станциядә директор үзе каршы алыр,— диде.

Министрлыкның баскыч төбендә аны Җәүдәт каршы алды. Нәркиснең кулындагы приказны күргәч, Җәүдәтнең күзләре яшьләнде, ул дәшмичә генә озак итеп Сөембикә манарасының очына карап торды.

Нәркис тә шатлана алмады. Бу минутта алар икесе дә бәхетсез иделәр.

Менә бу каникулда инде күпер яндырылды, кияү белән бәйләнеш өзелде. Җәүдәт бөтен байлыгына карап Нәркис алдында елады:

— Менә болар бөтенесе синеке, аерылма,— дип ялынды.— Нужели шул сала мужиклары арасында каласың син? Моның булуы мөмкин түгел...

Бу драма әле өченче көн генә узды. Нәркисне ул көнне поездга карт әнисе, буй житкән ике сеңелесе озатып куйдылар.

Никахлы кәләш. Кияүсез хатын. Сыерчык әнә шуннан көлә. Тополь башында оча-куна көлә.

— Ка-ка-ка-ка!

Еларга, еларга иде хәзер, күз яшьләрең дәрья булып бөтен хәсрәтеңне алып китсен иде. Шул дәрьяда үзең дә йөзеп кит идең, тыныч, кешесез яр буена чык идең. Юк, анда бер генә кеше булсын иде — ул сиңа елмаеп кулын биреп торсын иде. Мәсәлән, кем? Рушад! Әйе, әйе, шул булсын иде! Их, менә хәзер янында шул егет булсын иде, бөтен тәрҗемәи хәлеңне шуңа сөйләргә иде. Ул егет нигә астыртын икән?

Нәркис капка баганасына сөялде. Башы әйләнеп китте. Урамнан Рушад килә иде. Ул туп-туры Нәркискә таба атлады. Шактый кыю.

— Шәһәрдән килгән ука башмаклы кызга кичен суда ут җибәргәнне күрсәтер идем мин, мөмкин булса,— дип, чәнчеп сүз башлады.

— Ә нинди су да нинди ут ул?

— Боз кисәгенә салам салып ут төртәләр дә агызып җибәрәләр. Боргалана-сыргалана су юлыннан бара. Кызык... һәм сезнең кебек барышнялар өчен романтично!

Нәркис аңа рәнҗеп карады.

Рушад йомшады.

— Бер сәгатьтән, ягъни егерме сәгать ноль-нольдә мин нәкъ шушы причалга килеп швартоваться итәр идем. Билгеле, сезнең тарафтан «добро» булганда гына.

Мондый кәжүнни җөмләләр Нәркиснең җанын каһәрләде, җәрәхәтле күңелен рәнҗетте.

...Кичке сигездә алар тегермән күпере аркылы елга аръягына чыктылар. Тау башындагы тигез урында инде сызык уйнарлык булып җир кипкән иде. Аста — авылның елга буена сузылган ике озын урамы. Болынга җәелгән дәрьяда авылның утлары җемелди. Бөтен дөньяны бер генә төрле тавыш баскан: ул — язгы ташу тавышы. Күп тавышлы, серле, куркыныч тавыш. Кичке караңгылыкта бөтен тыкрыклардан, басу кырыннан төшкән гөрләвекләр чурлый, вак чурлау тавышлары елганың мәһабәт, салмак шавына килеп кушыла. Кичке һава биткә әле җылы катлам, әле салкын катлам булып бәрелә. Авыл урамыннан, мәмердәгән бәрәңге бакчаларыннан, абзарлардан җылы һава күтәрелә, шунда ук түбәндәге бозлы, болганчык ташу суының салкыны үзен сиздереп куя. Узган елдан калган үлән дымлы кара җиргә изелеп сеңгән — тау башындагы бу урынга әле утырып булмый. Рушад сүзсез генә барган Нәркисне култыклап алды. Кемдер нәрсә турындадыр сүз башларга тиеш иде — шуны көтеп тау өстендә йөрделәр. Ниһаять, тегермән буасы янынннан ут җибәрделәр. Куркыныч, тылсымлы әкиятләрдәге кебек караңгы күккә ут шәүләсе инде. Аста берсе кычкырып җибәрде:

— Һа-лә-лә-ләү-ү-ү! Ут килә, у-у-ут!

— Менә,— диде Рушад,— карап калыгыз: безнең як халкының гасырлардан бирле килә торган бер күңелле уены бу. Боз киткән көнне ел саен бер кич шундый иллюминация була...

Икенче бер бакча артыннан тагын ут салдылар. Башка урыннардан да бер-бер артлы шундый утлар чыгып киң болынга таба юл алды. Утларның кайбере елганың үзәгенә килеп чыга да кызу гына узып китә, кайберләре агымның кырыена чыгып әйләнәләр, бөтереләләр, кире китәләр, бер-берсенә барып кушылалар, салмак кына аерылышалар. Аларның яктысыннан астагы тирән карангылыкта әллә нинди куркыныч, сихри тамаша ясала. Ул арада берсе тальян уйный башлый.

— Менә музыкасы, бутафориясе — бөтенесе дә бар,— диде Рушад. Нәркис бу тамашадан бик хисләнеп аның беләгенә елышты, йотлыгып түбәнгә карады.

— Әйе, барысы да бар. Мин моны үз гомеремдә беренче күрәм. Караңгы пычрак язгы төндә, авылда шушындый күренеш була алыр дип башыма да китергәнем юк иде. Беләсезме, нәрсә? Әйдә иң башта бер нәрсәне килешеп куйыйк әле: миңа «син» дип дәшә аласыңмы? Һәм баягы төсле чәнечмичә генә дә?

Рушад шатланып аның кулын учына алды.

Нәркиснең нәзек бармаклары салкын иде. Рушад шаярып аларны өрә-өрә җылыта башлады. Кыз моңа каршы килмәде.

— Беләсеңме, нәрсә? Мин гомер буе операга йөргән кеше. Ләкин бервакытта да мондый декорацияне күргәнем булмады. Менә композитор, художник, шагыйрьгә азык: әнә теге якка кара әле... Әнә ике ут ничек бөтереләләр...

Нәркиснең хисләре кузгалган иде, кызлар белән сөйләшергә осталыгы булмаудан күп җәфа күргән Рушадка бу хәл бик ошады. Кыз тал чыбыгына кунган сандугачтай сайрый иде.

— Телисеңме, мин хәзер шагыйрь булам? Юк, шагыйрь түгел, ә шигырь сөйләүче булам. Әнә тыңла әле дулкыннар тавышын. Ә гөрләвекләр, гөрләвекләр... Тукта, дәшмә, тукта. Әнә табигать шигырь сөйли.

Ул Рушадның беләген кысыбрак тотты да түбәнгә, авылга карап шигырь әйтә башлады.

> У берега сонных вод один бродя случайно
> Прислушайся душой к шептанию тростников,
> Дубравы говору; их звук необычный,
> Почувствуй и пойми... в созвучии стихов
> Невольно с уст твоих размерные октавы
> Польются, звучные, как музыка дубравы.

— Ә син беләсеңме Горькийның шагыйрь дә булганын? Юкмы? Мин сиңа бүген аның бер шигырен укырмын. Ул шигырь минем сиңа әйтәсе бер сүзем булыр. Ә монысын Аполлон Майков язган. Мин аларны күңелдән беләм. Майков, Тютчев, Фет, Некрасов, Блок, Багрицкий, Есенин, Маяковский... Барысын да яттан беләм.

Ут Рушадка елышты. Егет дәшмәде, тәмәкесен чыгарды. Нәркис аның ике кулын да алып үзенең битенә куйды.

— Мин барысын да яттан беләм, аңлыйсыңмы шуны? Ишетәсеңме? Мин тик бер генә нәрсәне белмим: син нинди кеше? Нигә йомык син? Нигә сөйләшкәндә син миңа чәнчеп сөйләшәсең? Ни өчен минем күңелемне рәнҗетәсең?

Рушадның шундый гадәте бар: дәшми йөри-йөри дә, бер башласа, җайлы-җайсыз әйтә дә бетерә. Бу юлы да шулай булды.

— Тукта, сеңелем, тукта! Аз гына мин дә әйтим. Ике фронт дигән нәрсә бик хәтәр бит ул. Әнә Гитлер абзаң ничек булды...

— Ә син нәрсә беләсең минем турыда? Ә?

— Юк, берни дә белмим болай, ләкин Вахитов станциясендә бер чибәр егетнең сине ничек итеп озатып куйганын гына вагон тәрәзәсеннән күргән идек. Гата белән.

Нәркис телсез калды. Кулларын ычкындырды. Аннан кинәт кенә Рушадның күкрәгенә башын салды. Рушадның аркасына тир бәрде. Тукта, бик күпкә китте бит әле бу, шайтан алгыры. Минә Гата белән берәү дә болай сөйләшмәс. Мәсрүрә белән булган хәлдән әле айнып җиткәне юк. Никадәр уңайсыз. Болай гына симпатия белдереп йөрү күңеллерәк түгелме соң? Хәзер бит я — дус, я — дошман. Ә бу сон эгоистлык түгелме? Куркаклык түгелме? Мәхәббәттә нинди исәп булырга мөмкин? Син бу кызны күптән ошатып йөрисең түгелме соң? Сине нәрсә тота? Казан егетеме? Әйе! Флот сине нәрсәгә өйрәтте? Намуслы булырга! Сугыш үзе — намус эше иде. Син зурысында намусыңны сакладың. Ә кечесендә? Ерак тор бу кыздан, старшина, көмеш тешле егетнең бәхетенә кермә!

Көмеш тешле егет исенә төшкәч, Рушад бөтен тәне белән өстендәге пальтосының авырлыгын сизгән сыман булды. Кызык! Аполлон Майков... һәм Сорочида алыш-биреш итү... Иң яхшысы — кызны газапламаска. Әйтәсе килсә үзе әйтсен, ә сорау бирмәскә. Һәм, аннан соң, гомумән, мондый нечкә тойгыларга бирелмәскә. Менә җай җитәр, читтән торып укучы студент бит син! Мәхәббәт кая да чурт кая! Синең эшмени болай йөрү...

— Их, син, эгоист... Эгоист бит син.— Нәркис яңагын Рушадның иреннәренә тераде. Аның бите юеш иде.— Кая инде ул кешене аңлау сиңа. Мин бит сезнең арада иң комедиячел кеше. Чибәр егет — минем ирем бит ул, белдеңме?

Фу, шайтан! Рушад эсселе-суыклы булып китте. Культуралы, нәзакәтле бу хатынны кинәт кенә шушында ук сугып очырасы килде. Менә шушыннан ук сугып җибәр идең дә, теге астагы дәрьяга очып барып төшсен дә теге утлар белән агып китеп юк булсын иде! Шуның белән бу газаплы әкият тәмамланыр иде һәм кайтып ятып йоклар идең...

— Минем ирем бар иде, белдеңме шуны, эгоистым минем! Ирем бар иде! Мин уңай герой белән яшәгән кеше. Әчми, тартмый. Гата белән синең шикелле түгел. Сез бит юньсезләр! Ял көне саен авыз итми калмыйсыз, мин бит сизәм. Ә минеке — бер тамчы да капмый! Ха-ха-ха!

Нәркис кайнар иреннәре белән Рушадның авызын томалады. Шул вакыт яшь фронтовик югалып китте. Дөнья әйләнде, йолдызлар йөгерештеләр, борынга бик нечкә, бик тә исерткеч пудра исе килеп бәрелде — Рушад күзләрен йомды.

— Минем ирем — уңай герой! Аракыга, тәмәкегә акча әрәм итә алмый ул. Аңа йөрәге җитми аның. Минем тормышым — комедия. Мин Майковны күңелдән укыйм — ә ирем акчаны «почмак», «багана» дип сөйләшә! Майков һәм чумара! Бездә кызык! Калай түбә — күн бүрек дигән сүз. Суык тәпи — базарда кеше кесәсенә керүче дигән сүз. Дүкәш — ике сум! «Шухыр» — милиционер килә, кач дигән команда!

Кыз онытылып тагын үбәргә тотынды.

— Рәхмәт сиңа мондый кичтә мине дөньяга алып чыгуың өчен! Сау бул, мәңгегә хуш, сөеклем минем! Мин әнә шул паспорттагы ирем белән аерылыштым өченче көн. Бүген синең белән аерылышам. Мин — Ганнибал. Күперләрне яндырырга яратам. Мин шәһәрне ташладым. Авылда яшим, шушында кияүгә чыгам. Ләкин сиңа түгел, курыкма! Ха-ха-ха!

Аптырагач Рушад та көлде.

— Сиңа түгел. Без беркайчан да килешә алмаячакбыз. Бераздан бездә бер-беребезгә нәфрәт тууы бар. Мин кара куллы крестьян егетенә чыгам. Интеллектуальлектән минем күңелем бозыла хәзер. Миңа саф күңелле егет кирәк! Ул мине яратса — шул җиткән! Миннән — ихтирам, яратканы өчен. Ә бәлки — мәхәббәт тә.

Кыз елый-елый Рушадны үпте. Ул калтырый иде. Рушад аны пальтосы эченә алды. Кыз тынычланды. Аннан йокымсырагандай итте дә акрын гына үзенең Җәүдәт белән булган хәлләрен сөйләп бирде. Аның

сөйгән егете, мединститут студенты, фронтта үлгән. Рушад аңа охшаган икән. Кыз, кара шинель киеп Рушад мәктәпкә килеп кергәннән бирле, тынычлыгы югалганлыгын әйтте. Барын да сөйләде. Аннан яңадан калтырап кайнар яшь койды да Рушадның куеныннан чыгып каршысына басты, Горький шигырен укый башлады:

— Прощай! Я поднял паруса
И встал со вздохом у руля...
И резвых чаек голоса
Да белой пены полоса —
Все, чем прощается земля
Со мной... Прощай!

Мне даль пути грозит бедой,
И червь тоски мне сердце гложет,
И машет гривой вал седой...
Но — море всей своей водой
Тебя из сердца смыть не может!
О нет!.. Прощай!

Рушад нишләргә дә белмәде. Моңарчы бу кызның язмышы, хисләре белән җиңелчә генә шаярып йөрүе аңа җинаять булып тоелды. Юк, бу кыз иң бөек мәхәббәткә лаек! Шекспирлар, Тургеневлар язган тугры, пакь, бөек хисләргә генә лаек бу! Ә син үзеңнең тупас ботинкаларың белән кызның хисләренә басып кереп аның шәхесен рәнҗеткәнсең. Янәсе, син авыл егете, син гади бер матрос, ә бу — шәһәр аристократы, профессор кызы!

— Миңа тормыш итү өчен таза нервлы крестьян егете кирәк. Минем сәламәт бала үстерәсем килә, белдеңме шуны? Тик — ул егет сезнең кебек фронтовик булсын. Фронтовиктан башка кешене мин якын итә алмам...

Кыз тагын кайнарланды, пышылдауга күчте.

— Бүген мин яшьлек белән саубуллаштым, бу минем соңгы кичем, соңгы егетем, соңгы үбүем...

Ә Рушад өчен бу — беренче иде.

Авылда инде утлар сүнгән, елга буенда да ут җибәрүчеләрнең тавышы ишетелми, төнлә туңдырганлыктан, гөрләвек тавышлары да тынган иде. Бер төрле хис белән килделәр, бөтенләй икенче уй белән кайтып баралар. Нәркис — елаганнан соң бушанып, җиңеләеп калган. Рушадны исә әллә ниткән авыр уйлар баскан иде.

Нәркисләрнең капка төбенә җиткәч, Рушад аның кайнар битләреннән үпте. Нәркис шул хәлдә озак торды, берөзлексез Рушадның чәчләреннән, яңагыннан сыйпады. Кесә фонареның яктысы боларның битенә бәрелгәч кенә айнадылар. Урамның теге ягында чырык-чырык килгән тавыш ишетелде. Димәк, күзәтеп йөргәннәр. Я, ярар, авылда шунсыз булмый инде.

Рушад төне буе саташып чыкты. Тәндә әллә нинди, моңарчы бер дә татылмаган рәхәтлек сизелә, ә йөрәк нәрсәдәндер сызып-сызып ала иде. Тизрәк таң атсын иде, тизрәк аны яңадан күрергә иде, коридордан узышлый гына булса да аңа бер иркәләү сүзе әйтергә иде...

Иртән ул башы чатнаган хәлдә мәктәпкә килде, дәрес планнарын шунда утырып төзеде. Баш авыртуы — укытучының иң еш юлдашы инде. Әнисе шулай дип сөйли. Бу авыруның нәрсә икәнен мәктәптә икеөч кенә укытучы белми кала, имеш: җыр, физкультура һәм рәсем укытучысы...

Нәркис дәрес башланырга биш минут кала гына укытучылар бүлмәсенә килеп керде, аның күзләре зураеп калган кебек иде. Аның да башы авырта, ахрысы. Журналын алды да бер кочак дәфтәр күтәреп класска кереп тә китте. Ул кереп киткәч тә звонок булды.

Класста ни өчендер гадәттән тыш җанлылык иде. Бичара шәһәр кызы! Авыл малайларының психологиясен син беркайчан да бөтен нечкәлеге белән аңлап бетерә алмассың! Малайлар ыгы-зыгы киделәр, нигәдер күбесенең авызы ерык иде. Ул арада берсе кычкырып сорау да бирде:

— Апа, ут җибәргәнне карадыгызмы кичә?

Икенчесе ярдәмгә килде:

— Кая инде төн уртасында шуны карап йөрсен! Караңгыда йөрергә пычрак бит...

Галәвиев эре тешләрен күрсәтеп мәгънәле генә көлде.

— Гы-гы-гы-гы...

Нәркис барысын да аңлады. Кичәге фонарь хикмәте бу. Галәвиевне тактага чыгарды. Тегесе материалны әйбәт белә икән. Нәркис икеле куеп бер ачуын басармын дигән иде — булмады. Шулай да әйтеп торып бер җөмлә яздыртты да анализ ясатты. «Что ты ржешь, мой конь ретивый!». Кычкырып укытты. Галәвиев, әлбәттә, моның иронияссен аңламады.

Шул көннән соң Нәркис йомылды.

...Авыл бакчаларында кызгылт бакыр төсле иң гади күбәләкләр була. Алар көннең әллә ни вакытында, әллә каян гына тәрәзә төбендәге гөлләргә кереп куналар да пыр-пыр очып ярты көн уйныйлар. Аннары канатларын йомалар. Һәм шуннан соң инде аларны бернинди нурлар, җылылык, наз белән дә ачтыра алмыйсың. Тәрәзә рамына ябышып, җилгә дерелдәгән кара яфрак сыман алар көзгә хәтле утыралар...

Дәрес беткәндә күк йөзен болыт каплаган, сыек соры болыт тегермән буасы артындагы тау белән тоташкан, су буендагы карт тирәкләргә кереп чорналган, урамнарга ишелеп-ишелеп төшкән иде. Яңгыр ява, җылы, шифалы ләйсән яңгыры күңелләргә рәхәт биреп тавышсыз гына сибәли, калган карны эретә, чыккан җирне пешерә — тук, икмәкле, имин җәй вәгъдә итә иде. Бөтен дөньяны кара балчык исе — җир исе алган, моңа борыннар рәхәтләнә, үпкәләр киңәя сыман, сулаган саен кыш буе йоткан мәктәп тузаны үпкә юлларыннан тышка чыга сыман... Дөньяда язны күрер өчен генә дә яшәргә ярый!

Авыл язын Нәркиснең беренче күрүе иде, шуңа күрә урамга чыгуга аның башы әйләнде, ул җир исен дә тоймады, ә ниндидер сихри балет декорацияләре арасында йөргәндәй, яңгыр пары астында өенә таба атлады.

Өенә кайткач, Толстой томнарыннан ашыга-ашыга нәрсәдер эзләп тапты һәм көндәлек дәфтәренә болай дип күчереп язды:

«Гомер буе өзлексез борчылу, авыр хезмәт, көрәш, югалтулар — болар бер генә кеше дә, бер генә секундка да алардан читкә тайпылуны уйларга кыймаска тиеш булган зарури шартлар. Намуслы яшәр өчен ашкынырга, буталырга, азапланырга, ялгышырга, башларга һәм ташларга, яңадан башларга, яңадан ташларга, өзлексез көрәшергә һәм мәхрүмлекләр кичерергә кирәк. Ә күңел тынычлыгы — рухи намуссызлык ул».

Тышта шифалы яңгыр — ләйсән ява иде.

## XIII

Укытучы булу өчен берәүләргә еллар кирәк, икенчеләргә айлар... Сез беләсезме, укытучы кайчан чын мәгънәсендә укытучы булып җитә? Дәрес биргәне төшенә керә башлагач. Укытучының төшенә бары тик бер генә сюжет керә: дәрес башланасы икән. Укытучы әнә шул дәресенә хәзерләнмәгән. Менә-менә звонок булырга тора. Ә моның планы юк. Директор ишек янында моның дәресенә керергә көтеп тора. Ә план юк

та юк. Завуч (алланың иң ачы телле бәндәсе!) моның планы юклыгын күптән белә, шуңа күрә зәһәр елмаеп расписание янында басып тора. Эләктеңме, янәсе... Менә бөтен сюжет шул. Кайвакытта сюжет тагы да фаҗигалерәк була: укытучы планын тәмамламаган көе генә дәрескә кереп китә, укытып азаплана, ләкин дәреснең ниндидер бер моментында иң арткы рәтләрнең берсендә утырган инспекторны күреп өнсез кала. Укытучының бөтен тәненә электр тогы йөгерә, йөрәк эшчәнлеге начарлана, башы түнә... Ә инспектор урыныннан торып, укытучы өстәле янына килә дә тегенең якасыннан тотып:

— Дәрес планыңны күрсәт! Күрсәт! — дип бәгырен телгәли.

Монысына, әлбәттә, укытучы түзә алмый, үкереп елый башлый һәм... уянып китә. Уянса, чәчләр маңгайга ябышкан, мендәр юеш, бөтен тәнне салкын тир баскан. Шөкер, төш кенә икән.

Ләкин директор хатыннарына мондый төш керми. Әмма директор хатыннары да гел генә тыныч йоклап тормый. Һәркемнең үз борчуы бар бу дөньяда. Колхоз көтүчесе, мәсәлән, кайчак төн буе йокламый ята: кичә малларны люцерна басуында утыз минут урынына кырык биш минут йөрткән. Күбенмәделәрме икән?

Ә менә Гөлчирәнең йокламау сәбәбе икенче, бөтенләй икенче. Моны сөйләп аңлатып булмый. Моңа бер язучының да осталыгы җитмәс. Чөнки моның нәрсә икәнен бары тик үз башыннан кичергән хатын-кыз гына белә. Башка берәү дә аңламый моны. Ул — бер чир. Ул сине эчтән суыра, киптерә, ул синең көнеңне төнгә әйләндерә, төнеңне газапка әйләндерә. Кеше белән сөйләшкәндә син аңлап сөйләшмисең, аңлап җавап бирмисең. Көлгәндә кеше көлгән өчен генә елмаясың, битең генә көлә, рухың елмаймый. Эчең тулы бушлык, сызлану.

Бу — көнләшү дип атала.

Хатыннарны ул авырудан берүк алла сакласын. Бу авыру эләктеме — беттем диген. Гөлчирә ябыкты. Зур күзләре тагы да зураеп калды, аларның арасы ераклашты. Ябыксаң шулай була икән. Битләрдә, тамак асларында әллә ниткән хыянәтчел җыерчыклар күренде. Янбаш сөякләре чыкты. Ашауның тәме бетте — дөнья беткесез, рәтсез бер озын төшкә әйләнде.

Гөлчирәнең күңеле бу авыруга күптәннән юл эзли иде инде. Сугыш бетәсе елны ук мәктәпкә бер-бер артлы яшь хатыннар, югары белемле кызлар килә башлады. Дөрес, алар озакка калмадылар, ул кызларны Нәркисләр, Бәлкыйсләр алыштырды. Алары да бер кат җанны тетрәтте. Аннары директор унынчы классны тәмамлаган чибәр Нәсимәне, Гөлчирәнең ай-васына карамыйча, пионервожатый итеп алды. Бу — Сабирның үз гомерендә хатын сүзенә беренче тапкыр каршы килүе иде. Шуның өстенә, педсоветларның берсендә Сабир болай дип тә әйтте:

— Пионер, комсомол эше директор кулында, учком һәм башка оешмалар завучка карыйлар,— диде.— Пионер эше миндә,— диде.

Мәхәббәттә иң хәтәр кеше — яше узган ир. Сабир картая. Чәчләре инде маңгайдан коелып кerә башлаган. Гәүдә дә көпшәкләнгән, бушаган. Бу вакытта кеше бер акылсызланып ала. Яшь вакытта нәрсә ул? Алла тышкы кыяфәтең, яшьлегең, тазалыгың үзе синең өчен эшли. Ә картайгач уйлап эш итәргә кирәк. Монда инде бүләкләр, төче тел кирәк. Семьяң бар — шулай булгач, мин сине алам дип тә әйтә алмыйсың. Монда бердәнбер юл — хатынны яманлау кала. Уңмадым, бәхетем булмады, дисең, чәчең дә юньләп тарый белми, ятуга гырлап йокыга китә... Ә миңа рухи тормыш та кирәк, янәсе...

Ай, бу ирләрнең телләрен! Менә син эшлә дә, ашарга да пешер, савыт-саба ю, кер уып тор, балаларыңны кара, иреңне кара! Бер генә тапкыр өй җыештыр, бер генә тапкыр, эгоист! Аннан белерсең. «Рухи тормыш», имеш, әҗәткана...

Бер-ике ел элек Сабирның шактый хәтәр номерлары булды. Мәк-

тәптә ул чагында шәһәрдән килгән ике кыз, бер егет бар иде. Кич булдымы — патефон борып танцы ясыйлар, дәрес беттеме — спорт костюмнарын киеп чаңгыда чыгып китәләр. Сугыш вакыты, ачлык, салкынлык, әйтерсең лә боларга кагылмый. Ә бит кичләрен бөтенләй гөнаһсыз сабыйларга әйләнәләр болар. Баксаң — болар арасында гыйшык дигән нәрсәнең заты да юк икән. Сабир моны һич тә аңламады. Ничек инде ул шундый кызларга гашыйк булмыйча калып була? Әй, бу яшьлекне! Әй, бу картлыкны!

Юлбарыслар була диме? Кеше ашаучылар? Берәр җиренә пуля кереп җәрәхәт алып калса, кыргый хайваннарны тота алмый, имеш. Юлбарыслар семьясыннан аерылып китә, имеш. Ачтан үлмәс өчен кеше ашый башлый. Нишләрсең? Башка чара калмагач — бер хәлең юк. Сабир да шундыйрак хәлдә бит. Чаңгы шуа торган кызларның берсен мәктәптә ялгыз очратып ул актык чарасын кулланды. Шимбә көн кич иде, теге кыз авылда ялгызы гына калган да эче пошып мәктәпкә килгән. Сабир бу моментны инде кыш буе көткән иде. Һәм ул, моменттан файдаланып, аңа үзенең хисләрен белдереп карады. Хатын-кыз мондый хәлләрне үзенең иң якын дустына сөйләми каламы соң! Бу хәл, әлбәттә, Гөлчирәгә дә килеп житте. Сабир тиз гашыйк була, анысы яңалык түгел. Ләкин болары әле ярыйсы булган икән. Әле ул вакытны сагынып сөйләрлек икән. Менә хәзергесе... Гөлчирә тәрәзә пәрдәләрен тартты — дөньяны язгы таңның кызыллыгы баскан иде. Кояш чыгарга әле шактый вакыт бар, йорт эче, ишек алды, урам тып-тын. Шундый тын, җирнең акрын гына әйләнгәнен ишетеп, сизеп булыр сыман. Таң кызыллыгы тәрәзә аркылы үтеп морҗа акшарына төште, агач караватында таралып йоклап яткан Тәлгатьнең ризык бөртекләре ябышып каткан, кичтән юылмаган авызына-битенә төште. Бөтен дөнья кызгылт нурга чумып, язгы кояшның чыгып килүен көтмәктә. Әле тәрәзә өстендәге чыпчыклар да чыркылдашмый, сыерчыклар да йоклый, мутлыктан төн уртасында гына кайтып яткан эшлексез мәче дә йоклый әле. Ә Гөлчирәнең урыны салкын, ул аңа баш та тертмәде. Сабир өйдә юк. Район киңәшмәсеннән кайтмады. Бибисара кайтты — төнге икедә аларның уты булды. Ялгышканмын дияр идең — нәкъ шул вакытта Бәлкыйснең дә уты булды, киңәшмәгә бергә киткәннәр иде. Ә Сабир кайтмады. Инде сәгать бишенче. Әгәр бер көн Закиров такмаклаган дөрес булса.

...Закировның мәктәптән китәренә бер-ике генә көн кала булган иде бу хәл. Гөлчирә белән Сабир сумка тотып кибеттән кайтып киләләр иде. Закиров абзар түбәсенә менгән дә таяк башына җил тегермәне беркетеп маташа. Бик җилле көн иде, көньяктан искән җил бу уенчык тегермәннең тавышын әллә кайларга алып китә. Ул тегермәннең карандаш буеннан да кыска канаты язгы саф җилгә зерелдәп әйләнә, аяз зәңгәр күк, кояш нурлары, саф җил һәм шул уенчыкның тавышы авыл халкы гына аңлардай ниндидер бер язгы тәэссорат тудыра иде. Ләкин шул абзар түбәсеннән җил бер такмак та алып килде. Моны Сабир ишеттеме-юкмы, әмма шуны ишеткән минуттан башлап Гөлчирә өчен бу дөньяның ярты тиенлек тә кызыгы калмады. Закиров болай дип такмаклады:

Сабир, Сабир — сабаке,  
Сабир тарта тәмәке.  
Тәмәкесен ташлаган,  
Мәрүрәне башлаган.

Аңа теге уенчык тегермәннең яз җырыдай саф тавышы кушылды:

— Зер-р-р-р-р...

Гөлчирәнең колагында исә болар бергә буталдылар. Ташлаган... Башлаган... Кемне?

Сабир соңгы көннәрдә берничә тапкыр төн уртасында кайтты. Гөлчирә сизенде, анда да тавышны көнләшәм дип түгел, ә башка яктан чыгарган булды.

— Мин монда тәүлегенә егерме сигез сәгать эшләп эт булам, йорт эшенә ярдәм итүчем юк,— диде.

Гөлчирә үзенең салкын караватына күз ташлады. Кичтән күпертеп салган ике мендәр аңа мыскыл итеп карый кебек тоелды. Ике мендәрнең икесе дә кабарынып яталар иде.

Таң атканда янында ире гырлап йоклап яткан хатын — дөньяда иң бәхетле хатын икән.

Кояш чыкканда тәрәзәдән тәрәзәгә йөреп иренең читләр куенынннан чыкканын көтеп торган хатын дөньяда иң бәхетсез хатын икән!

Гөлчирә баскычка чыкты. Кояшның беренче нурлары белән акрын гына җил исеп куйды, җил Закировның уенчык тегермәненә кагылды, ул зерелдәп әйләнә башлады. Чыпчыклар чырылдаштылар, сыерчыклар чыгып битләрен юдылар. Иртәнге тынлык бозылды. Авыл читендә ат абзарлары янында колхоз бригадирының тавышы ишетелеп тора иде. Мәктәп ишек алдында да хәрәкәт башланган: Заһир ат чистартып маташа, аның тирәсендә кычкырып-кычкырып күрсәтмәләр бирүче кеше — Сабир иде.

Димәк — дөрес...

Димәк — бары да дөрес.

Гөлчирә төш күргән сыман ярым саташып өенә керде, көзге янына килде. Көзгедән аңа күз аслары кара янган, яңак сөякләре чыккан ямьсез бер хатын карады. Ямьсез хатын күзләрен йомды. Дөньяның икенче бер читендә тагын бер хатын күренде. Анысы — тулы күкрәкле, мут күзле, һәрвакыт дымлы иренле, калын ике толымлы, матур ап-ак беләкле — яшь бер хатын. Шул минуттан башлап җир шарында бөтен кешелек җәмгыятенең Гөлчирә өчен бер генә дә кирәге калмады. Хәзер дөньяда ике генә кеше бар иде: ул һәм Мәсрүрә.

Гөлчирә улы янына ауды, аның кайнар битенә маңгаен терәде, дөнья әйләнде, кояшлар, айлар, йолдызлар бәрелештеләр, зилзилә башланды. Дөнья буталды, тик шул гарасатның эчендә ерактан һәрвакыт аңа бер йөз күренеп торды: киерелгән кашлы, дымлы иренле, мут карашлы...

Сабир Ишмуратович исә урам буйлап уйланып кайта. Бу фани дөньяда берәү дә мөгезле түгел, янәсе. Фәрештәләр дә аз. Җүләрләр тагы да азрак. Берәү кыек-мыек юлда йөреп соң гына өенә кайта — ай да кояш. Хатынының күзенә туры карый. Хатынына әйтмәгән җылы сүз калмый, ул төче теллелек, ул игътибарлылык дисеңме. Бичара хатын ул көнне гомердә күрмәгән назын күрә, «бу иремә нәрсә булды соң әле бүген, шулай ук тора-торып мәхәббәте артамыни соң, ярабби, бу бәхетне миннән күпсенмә», дип рәхәт чигә. Алдана мескен! Теге дуңгызга шушы минутны исән-сау уздырып җибәрергә кирәк, бары тик әлеге кыек юлда чиккән рәхәтнең михнәтен күрмәскә, тотылмаска гына кирәк. Шуңа күрә артык төче телле ул бүген, явыз! Тегесе шуны белми...

Икенче берәү яратмаган хатыны янына кайтып керә, ул да әле генә «ужым»га чыгып керде, әлбәттә, аңа да тотылмаска кирәк. Ул түбән карый, хатынының күз карашы белән очрашмый. Ләкин ул татлы телле булып кыланмый гына түгел, киресенчә, яратмаган хатыны андый вакытта аңа тагы да шикелсезрәк күренә. Шуңа күрә, кыек юлдан кайтып керүгә, ул әле теге, әле бу сәбәп табып хатынына бәйләнә башлый. Ишектән килеп керүгә, өйдә рәт юк, нәрсә эшләп ятасың, дип мыгырдый, ашарга утырса ашының тозы чыкмаган, кайнамаган, фәлән-төгән дип бәйләнә. Хикмәт, югыйсә бер дә анда түгел, яраткан хатын булса барысы да рәтле, барысының да тозы чыккан... Мәхәббәт юк, йортта

иң кирәкле, иң кыйммәтле байлык юк — хикмәт шунда. Әнә шуңа күрә ул тимер кашыгын таш тәлинкәгә бәрә-бәрә ашый. Ир кеше тәлинкә тавышы чыгарып ашадымы — белеп тор, ул нидәндер риза түгел, ә иң дөресе — каршысында утырган хатынын яратмый. Ул әнә шул кырыслыгы белән үзенең кыек юлын йомып калдыра, бичара хатын икенче пешергәндә ашның тозын мулрак салырга кирәк дип алданып уйлап утыра...

Була өченче төрлесе. Соң гына кайта, арган, йончыган кыяфәттә сөйләшә, киңәшмә, утырыш, фәлән-төгән дип мыгырдана, дөньяны, кешеләрне сүгә — монысы иң хәтәре. Моны тотуы кыен. Ләкин бу вакытта андый кеше хатынына карый алмый, карашын читкә бора. Читкә карадымы, көт тә тор — ул көнне утырыш та, киңәшмә дә булмаган... яки алай озакка сузылмаган. Барысы да булган, әмма андый озак киңәшмә түгел.

Сабир Ишмуратович үзе соңгылар рәтенә керә иде.

— Свещаниене бик суздылар, пнимаетели, яктыргач кына кайтырга чыктым, чытлы йокы күрмәгән...

Бу сүзләрне әллә кем әйтте. Хәер, кем әйтсә дә барыбер түгелмени! Җир шарында бер хатын да Гөлчирә күргәнне күрмәсен!

Бу яз гел хәсрәт кенә алып килергә булган икән... Кояш чыга, кояшның кызгылт нурлары — Гөлчирәнең канлы күз яшьләре.

Гөлчирә уянып китте — сәгать сигезенче икән. Аның муенына Сабир кулын салган, икенче кулы — Тәлгатьнең маңгаенда. Радио сөйли — Казан станциясе кыллы инструментта «Нәфисә» көен тапшыра. Бу — аның «позывной» сигналы. Менә хәзер диктор хәерле көн теләр — Гөлчирәнең хәлен беләмени ул!

— Свещаниене бик суздылар, пнимаетели, яктыргач кына кайтырга чыктым, чытлы йокы күрмәгән... Әйдә тор, самовар кайнады, тавыкларны-казларны чыгардым,— диде Сабир, читкә карап.

Гөлчирә торды, башын бәйләде, сүзсез генә чәй эчтеләр. Ренат ашык-пошык капкалап чыгып йөгерде, хәрби хәзерлек буенча аларга бүген военкоматтан бер офицер килеп зачет алырга тиеш иде, Хәкимҗан малайларны дәрескә хәтле үк җыеп сөйләшмәкче булган.

Радиодан концерт башланды.

Суган кабыгында кайнатып буялган йомыркалар, кипкән җиләкләр күтәреп Гайнелвафа карчык килеп керде. Керде дә агач караватянына узды — Тәлгатьнең башы эссе иде. Карчык Гөлчирәгә сынаулы караш ташлады һәм барысын да аңлады. Тәлгатьнең авыруы узачак, әмма Гөлчирәнеке — мәңгелек.

Кияү белән кыз мәктәпкә киттеләр, карчык сөт кайнарлап дәва итәргә калды.

Мәктәпкә якынлашкан саен Гөлчирәнең йөрәге ешрак типте. Укытучылар бүлмәсенә ул үзе генә килеп керде. Радиоалгыч янында Рушад, Гата, Хәкимҗан утыралар. Мөнирә Булатова йомшак, бәрхет тавышы белән «Геройлар маршы»н җырлый иде:

> Батыр сугышчы — геройлар кайта,
> Җиңү шатлыгы илне яңрата.
> Алар шатлыгы — безнең шатлык ул...

Кинәт кенә Гөлчирә сәгать астында звонок тотып торган Мәсрүрәне күреп алды. Ике хатынның күзләре очраштылар. Мәсрүрә түбән карады. Бу — шикне раслау иде. Гөлчирә тамак төбенә утырган төенне, күзенә тыгылган яшьләрне тыеп, тешен кысып радиоалгыч янына килде. Радиодан тапшырылган марш, моны тыңлап утырган фронтовик егетләр шул минутта аңа чисталык, пакьлек, гаделлек сакчылары булып тоелдылар. Егетләрдән берсе аңа урындык тәкъдим итте — Гөлчирә көн

туганнан бирле беренче мәртәбә жинел сулап куйды. Ә Мөнирә Булатова һаман шул тантаналы калын тавышы белән жырлый бирде:

Әйдәгез, дуслар, бергә жырлашыйк,
Жырлыйк без бергә, дөнья шаулатыйк...

Юк, әле яшәргә була...

Мондый жыр, мондый тантана, мондый эчкерсез егетләр барында дөньяда әле яшәргә була. Өметсез — шайтан, диләр...

...Гайнелвафа карчык — дипломат. Күзлеген элеп куйган да иске китаптан әллә нинди бәетләр укып утыра. Янәсе, Тәлгатьне юата. Ә эчтәлеге — Тәлгатькә түгел, Сабир кияүгә дә аңлашылмаслык.

Кияү белән кыз кайтып кергәндә мич томаланган, аш пешкән, чәй кайнаган иде.

Гөлчирәнең дә кәефе бераз рәтләнгән кебек күренде. Ләкин Гайнелвафа карчык аларга борылып карамады, кызының хәлен ул болай, карамаган көе дә, ишектән килеп керү рәвешеннән дә белә, аңлый иде. Шуңа күрә ул берни дә сизмәгәндәй, саргайган борынгы бер китапны актаргалап, гарәп хәрефләре өстеннән кытыршы бармакларын ышкып Тәлгать өчен генә шигырь укый иде.

Бисмилланың әүвәл башы — вәл гашери,
Егетләрнең кыз сөйгәне сер яшерер.
Без уйнаек, без көләек тереклектә,
Адәм угылын бердәнбер жир яшерер.

Карчык аш янына утырмады.

— Без,— диде,— улым белән бергә жиләкләп чәй эчтек, буяулы күкәй ашадык, бер кабар урыныбыз юк.— Шулай дип ул тагын китабына иелде.— Башта Тәлгать улым үзенең «И туган тел» китабын укыды, хәзер менә мин укыйм.

Агыйделдә үрдәк йөзә бата-калка,
Өсләрендә булыр аның алтын камка.
Егетләрнең ярдин-ярга йөргәненең
Колагына кидерерләр чуен алка.

Агыйделнең аръягында болыт тора,
Яңа ярлар иске ярны оныттыра.
Яңа ярлар табак белән аш китерә,
Иске ярлар ике күздән яшь китерә.

Кияү чык-чык китереп калай кашыгын таш тәлинкәгә бәрде. Шопыр-шопыр аш чөмерде. «Яңа ярлар» дигән юлларны карчык әллә ничек кенә ике кабат укыды. Кияү кашыгын һаман бәргәләп ашады. Чәй эчкәндә дә Сабир кияү берөзлексез калагын стаканга бәрде. Күзләрен стакандагы чәйгә төбәгән килеш сүзсез генә чәен болгатты, калак бәрелгәннән кыңгырау тавышы чыкты, ахрысы, Сабир моны аңлап эшләми иде. Чөнки Гайнелвафа карчык китапны актаргалап икенче бер бәет тапкан һәм икенче көйгә тагы да йөрәк уйнатырлык эчтәлекле нәрсә укый иде.

Илебездә үксез бала бик күбәйди,
Аталардин жәтим булып калгангами?
Илебездә карый-карчык бик күбәйди,
Балалардин мәхрүм булып калгангами?

Хатыннарда әдәп-хәя һич калмади,
Хәләл булган никахларни бозгангами?
Хак тәгалә бәла кабыгыйн тәмам ачти,
Үзебездә шомлыклар күп булгангами?

Тәлгать тирләп йокыга талды. Карчык та күзлегән, китабын куенына төреп тыкты да исәнлек-саулык теләп кайтып китте.

— Кичке сөтне үзем китерермен,— диде.

Кара син аны, йөр син аны бер надан карчык дип! Нинди хәйләкәр, нинди бәетләр укый бит! Кияүне тәрбияләргә тотынган бит! Үпкәләми, үпкә сүзе әйтми — бары тик укый гына.

Гайнелвафа карчык — дипломат.

## XIV

Майга бер атна кала юл төште.

Акбалык мәктәбенә быел тынгысыз яшәргә язган, ахры. Бөтен уку елы буенча бер генә тыныч атна булдымы икән? Сугыш беткәч тормыш тыныч, бик тыныч булыр дип уйланыла иде бит соң! Нәрсә булды соң бу дөньяга?

Кинәт кенә бер көнне райком пленумы җыйдылар. Беренче секретарь башка эшкә күчерелгән. Әллә кайсы районнан килгән, сугыштан капитан дәрәҗәсендә кайткан Даутовны аның урынына сайладылар. Тегесе мәктәп буенча йөз процент өлгереш бир дип Сабирның бик теңкәсенә тигән иде — монысы нишләр? Пленумнан таралырга дип кенә кузгалышканнар иде — яңа секретарь Акбалык мәктәбе директорын сәхнә артына чакыртты.

«Беттем,— дип уйлады Сабир.— Кемдер, димәк, жалу биреп өлгергән. Беттем, яндым... Ну соң, эләктем...»

Даутов елмаеп аңа кулын бирде. Күптәнге танышыдай итеп дәште.

— Сезнең мәктәптә чит тел укытучысы юк дип әйттеләр, шул сүз дөресме?

Сабир мондый гади мәсьәләгә хәзерләнеп житмәгән иде — каушап калды.

— Һи-и, иптәш Даутов... Чит тел генәме соң? Миндәге нагрузкалар беләң әле югары классларга гына да тагын өч укытучы кирәк. Предметниклар утыз алтышар сәгать укыталар, утыз алтышар...

— Без алайса болай итик: минем хатыным чит тел укытучысы. Унсигез еллык педстажы бар. Мәгариф бүлегеннән аңа приказ яздыртыйк. Май башыннан эшкә тотынсын. Сез шуңа ризамы?

Сабир Ишмуратович бөтенләй кешелектән чыкты. Берни аңламады. Ничек инде ул, беренчедән, райком секретареның хатыны авыл мәктәбендә эшли? Икенчедән, ничек инде ул, райком секретаре, рядовой бер директордан: «Сез ризамы?» дип сорап тора. Директор тирләп чыкты. Аның уйларын белгәндәй, Даутов үзе ачыклык кертте.

— Хикмәт менә нәрсәдә: беренчедән, элек-электән килгән бер яман гадәт бар. Районга кем генә килмәсен, шуның хатынын әллә кемнәргә зарар китереп булса да район үзәгенә эшкә урнаштыралар. Үзәк начальник хатыннары белән тула. Мин бу мәсьәләдә оригинальлык күрсәтмәкче булам...

— Сез соң ничек, семьяны шулай пыран-заран китермәкче буласызмыни?

Даутов көлде. Тәмәке кабыздылар.

— Юк, нигә алай дисез? Юк. Икенчедән, сезнең авыл Советы председателе белән иптәшләр инде сөйләштеләр — анда бер абзыйларның кара-каршы ике йорты бар икән, без шунда урнашабыз.

Сабир монысын ук көтмәгән иде.

— Ничек инде ул, райком секретаре — и авылда яши?

— Ә кайда язылган соң ул райком секретаре именно район үзәгендә яшәргә тиеш дип, ә? Син әллә Үзәк Комитетның политбюро членнары

көн-төн Кремльдә генә ята дип беләсеңме? Кырык беренче елның кышында Наркоматларның Куйбышевтан торып идарә иткәнен хәтерлисеңдер? Миңа сигез километр диделәр, дөрестер ич?
— Әйе, сигез. Ләкин бит юлның төрле чагы була.
— Ансы проблема түгел. Газик уза алмаган юл безнең илдә юк... Һәм өченчесе: минем кызым моңарчы гел татар мәктәбендә укыган. Ә район үзәгегездә татар класслары җиде белән туктый икән. Кызымның иң җаваплы чоры — унынчыны тәмамлый. Сездә укытмый кайда укытыйм? — Даутов җитдиләнде.— Билгеле, бернинди яклашу күрсәтмисез. Бу мәсьәләдә миннән бернинди шәфкать көтмисез. Хатынга сәгатьләр биргәндә, расписание төзегәндә — райком секретаре хатыны итеп түгел, рядовой бер укытучы итеп карыйсыз. Кызга бирәр льгота ясаганнарын сизсәм — лично үзегез җавап бирерсез... Димәк, болай: әгәр сездә шундый урын бар икән — рәхим итәсез. Югары белемле, унсигез ел педстаж. Немец һәм инглиз телләре буенча белгеч. Үкенмәссез дип беләм...
— Юк, шту сез... Бик шәп. Рәхим итсен.
...Бу дөнья — әллә нәрсә. Райком секретаренең хатыны белән бергә эшлә әле син. Димәк, мәктәптәге бөтен хәл райкомга фаш булып барачак. Менә сиңа перспектива! Кызы инде аның — бер хәл, мондый семьядан чыккан кыз әйбәт укыйдыр.
Даутов көчле куллары белән Сабирның кулларын кысып калды. Киң каешка җыерып кысылган гимнастеркасын рәтләде. Күкрәгендә орден, медаль колодкалары һәм өч тапкыр яраланганлык билгесе — өч аркылы тасма тегелгән иде. Кара янган битле, эре ак тешле. Бөтен битен тутырып елмая белә. Кинәт кенә җитдиләнеп ала. Хәтәр кеше...
«Даутовлар авылда торачак», дигән хәбәр күпләрне сагайтты. «Хатыны мәктәптә эшләячәк», дигәне мәктәптәге күпләрнең колагын торгызды. Пленумнан соң ике көн үтүгә, ЗИС машинасына төялеп Даутовлар авылга күчеп тә килделәр. Алар урнашып беткәнче район элемтә бүлеге егетләре баганадан баганага йөреп Даутовның өенә телефон кертеп киткәннәр иде инде.
...Даутовның хатыны икенче көнне үк эшкә чыкты. Чит тел укытучысының чынысын мәктәпнең беркайчан да күргәне юк иде — шуңа күрә кызыксыну зур булды. Разия Вәлиевна — бу мөлаем хатынның исеме шулай икән — Казанның Татарстан урамында яшәгән. Өч минут эчендә Нәркис белән таныштылар, уртак танышларының исемен әйтә-әйтә, гөр килеп бер сөйләшеп алдылар. Разия Вәлиевна — юаная башлаган, чәчен шома итеп тарап уртадан юл ачкан, затлы күзлек кигән, бер-ике алтын теш куйдырган ике иякле таза хатын. Күренеп тора — мишәрләрдән. Каты итеп сөйләшә, кеше белән тиз таныша, кыю.
— Ә бу егетләрне кемнәр дип белик?
Радиоалгыч янында соңгы хәбәрләр тыңлап утырган егетләр янына барып ул кулын сузды.
Гата чатылдап сикереп торды. Үзенең бөтен булган дәрәҗәләрен, хезмәт урыннарын әйтеп таныштьг. Рушад та кыю хатынның кулын кысты:
— Тарих укытучысы,— диде.
— Күрәм, сез дә хәрби хезмәттә булгансыз?
— Ә каян белдегез?
— Ә бляха соң, бляха! Ай, алла сакласын, сезнең матрос халкы белән бәйләнешергә! Эчәләр, сугышалар... Аз гына бер нәрсә булдымы: «Полундр-р-р-ра!» дип бляхаларын селти башлыйлар. Алла сакласын...
Гата рәхәтләнеп көлде. Рушад кызарды.
Гимнастеркасын рәтли-рәтли, авызын ерып Хәкимҗан кулын бирде.
— Без шушы авылда туып-үскән егет булабыз. Хәзергесе көндә шушы мәктәптә военное дело и физкультура укытабыз...

Звонок булуга, завуч Разия Вәлиевнаны класска алып кереп китте. Мәктәптә гадәт шулай — яңа укытучыны я директор, я завуч кертеп куярга, таныштырырга тиеш.
Яңа укытучыны башта яратмыйлар. Ул фәннән элек кергән кешене сагынып сөйлиләр. Ләкин бераздан яңа укытучыга укучының күзе ияләнә башлый. Элек аның ямьсез ягын гына күрәләр. Тавышы черелдек, күзе нурсыз, сөйләве тәмсез, соравы рәтсез, диләр. Бераздан карыйсың — тавышы да, күзләре дә, сөйләве дә, соравы да әйбәт кенә. Мөлаем генә икән. Разия Вәлиевна шул этапны, шул сынауларны узарга дип тугызынчы класска кереп китте.
Рушадның беренче дәресе унынчы «а» классында иде — хәзер кабатлау вакыты, дәрескә әллә ни хәзерләнәсе юк, сөйләт тә утыр. Исемлек тикшерде, ашыкмыйча гына кабатлау темасын журналга язды. Зрә мыскыл итте бит әле бу мишәр хатыны! Бляха тотып сугышып йөрүчеләр дигән була бит! Фронттан кайткан кешегә шулай дисеннәр әле! Дөрес, матросның андые да була. Демобилизация белән кайтканда Рушад Рига шәһәрендә трамвайда бер яшь матросны күргән иде. Япь-яшь малай, өстендә өр-яңа кием, чәчләре кырылган, әлбәттә, әле диңгез тозы тәненә үтмәгән, дөресрәге — диңгезне әле бөтенләй күрмәгән. Эчеп исергән дә трамвайның арткы площадкасына аркылы яткан, үзе йокы аралаш сүгенә:
— ...мать! Хто взял Зимний? — дип мыгырдый. Кешеләр елмаялар, торгызмакчы булалар, ә ул тыпырчына, бляхасын ходка җибәрмәкче була, һаман сүгенә.
— Хто взял Зимний?
Тукталышның берсендә хәрби патрульләр килеп аны машина кузовына күтәреп салдылар. Рушад аны кызганып калды.
— Эх, син, сары авыз! — дип авыр сулады.
Инде шул сары авызлар белән бер үлчәүгә салып карагач бу хатынга ни диярсең...
Я, ярар, кабатлау дәресен башлап җибәрик...
— Ярый, дәресне башладык. Узган дәрестә без, укучылар, сезнең белән...
Рушадның күзе кинәт кенә арткы партада ялгыз утырган берәүгә төште. Төште... һәм шуның белән бөтен дөнья чуалды да китте. Арткы тәбәнәк партада, аякларын бераз гына янга чыгарып, буй җиткән бер кыз утыра иде. Коңгырт чәчләрен, нәкъ уртасыннан юл ачып, шома итеп тараган, коңгырт битле, озын керфекле, кара күзле бер кыз. Өстендә эре-эре кара таңкә төшкән ак кофта. Күкрәгенең бер ягында — калку урынында кечкенә генә кесә. (Никадәр зур булсаң да, син әле яшүсмер дигән сүз инде бу!) Калын толымының берсен алгы якка салындырган, бу толым аның тыйнак кына булып калыккан күкрәгеннән узып парта астына төшеп киткән. Тәбәнәк булганлыктан ул партада моңарчы кеше утырмый иде — бу кызый анда кысылып кына утыра. Парта арасыннан читкә аның түгәрәк ял-якты тез башлары чыккан. Ул китабын ачкан да озын керфекләрен салындырып җитди генә кыяфәттә укып утыра иде. Бер секунд, ике секунд үтте. Әллә өч үк булдымы? Рушад тиз генә хәтерен җыеп җөмләне әйтеп бетерә алмады. Шул вакыт теге керфекләр күтәрелделәр һәм Рушадның күзләре белән очраштылар. Кызый керфекләрен тиз генә төшерде, битенә кызыллык йөгерде. Рушадның да колаклары яна иде бугай...
— Узган дәрестә без... без...
Нәрсә «без»? Без нишләдек? Шайтаным! Берни дә белмисең син! Берни аңлап сөйләмисең! Сиңа хәзер журналга иелергә, үзеңне тынычландырырга кирәк. Ләкин Рушад класстан күзен ала алмады. Шул вакыт теге кызый керфекләрен сирпеп аңа тагын бер тапкыр карап алды. Чуалды фронтовик егет, бетте, зиһене таралды...

— Узган дәрестә без... сезнең белән... кабатлый башлаган идек. Әйе, кабатлый башлаган идек. «Рус-япон сугышы» дигән темага кереп килган идек. Бу тема буенча,— Рушадның тамагын нәрсәдер кысып алды,— бу тема буенча нинди сораулар бар? Ниләр аңлашылмады?

Класс өчен барысы да аңлашылган! Борчылма! Үз хәлеңне генә бел! Сиңа ниләр аңлашылмаган? Син шул турыда уйлап кара. Бөтен хикмәт менә шунда! Син ул кызыйның укучы икәнен беләсеңме? Син ул кызыйның әнисе әлеге мишәр хатыны икәнне онытмадыңмы?

...Кемдер сөйли. Кемдер шәп кенә җавап бирә. «Рус хөкүмәте бу сугышны техник яктан хәзерлексез башлап җибәрә. Адмирал Рожественскийның эскадрасы Көнчыгышка бик озак бара. Бу эскадра турында Владимир Ильич Ленин үзенең «Порт-Артурның бирелүе» дигән мәкаләсендә болай дип яза...

Рушад тәрәзә янына килеп басты. Мәктәп бакчасындагы көяз топольләр инде яфрак ярырга бөртенгәннәр, җир кипкән, ишек аллары себерелгән, җирдә вак кына үлән тибә башлаган. Бөтен нәрсә уянган, бөтен нәрсә яшәрә, сулыш алырга талпынган көн икән бу. Юк, бу дөньяда яшәве шулай да нинди кызык! Яшәргә, яшәү өчен, эш өчен янарга кирәк!

...Унынчы «а» да тарихтан соң рус әдәбияты дәресе иде. Нәркис дәрестән чыгуга ашыгып расписание янына барды һәм нәрсәдер карап алды. Аннан ул укытучылар арасыннан күзләре белән кемнедер эзләде. Ачык форточка янында каушаган, кызарынган Рушадның кызу-кызу суыргалап тәмәке тартып торганын күреп алды да аңа озак кына карап торды...

Укытучы халкы, гомумән бик сизгер була.

Нәркис исә арадан иң сизгере. Ул барысын да аңлады. Юк, аңлады дип әйтү дөрес булмас, ул сизенде. Нәрсәне сизенде? Ул әле моны исеме белән атап әйтерлек дәрәҗәдә түгел иде. Ләкин журнал тоткан кулы аның хәрәкәтсез калды, күзләре билгесез бушлыкка төбәлде. Ул нәрсәдәндер, ниндидер көч тарафыннан үзен җиңелгәндәй хис итте.

Нәркис ялгышмый иде. Бу — бөтен дөнья хәрәкәт законының рәхимсез бер объектив күренеше — яшьлекнең җиңүчән көче иде.

## XV

— Иртәгә хәрби формам белән саубуллашам,— диде Гата, сигезенче май көнне дәресләр беткәч.— Иртәгә саубуллашам. Тугызынчы май — дөньядагы иң бөек бәйрәмнәрнең берсе. Килер бер көн — тугызынчы майны бөтен планета билгеләп үтә башлар. Бөтен дөнья ул көнне ял итәр...

Гатаны погонсыз, кительсез күрүе әллә ничек булыр кебек иде — шуңа күрә аның бу сүзләренә бөтен кеше дә игътибар бирде. Ләкин бу темага озак сөйләшеп торырга вакыт юк — кичен колхоз клубында мәктәп коллективы тарафыннан концерт куелачак иде.

Сәхнәдә балалар концерт биргәндә сәхнә артында торган укытучы кадәр бер генә режиссер да дулкынланмыйдыр. Бу вакытта укытучының тыны кысыла, аркасына тир бәрә, ул үзенең укытучы икәнлеген оныта, ир укытучылар, бөтенләй чыгырдан чыгып, балалар барында тәмәке кабызалар... Монда укытучы белән укучы арасындагы данлыклы традицион киртәләр алып ташлана, монда күңелләр нечкәрә, киеренкелек соң дәрәҗәсенә җитә. Дәресен белмичә чирек бүе үзгегә уткән кыз баланы монда укытучы гафу итә — ул кыз бала бары тик яхшы итеп җырлап кына керсен. Монда укытучы күзенә чалынган саен тешен кысып узып китә торган тәртипсез, ялкау малайны кысып кочакларга әзер — бары тик ул малай матур итеп биеп яки сөйләп кенә керсен...

Сәхнә артының үзенә бер дөньясы, бары тик укытучылар гына аңлый торган дөньясы була бу вакытта. Монда ыгы-зыгы, тау хәтле өеп куйган кием-салым, берөзлексез мыжгып сөйләшү, ашыгу, үпкәләү. Сәхнә артындагы бүлмә такталары чыгыр-чагыр килә, ә клубтагы халык тып-тын булып бер баланы тыңлый. Колхозчы үз балаларының концерты кебек бер генә концертны да ул кадәр игътибар белән тыңламый. Үзеңнеке — үз...

Менә сөйләргә дип Тәлгать чыгып басты — сәхнә артындагы Гөлчирәнең эчен ут алды, беренче рәттә утырган директор башын түбән иде, бер дә кирәксезгә янындагы Минжамал белән шушы көннәрдә мәктәп атының колыннарга тиешлеге турында сүз башлады. Тәлгать атылып чыкты — әсәргән күзләре белән клубның түшәменә карады да катты да калды. Артта борчылдылар. «Түшәгем дә!» «Түшәгем дә!» дип пышылдадылар. Берничә секундтан Тәлгать кычкырып әйтеп салды:

«Шилень»!

Халык гөр килеп көлде. Малай каушады. Ул «Шинель» дигән шигырьне сөйләмәкче икән. Шулай да бер тын алгач ниргәсенә төште. Чатый-ботый китереп сөйләп китте:

Түшәгем дә син минем,
Ястыгым да син минем...

Алтынчы классның хор коллективы чыгыш ясаганда Рушад та сәхнә артында марш атлап йөрде, тирләде, тәмәке суырды. Дөрес, әллә ни матур җырламадылар, ләкин кыш буе укытучыларның үзәгенә үтеп «тәртипсез» дип дан алган классның сәхнәдә җырлап торуы Рушадның зур җиңүе иде. Ул хорның җырлавын горурлык белән тыңлады. Ахырдан «Дороги»ны шактый уңышлы гына ерып чыктылар. Моның соңгы куплетын сәхнә артыннан торып кына Нәркис башлады.

Снег ли ветер,
Вспомним, друзья...
Нам дороги эти
Позабыть нельзя...

Клубта хәрби формада утыручылар байтак күренә, чөнки авылга унсигезенче, унтугызынчы, егерменче елгылар кайта башлаган вакыт иде. Соңгы җырга аерата көчле кул чаптылар. Рушад сәхнәдән сөрлегеп кергән балаларның берәм-берәм аркаларыннан сөеп калды. Малайларны якландырып ук җибәрде.

— Молодцы, егетләр, болай булсагыз сезне флотка гына түгел, ә Балтик флотының җыр һәм бию ансамбленә алачаклар...

Концертның икенче бүлегенә өлкән класс укучылары белән укытучылар да катнашты. Мәгълүм кичерешләр аркасында Гөлчирә беренче тапкыр сәхнәгә чыкмый калды. Хәкимҗанның венский гармунына Гатаның аккордеон тавышы туры килә икән. Биолог Мостафа боларны сәхнәгә өстерәп ук чыгарды. Бу номер өчен көрәш өч көн барды. Хәкимҗан, үз гомеремдә сәхнәгә аяк басканым юк, дип тартышты. Гата сәхнәгә чыгып гармун тартып йөрү үзенең дәрәҗәсен төшермәсме икән дип шикләнде. Мостафа үзенә хас җиңеллек һәм кызу канлылык белән бу мәсьәләне директор алдына куйды. Кызды, сүгенде, дулады.

— Халыкка культура хезмәте күрсәтүдән баш тарткач, мәктәптән бураныңны очырырга кирәк,— дип Хәкимҗанны эт итеп сүкте. Аннан Гатага тотынды.

— Син соң коммунистмы, түгелме, елки-моталки,— дип, авызыннан төкерекләр чәчте.

Егетләр җиңелделәр. Менә алар хәзер сәхнәдә утыралар. Мостафа кара чәчләрен тузгытып башын селкетте, ияк астына ак кулъяулык

тыкты да скрипкасын күтәрде. Смычогын ыңгыр-шыңгыр шудырып йөртте дә кинәт кенә бер кылны елатып куйды. Бу — сигнал иде.

Клуб эченә музыка тулды.

Ватан сугышының бөтен моңы, сагышы, фаҗигасе, аерылышу кайгысы, көрәшү дәрте, җиңү шатлыгы — барысы да шушы көйгә — «Идел» көенә сыеп беткән иде. Зал башын түбән иде. Бу көйне Җиңү бәйрәме көнне сәхнәдә өч фронтовикның уйнавы, аларның өчесе дә гимнастеркадан, кительдән булуы, Гатаның погоннары — шул көйнең салмак моңына кушылып кешеләрнең күңеленә ләззәт бирә, шомлы, дәһшәтле еллардагы халык батырлыгына, халык рухына бөек ихтирам уята һәм кисәтә иде. Бу көй — сугышта җиңеп чыккан халыкның батыр хезмәтенә, тыныч күктәге тургайлар тавышына, мәхәббәттәге турылыкка гимн иде. Бу — сугыш кырларында үлеп калган шәһитләргә халыкның музыкаль сәламе, маршы иде. Шул көйнең моңы белән тәэсирләнеп сәхнә, клуб бер коллектив булдылар, клубтагы халык музыкантлар белән бергә сулады, бергә хәрәкәтләнде. Берничә секунд шулай дәвам итте, һәм егетләр соңгы тапкыр уйнарга дип бер-берсенә карашып алган арада клубның артыннан бер тавыш ишетелде. Бу тавыш кешеләрне сагайта калды... Ләкин ул җыр тавышы икән. Хатын-кыз тавышы. Кемнеңдер нервлары чыдамаган, сәхнәдәге музыкага кушылып җыр башлаган.

Идел бит ул тирән бит ул...

Бу тавышка кешеләрнең тәэсирләнүе тагы да артты, зал өстеннән электр тогы узгандай итте һәм алдан сөйләшкәндәй бөтен халык бер булып бу тавышка кушылды. Бөтен клубның тәрәзәләре зыңгылдый, кәгазь лозунглар дерелди сыман иде. Йөзләгән кешенең бердәм тавышы клуб стеналарына сыймады.

Караңгы төн, томанлы көн —
Без аерылган көн бит ул...

Халык үзен-үзе белмичә кул чапканда Хәкимҗанның каушаудан теле тотлыккан, Гата кеше белмәслек ниндидер хисләрдән тешләрен кысып яңагына ямьсез сеңерләр йөгерткән, Мостафаның чәчләре тузгып беткән һәм юеш маңгаена ябышкан иде.

Ду китереп кул чапкан халыкка башларын иеп кереп киткәч, Мостафа әллә яратып, әллә ачу белән Хәкимҗанның аркасына сукты.

— Их, син, мокыт, гармунда уйный беләсең, ә музыканың нинди көчкә ия икәнен белмисең,— диде. Аннары гына Гата янына килеп әллә ниткән ачу белән аның күкрәгенә төртте. Гата чайкалып китте.

— Безобразие! Шундый мөмкинлек була торып сәхнәгә чыкмаска аяк терәп ятасың! Печән өстендәге эт! Мужик!

Мостафаның күзләре ау бөркетенеке кебек яна иде — сәхнә артында бөтен кеше аңа юл бирде. Арткы ишектән тышка чыгып барганда ул Рушадның да җилкәсенә шактый дорфа итеп берне утыртты.

— Син, полундра, мандолинада уйный беләсең бит! Мин сиңа ни әйттем! Күрдеңме, халык ничек кабул итә? Юеш фитильләр сез! Юеш фитиль чытыр-чытыр килә, үзе сүнми дә, яктылык та бирми! Сәхнә — яктылык ярата!

Алдагы номерны әйтергә халык мөмкинлек бирмәде. Клубны селкетеп кабат кул чаба башладылар. Егетләр инде чыгып тагын бер кат уйнарга әзер иде — Мостафаны таба алмадылар. Рушад кесә фонарен яндырып клуб артындагы ишектән караңгы чоланга чыкты. Мәһабәт гәүдәле Мостафа чолан баганасына сөялеп сабый баладай үксеп-үксеп елый иде...

Рушад аның җилкәсенә кулын салды.

Жиңү көненә багышланган докладында ул шактый киңәеп китеп фашизмның зарарлы, явыз идеологиясе турында сөйләгән иде. Шунда ул күп кенә мисаллар китереп оккупацияләнгән районнардан көчләп Германиягә куылган халыкларның фаҗигасенә тукталды. Трибунага таянып үзе сөйләде, үзе сәхнә кырындагы чаршау ярыгыннан Мостафаның карчыга күзедәй янган күзләрен сизеп торды. Бәлки алай ук тәфсилләп сөйләргә кирәк булмагандыр? Рушад бит бу кара егетнең бөтен кайгысын белә иде. Мостафа — сугышка кадәр Луганск бистәсендә тәҗрибә участогында эшләгән, утыз дүртенче елда Мичурин янына барып аның белән күрешкән, консультация алган кеше. Көньякта үскән бу егет сугышка кадәр яңа сорт алма чыгару белән хыялланган. Кырык беренче елның маенда хәрби сборга алынган вакытта өйдә хатыны, мәктәп яшендәге ике кызы калган. Шуннан сугыш... Сугыштан соң Мостафа үзенең семьясын эзләп ярты Украинаны йөреп чыкты, бик күп урыннарга язды. Бөтен мәгълүмат бер нәрсәгә кайтып кала иде: аның хатынын һәм балаларын теплушкага төяп Көнбатышка озатканнар. Семья шулай итеп суга төшкән балта кебек юк булды...

— Мостафа агай... Бәлки мин докладымда кирәгеннән артык детальләргә бирелгәнмендер? Гафу ит, зинһар. Минем үземә дә җиңел булмады сөйләгәндә...

— Юк, туган, болай гына. Болай гына. Шул көйне уйнаганда минем елап ала торган гадәтем бар. Тик син кешегә әйтмә моны. Килештекме? Я, әйдә киттек, эчкә керик.

Концертны алып баручы Нәсимә тирләп-пешеп сәхнә артында бәреләләп йөри иде. Чираттагы номер әзер түгел икән. Унынчы класс кызларыннан кемнедер чишендереп-киендереп маташалар, шуна күрә Мостафа сәхнәнең бер ягына, Рушад икенче ягына уңайсызланып китеп бастылар. Хәкимҗан аска төшкән, алгы рәттә хатыны янында утыра иде.

Гата сәхнә артыннан аккордеонда ниндидер бер марш уйнап җибәрде. Оста, шайтан! Сәйдәшевнең «Шәрык вальсы» икән. Ашыгудан, каушаудан кызарып пешкән Нәсимә тантаналы рәвештә сәхнә уртасына чыгып басты.

— Хәзер унынчы «а» классы укучысы Даутова Ләйләгөл сәхнәдә акробатик күнегү башкара.

Зал бер мәлгә аптырап калды. Кем ул Даутова? Нәрсә ул акробатик күнегү?

Гата аккордеонын гөрләтеп алды да тын гына моңга күчте. Шул вакыт сәхнәгә зәңгәр трико кигән Ләйләгөл чыкты. Сәхнәгә җәелгән паласның уртасында кулларын өскә күтәреп тоташтырды, аякларының очына гына басты да ярты гына секундка тынып калды. Җәйнең кояшлы иртәсендә күл уртасына йөзеп кергән аккош шулай бер мәлгә туктап кала: мәрмәр муенын көяз генә бөгеп су өстенә карый, үзенең күләгәсенә соклана. Туган көннең рәхәтлеген, гыйшык назын алдан сизгәндәй аның гәүдәсе җиңел генә дерелди — су өстендә күбәләк канат җилпегәндәй генә боҗралар тарала...

Ләйләгөл сәхнә кырыннан өч-дүрт кенә адым ераклыкта иде, Рушад аның сулаганын ишетте. Аның борынгы грек статуясы кебек сылу гәүдәсе аз гына дерелди иде — шул позадан алга таба йомшак кына ыргылып ул баш аркылы чыкты һәм күпер ясады, аннан кире якка мәтәлеп салмак кына урынына басты. Зал гөрләп алды. Боларның Гата белән, күрәсең, репетицияләре бер генә булмаган, музыканың һәр тактына моның хәрәкәте туры килеп тора иде. Менә ул халыкка ян белән басты да кинәт кенә кулларына таянып тәгәрмәч ясап сәхнәне йөреп чыкты. Аннан паласка сузылып ятты. Уртадагы рәтләрдән торып кузгала башладылар, тавыш китте.

— Урыныгызга утырыгыз!
— Басмагыз!
— Тавыш!

Кызның күкрәге салмак кына күтәрелә-төшә, сузып салган куллары Рушадка күренерлек үк дерелди иде. Аннан ул капланып ятты. Рушад үзен әллә ничек уңайсыз хис итте. Ләйләгөлнең өлгергән тыгыз груша кебек күкрәкләре гәүдәсе астында басылып авыртырлар кебек тоелды. Халык һаман гөрләде.

— Басмагыз!
— Утырыгыз урыныгызга, сыбызгы борыннар!

Аннан Ләйләгөл иң катлаулы номерын ясады. Рушадка аркасы белән басты да, артка сыгылып төште һәм шәрыкның елаган, сыктаган үзәк өзгеч көе астында гәүдәсен аз гына калтырата-калтырата аякларын бөрәм-бөрәм ычкындырып кулларында калды. Шул вакытта аның күзләре чаршау кырыеннан карап торган Рушадның күзләре белән очрашты. Ләйләгөлнең күгәрчен тамагы төсле тасма белән җыеп бәйләнгән чәчләре идәнгә салынып төшкән, керфекләре тирләгән иде. Ул Рушадка карады һәм бары тик ул гына сизәрлек итеп аз гына елмайды. Халык кул чапты... Аннан Ләйләгөл кызу-кызу хәрәкәтләр ясап палас өстендә кулын-аягын аерып алмаслык итеп баш аркылы мәтәлчек атып йөрде — «Шәрык вальсы»ның ахыры уйнала иде. Шулай йөргән көе ул сәхнә артына кереп тә китте. Клубны селкетеп кул чаптылар, сәхнә артындагы кешеләр — укытучылар, укучылар аны кочактан-кочакка йөрттеләр. Аста сызгырдылар, аяк тибеп кычкырдылар, кабат сорадылар. Тик хатын-кыз гына сабыр утырды. Хәкимҗан авызын актык чигенә хәтле ачып, елмаеп, дәү кулларын шап-шоп бәреп туйганчы кул чапкач, тыптын утырган Былбылнисасына карады да туктап калды. Бераздан, клуб тулы укучылар булуын бөтенләй уйлап та бирмәстән, хатынының юантык биленә кулын салды да тынып калды.

Гата вальсның ахырын уйнап җибәрде. Җиңел хәрәкәтләр белән сикергәләп Ләйләгөл кабат сәхнәгә чыкты һәм ду күчереп кул чапкан тавышлар астында әллә ничә мәртәбә рәттән баш аркылы сикерде. Аннан сәхнә алдына килеп халыкка баш иде дә йөгереп кереп китте. Ләкин бу юлы кызый сәхнәнең ягын бутады. Шунда әллә нәрсә генә булды: көтелмәгән бу хәрәкәттән сискәнеп Рушад артка караңгылыкка таба чигенде һәм шул вакытта үзеннән-үзе Ләйләгөл аның кочагына килеп керде. Җир шары бер мизгелгә әйләнүеннән туктап торды: дөньяда сугыш та булмаган, тугызынчы май да булмаган, Акбалык мәктәбе дә юк, имеш. Дөньяда бары тик табигатьнең менә шушы сылу иркәсе, шушы фәрештәсе, шушы аккошы гына бар икән... Сәхнә артындагы караңгылыкта Ләйләгөлнең кайнар бите Рушадның яңагына кагылды — аннан Рушад кызның биленнән күтәреп алды да үзен-үзе белешмичә үпте. Кыз аңа сарылды, беләкләре белән муенына чорналды. Аның яшь, көчле гәүдәсенең бөтен күзәнәкләре хәрәкәттә, бөтен тәненнән яшьлек дәрте бәреп тора иде. Рушад үзен урмандагы браконьер кебек хис итте: менә ул көне буе урманда качып ятты да су эчеп кайтучы көтүдән аерылып калган яшь болан баласын сукмактан ыргылып барганда хыянәтчел рәвештә тотып калды. Тегесе калтырый, куркына — ләкин ычкына алмый. Кыз елый иде, ахрысы — Рушад иренендә тоз тәме сизде. Алар бер-берсенә ярты гына җөмлә дә әйтмәделәр, ичмасам! Бары тик берни дә аңламаган килеш кызу-кызу пышылдаштылар:

— Рушад абый... Рушад абый...
— Ләйләгөл... сеңелем!

Бу газаплы, татлы төштән айнырга кирәк иде, моны икесе дә сизделәр. Монда кеше килеп керүе мөмкин иде — анысын да уйладылар. Тагын бер генә секунд! Тагын бер генә...

И дөнья! И бу дөньяның кырыс кагыйдәләре! И кеше рәхәтлеген рамкалар белән чикләүче педагогика фәне! Боларны гафу итегез, боларга тимәгез. Тимәгез, тагын бер-ике генә секунд шулай торсыннар. Явыз җаннар, шыксыз күңелләләр, мәхәббәт дигәннең нәрсә икәнен белмәгән кызганыч бәндәләр! Тимәгез аларга, тимәгез... Бу егет шушы ләззәтле минутны татыр өчен аз гына гомерендә зур, кыен юл үтте. Ил каршында үзенең егетлек бурычын намус белән үтәде. Шушы мизгелне анна кызганмагыз! Бу кыз үзенең бөтен барлыгы — яшьлеген, пакьлеген, саф хисләрен, күбәләк канатыдай җилфердәп торган күңелен, яшь бала баласыдай ыргым, сагълам гәүдәсен менә шушы мизгел өчен саклап алып килде — бу татлы төшне аннан кызганмагыз...

Татлы төш өзелде. Ләйләгөл Рушадның күкрәгеннән шуып кына төште дә юк булды. Рушад клубтан чыгып китте — аңына килә алмыйча, шактый вакыт чолан баганасын кочаклап торды. Күз алдына сугыш дәһшәте, дингезнең салкын кургаш дулкыннары йоткан иптәш егетләре килде. «Дусларым... Җаннарым! Мине гафу итегез... Мин бүген эгоистларча бәйрәм итәм. Җиңү көнен билгелим. Мин бүген үземнең бәхетемне таптым. Сез мине гафу итегез. Кострома егете Ваня Курагин! Суга батканда мин синең зур ачылган зәңгәр күзләреңне күрдем кебек. Ләкин икенче тапкыр су тавы астыннан чыкканда син инде юк идең... Винница егете Илья Дорошенко! Син җырчы идең... Мин синең соңгы секундтагы йөрәк өзгеч тавышыңны ишеттем. Ул тавыш әле дә минем колагымнан китми. Мин төннәрен шул тавышны ишетеп саташып уянам. Безгә ул вакытта егерме яшь тә тулмаган иде...»

Рушад клубның арткы рәтенә кереп утырды. Монда ирләр генә, иркенләп фикер алышып, тәмәке суырып концерт карыйлар иде. Сәхнәгә урындык чыгарып куйдылар. Зәңгәр сөяктән коелган аккордеонын күтәреп Гата чыгып утырды. Биек үкчәләрен шыкылдатып, сәхнәгә Нәркис чыкты, урындыкка тотынды. Аның чәчләре күпертелеп ясалган, өстендә чытыр ак кофта, затлы кара юбка, аягында кара ялтыравыклы туфли иде. Биек, озын, килешле аякларында тән төсле оекларКуйган да куйган матурлык! Арттагы ирләр үзара фикер алыштылар:

— Да, малай, моның төсле хатының булса...

— Алай да... Ничу тракторда эшләп йөрергә. Кочакла да тик ят, име?

— Ашарыңа ипиең булмаса, бик кочаклыйсын килмәс шул...

— Һи-и-и, исең киткән икән... Моның төсле патша кызы булса — ашау нәрсәгә...

— Тукта, тынлыйк әле.

Сәхнәдә Нәсимә тавышы яңгырады:

— Бөек Ватан сугышы елларында иң популяр булган җырлардан «Зәңгәр яулык».

Гата бармагын сөяк клавишалар өстеннән шудырып җибәрде.

Нәркис — яңгыравыклы тавыш иясе түгел. Ул, гомумән, җырчы түгел. Ләкин ул җырның тәмен, нечкәлеген белә. Берәүләр тамак белән җырлый. Нәркис — йөрәк белән. Хис белән. Ул — гомумән, хиссият колы. Менә ул керфекләрен аска төшерде, калку, килешле күкрәген салмак кына күтәрде. Күкрәге төшә башлады, шул вакытта гына күкрәк түреннән моң чыкты, көй агыла башлады... Соңгы куплетта аның тавышы елады. Тамагында әллә нинди кыллар өзелгәндәй итте, әйтерсең күз яше көйгә тавыш булып кушылды. Фронттан кайткан егетләр дөнья күчереп кул чаптылар. Алар арасында ашыгыч сорашу, белешү китте.

— Каян килгән асылкош бу?

— Нәрсә укыта бу?

— Ире юкмы? Егете201 бармы?

Фронтовиклар «бис» кычкырдылар. Карт-коры, бала-чага, хатын-кыз аптырашып аларга карады. Мырлашып алдылар.

— Ул хәтле... Орден тагып кайттым дигәч тә. Нинди матур җырлаган кешегә әллә нәрсә кычкыралар...

Концерт беткәч, сәхнәгә Бибисара менеп басты. Кулын күтәрде. Тавыш басыла төште.

— Иптәшләр, бер генә минутка тавышны бетерегез әле... Егетләр! Рөхсәт итегез башлангыч партия оешмасы, авыл Советы һәм дә правление колхозы идарәсе исеменнән шушындый яхшы концерт куйганнары өчен Акбалык урта мәктәбе укучыларына и укытучылар коллективына бик зур рәхмәт белдерергә. Бу концерт, иптәшләр, бик урынлы, бик яхшы булды. Күргәнегезчә, иптәшләр, мәктәп коллективы моны хәзерләргә бик күп көч куйган и Җиңү көненә багышланган концерт буларак монда сугыштан кайткан кешеләр дә бик актив катнаштылар. Иптәшләр! Үзегез беләсез, колхозыбыз кырларында язгы чәчү кампаниясе бара, шундый асубынни киеренке хезмәт атнасында колхозчыларга культура хезмәте күрсәткән бу иптәшләргә рөхсәт итегез тагын бер мәртәбә сезнең исемнән рәхмәт белдерергә.

Урам тутырып сөйләшә-гөрләшә халык таралды. Бөтен сүз — концерт турында гына иде.

«Идел» көенә кушылып җыр башлаучы кеше Мәсрүрә булган икән...

*Дәвамы бар*

## Клара Булатова

### Таныш моңнар

Яңа иртә туып килә җирдә,
Тәрәзләрдән якты бәркелә.
Казан бугай, ахры, концерт бирә,
Безнең якның яңа көненә.

Бу — Шопен да, Бетховен да түгел,
Ә шуларның асыл кардәше.
Бу — татарның,
Олы, тере илнең
Кабатланмас Салих Сәйдәше.

Бу көйләрдә
Көнбатыш та, көнчыгыш та түгел,
Үз аһәңе шушы якларның.
Бу моңнарда мин тарихын таныйм,
Кан тибешен таныйм татарның.

Туган якның табигатен таныйм
Шунда туган Сәйдәш моңыннан.
Кыйгачлатып, әнә, киек кошлар
Күтәрелә Кандыр буеннан.

Туган якның болыннарын таныйм;
Шул көйләрдә җанга тирбәлеп,
Яшь егетләр анда печән чаба,
Изүләрен чишеп җибәреп.

Туган якның үткәннәрен таныйм:
Иске авыл алга килә дә,
Җырлый-җырлый кызлар киндер талкый,
Ак тулалар баса өмәдә...

Мин халкымның үткәннәрен таныйм,
Көрәшләрдә алган җиңүен,
«Без кабызган утлар» яктысының
Бу көннәргә балкып килүен.

Бу көйләрдә бөтен тулылыгы,
Матурлыгы безнең якларның.
Бу — Шопен да,
Бетховен да түгел.
Бу — Сәйдәше безнең татарның.

●

Гөрләвекләр шаулап төште ярга.
Тын чоңгыллар кайнап болганыр.
Яраларын җирнең бальзамларга
Шундый кирәк иде бу яңгыр.

Урсал суы ташып кинәт артты.
Шул муллыкка җаным куанып,
Басуларны иңләп йөреп кайттым,
Яңгыр суларында чыланып.

Дәррәү килгән яңгыр тынды тагын,
Көяз таллар, назлы юкәләр
Яңгырларда юган яулыкларын
Киптерергә кояш көтәләр...

●

Яз көткәндә кабат көзгә кереп
Нишә тапкыр сынды бу күңел...
Алданудан ачы яшьләр түгеп
Көн елады бүген,
мин түгел.

Яз яктырып китәр төсле кинәт,
Көн елмайса яше аралаш.
Күкләр шаһит,
һәрчак бу табигать —
Минем җаным белән аваздаш.

●

Дымсу гына тыныч апрель киче,
Су шауламый, тора җыелып.
Су тынлыгын гүя саклар өчен
Таллар ята ярга сыенып.

Шул талларның итәгенә тиеп,
Үз җаена гына ага су.
Ерактагы казлар җыры кебек
Үзе матур, үзе ямансу.

≈≈≈≈≈≈

## Лена Шакирҗанова

### Синең күңел

Җилләр төсле җитез була алам...
Ләкин сине куып җитә алмам,
Җилдән җитез синең күңелең...

Аккош кебек оста йөзә беләм,
Әмма куркам,
Синең күңел тирән
Һәммә күлдән...

Хисләреңнән мәрҗән тезәр идем,
Төшләремне бизәр идем,
Мөмкин түгел,
Ефәк җептән нечкә синең күңел...

Синең күңел гөлләр бакчасы ул...
Әллә яшереп гөлләр өзимме?
Юк, кирәкми,
Шул бакчада шытып,
Бөреләнсәм иде үзем мин,
Чәчәк атсам иде үзем мин!..

### Учаклар ягасым килә...

Чит учаклар тирәсендә
Күп җылындым. Мин әле
Учаклар яндырыр идем
Җылытырлык җилләрне...

Учаклар ягасым килә
Очкынланып үрләрлек,
Йолдызларга тоташырлык,
Балкытырлык үрләрне...

Ягасым килә учаклар,
Һәр юлчыны дәшәрлек...
Сүнәргә түгел, гомергә
Ялкынланып яшәрлек!..

### Кызлар җыры

Кояш безгә, без кояшка
Карыйбыз да көләбез.
Ник икәнен сорамагыз,
Тик үзебез беләбез...

Бик моңсу зәңгәр кичләрдә
Тын суларга киләбез:

Бер суга, бер айга карап,
Елыйбыз да көләбез...
Ник икәнен сорамагыз,
Тик үзебез беләбез...

## Кышкы этюд

Шук та соң бу җил, кар кызын
Элəктереп ала да,
Кочып нечкә билләреннән,
Вальс бии һавада,

Арып беткәч, урамнарда
Парлап биеп көнозын,
Тирбәтеп ак тирәкләрдә,
Йоклата ул кар кызын...

## Беренче кар

Беренче кар...
Кыймый гына басам.
Яп-яңа кар...
Бик таныш та,
Ләкин
Онытылган,
Сагынылган...
Санап кына салам эзләремне,
Саклыгымнан...

Салкыныннан түгел,
Оялып
Аклыгыннан...
Яп-яңа кар, назлы, йомшак,
Иплəп кенә
Кулларыма алам.
Алларыма
Тамчы-тамчы
Көмеш тама...

## Ә син җырдан сора

Ямьсез дисең, дөнья,
Алсу төсләр
Тик җырларда гына, ахрысы...
Ә син менә уян кояш белән,
Күрер өчен ал таң яктысын...

Таһир-Зөһрә кебек сөешүләр —
Хыял гына, дисең, ул бар да.
Ә син җырдан сора, ул күп белә,
Халык сала серен җырларга...

## Кайнар чишмә

Син гейзерларга —
Кайнар чишмәләргә гашыйк.
Минем хисләрем дә
Шулар кебек,
Вакыт-вакыт
Ургылалар тышка,
Кайнап, ташып...
Син бит
Кайнар чишмәләргә гашыйк!..

**Равил Вәлиев**

# КАУРЫЙЛАР ЧЫНЫККАНДА

## Чыдамлыкка имтихан[1]



Чокыр казылып бетә дигәндә, мастер В. Журавин яңадан нарядлар күтәреп килде. Боларында канализация трубалары өчен каналлар казырга кушылган.

— Борыннарны салындырмыйк, егетләр. Кешедән ким түләмәбез,— дип куйды мастер, безнең күңелләрне күтәрергә теләп.

— Шулай шул! Казы да казы. Барыбер...— дип, Рамил Хаҗиәлиев аның сүзләрен җөпләде. Тагын нидер әйтергә теләгән иде, Петя Алексеевның усал күз карашын тоеп, туктап калды.

Былтыр Мөслим сабан туенда үзен еккан батырдан күптән үчне кайтарырга хәзерләнә инде ул. Хәтта буш вакытларында, спорт залына йөгереп барып, штанга белән күнегүләр ясап килергә дә өлгерә.

Петя, балчык умырып алырга теләп, кулындагы көрәген җиргә шундый каты итеп кадады, агач сап «шырт» итеп сынды.

Петя ул аз сөйләшә. Ләкин бер әйтсә, берәгәйле итеп әйтә. Бу юлы аның авызыннан бер сүз дә чыкмады. Кара бөдрә чәчле башын күтәреп, чәбата кашлары астыннан элек Рамилгә, аннары мастерга бер сөзеп карап кына алды ул. Шул җитте. Бер кулына әле генә шартлап сынган көрәкне, икенчесенә аның чәрдәкләнгән сабын тоткан Петябызың бу карашы барыбыз өчен дә теләсә нинди сүзләрдән аңлаешлырак иде.

Эх, әйтми калган булсаңчы, мастер, ул сүзләреңне, ичмасам! Ук булып кадалдылар бит алар бригада членнарының йөрәгенә. Эш акчада гынамыни соң? Бригада членнарының барысы да диярлек бирегә комсомол путевкасы белән, йөрәкләре кушуы буенча килгән бит.

Шәһәрнең ашханәләр челтәрен киңәйтү көн кадагында торган иң җитди мәсьәлә хәзер. Халык көннән-көн арта тора. Һәр ашханә янында чират бормаланып аккан елга кебек сузыла. Шуларны күреп тор да кул белән җир казып маташ, имеш. Хәзерге заманда, шундый техника барында!

Юк, дөрес әйтмәдең, мастер иптәш! Уйлап әйтмәдең. Әрле-бирле йөреп, әнә бригадада дисциплина да йомшап киткән. Шамил Асеров, Казагыстаннан килгән үнси-

[1] Дәвамы. Башы 2 санда.

гез яшьлек егет, җәмәгать тәртибен бозганы өчен, әле күптән түгел милиция бүлегендә булып кайткан. Хәзер үзенә уңай характеристика язып бирүне сорап йөри.

Беренче смена тәмамлангач, бригада җыелышы булып алды. Ш. Асеровның язмышын хәл итәргә кирәк иде.

Ул үзе төзелештән китәм дигән була. Сер бирми, янәсе. Ә үзе бүген көне буе ничек йөгереп эшләп йөрде? Бригадирның кушканын да көтеп тормый, кайда авыр, шунда атлыга. Бригада егетләре берничә минутлык ялга туктагач, үзенең дә көйрәтеп алырга тиешлеген онытып, Әлфинур белән Тамарага булышты.

Вазих Шамил турында күп сөйләп тормады:

— Куарга! Бригаданы хурлыкка калдырып ятмасын монда! — диде дә сүзен бетерде.

Бу сүзләрне ишеткәч, Шамилнең нечкә генә итеп калдырылган мыек очлары тартышып куйгандай булдылар. Ул, ашыгып, «ковбой» дип язылган чалбар кесәсенә тыгылды. Аннан карандаш кебек озын сигарет тартып чыгарды һәм фильтрсыз башыннан авызына капты. Ул кабыза алмый азаплангач, ниһаять, эшнең нидә икәнлеген аңлап, сигаретын бер читкә атты.

Вазих, гомумән, һәр нәрсәне тиз, кискен хәл итәргә ярата. Армиядә дә бит ул старшина булган. Шулай да кешенең язмышын болай җиңел, «уптым илаһи» гына хәл итәргә ярыймы соң инде? Шамил әле яшь. Аның тормышы яңа гына башлана.

Кызлар Шамилне бригадада калдыру ягында булдылар. Николай Курицын белән комсорг Хәбир Нәбиуллин да алар́ны яклады.

Шундый карарга килдек: бер ай сынау срогы белән Шамилне бригадада калдырырга!

Төзәлергә охшый егет. Хәзер аны эшнең гел авыр, иң җаваплы участокларында күрәсең.

Бер кенне бригадага 32 нче төзү идарәсенең комсомол комитеты секретаре Юрий Завьялов килгән иде. «Тиздән классик көрәш, самбо, бокс түгәрәкләре ачабыз. Теләүчеләр булса, язылырга мөмкин»,— ди. Бу сүзләрне ишеткәч, Шамил, чабыш аты шикелле, кая басып торырга белми башлады. Аны бигрәк тә самбо көрәше кызыксындыра. Тик комсомол комитеты секретаре: «Бу төр көрәшкә сугышчан комсомол дружинасына йөрүчеләрне генә алабыз»,— дигәч, Шамилнең кәефе кырылды.

— Ничего, Шамилька! Күңелеңне төшермә,— дип юатырга керешә «дядя Коля».— Үзеңне яхшы яктан күрсәт кенә менә. Вазих «үзебезнеке». Ә бит ул дружина комиссары...

Төзү материаллары һаман җитешми торса да, ниһаять, ашханәнең түбәсенә аяк бастык.

Хәзер ашханәнең эче шаулап тора. Бирегә М. Никишин җитәкчелегендәге буяусылаучылар бригадасы килде. Икенче башта Казан төзүче инженерлар институты студентлары — өченче семестр «солдатлары» бетон җәелгән идәнгә фарфор плитәләр түши башладылар. Тәрәзәчеләр, үткен алмазлары белән чаж-чож китереп, пыяла кисә, сантехниклар трубалар суза.

Менә шундый ыгы-зыгы арасында Ринат Кисюшев җәлт кенә каяндыр балта алып килде. Без, берничә кеше, бу вакытта түбәгә җәю өчен бетон вакдый идек. Бу эштә иң шәбе балта инде. Ринатка рәхмәтләр укый-укый, бер ярты сәгатьләп эшләп алырга да өлгермәдек, «балтасы суга төшкән» кеше кебек әлсерәп, бер студент килеп җитте.

— Алай-болай безнең балтаны алып тормагансыздыр бит? Хәзер үк калыплар ясыйсыбыз бар иде, ике кулсыз булдык менә,— диде ул, сулышы кабып.

— Юк, күрмәдек. Без бит — ташчылар. Ни пычагыма ул безгә? — диде Ринат, күзен дә йоммыйча. Ә үзе, тиреслектә җим тырманып йөргән тавык кебек, аяклары белән әлеге балтаны ком эченә күмә башлады.

Ни әйтергә белмичә барыбыз да телсез калдык.

— Ник бирмәдең балтаны? — диде Ганс Нәбиев, студент ары киткәч.

— Үзем өчен тырышаммы әллә,— диде Ринат.— Бригада өчен бит... Кеше балтасы өчен нәмәгә эчең авырта башлады әле синең, Ганс? Үзеңнекен алмаганнардыр ич?

Смена тәмамланганчы, әлеге балта комда күмелеп ята бирде. Кирәге булса да, аңа кагылырга беребезнең дә кулы бармады. Шулай да баягы сөйләшү Ринат өчен

эзсез генә үтмәде, күрәсең. Смена алышынганда ул, «әле яңа гына табылган» балтасын күтәреп, студент егетләр янына китеп барды.

Ринат Түбән Тагил шәһәре заводларының берсендә Ганс белән бергә эшләгән. Бригадага Чаллы җиренә килгәч, кабат очрашканнар. Аларның тышкы кыяфәтләре дә охшаш: икесе дә базык гәүдәле, икесе дә кара комбинезон киеп эшлиләр. Хыялый һәм саф җанлы, кеше турында нәрсә уйлаганын ачык йөзенә бәреп әйтә белүче Ганс тере холыклы, үзе әйтмешли, «әнә күзеннән үтеп йөри алучы» якташының нәкъ киресе. Шуңадырмы, бригададагы шаярту укларының да күбесе аңа кадала. Ганс аларның күбесен ирләрчә генә үткәреп җибәрергә тырыша. Әмма инде бу шаяртулар артыбрак китсә, аны тыныч калыр димә. Мондый чакларда күп сорап тормый. Сүз аның профессиональ осталыгы турында барганда бигрәк тә.

Бүген дә шулай булды.

Менә бер айга якын инде, бригада ташчылары берьюлы өч объектта — төзелеп бетеп килүче ашханәгә, өченче кварталда салына башлаган аптекага һәм район элемтә бүлеге бинасына таралып эшләргә мәҗбүр. Моның сәбәбе бер генә: эш фронты җитеп бетми.

«Башыңа төшкәч, башмакчы булырсың» дигәндәй, менә шул аптекада гипсоплитәләр коеп маташкан идек. Кайсыбыздыр ишекне берничә сантиметрга таррак калдырган. Өйләгә чаклы Витька Митченков дигән егетебез шуны киңәйтеп йөрде. Бераздан аңа булышка тагын бер кеше кирәк булды.

Бу вакытта Рамил белән Ганс табельщица Кәүсәрия Алекеева алып килгән яңа пычкыны бүлешә алмый тарткалашалар иде. Шушы чакта алар янына Вазих килде дә Ганска Витькага булышка барырга кушты. Гансның ачуы кузгалган чагы иде, шуңадырмы, икe дә уйламыйча, кырт кисте дә куйды:

— Җыен тишек-тошыкны ямап йөрергә миңа кушасың. Инструментны да бирмиләр әле. Э искесе белән бармыйм!

Вазихның да чигенергә исәбе юк иде:

— Үзең эти кеше, үзең, бала-чага шикелле, шул пычкы өчен тарткалашып маташасың. Бармыйсың икән, иртәгә эшкә чыкмаска можешь! Кирәгең юк! Гочка! Армиядә моның өчен хәрби трибуналга бирәләр, ә сугышта...

Ганс аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде. Кырмыска оясына таяк тыгылган иде инде, моңарчы җыелып килгән бөтен үпкәләр дә тышка бәреп чыкты:

— Китәрмен дә шул! Дүртенче разрядлы ташчы була торып, нигә монда җыен тишек-тошыкны ямап йөрергә? Ачтан үләрсең...

Гидротөзүчеләр поселогындагы яшь нәратлык эченә салына торган Кунак йортында каравыл торганы өчен (кем булып кына эшләргә туры килмәде ташчыларга бу көннәрдә?) тиешле хезмәт хакын аңа һаман түләп җиткермиләр иде әле. Аның бу сүзләре шуңа ишарә ясау иде инде. Ә Түбән Тагил шәһәрендә Гансның ике игезәк баласы, шуларны карап өйдә утыручы хатыны калган.

Ганс кайтып китәргә җыенып бераз баргач, кире борылды да, сөзәргә торган үгез кебек, Вазихның каршысына килеп басты:

— Нәрсә, бригадир? Иртәгә эшкә чыгаргамы, юкмы? Инструментларны кайчан тапшыра башларга мөмкин?

— Анысы синең эш...

Гаеп атта да, тәртәдә дә бар инде анысы. Ганска җитдилек җитеп бетмәде. Вазих та, гадәтенчә, кызыбрак китте.

Кешеләрне бригададан куып кына эш бетми ләбаса! Алар белән сөйләшә белү, аларның йөрәгенә ачкыч таба алу, ай-һай, авыр икән ул! Бу турыда Вазих, һичшиксез, уйланачак әле. «Анысы синең эш» дип, капканы ябмыйча калдыруы шушы турыда уйларга нигез калдыра...

* * *

Шулай төрлебез төрле объектларга таралышып эшләп йөргән көннәрнең берсендә бригадага Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше штабы начальнигы Валерий Стекольщиков һәм «Жилстрой-1» идарәсенең комсомол комитеты секретаре Юрий Завьялов килде.

— Бригада члennарының кәефләре төшенке икән дип ишеттек,— дип башлады

сүзне штаб начальнигы, ашыкмыйча гына. Валерийның сөер гадәте бар икән: бер җөмлә әйткән саен, теле белән авыз эчендә бераз нидер әвәләп тора. Әйтеләсе фикерен гүя шулай чәйни-чәйни чыгара.

— Тиздән үзегезгә җиденче кварталдагы 100 квартиралы яңа йорт салуны тапшырырга уйлыйбыз. Менә анда сәләтегез күренәчәк инде. Сезнең бригадага игътибар бик зур. Кем бу коллективта эшләргә лаек түгел, андыйларны без бередән алачакбыз. Ләкин эш моңа барып җитмәс, сынатмассыз дип уйлыйбыз.

Бу сүзләрне ишеткәч, күңелләр күтәрелеп китте.

Йорт төзегәне булмаган ташчы ташчымыни ул?

— Бик сикеренмик. Ишеттегезме, ул йорт әнә Липецк ысулы белән салыначак, ди. Болай да осталык ягыбыз чамалы. Моңа чаклысы — баласы, алда әле — анасы! — дип кемдер әлеге хәбәрдән башлары күккә тигән егетләрне кабат җиргә төшереп куймакчы иткән иде дә шунда ук төрле яктан яуган сораулар яңгыры астында күмелеп калды:

— Җир казып йөреп, осталыкны ничек күтәрәсең ди?

— Йорт кына бирсеннәр, анысы... Кешедән кай җиребез ким? — диештеләр бригада членнары.

## Боз кузгалды

«Жилстрой-1» идарәсендә «ЧП». А. Селицкий, В. Тихонов, Г. Геворгян, К. Хәйруллин һәм В. Мәүлихов бригадалары менә берничә көн инде эшсез тора. Әлеге дә баягы шул — эш участогы җитми. Объект тирәләрен җыештырып, төрле вак-төяк эшләр белән көн үткәрәбез. «Фундаментлар салу өчен блоклар ясап өлгертә алмыйлар икән»,— дигән имеш-мимешләр йөри.

Бу «өзеклек» турында күбрәк белү, хәлне ачыклап кайту нияте белән, 32 нче төзү идарәсенә үз «делегация»безне җибәрдек.

«Тегәрмәчләр» өстендәге төзү идарәсен эзләп табу шактый четерекле хәл булып чыкты. Сугыш хәрәкәтләренең иң кайнар, иң хәлиткеч участоклары алышына барган саен урынын үзгәртеп торучы хәрби штаб кебек, шырпы тартмасыдай кечкенә генә ике зәңгәр вагонга урнашкан төзү идарәсенең дә гел күченеп йөргән көне. Кичә генә өченче кварталда иде әле ул, ә менә бүген аны көч-хәл белән бишенче микрорайоннан эзләп таптык.

— Балык баштан чери инде ул, егетләр,— диде Роберт Гумерович, безнең ни өчен килгәнлекне белгәч.— Нуль циклын салучы 34 нче төзү идарәсе йорт нигезләрен әзерләп өлгертә алмый. Акрынрак кыймылдыйлар. Үзебез дә җитәрлек таләпчәнлек күрсәтеп бетерә алмыйбыз...

Без бригадага әйләнеп кайтканда, ашханә каршындагы ком өеменә кырын ятып, егетләр гәп саталар иде. Алып кайткан яңалыкларыбызны «бушатырга» да өлгермәдек, һич көтмәгәндә, ашханә почмагыннан «Камгэсэнергострой» идарәсе начальнигы Аркадий Владимирович Эгенбург үзе һәм аның кадрлар буенча урынбасары Хәниф Шәйхетдинов килеп чыкты. Аларны күргәч, башта бераз каушап калган булсак та, «гомуми килешенү» буенча, урыннардан кузгалмаска, шундый зур кешеләр алдында ризасызлыгыбызны белдерергә булдык.

Ай, бу Ринатның мутлыклары! Аның үзе белән эшкә ияреп йөри торган транзисторы юри кычкырыбрак сөйли башлады. Безнең хәлләр хәзер шулай: «дядя Коля» әйткәнчә, «пан или пропал».

— Сез кемнәр? Бригадирыгыз кайда? — диде Аркадий Владимирович, килә-килешкә.

— Мәүлиховныкылар,— дибез хор белән һаман да шул кырын яткан көенчә.— Ө бригадирыбыз юк, ул хәзер тәэминатчыга әйләнде. Эш сорап, төзү материаллары сорап, конторадан конторага чаба.

Ләкин төзелеш начальнигы безне тиз кулга алды. Депутат значогы җемелдәгән костюмының төймәләрен чишеп җибәрде дә кырын яткан Йосыф Галләмов янына килеп басты.

— Олылар белән кырын ятып сөйләшергә ничек оялмыйсыз? Кайда өйрәттеләр моны сезгә?

Арттырыбрак җибәрдек инде үзебез дә. Гадәттә сүз эзләп бер дә кесәгә керел тормаган Йосыф бу юлы ык-мык итте дә телсез калды. Калганнарыбыз да җир ярылса җир тишегенә кереп китәр хәлгә җиткән идек, барыбыз да берьюлы аякка бастык. Азрак сүзсез торганнан соң, ашыга-ашыга, күңелләребездә җыелып килгән моң-зарларыбызны сибә башладык:

— Дүртенче көн инде юкны бушка аударабыз.

— Төзелешкә ташчылар җитми, ә без эшсез утырабыз. Моны ничек аңларга?

— Июнь ае өчен нәрәтне нибары 3 сум 60 тиен белән япканнар.

— Иптәшләребез башка бригадаларга күчә, коллектив таркала.

Эгенбург безне сабыр гына тыңлап торды да һәркайсыбыздан ничәнче разряд белән эшләвебезне сорашып чыкты. Чират Коля Курицинга килеп җиткәч, аның тормыш шартлары турында да җентекләп сорашты:

— Кайдан?

— Саратов шәһәреннән. Минә дигән ике бүлмәле квартирамны калдырып килдем.

— Син больницалар шәһәрчегендә эшләмәгән идеңме?

— Туры килде.

— Ә-ә-ә, хәтерлим, хәтерлим. Ә нигә сезне аннан алдылар соң?

— Менә бу ашханәне төзергә җибәрделәр. Прорывка.

— Менә нәрсә, егетләр, Мәүлихов кайткач, бөтен бригадагыз белән минем янга килегез. Эш турында бераз киңәшеп алырбыз.

«Кунаклар» китте.

Әйтерсең бригадага яшәү сулышы өрделәр, һәркем җанланган, һәркем дулкынланган иде.

Яңа бияләйләр күтәреп, ниһаять, Вазих та әйләнеп кайтты. Төзелеш җитәкчеләре белән булган очрашу турында бәйнә-бәйнә аңа да сөйләп бирдек.

— Димәк, боз кузгалды, алайса...— диде шатлыгы йөзенә чыккан бригадир.

Эш сәгате беткәч, сөйләшенгәнчә, җыелышып «Камгэсэнергострой» идарәсенә, А. Эгенбург янына киттек. Төзелеш начальнигы бүлмәсенә барып кергәндә, анда «Жилстрой-1»нең партком секретаре А. Майоров, 32 нче төзү идарәсе начальнигы Ф. Макаев һәм аның урынбасары Р. Вәлиев тирләп-пешеп утыралар иде инде. «Мунча» кызу булган, күрәсең. Төзелеш начальнигы исә эссене һаман өсти тора:

— Ничә көн эшсез торасыз? — диде ул, без утырышып беткәнне дә көтмичә.

— Дүртенче...

— Бригадада күпме кеше?

— Егерме биш.

Аркадий Владимирович, «ишеттегезме инде?» дигәндәй, «Жилстрой-1» җитәкчеләренә карап алды, бер мәлгә дәшми торды. Аның бармаклары, чапкан ат тояклары тавышын хәтерләтеп, өстәл өстендә биешеп алдылар. Аннары ул сүзен дәвам иттерде:

— Бу хәлне бригадага аңлатып бирегез! Бер дә оят түгелмени сезгә? Әйтү шушы булсын: дүрт көн простойда торткан өчен, бригада членнарына хезмәт хакын үз кесәгездән чыгарып түләячәксез!

Ә сез, Вәлиев, идарәнең парторгы була торып, комсомол-яшьләр бригадасына игътибар бирә алмыйсыз. Күптән түгел генә Мәүлихов белән комсомол съездында булып кайттыгыз тагын үзегез. Кая китте аннан алып кайткан ялкын, кайда комсомол турында кайгыртуыгыз? Бирелә сүз төзелешнең, шәһәребезнең киләчәге турында бара бит. Ә сезнең берегез дә, бу мәсьәләне күтәреп, парткомга яки минем янга килеп карамады.

— Эш моңа килеп җитәр дип кем уйлаган, Аркадий Владимирович,— дип акланырга тырышты Федор Алимович.— Аннары Мәүлихов бригадасы әле яшь, коллектив яңа оешып кына килә. Мастерок тотарга өйрәнсеннәр, шомарсыннар, дидек.

— Гафу итегез! Сез Хуҗа Насретдин кебек фикер йөртәсез, иптәш Макаев! Суга кермичә генә йөзәргә өйрәнеп буламы? Кызык, кызы-ыык... Ә нигә бу комсомол-яшьләр бригадасында югары разрядлы ташчылар аз? Чөнки сез килгән бер кәчкәләрне Геворгян бригадасына җибәреп торасыз. Әйтерсең Чаллының бер бригада гына тези. Яшьләргә ышаныч юк, янәсе. Бу гаделсезлек, иптәшләр! Болай ярамый! Болай эшләргә безнең хакыбыз юк...

Сөйләшүнең нәтиҗәсе булды: безнең бригаданы шәһәрнең коньяк-кошбатыш өлешендәге җиденче кварталда 100 квартиралы йорт төзергә дип билгеләделәр. Әмма һаман да шул блокларга кытлык аркасында, бу йортның да нигезе әзер түгел икән әле. Тимер-бетон конструкцияләре заводыннан блоклар алып кайтып, аның нигезен үзебезгә үк төзеп бетерергә туры киләчәк, ди.

Салырга йорт кына бирсеннәр, аңысы. Нигез салу түгел, кирәк булса, шайтанның үзен дагалап куярга әзер идек без бу минутта. «Йорт» сүзен ишеткәч, башлары күккә тигән бригада ташчыларын Аркадий Владимирович бармагын селки-селки озатып калды:

— Карагыз аны! Сынатасы булмагыз! Ышанычка тап төшерсәгез, башка борылып та карамабыз үзегезгә.

## Нигез ташлары

Әле эш көне башланырга ярты сәгатьләп вакыт бар. Бригада членнары тимер-бетон конструкцияләр заводы конторасы янында җыелышып беткәннәр иде инде. Бераздан полигон мастеры Нәҗип Хәлиуллин да килеп җитте.

— Әлегә шатландырып булмый шул, егетләр,— диде ул, безнең нинди максат белән йөрүебезне белгәч. Аңнары, нәрсә турындадыр уйланып, бераз дәшмичә торды да, «әйдәгез, биредәге хәлне үзегез күреп китегез» дигәндәй, безне полигонга ияртеп алып китте.

Полигон дигәннәре бетон белән катырылган шактый зур мәйдан булып чыкты. Кырыйда — әрдәнәләп өелгән берничә дистә блок.

— Бар булганы шушы инде. Ә-әнә, күрәсезме,— диде мастер, блок әрдәнәләре янына әле яңа гына килеп туктаган ике «Краз» машинасына күрсәтеп.— Табадан төшкән коймак кебек, әзер булган берен алып китеп кенә торалар.

«Инде нишләргә? «Блоклар юк!» дип яңадан идарәгә, начальникларыбыз янына, кайтып егылыргамы?» — дип ут йотып торганда, «дядя Коля» әйгә куйды:

— Ә нәрсә, егетләр... Әгәр блокларны үзебез коеп карасак?

— Бу эштә арпаны кибәктән аера белмичә торыпмы?

Ләкин күбебез Николай Курицин яклы иде:

— Өйрәнербез...

— Үзебез койган нигез ташларыннан үзебез үк йорт салачакбыз! Кайсы ташчыга тигән бу бәхет?

— Тик миңа рөхсәт итсеннәр генә иде.

— Күренеп тора: сез эшкә чынлап торып тотынгансыз, ахрысы,— диде мастер, кызып-кызып бәхәсләшүләр басыла төшкәч.— Запас калыпларыбыз бар. Киңәш-фәләнен дә кызганмабыз...

Ул безне киптерергә куелган блоклар янына алып килде дә җентекли-җентекли блоклар кою процессы турында сөйли башлады.

Шикәр кебек коры, корычтай нык әзер блоклар әрдәнәләргә өелеп куелганчы, шактый тир агызырга туры килә икән әле. Баш-башларындагы «колаклар»ына тимер чөй кагып, калыпларны «тегәргә», «табага» ябышмасын өчен, төпкә пыяла чүбе җәеп чыгарга; калыпларның эчке стеналарын сумала белән майлап торырга; калып эченә бетон тутырырга, тутырылган бетонны бик җентекләп вибрацияләргә, ката башлаган бетонга монтаж элмәкләрен киертергә, бетонның катканын көтеп, ниһаять, калыпларны салдырырга — әнә шуннан соң гына блок дигәннәребез әзер була икән.

— Блокларны ясау аннан-моннан эшләгәнне яратмый,— диде мастер.— Иң әһәмиятлесе:— калып эченә бушатылган бетонны, үз вакытында һәм яхшы сыйфат белән вибрацияләп, тыгызлау. Йорт астына ятачак нигез ташларының ныклыгы, нигездә, әнә шуңа бәйле... Ягез, сораулар булырмы?

— Нәгыйм абый, сезнекеләр сменага ничә блок бирә? — диде шунда Иосыф Галләмов.

— Э-һ-ем-мм,— дип тамак кырып куйды мастер.— Ничә дип... Әйтик, җан башына бер дистәне тутыра алсагыз, начар булмас иде булуын.

Без салачак 7—6 нчы йортның нигезе өчен проект буенча 1200 блок каралган. Димәк, бу блокларны коеп бетерү өчен, кара исәп белән уйлап караганда да, безгә ун эш көне кирәк булачак. Бәлкем әле сменага 50—60 блок биреп булыр. Һәрхәлдә, һәр звено шуның өчен тырышачак.

Блоклар ныгып җиткәнче 4—5 көн үтә икән. Ә тимер калыплар 20 генә. Шуңа күрә, эштә өзеклек тудырмас өчен, дүрт звенога бүлечеп, өч сменада, күчмә график буенча эшләргә дигән карарга килдек. Һәр звенода дүрт кеше. Кем күбрәк бирер?

«Жилстрой-1» идарәсе тарихында бу әле беренче тәҗрибә. Уңышлы чыксын иде инде. Сынатмыйсы иде. Хәзер бик күпләрнең күзләре безгә текәлгән.

Без дүртәү: Коля Курицин, Хәбир Нәбиуллин, Ринат Кисюшев һәм мин — өченче звенога эләктек. Өченче звено — өченче смена. Димәк, төнге уникедән иртәнге җидегә хәтле эшлибез. Шуңарчы бераз хәл җыеп алырга кирәк дип, тулай торакка кайтып киттек. Ләкин барыбер юньләп ял итеп булмады. Кроватьта әйләнеп-тулганып ятып та, йокы симертә алмагач, Хәбир белән Мәләкәс елгасы буена балык каптырырга төшеп киттек. Ләкин анда да җанга тынычлык табып булмады. Күзләр — калкавычта, уйлар — полигонда, егетләр янында...

— Әйдә, әйләнеп кайтыйк әле булмаса үзебезнекеләр яныннан,— диде Хәбир, ашыга-ашыга кармакларны җыя башлады.

Тулай торакка кереп тиз генә өс-башларны алыштырдык та, машиналар быз-быз үтеп торган Чаллы — Әлмәт юлын көч-хәл белән аркылы чыгып, аска — Кама буена урнашкан полигонга төшеп киттек.

Хуш исле наратлыкны үткәч, «Камснаб» идарәсе складларына таба сузылган тимер юлны чыгарга кирәк иде. Менә ул да артта калды. «Пош-ш, пош-ш-ш!» сулап, төзү материаллары төялгән тимер юл составы үтеп китте.

— Кара әле, син ничек уйлыйсың?..— дип, Хәбирдән төнге сменада ничек эшләячәгебез турында нидер сорарга җыенып, авызымны ачкач идем дә, янымда аның юклыгын тоеп, кинәт тукталып калдым. Артыма борылып карасам, аякларын ерып шпалга баскан да, чандыр гәүдәсе белән тимер юлда тырпаеп, ерагая барган паровозга моңсуланып карап тора Хәбир.

— Әйдә инде, нәрсә тораташ булып каттың анда? — дип кычкырам аңа.

Юк, кымшанмый да! «Әллә ишетми инде?» дип уйлап түземсезлек белән яңадан кабатлыйм:

— Хәбир дим...

Шул чак, кылт итеп, Чаллыга КамАЗ төзешергә килгәнче Хәбирнең Казанда паровоз машинисты булып эшләве исемә төште. Ул бит тимер юлчылар мәктәбен бетергән. Ул бит һөнәре буенча тимер юл кешесе!

— Паровоз исе килә,— диде Хәбир, һаман да күзләрен горизонт читенә китеп тоташкан корыч тасмадан алмыйча.— Сагындыра шайтан алгыры...

— Завод белән яңа шәһәрне генә төзеп бетерик менә. Тагын корыч айгырга утырып, конвейердан гына төшкән КамАЗ автомобильләрен ташый башларсың. Кайгырма, дускай! — дим мин, аның сагышын җиңеләйтергә теләп.

Бая гына паровоз кереп югалган зәңгәр киңлеккә карап бераз дәшмичә тордык та, тимер юл хәтердә яңарткан Казаныбыз, анда калган дуслар, туган-тумачалар турында сөйләшә-сөйләшә, үз юлыбызны дәвам иттек.

Килсәк, ни күзләребез белән күрик: Коля белән Ринатыбыз икенче сменадагылар арасында буталып йөриләр иде инде. Димәк, аларның күңелләре тыныч түгел.

— Нәмә, йокы кермимени? Шулай ул, шулай... Ә кәк же, ызба чаклы ызбаны салырга кереш тә, көпә-көндез йоклап ят, имеш! Китең, китең, булмаганны. Тавыклар кәләр үзегездән,— диде Ринат, гадәтенчә, тешләрен ялтыратып, безнең соңлап килгәнлеккә терттереп алды.

Беренче сменадагылар өйләренә таралышканнар, икенче звено — Арча малайлары — эшкә керешкән иде инде. Вазих та бирелә.

— Беренче сменада 34 блок хәзерләнде. Башлап җибәрүчеләр өчен аз түгел. Ләкин икенче һәм өченче звенодагыларга бу сан чик булмаска тиеш,— диде ул.— Сез югында шундый тәкъдим керде: үзебез ясаган блоклардан үзебез салачак йортның нигез ташларын беренче булып монтажлый башлау хокукын алу өчен звенолар арасында ярыш игълан итәргә. Беренче партия блоклар әзер булу белән үк, тагын дүрт-

биш көннән, монтаж эшенә тотыначакбыз. Ә калган звенолар блоклар коюны дәвам итәчәк.

Аннары ул миңа карап алды да сүзен дәвам итте:

— Менә шушы ярышның ничек барышын смена саен «Молния»ләрдә яктыртып барырга кирәк. Йөрәгегез түзмичә килгәнсез икән инде, әйдәгез, шуның беренче номерын чыгарып, әнә шул каршыдагы баганага элеп куйыйк әле!

— Эшлибез аны!

Бераздан ат башы чаклы кыек-мыек хәрефләр белән «Беренче звено 34 блок бирде. Беренче көннең рекордын кайсы звено куяр?» диган гап-гади сүзләр язылган «Молния» тиешле урынына менеп кунаклаган иде инде.

Икенче смена тәмамланганда, бу сан 36 га алыштырылды. Ләкин без моны күрми калдык. Эшнең ничек барышы белән танышып йөрәкне бераз тынычландыргач, төнге смена алдыннан янәшәдәге җылы пыяла чүбе өемендә черем итеп ята идек. Йосыф тавышына дүртебез дә берьюлы уянып киттек.

— Торыгыз! Рольләрне алыштырырга вакыт!

Карасак, сәгатьнең кече теле 12 гә якынлашып килә. Тирә-якны караңгылык пәрдәсе каплаган. Тып-тын. Күктә чекерәшеп йолдызлар яна.

Калган йокы тамчыларын коя-коя, ныгытып бер киерелештек һәм эшкә тотындык.

Их, бу Арча малайлары! Вакытлары калса да, өзер блоклардан калыпларны салдырмыйча, өйләренә шылганнар бит. Шунлыктан, менә хәзер ярты сәгатьләп вакытыбыз әрәм булачак инде!

— Утыз алты блок, имеш, рекорд, имеш... Белдек эшегезне, коярбыз тешегезне! — дип, комсорг Хәбир сукранып йөри.

— Коярбыз дип... Кеше өчен кешенең нәмәгә эче авыртсын, ди? Аңар карап, барыбер блокларының саны артмый ич аларның,— дип каршы төшә аңа Ринат. Аннары, Хәбирнең комсорг булуына ишарә ясап, өстәп куя.— Чыгарың булмаса куен дәфтәреңне! Язып куең, куең... Иртәгә мулния чыгарганда кирәк булыр үзеңә.

— Куең, куең...— дип бераз үчекләп тора да Хәбир, аннары җөпләп әйтеп куя:— Куең көтүдә әнә, бик беләсең килсә! Бирегә сүз блокларның саны, рекордлар турында гына түгел, бергә эшләүче иптәшләреңне, коллективны санга сугу-сукмау турында да бара.

Соңгы калыпларны салдырганда, Арча звеносының тагын бер «гөнаһ»сы ачылды. «Рекорд» куярга ашыкканнармы, китәр алдыннан берничә блокка вибраторны аннан-моннан гына тыгып чыгарганнар. Калыпларны салдырганда, начар тыгызланган блокларның баш-башлары берничә урыннан кителеп төште.

Калып стеналарын солярка белән майлап, төпкә пыяла чүбе җәеп йөргән арада, бетон төягән үзбушаткыч машина да килеп җитте. Ул, артына чигә-чигә килде дә, звено башлыгыбыз «дядя Коля»ның кул ымлавына буйсынып, әрҗәсен күтәреп җибәрде. Комбайн бункерыннан калыплар эченә юеш бетон ага башлады. Кесәләребездә булган бакыр акчаларны, кешечә булсын дип, шул бетонга ыргыттык. Беренче блокның язгы җиңел булсын, янәсе. Газеталарда язарлык зур вакыйга булмаса да, безнең дүрт кешелек звено өчен, ни дисәң дә, бу тәүге блок бит әле!

— Камыр әзер, мичкә кертергә дә була,— диде Ринат бераздан.

Шакмаклы яшькелт күлмәгенең җиңнәрен терсәгенә кадәр сызганып, изүләрен чишеп җибәргән, ике куллап үзе чаклы диярлек вибратор күтәргән, кыска, базык гәүдәле Ринат Кисюшев бу минутларда дөрестән дә камыр изүчегә охшап калган иде.

«Камыр»ката башлаганчы дип, Хәбир бер, мин икенче баштан кайнар бетон эченә тиз генә монтаж элмәкләре тыгып калдырдык.

Четерекле эш икән бу блок кою эше. Килгән бетонны калыпларына урнаштырып кына бетергән булабыз, үзбушаткыч тагын килеп җитә. Папирос кабын алырга дип кесәләргә тыгылган куллар кире чыга. Әнә машина әрҗәсендә бетон ката! Йөгер тизрәк әзер блоклардан тимер калыпларны салдырырга! Авыр кувалдалар белән «чаңчоң» бәреп, калыпның баш-башларыннан тимер чөйләрче бәреп чыгарабыз. Ринат калып стеналарын күтәрү кранының кармагына эләктереп озата, «дядя Коля» белән Хәбир аларны бераз читтәрәк кабул итеп, яңадан «тегә», бер рәткә тезә тора. Ә мин исә йөгерә-йөгерә чиләк белән пыяла чүбе ташыйм, аннары, кулга пумала алып, калып эчләрен майлап чыгам.

— Акрын кыймылдыйсыз, машина хәтле машинаны буш тотасыз,— дия-дия, кабинасыннан башын чыгарып, шофер җанга тиеп тора. Түземлеге беткәч, машинасыннан сикереп төшеп, ул да безгә булышкалап ала.

Кайнар бетонны суытмаска тырышып эшли-эшли, таң атканын да сизми калганбыз. Ләкин ни итсә иттек, үзбушаткыч килешкә, калыпларны салдырып, рәт-рәт итеп тезеп куярга өлгерә башладык. Әзер калыпларны күргәч, теге шофер егетебезнең дә авызы колагына җитте.

Смена тәмамланыр алдыннан Хәбир коелган блокларны санап чыкты. Утыз сигез. Нормага ике блок җитеп бетми бетүен. Ләкин төнге сменада, сыңар күзле прожектор яктысында абына-сөртенә беренче көнне эшләвебезне исәпкә алганда, бу сан аз түгел иде. Димәк, иртәгә, икенче сменада, бүгенге нәтиҗәне яхшыртачагыбызга өмет бар.

Икенче көнне барлык звенолар да норманы арттырып үтәде. Безнең звено исә, икенче сменада 54 блок биреп, бригада рекордын куйды. Көнлек норма 135 процентка үтәлде дигән сүз иде бу. Моңа ирешүебез звено башлыгыбыз Николай Курицин аркасында булды.

Гадәттәгечә эшләп ятабыз шулай. Ринат белән әзәр блоклардан калыпларны салдырырга гына тотынган идек, яныбызга дулкынлануы йөзенә чыккан Коля Курицин йөгереп килде.

— Егетләр, чөйләрне чыгарырга ашыкмыйк әле! — ди бу.

— Нигә? — дибез, гаҗәпләнеп.

— Бер уй килде әле башка,— диде ул, тыныч кына, һәм калыпның бер ягын салдырып, калган өч ягының элмәкләренә автокран кармакларын кидерде дә, кран кабинасына күчеп утырган шофер егеткә үзенең күрсәтмәләрен бирә башлады:

— Вира! Ашыкмыйча гына!

Кран угына эленгән корыч трос, зур балык эләккән кармак җебедәй, тартылып килде һәм сүтелеп бетмәгән калып стеналары, блокның ян кырыйларыннан шуышып, акрын гына өскә күтәрелә башлады. Без дә Коляның нишләргә теләвен аңлап алдык һәм Ринат белән тиз генә барып, блок кырлары сыдырылмасын өчен, сүтелгән башыннан калыпның ян «канатлар»ын икебез ике якка аерып җибәрдек.

Менә калып салдырылды. Бетон идәндә ятып калган блокка берничә зыян тимәгән, аның стеналары яңы гына үтүкләнгәндәй шома, тип-тигез иде.

Кайсыбыз аягыннан, кайсыбыз биләгеннән эләктереп алып, «дядя Коля»ның телеграмм баганасы чаклы гәүдәсен һавага чөйдек.

Шатланырлык урын да бар иде шул. Безнең кулны иң күп тотканы да нәкъ менә шушы калыпларны сүтеп-җыю мәсьәләсе иде бит. Башта калыпның сигез почмагыннан сигез чөйне суккалап чыгарырга кирәк. Аннары дүрт як стенаның һәрберсен аерымаерым кран кармагына эләктереп, икенче башка озатасың. Бу операцияләрне аннары тагын кабатларга туры килә. Аларны җыйганда чөй элмәкләрен туры китерә алмыйча җаның чыга. Туч та тук, кувалда белән сук та сук! Берсе керсә, икенчесе туры килми. Калып стеналары да бутала әле. Яңадан сүтәсең, яңадан җыясың. Бу әле бер блокны сүтеп-җыю гына. Ә сменада кырык блок ясалырга тиеш!

Ә хәзер... Нибары ике чөйне чыгарып, калыпның стеналарын бераз бушатып җибәрәсең. Яңадан җыеп ятасы да юк. Кран да нибары бер әйләнеш ясый. Элек сәгатькә алты-җиде блок коелган булса, хәзер тугыз-унны бирә башладык.

— Чыгар карандашыңны! — диде Коля, смена тәмамланыр алдыннан.— Звеноның ничек рекорд куюын «Молния» аша башкаларга да җиткерергә кирәк булыр.

— Коля, әллә сер капчыгын чишми торыйкмы, малай? Эшләр хутка киткәч кенә...— дия башлаган иде дә, каршында чекерәеп басып торучы Хәбирне күреп, Ринат тукталып калды.

— Нигә телеңне йоттың? Алайса, синең өчен әйтеп бетерергә рөхсәт ит: «Үзем өчен генә тырышаммыни, звено өчен бит!» Шулаймы? Ну кермәсә кермәс икән кешегә! — диде Хәбир һәм, һәрвакыт куен кесәсендә йөрүче чиста «Молния» битен чыгарып, эвеш-түеш хәрефләр белән «Рекорд һәм аның «сере»» дигән сүзләрне яза башлады...

**Әминә Гобәйдуллина**

# ТАБИГАТЬНЕҢ СӘХНӘГӘ БҮЛӘГЕ



Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы Галимә Ибраһимова ТАССРның элекке Тәкәнеш районы Түбән Шүләнгер авылында туа. Шул авылда аның бала чагы уза, шунда ул зифа буйлы яшүсмер кыз булып җитә. Билгеле, кайчан да булса артистка булырмын, халыкның ихтирамын казанырмын дигән уй аның башына да килми. Очраклы бер вакыйга Галимәнең язмышын көтелмәгән якка борып җибәрә, аны олы сәнгать дөньясына алып килә.

...Ул елны Түбән Шүләнгер тирәсендәге урманнарда чикләвек бик уңа. Галимә иптәш кызлары белән җәй буе чикләвек җыя. Җәйләр, көзләр узып, йорт эшләре җиңеләйгәч, үзе җыйган чикләвеген сатып аз-маз акча юнәтер, бер уңайдан театр техникумында укучы Мәрьям апасын да күреп кайтыр дип, аны Казанга җибәрәләр. Исән-сау шәһәргә килеп җитә кызый, апасы яшәгән тулай торакны эзләп таба һәм шунда айдан артык кунак булып ята: Мәрьям апасына ияреп, репетицияләргә йөри, татар театрында барган спектакльләрне карый. Шулай көн саен артистлар тирәсендә йөри торгач, бер вакыт моны Зәйни Солтанов күреп ала. Мәшһүр артист чикләвек сатарга килгән авыл кызының ике якка үреп салган калын чәч толымнарына, тал чыбыктай буй-сынына сокланып, басып торатора да:

— Мәрьям, синең бу сеңелең табигатьнең сәхнәгә дигән бүләге икән ләбаса. Син аны артистка ит,— ди.

Шул вакыйгадан соң күпмедер вакыт узгач, Галимә Казан театр техникумында укый башлый. Техникумны тәмамлауга, аны Мәскәүдәге эшче театрына җибәрәләр. 1929 елда әлеге театр белән ул Урал, Себер якларында гастрольләрдә йөреп кайта. Татар һәм рус драматургларының әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә катнаша, төрлесе төрле характердагы байтак рольләр башкара. Иптәшләре яшь кызның сәләте барлыгын күрәләр, киләчәктә аңардан яхшы артист чыгар дип өметләнәләр, укуын дәвам иттерергә киңәш итәләр. Аларның киңәшен тотып, ул Театр сәнгатенең Мәскәүдәге үзәк техникумына (шул замандагы югары уку йорты — Ә. Г.) укырга керә. Бу техникумда узган еллар аңа күп нәрсә бирә. Ул күренекле профессорларның лекцияләрен тыңлый, атаклы педагоглардан дәресләр ала, башкала театрларында бара торган спектакльләргә йөри.



Мәскәүдә югары белем алгач, Гәлимә Ибраһимова Казанга кайта. Аның шуннан соңгы бөтен иҗат гомере Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры белән бәйләнгән. Академия театры сәхнәсендә ул бик күп образлар иҗат итә. Билгеле, аларның барысына да тукталу, һәр кайсына бәя биреп чыгу һич мөмкин түгел. Шулай да артистка өчен аеруча характерлы образларның кайберләрен искә төшереп үтәсе килә.

Галимә Ибраһимова — асылда лирик табигатьле артистка. Яшь һәм сөйкемле булуын, ягымлы тавышын һәм табигый матурлыгын да искә алып булса кирәк, режиссерлар аңа күбрәк дөнья һәм рус классикларының әсәрләрендәге кызларны яки яшь хатын рольләрен бирәләр. һәм артистканың иҗат йөзе дә нәкъ менә шундый образларда тулырак ачыла.

Галимә Ибраһимованың академия театры сәхнәсендә башкарган беренче роле — Ф. Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясендәге Луиза образы. Хәзер әйтүе кыен, дөнья драматургиясенең иң гүзәл казанышы саналган бу рольне тәҗрибәсез яшь артист никадәр тулы һәм төгәл гәүдәләндерә алгандыр. Күрәсең, табигый матурлыгы һәм яшьлеге коткаргандыр. Халык Галимәнең беренче ролен җылы каршылый. Әлеге рольдән соң исә аның һәр чыгышын алкышлар белән каршылау гадәткә кереп китә. Шул елларда театрда труппа мөдире булып эшләгән Мәрьям апа Чанышева:

— Бик күпләр театрга Галимә өчен генә килә иде. Бүген уйнамаса, ичмасам, сәхнәгә генә чыгарып бастырыгыз, дип ялваручыларның исәбе-саны булмый торган иде,— дип сөйли.

«Мәкер һәм мәхәббәт»тән соң театр В. Шекспирның «Отелло» трагедиясен хәзерли башлый. Отеллоны татарның мәшһүр трагигы Мөхтәр Мутинга, ә Дездемонаны Галимә Ибраһимовага бирәләр.

Мөхтәр Мутинның артык кайнар табигатьле, демоник көчкә ия артист булуы мәгълүм нәрсә. Үзенә тапшырылган рольләрне ул шулкадәр мавыгып, бирелеп уйный торган була, еш кына хәтта артист икәнлеген үк онытып җибәргәли. Мутинның Отеллосы да ифрат кызу канлы, дуамал һәм куркыныч кеше була. Мондый партнер белән уйнау җиңел булмый, билгеле. Кан баскан күзле, куркыныч кыяфәтле Отелло-Мутинны күрүгә Галимә Ибраһимова калтырап төшә, чытырдатып күзләрен йома, сүзләрен әйтә алмый җәфалана. Гомумән, Галимә Ибраһимова күңелендә Мөхтәр Мутин ифрат таләпчән, туры сүзле һәм принципиаль сәнгать кешесе булып кереп калган.

Шулай бер вакыт «Отелло» спектакленнән берничә өзекне фотога төшереп алырга булалар. Галимәгә дә киенергә, киенеп, әзерләнеп торырга кушалар. Нишләсең, кушкач килә бу. Әмма М. Мутин кызны бик коры тота:

— Бар әле, сеңелем, буталып йөрмә. Сара Бернар булгач минем белән төшәрсең,— ди.

Аның бу сүзләрендә тәҗрибәсез артистканы санга сукмау, кимсетүдән дә бигрәк, аны Сара Бернар дәрәҗәсендәге атаклы партнер итеп күрәсе килү теләге көчлерәк кебек.

Театрда Отеллолар алмашына тора, ә Дездемона һаман Ибраһимовада кала. Мутиннан соң Отеллоны Шакир Шамильский уйный башлый. Аның Отеллосы уйлап эш итәргә ярата, салмаграк та, басынкырак та була. Бусыннан инде Галимә дә артык курыкмый, үзен иркенрәк тота, образны тирәнрәк, тулырак ачуга ирешә. Шулай да Г. Ибраһимованың «Отелло» трагедиясендәге төп партнеры — РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Камал III. Алар озак еллар буе гел бергә уйныйлар, һәр вакыт

диярлек зур уңыш казанып киләләр. һәм безнең театр тарихына Галимә Ибраһимова барыннан да бигрәк үзенең Дездемоналары, Луизалары белән кереп кала да.


Өстә бер тапкыр әйтелгәнчә, Г. Ибраһимова күбесенчә классик драматурглар иҗат иткән образларны уйный. Дездемона белән Луизадан тыш, ул Виктор Гюгоның «Анджело» драмасындагы Катарина, Вильям Шекспирның «Король Лир» трагедиясендәге Корделия, Александр Островскийның «Яшенле яңгыр» драмасындагы Катерина, төрек язучысы Назыйм Хикмәтнең «Мәхәббәт хикәясе»ндәге Ширин образларын башкара. Артистка башкарган бу образларның һәркайсы турында күп мактау сүзләре сөйләргә булыр иде. Шул кадәресен генә басым ясап билгеләп үтәсе килә: спектакльдән спектакльгә Галимә Ибраһимованың артистлык осталыгы үсә бара, ул үзе башкарган һәр рольнең үзенчәлекле якларын тотып алырга өйрәнә, сәхнәдә тулы канлы, тормышчан образлар тудыру югарылыгына күтәрелә.



*Г. Ибраһимова Ширин ролендә.*

Галимә Ибраһимова иҗат иткән образлар арасында үзебезнең татар драматургларының геройлары да байтак очрый. Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясендәге Сәлви образы — шуларның иң характерлысы. Муса Җәлилнең «Хуҗа Насретдин» спектакле турында язып калдырган рецензиясендә мондый юллар бар: «Рольләрне аеруча матур башкаручылардан Аксак Тимер ролендәге Гайнуллинны, Сәлви ролендәге Г. Ибраһимованы күрсәтергә була. Бу иптәшләрнең уеннарында җанлы характер, образ тудырырга тырышу — уенны спектакльнең эчтәлеге белән органик бәйләп, тигез алып бару, һәр хәрәкәтне һәм сүзне җентекләп, уйлап эшләү күзгә бәрелә». Герой шагыйребезнең бу фикерләренә өстәп, тагын шуны әйтергә мөмкин: Сәлви ролен Галимә Ибраһимова озак еллар уйнады, һәм ул аны һаман баета, һаман тирәнәйтә торды. Әгәр «Хуҗа Насретдин» комедиясе татар халкының иң яраткан спектакленә әйләнгән, ул дистәләрчә еллар буена өзлексез уйналып килә икән, бу уңышта, башкалар белән бергә, Галимә Ибраһимованың да өлеше бар.

Драматургия — сәнгатьнең иң катлаулы төре. Сәхнә әсәре — коллектив иҗат. Театрда эшләүчеләр бер җан, бер кан булып тырышканда гына спектакль уңыш казанырга мөмкин. Шулай да театрның төп хуҗасы — режиссер. Рольләргә артистларны ул сайлый, спектакльнең ничек чыгуы беренче чиратта аңа бәйләнгән. Әгәр режиссер артистның иҗат мөмкинлекләрен яхшы белсә, аны мавыктыра, канатландыра алса, бу — артистка да, режиссерга да куаныч, шатлык кына китерә. Галимә Ибраһимова бу яктан да бәхетле булып чыга. Татар академия театрында аңа тәҗрибәле, игътибарлы режиссерлар кул астында эшләргә туры килә. Артистканың иҗади үсешенә аеруча күп



*Г. Ибраһимова — Туктабикә.*

көч куйган режиссерларның берсе Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла ага Юсупов була. Нинди рольләрдә, нинди спектакльләрдә генә сынап карамый ул аны. Галимә Ибраһимовага илле яшь тулып килгән көннәрдә Габдулла Юсупов аңа К. Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» драмасындагы яшь кыз Сара ролен бирә. Уены яхшы, тик, ни генә димә, яшь бара, Галимә Ибраһимова олыгаеп килә. Шул ук вакытта режиссерның гаҗәеп сөйкемле бу артистканы сәхнәдән читләштерәсе дә килми. Димәк, аны олы яшьтәге хатыннар роленә кертергә вакыт. Ләкин бу да — җиңел эш түгел. Күп кенә талантлы артисткалар, икенче амплуага күчә алмыйча гаҗиз булалар, кайвакыт унар ел буе сәхнәдә күренмиләр яки бөтенләй сәхнәне ташлыйлар. Мостай Кәримнең «Кыз урлау» комедиясен куйганда, Г. Юсупов Ибраһимовага урта яшьтәге тол хатын ролен тапшыра. Аю төсле салмак хәрәкәтле Дәүләтбай (артист Надрюков) янында Ибраһимова-Туктабикә бик яшь күренә. Режиссер һаман өметен өзми. Ниһаять, ул аны Аяз Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләрдә» драмасындагы Ак тути ролендә сынап карарга була. Башта артистка үзенә бирелгән роль белән килешми. Репетицияләр киеренке шартларда уза. Мамыктан сырмалар тегеп киеп карый, әмма йөреше, үз-үзен тотышы, сөйләшүләре белән ул һаман да яшь кыз булып кала. Авызын уймак кадәр генә ачып, гөнаһсыз кыз бала кебек күзгә карап торуларын күргәч, режиссер үзе дә шикләнә башлый. Шулай да өметен өзми үйланырга, эзләнергә куша.

Актер хезмәте, никадәр авыр, газаплы һәм мәрхәмәтсез син! Башка иҗат кешеләренең — язучыларның, художникларның, композиторларның — эш вакытындагы үйлачуларын, тир түгүләрен, газаплануларын, ичмасам, язып-сызып ыргыткан тау-тау кәгазь өемнәреннән чамалап була. Уйлап карасаң, артист та алардан ким газапланмый. Төннәр буе утырып, рольгә хас эчке һәм тышкы буяулар эзли. Күпме дулкынлана, ачы күз яшьләре түгә... Ә менә шуны тамашачылар сизми дә кала.

Ак тути — Галимә Ибраһимованың әнә шундый күп хезмәт куеп, озак эзләнеп табылган образы. «Көзге ачы җилләрдә»н соң артистка Ч. Айтматовның мәгълүм повесте буенча эшләнгән «Гүзәлем Әсәл» спектаклендә катнаша. Бу юлы инде олы яшьләрдәге кыргыз хатынын ул шундый итеп уйный, премьера көнне спектакль карарга еш йөрүче театр әһелләре дә хәтта: «Әсәлнең анасын кем уйный соң?» — дип сорарга мәҗбүр булалар.

Шулай да Галимә Ибраһимованың соңгы еллардагы иң уңышлы роле — Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» драмасындагы Ана образы дияргә туры килә. Баштарак аңа бу роль дә җиңел бирелми. Рольне кулына алгач, ул шактый вакытлар фикер туплап, образның асылына төшенә алмыйча аптырап йөри. Ни өчен бу ана шундый коточкыч хәлдә кала соң әле? Гомер буе җиргә ябышып яткан, тамырланып беткән



*Г. Ибраһимова «Көзге ачы җилләрдә» спектаклендәге Ак тути ролендә.*

куллары бер кайчан да ал-ял күрмәгән, авыр сугыш елларында, үзе ач торып булса да, балаларын туендырган, аларны киендергән ана нигә чит кеше бусагасында калә? Аны әнә шундый авыр сораулар борчый. Хәтта премьерадан, котлаулардан соң да ул һаман эзләнде, үзе башкарган образга яңа детальләр өсти торды. Нишлисең, табигате белән үк шундый артистка инде ул. Үзенә дә, партнерларына да, режиссерга да тынгылык бирми торган кеше.

Татарстанның илле еллыгы уңае белән театр Мәскәүгә гастрольләргә баргач, бу спектакльне башкала тамашачылары да яратып карады. «Правда», «Известия», «Советская культура» газеталарында һәм «Театральная жизнь» журналы битләрендә «Әни килде» спектакленә багышланган рецензияләр басылып чыкты. Ул рецензияләрдә Ана ролен башкаручы Галимә Ибраһимова адресына да күп җылы сүзләр әйтелә. Әлеге спектакльдә иҗат иткән Ана образы белән ул үзенең иҗат мөмкинлекләре иксез-чиксез булуын тагын бер кат раслады.

Галимә Ибраһимованың иҗат эшчәнлеге академия театры сәхнәсендә тудырган образлары белән генә чикләнми. Аны радио тыңлаучылар да көтеп ала. Радио аша ул башкарган рольләрдән Муса Җәлилнең «Хат ташучы» поэмасындагы Фәйрүзә, Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестендагы Галия, Лев Толстойның «Анна Каренина» романындагы Анна образлары халык күңелендә тирән эз калдырды.

Роберт Батулла

# «АКЧАРЛАКЛАР» СӘХНӘДӘ

Проза әсәренең сәхнәгә менүе әдәбият, театр сөючеләр, тәнкыйтьчеләр, белгечләр тарафыннан зур кызыксыну һәм шул ук вакытта сагаю белән каршы алына. Чөнки сәхнәләштерелгән классик проза җәүһәрләренең уңышсыз куелу очраклары театр тарихында булмады түгел. Андый чакта премьерадан соң: «Әсәрне бозганнар! Автордан берни дә калмаган!» — кебек сүзләр ишетергә туры килә.

Ләкин, минемчә, мәсьәләгә җитдирәк карарга кирәк. Автор әсәре әерым, мөстәкыйль әсәр, ә сәхнәләштерелгән вариант аерым әсәр лабаса. Билгеле, автор тудырган проза әсәре белән сәхнәдәге әсәр тәңгәл килсә — бу театрның зур уңышы булыр иде.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры әледән-әле проза үрнәкләрен сәхнәгә менгезә. (Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Әпсәләмов, А. Расих әсәрләре). Инде менә бүгенге көндә сәхнәдә Шәриф Камалның «Акчарлаклар»ы нигезендә куелган спектакль бара. Әсәрнең сәхнә вариантын Гариф Ахунов эшләгән. Рәссамы — Әнәс Тумашев, композиторы — Хәснул Вәлиуллин. Режиссеры — Празат Исәнбәт.

Ш. Камал повестенда туган җирләрен ташлап, бәхет эзләп, Каспий буйларына килеп чыккан кешеләрнең язмышы сурәтләнә. Нинди генә кыенлык күрмәсеннәр, нинди генә эшчән булмасыннар, повесть азагында бу кешеләргә никтер акча бик аз бирелә. Алар эзләгән бәхетләрен таба алмыйча тагын ил буйлап чыгып китәләр. Ләкин шул ярлы-ябагайның, эчәргә кимен куймый торган «зимагурның» рухи байлыгы повестьта ярылып ята. Бирегә саф мәхәббәт тә бар, авыр чакта эчеп-сүгенеп йөреп тә миһербанлылыкларын югалтмаган җор сүзле адәмнәр дә бар. Бары тик бәхет кенә юк. Әмма повесть киләчәккә зур өмет, шул бәхетне таба алуга олы ышаныч белән тәмамлана. Ике саф күңел, социаль шартлар аркасында, кавыша алмыйча аерылалар. Газизәнең «Мин сине көтәрмен», дигән сүзләре белән тәмамлана әсәр.

1914 елда иҗат ителгән «Акчарлаклар» инде менә илле елдан артык укучыларны дулкынландырып килә. Сафлыгы, лирик җылылыгы, хезмәт кешеләренә карата эчкерсез туганлык тойгысы белән дулкынландыра. Повесть баштанаяк лирик драматизм белән сугарылган. Ул лирик драматизм күбесенчә авторның ремаркаларында тупланган. Игътибар итегез: ремаркаларында! Повестьта диалог бик аз, ә бит авторның ремаркаларга салган уй-фикерен, тәэсир көчен сәхнәдә чагылдыруы шактый кыен эш. «Акчарлаклар» повесте бары тик автор ремаркасы тудырган настроениедән гыйбарәт. Әгәр ул настроение булмаса, әсәр тәэсир көчен югалтыр иде.

Шуңа күрә дә спектакльне карарга мин зур шикләну белән килдем. Ләкин шикләнү, борчылуларым «Акчарлаклар» спектаклен карагач юкка чыкты. Иң мөһиме — повестьтагы уй-фикер, сюжет сызыгы гына түгел — повестьтагы әнә шул настроение дә сәхнәгә менгән. Һәм спектакльне нигездә әнә шул настроение тәшкил итә, тотып тора. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, сәхнәләштерү югалтуларсыз гына була алмый. Әмма шул югалтулар бәрабәренә театр коллективы табыш та китерергә бурычлы. Һәм ул табыш бу спектакльдә шактый. Әйтик, повестьта бөтенләй булмаган Атсыз Хамит әсәрнең канвасыннан читкә

чыкмый гына түгел, ул аның без әйткән настроениесен тудырырга булыша. Ничек итеп диярсез? Хәмит ат алырга килгән. Ат. Бу — бәхет дигән төшенчәнең конкрет чагылыш табуы, предметлашуы бит. Әсәрдәге Шәрәфи карт, Хәсәен солдат, җор табигатьле Сафа һәм бүтәннәрнең бәхете дә күпмедер күләмдә атка бәйләнешле. Табигый, алар Атсыз Хәмитне үз итәләр, аның кайгысын кайгырышалар, вакыт-вакыт аңардан үз итеп көләләр. Режиссер Хәмитнең ат турындагы хыялын сәхнәдә төп урынга куеп, басым ясап, эффектлы алымнар белән күрсәткән. Беренчедән, «ат булсамы?!» дигән эпизод. «Ат булсамы?» — дип күзләре чаткыланып торып баса Хәмит. һәм... дилбегәне болгап җибәрә. («Ярмәкләргә кайтыр идем алмачуар ат җигеп, алмачуар атым булса, китмәс тә идем чыгып»). Дәртле җыр, сызгыру тавышлары астында халык төялгән сәхнә кругы әйләнеп китә. Бөтен зал гөр килеп кул чаба. Кул чаба — чөнки аның күңелендә бәйрәм, сабан туйлары, кыр җыеннары, атка төяләп печән чабарга барулар яңара. Шушы күренеш спектакль азагында драматизмны тагын да куәтләндерә төшә. Шушы матур хыяллары чәлпәрәмә килеп, җәй буе эшләгәненә нибары унөч сум акча алгач, Хәмит ачынып кычкыра башлый:

— Мин моңа ничек ат алыйм? Моңа ничек ат алыйм!

Хәмитнең спектакль дәвамында шушы хыял белән яшәп тә спектакль соңында шушылай өзгәләнеп сәхнә буйлап йөрүе нык тәэсирле. Артист Р. Шамкаев башкаруында Хәмит әнә шулай чишелгән.

Сәхнәләштерүче тарафыннан үстерелгән образлардан Мәкәйне алыйк. Повестьта ул күзгә ташланып тормаган бер кеше. Спектакльдә ул аз сүзле, хәрәкәтләргә саран булуы, сагышы белән күңелдә уелып кала. Ертык күлмәк, сәләмә кавказ башлыгы кигән, кулына «чогыр» дигән музыка коралы тоткан бу кавказ егете балыкчылардан шактый читтәрәк, уйланып утырырга ярата. Аның еракта калган туганнары турында уйлануы, авылына кайтырга өзелеп хыялланганы сүзсез дә аңлашыла. Бу рольне артист Р. Сәләхов башкара. Мәкәйгә сукыр тиен дә акча язмаганнар. Мәкәй сукранмый, башкалар кебек ачынып сүгенми, ул бераз читтәрәк утыра. Мәкәйнең бөкрәеп утыруыннан без аның никадәр кайгы кичергәнен яхшы тоешенәбез. Баракта бурсып бетә язган исерек балыкчылар барлы-юклы акчаларыннан өзеп, Мәкәйгә өлеш чыгаралар. Хәерче хәлендә калган горур кавказлы шул акчаларны битенә каплап елап җибәрә. Рәсим Сәләхов монда саран детальләр куллана. Ул үксеми, елаганын кешегә күрсәтмәскә тырыша. Аның кимсетелгән рухы елый. Мизансценаның уңышлы куелышы һәм актерның уены аша кечкенә роль тулы образ булу дәрәҗәсенә җиткерелгән.

Промысел хуҗасы Андрей Семенович (Б. Әшрәпов) белән Исакның очрашуы гаять көчле эшләнгән. Андрей Семенович десятник Исакны кыйный.

— Талама балыкчыны! Талама балыкчыны!

Тамашачы аптырап та, куанып та куя. Баш эксплуататорның эшче халыкны яклавына аптырый, рәхимсез Исакның җәза алуына сөенә. Ләкин тора-бара Андрей Семеновичның кем икәнен ачык күрәбез. Әгәр балыкчыны күрәләтә таласаң, гауга, чуалчык башлануы бар! Беренче караштә балыкчы яклы булып күренгән Андрей Семеновичның бәрән тиресе бөркәнгән бүре икәнлеге ачыклана: йомшак җәеп, катыга утыртырга; яхшылык эшләгән булып, эшчене ныграк таларга! Менә нәрсәгә өйрәтә промышленник үз ярдәмчесен. һәм Исак моңа ирешә дә. Бәйрәмгә дигән булып, балыкчыларга бер чиләк аракы китерә. Аның яхшылыгы су кушылган бер чиләк аракы, бер төрерлек тәмәке! Салпы якка салам кыстырып, эшчеләрне соңгы чиккә кадәр эшләтү! Бу — эксплуатацияләүнең төп принцибы. Кыйналу өчен Исак Хәмиттән ала. Бер гөнаһсыз Хәмитне Исак эт иткәнче тукмап ташлый. Бу күренешкә шактый урын бирелгән. Режиссер бу эпизодны аеруча басым ясап эшләгән. һәм ул тамашаның тукымасына ятып тора. Бу — театраль эффект өчен генә эшләнмәгән, ә бәлки ансамбль-настроениене тагын да тирәнәйтү өчен контраст итеп алынган.

Повестьта да шактый урын алып торучы десятник Исак спектакльдә дә шактый тулы образ булып җанланган. Артист Ә. Зарипов күп көч сарыф иткән, нәтиҗәдә балыкчыларны талап ята торган, кансыз, рәхимсез бер кабахәт образы туган. Ә. Зарипов Исакны демагог итеп гәүдәләндергән. Ул балыкчыларны эшләтү йөзеннән, кирәк җирдә мактый, салпы якларына салам кыстыра, яхшы булып, кешелекле һәм юмарт булып күренергә тырыша. Ә чынлыкта исә Исак балыкчыларны оятсыз рәвештә алдый, кыйный. Ә хуҗалар алдында ул аларны хайваннар белән чагыштыра, донос ясый. Үзенә кирәк чакта

елый-елый балыкчыларга ялына, бүләкләр вәгъдә итә. Эш узгач, вәгъдәсе урынына тукмак һәм штраф белән бүләкли.

Әнвәр Гобәйдуллин тудырган Шәрәфи карт образына аерым тукталасым килә. Шушы «сасы балык базында» Шәрәфи абзый булмаса шактый күңелсез булыр иде. Кирәк чакта киңәш белән, авыр чакта җылы сүз белән кешеләргә ярдәм итүче Шәрәфи абзый — якты образ. Шушындый кыен шартларда да кешелеген саклап калган миһербанлы бу кешене күреп рухың ныгый. Әнвәр Гобәйдуллин шушы җор мишәр картын гаять дәрәҗәдә яратып, талантлы итеп башкара. Ул әсәрдәге үзәк образларның берсенә әверелгән.

Әче телле, баламут Сафа (Г. Фәтхуллин), күпне күргән Солдат (Ф. Кульбарисов), Николай (И. Баһманов), Сагыйдә (Г. Ибраһимова), Федор (И. Вәлиев) шушы лирик спектакльнең ансамблен тәшкил итәләр.

Гариф белән Газизә — спектакльдә үзәк урында. Гүзәл кыз Газизәнең Гарифка булган саф хисләре гаять нәфис итеп, артык күзгә ташланып тормаган буяулар ярдәмендә сөйләнә. (Гариф — Н. Әюпов, Газизә — Н. Ихсанова.) Аларның мөнәсәбәтләре сюжет сызыгында ярылып ятмый кебек. Алар нибары өч тапкыр очрашалар. Бер-берсенә гыйшык сүзләре дә сөйләмиләр. Аларның сак карашлары, хисләр белән тулган эчке монологлары, уңышлы мизансценалары аша без бу ике яшь йөрәкнең никадәр чиста, саф мәхәббәт белән янууларын ап-ачык тоябыз. Режиссер ул акцентларны төгәл куйган. Ләкин ул басымнар тамашачыга көчләп тагылмыйлар, актерлар тарафыннан гаять йомшак эшләнәләр. Пычрак баракта, эшчеләр, зимагурлар арасында Гариф белән Газизәнең сафлыгы аеруча кыйммәтле. Әткәсе кушкан йомышны үтәргә, Гарифның юеш киемнәрен алырга дип, Газизә Гариф йоклап яткан баракка килә. Бер-берсен өзелеп яраткан ике кешенең салкын шыксыз баракта очрашуы шундый йомшак итеп бирелгән. Монда берниндн артык хәрәкәт тә, артык сүз дә юк. Ике яшь кеше, беренче күргәндәй, бер-берләренә озак кына карап торалар. Бу карашта гаҗәпләнү дә, соклану да, тартыну да, ярату да, сафлык та бар. Алар икесе дә әдәпле гаиләдә тәрбияләнгәннәр. Алар олы һәм чиста мәхәббәткә лаек кешеләр. Алар сүзсез дә бер-берсен яхшы төшенәләр. Диңгез буеннан кайткан балыкчылар Газизәнең бaрактан чыгып барганын күреп калалар. Кемдер кәлә башлый, кемдер ямьсез мәгънәле сүз ычкындыра. Шул чакта Хәснетдин солдат дусты Гарифка:

— Газизә ул безнең йөз аклыгыбыз, иманыбыз! Тимә син безнең иманга! Китермә син Газизәне баракка! — дип каттый әйтеп сала. Бу — дустына киңәш тә, янау да, хәтта ялвару да булып яңгырый. Чит җирләрдә йөреп шактый таушалган кешеләрнең үз намусларында бәлки тап та бардыр. Әмма алар кызның саф булуын чын йөрәктән телиләр, шуңа ышаналар да. Әгәр Газизәгә тап төшсә, аларның соңгы иманнары да бетәр сыман. Беренче карашта тупас һәм дорфа булып күренгән бу кешеләрнең Газизәне яклап чыгу күренеше спектакльне куючылар коллективының якты бер теләген аңлата. Социаль шартлар кешене тупасландырса да, хәтта тормыш төбенә төшерсә дә, кеше үзенең төп сыйфатын — миһербанлыгын сакларга тырыша. Шушы урында Сатинның: «Кеше ул горур яңгырый!» дигән сүзләре искә төшә.

Режиссер сәхнәдә күрсәтү өчен шактый кыен әсәрдән әйбәт спектакль тудырган. Алда әйткәнемчә, ул моңа актерларны, композиторны, рәссамны бер ансамбльгә туплап ирешкән. Минә шушы ансамбль спектакльнең әлеге дә баягы настроениесен тудырган. Настроение тудырырга режиссер ничек ирешә соң? Берничә мисал.

ГАЗИЗӘ. Әнкәй, нигә кешеләр туган җирләрендә генә тормыйлар икән?

Бу сүзләрне әйтер алдыннан без Газизәнең сагышлы рухи халәтен күрдек. Аңа нидер җитми. Ул нидер эзли. Бирдә, Газизәгә күңелсез эчпошыргыч мохитта, ул үзенә урын таба алмый.

— Әнкәй, бер дә татар булмаса, монда күңелсез булыр иде...

Бераз уйланып торганнан соң әнкәсе:

— Кайда гына юк инде ул татар, кызым, бөтен дөньяга таралган...

— Нигә, әнкәй, кешеләр туган җирләрендә генә тормыйлар икән?

Әнкәсе (бу рольне Галимә ханым Ибраһимова башкара) тирән итеп көрсенә дә уйчан, сагышлы бер йөз белән:

— Бәхет эзлиләр, кызым! Нужа куа адәм баласын,— ди.

Һәр ике актриса да диалог вакытында гаять уйчаннар. Аларның эчке кичерешләре, рухи халәтләре, эчке монологлары аша еракта бәхет эзләүнең моңы, сагышы — настроениесе тамашачыга күчә.

Әйтик, артист Әнвәр Гобәйдуллин (Шәрәфи карт) искәрмәстән генә:

— Кызамыктан буй җиткән улыбыз үлеп китте,— дигәч, Галимә хачым (Сәгыйдә карчык) эшләгән эшеннән туктап кала. Фатих Кульбарисовның, Наил Әюповның, Нәҗибә Ихсанованың берьюлы Галимә ханымга борылып сүзсез калулары, уңайсыз тынлыкта Галимә Ибраһимованың чак сизелерлек сулкылдавы спектакльнең гомуми настроениесен көчәйтәләр.

Акчарлакларның сагышлы чыелдаулары, Шәрәфи абзыйның акчарлаклар турында лирик сөйләме, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов сүзләренә язылган «Акчарлаклар» җыры да шул ансамбльне тәшкил итә.

Кораб китте еракларга, зур юлларга,
Карыйм күздән югалганчы шул якларга.
Сез китмәгез, акчарлаклар, акчарлаклар,
Чит җирләрдә каерыла пар канатлар.

Икенче пәрдәнең башланышы да гомуми ансамбль настроениесенә буйсына. Рәссам белән режиссер аз җиһазлар, саран хәрәкәтләр, төгәл ысул белән эш итәләр. Яр кырындагы бер төркем балыкчы диңгезгә карап үз бәхетләрен — балык килүен көтеп утыралар. Артта калган аграр ил — патша Россиясендә яшәгән крестьян, эшче өчен бәхет ул ат булып та, балык булып та, акча булып та күз алдына килгән. Татар халкының әүвәлге мәкален искә төшерик: бәхет ул — җаның теләгән эш, җылы куыш, киң күңел! Сыек яктыртылган зәңгәрсу пәрдә фонында көтеп утыручыларның шәүләләре күренә... Акчарлакларның чыелдаулары ишетелә. Шулар аша без «бәхет көтү» настроениесен тоябыз.

Гарифның Шәрәфи карт булмәсендә башлаган җыры да талгынлык, көчләп такмау, салмаклык белән ныграк тәэсир итә. Гомуми настроениедән чыккан бу җырны ишеткәч, тамаша залы тып-тын кала. Тамашачы режиссер тапкан настроениене тулысы белән үзенә кабул итә.

Ләкин, кызганычка каршы, шушы ансамбль вакыт-вакыт бозылып та куя. Әйтик, кайбер күренешләрдә актерларның көлке детальләр белән артык мавыгып китүләре аркасында ансамбль таркалып куя. Барактагы сугыш моментын алыйк. Актерлар кеше көлдерергә маташу белән ныграк мавыгып китәләр. Нәтиҗәдә диалог алып баручы актерларга комачаулыйлар. Беренче спектакльләрдә булган аерым кытыршылыклар шомара барэ, әмма чамадан чыгып китүләр спектакль сәен арта килә. Кумәк күренешләрдә актерларга менә бу саксызлыкны эшләмәскә иде. Чөнки алар тамашачы игътибарын төп настроениедән читкә алып китәләр. Тагын бер дәлил. Акча булганнан соң Атсыз Хәмитнең бөтен хыялы чәлпәрәмә килә. Аның өчен бу — фаҗига. Ләкин актер кайбер спектакльләрдә «Моңа мин ничек ат алыйм?» дигән репликасын комик тонда кычкыра. Шул чакта тамашачының бер өлеше көлеп куя. Ни өчен соң тамашачы бу фәкыйрьнең кайгысыннан көлә? Безнең тамашачы шулай каты бәгырьлеме? Минемчә, юк! Бу хәл һәр спектакльдә дә кабатланмый. Актер төп настроениегә буйсынып әйткәндә, тамашачы тып-тын утыра — бу инде Хәмиткә теләктәшлек белгертү, аны кызгану дигән сүз. Димәк, актерга мондый урыннарда сак эш итәргә кирәк.

Спектакльнең финалы якынлаша.

Кешеләр тагын юлга чыгалар. Тагын бәхет эзләп берәм-берәм таралалар. Акчарлаклар һаман чыелдый. Акылдан язган кеше кебек көлә акчарлак. Өллә көлә, өллә елый...

**ШӘРӘФИ КАРТ:** «Бәхет ул, энем, кашсыз йөзек!» — дигән иде Гарифка.

Юл капчыгын аскан Гариф Газизә белән саубуллаша.

— Мин Саричинга китәм әле, монда юллык та эшләп булмады ич,— ди Гариф.— Мин сиңа кашлы йөзек алып кайтырмын...

— Мин сине көтәрмен,— ди Газизә.

Утлар кими бара, кими бара.

Газизә болгаган ак яулык инде акчарлак канатлары булып күренә...

**Гази Кашшаф**

# НИГЕЗ ТАШЛАРЫН САЛГАНДА

«Казан утлары»...

Элек-электән Казан шәһәренең нурлары еракка, бик еракка сузылган һәм кешеләрнең күңелләрен яктыртып, җылытып торган. Кемнәрне генә ул үзенә тартмаган, һәм кемнәрне генә үстереп җибәрмәгән. Монда бөек галимнәр җитешкән, монда шигърият чәчәк аткан, моңлы көйләр чыңлаган. Меңнәрчә кешеләр монда белем алып, киң Рәсәйдә яшәгән күп милләтле халыклар арасында хезмәт итәргә, Казан нурларын тагын да киңрәк җәелдерергә юнәлгәннәр. Ә революция традицияләрен саный башласаң, бу нурлар тагын да яктырак балкый, тагы да дәртлерәк җемелди. Монда Ленин үзенә революция юлын сайлаган. Монда Федосеев, Ямашевлар самодержавиенең тамырын йолка башлаганнар.

Хәер, мин Казанның данлы, шәүкәтле тарихын язарга җыенмыйм. Казан болай да нурлы, ә монда аның утлары турында сөйләргә кирәк.

«Казан утлары».

Аңа хәзер 50 яшь! Моны әйтүе генә җиңел. Ярты гасырлык тарихы булган журнал — ул 192 биткә, ягъни унике басма табак эченә сыйдырылган төрле жанрдагы әсәрләр генә түгел. Ул шулай ук 12 табаклы бер җыентык та түгел. Ул — 620 саннан торган, үзе бер китапханә тәшкил итәрлек бай хәзинә асраган журналлар комплекты. Анда халыкның рухы салынган. Анда — халыкның иҗтимагый аң үсеше, анда — халыкның матурлыкны тану һәм аны бәяли белү осталыгы, анда — аның әдәби-сәнгать зәвыгы, образлы сиземләү осталыгын үзләштерү баскычлары. Шуңа күрә дә матур әдәбият тарихын тикшерәсеңме, театр, музыка тарихына күз саласыңмы, рухи культура тарихына материаллар эзлисеңме — бу журналны читләтеп узу мөмкин түгел.

Журналда басылган һәрбер язма аерым китап булып яки җыентыкларда тупланып басыла алмый. Шулай булгач, журнал тарихчылар өчен бердәнбер башлангыч чыганак.

Миңа бу журналда шактый еллар эшләү бәхете электе. Журналның укучыга никадәр якын һәм кадерле булуын мин шул елларда гел тоеп яшәдем. Журнал укучыларының бер конференциясендә өлкән яшьләрдәге бер укытучы болай дигән иде:

— Тәнкыйть артыграк булды шикелле. Сез үзегезнең никадәр зур эш башкаруыгызны белмисез булыр... Журналны даими укып баручыларга андагы «хроника» да бик кадерле...

Әйе, «Казан утлары» гаять зур эш башкара. Ул, анабыз Идел кебек, катлаулы бөек чорыбызны, бөек тормышыбызны чагылдырып, киң адым белән данлы юлын дәвам иттерә. Һәм мин, көл кадәренчә, аның үсү, чыныгу юлын сөйләп бирергә телим.

* * *

«Казан утлары» журналының тарихы бик кызыклы һәм укучыларның игътибарын җәлеп итәрлек. Бердән, ул Советлар Союзында чыгып килә торган әдәби, иҗтимагый-политик журналлар арасында иң өлкәннәренең берсе. Рус телендә, Ленин инициативасы белән чыгарыла башлаган «Красная новь» 1921 елның июнь аеннан гомерен башлап җибәрә. «Новый мир» — 1925 елдан, «Огонек» 1923 елдан чыга башлый. Иң өлкән журналлардан «Сибирские огни» 1922 елның мартыннан бирле, «Молодая гвардия» 1922 елның апрель-май аеннан чыгып килә. «Казан утлары» шулай ук 1922 елның май аенда үзенең эшен башлап җибәрә. Шул рәвешчә, ул илебезнең иң карт журналлары рәтендә тора. Шунысын да әйтергә кирәк, «Казан утлары»ның билгеле бер тәртипкә салынганнан соң чыгудан туктап торганы юк. Хәтта Бөек Ватан сугышының иң авыр айларында да ул эшен дәвам иттерде. Башка журналлар сугыш еллары чорында берничә айга булса да чыкмый тордылар.

«Казан утлары» журналы ярты гасыр вакыт эчендә исемен берничә тапкыр алыштырды. Бу — табигый күренеш, һәрбер чор, журналның эчтәлеген билгеләгән кебек, аның исеменә дә йогынтысын ясый. йөкләмә бирә.

Журнал башта «Безнең юл» исеме белән чыга һәм ул исем Галимҗан Ибраһимов тарафыннан тәкъдим ителгән булса кирәк. Әгәр 1917 елның сентябреннән Уфада Галимҗан Ибраһимов редакторлыгында шул исемдә газета чыга башлавын искә алсак, моңа шикләнмәскә мөмкин. 1927 елда, «Безнең юл»ның чыга башлавына биш ел тулуга багышланган санда, Г. Ибраһимов «Безнең юл»ның редакторларыннан» дип тәкъдим ителә һәм аңа «юл салучы»ның кем икәнлегенә ишарә ясала. Чынлыкта Г. Ибраһимов журнал редколлегиясенең председателе була.

Журналның беренче редакторы Гасыйм Мансуровның истәлегендә 1922 елның башында «мин, Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнаш, Гаяз Максуд, партиясезләрдән Садри Җәләл, Газиз Гобәйдуллин үзара фикер алышканнан соң «Безнең юл» журналы чыгарырга карар бирдек», дип языла. («Безнең юл», 1927 ел. 6—7 саннар.) Шунда ук «Безнең юл» журналы чыннан да безнең юлны, большевиклар, марксистлар юлын күрсәтә торган бер журнал» булып чыгарга тиешлеге билгеләнә.

Аерым язучыларның журнал чыгару теләкләре күптәннән туган булса да, тормыш авырлыгы, көчләрнең таркау булуы, сугыш һәм ачлык җәфалары бу эшкә практик рәвештә керешергә мөмкинлек бирми.

1922 елның башыннан Казанда «Кызыл шәрык яшьләре» исемле яшьләр журналы чыга башлый. Комсомолның Татарстан өлкә комитеты органы буларак, журнал комсомолец һәм укучы яшьләргә экономик-политик һәм фәнни тәрбия бирүне күздә тота. Яшь каләмнәрнең иҗатына да игътибарлы була, хикәя, шигырьләргә урын бирә, шулай да ул тормышын яңача төзергә керешкән һәм культура традицияләренә бай булган бер халыкның барлык әдәбият-сәнгать һәм культура өлкәсендәге ихтыяҗларын үти алырлык була алмый. Моның өчен аның күләме дә, тупланган көчләре дә җитәрлек булмый.

1922 елның март-апрелендә РКП(б)ның XI съезды була. Партия съездының резолюциясе, социализм төзүгә бәйләнешле гаять зур хуҗалык бурычлары белән бергә, эшче-крестьян яшьләре өчен әдәбият тудыруны иң кирәкле эшләрнең берсе дип билгеләде. Съезд Үзәк Комитетның гыйльми-популяр һәм әдәби журналлар чыгару турындагы карарын яхшы дип таба һәм бу эшне тагын да җәелдерергә куша. Партиянең XI съезды: «...Азчылык милләтләр өчен, аеруча төрки телләрдә газеталар һәм әдәбият бастыруга игътибарны юнәлтергә» куша. (О партийной и советской печати. М. 1954. 250—251 битләр.)

Партия карары белән рухланып, хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, татар телендә гыйльми, сәяси, әдәби-иҗтимагый айлык «Безнең юл» журналын чыгара башлыйлар. Беренче бөтендөнья сугышына гражданнар сугышы ялганган чор бу. Халык хуҗалыгы җимерек хәлдә, кырлар үксеп ята, аларны эшкәртерлек кеше көче дә, тарту көче дә җитәрлек түгел. Шуңа тагын 1921—22 елгы ачлык Идел буе халыкларын тәмам аяктан еккан. Әгәр дә яшь совет хөкүмәтенең чиксез зур ярдәме булмаса, эшче һәм авыл ярлыларының киләчәк буынын саклап калу эше дә мөшкел булыр иде...

Әнә шундый шартларда Ленин партиясе алга карап эш итә һәм хезмәт ияләрен әчтән коткарып калу чаралары өстенә, аларга рухи азык булдыруны да кайгыртә, хезмәт ияләре арасыннан күтәрелеп чыгарга тиешле яңа, яшь талантларның үсүенә җирлек әзерли.

Журнал чыгару расходларын Татарстан хөкүмәте тулысынча дип әйтерлек үз өстенә ала. 1923 елның март аена чаклы «Безнең юл» журналының нашире, ягъни бастыручысы Татар Социал Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз башкарма комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы була. Журналның тиражы да күп түгел, беренче сан 1000 данә басылган, аннан соң 1500 данә, журналны яздырып алучылар тагын да азрак, күбесенчә ул бушлай таратылган.

Беренче саннарның кәгазе соры, чүбекле була һәм техник яктан эшләнеше дә сокланырлык булмый. Шулай да журнал тиз арада үз укучыларын, авторларын таба. Ул чакта әле язучылар төрле төбәкләрдә яшиләр, аларны берләштергән җәмәгать оешмалары юк, журнал исә шул таркау яшәүче әдип һәм галимнәрне туплаучы бер органга әйләнеп китә.

1922 елда Казанга Һади Такташның бөтенләйгә күчеп килүен, шул ук елны Гадел Кутуй, Муса Җәлилнең Казанга әдәбият үзәге дип өметләнеп килүләрен, тиз арада Афзал Шамов, Гумир Толымбайский, Фәхри Әсгат, Зәйнәп Бәширова һ. б. яшь көчләрнең тупланууын искә алсак, журналның яшьләргә өмет баглавы нигезсез түгеллеген аңларбыз. Ул чакта Казанда яшәгән һәм әдәби хәрәкәткә сизелерлек йогынты ясап килгән Галимҗан Ибраһимов, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Әмири, танылып бара торган Шамил Усманов, Кави Нәҗми һ. б. журнал тирәсенә тупланалар.

Ниһаять, гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый журналның беренче саны укучыларга тәкъдим ителә. Ул 84 битле калын журнал булып чыга.

«Партиянең XI съезды», «Коммунистлар байлыгы», «Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык», «Татар-башкорт яшьләренең бөтенроссия конференциясе» кебек оригиналь политик мәкаләләр журналның көн сулышы белән яшәргә омтылуын һәм партия карарларын тормышка ашыру өчен тырышуын күрсәтәләр. Аннан тыш Г. Ибраһимовның ике санга бүлеп бирелгән «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» исемле мәкаләсе, Ф. Бурнашның татар театр әдәбиятына күзәтү ясавы игътибарга лаеклы.

Беренче санда журналның «Әдәбият» дигән бүлеге 68 нче биттән башлана. Анда М. Гафури, З. Бәширова, К. Әмири шигырьләренә һәм Г. Газизнең кечкенә күләмле хикәясенә урын бирелгән. Шунда ук Габди псевдонимы белән Г. Ибраһимовның «Төрки кавемнәрнең матбугаты-әдәбияты тирәсендә» исемле мәкаләсе басылган, мәкаләнең дәвамы икенче санда бирелгән.

Шул рәвешчә, «Безнең юл» әдәби мирасны марксизм методы белән өйрәнергә, әдәбият тарихын чорларга бүлүгә, тел-грамматика мәсьәләләрен өйрәнүгә беренче саныннан игътибар итә башлый һәм шул юнәлештә эшен алга алып китә. Бу аңлашыла да, чөнки әдәбият-культура тарихы да өйрәнелмәгән, борынгы мирас та ул чакта әле «төрки кабиләләр» арасында бүленмәгән, кайсы әдәби әсәр нинди милләткә карый икәне ачыкланып җитмәгән, телне өйрәнү дә гыйльми юлга салынмаган. Ә бу мәсьәлә зур әдәбиятны — яңа тип совет әдәбиятын үстереп җибәрү өчен җиң сызганып эшкә керешкәндә читләтелә торган мәсьәлә түгел.

Яшьләр яңалыкка тизрәк тавыш бирәләр һәм журналга омтылалар. Журналның 4 нче санында Һ. Такташ «Урман кызы» поэмасын, М. Максуд «Ике бәйрәм» исемле нәсерен бастыра. Бу аларның журналга беренче тапкыр аяк басулары. Бишенче саннан М. Җәлил белән Ф. Әсгат катнаша башлый. 6—7 саннарда инде без Ш. Усманов, Г. Толымбайский, К. Нәҗми кебек яңа исемнәр белән танышабыз.

Шул ук 6—7 санда (1923 ел, январь-февраль саннары) Г. К. имзасы белән Гадел Кутуйның ике шигыре басылган. Г. Кутуйның «Күкне төшерәм — туй ясыйм», «Базарда җан сатам» исемле шигырьләренә редакция шундый искәрмә бирүне кирәк тапкан:

«Безнең юл» идарәсе, рус һәм Европа әдәбиятындагы яңалыклардан булган футуризм агымы тарафында булмадыгы хәлдә, яшь футурист шагыйрьләребездән Г. К. иптәшнең бу юлдагы беренче тәҗрибәләренә үз битләрендә урын бирә, һәм шуның аркасында, бердән, кечкенә генә бер мисал аркылы гына булса да, футуризм белән үз

укучыларын таныштырырга вә, икенчедән, әдәбият дөньясында, бигрәк тә «Безнең юл» журналы битләрендә бу хакта фикер алмашуга мәйдан ачарга теләү. Идарә».

Шушы искәрмәдән күренгәнчә, журнал реалистик позицияләрдә тора һәм шул принципларны яклый. Яңа агымнар турында редакция фикер алышырга чакырса да, бәхәс куерып китми. Аның каравы, Гадел Кутуй үзе журналның биш елы тулу уңае белән бик характерлы сүзләр әйтеп чыга: «Мин татарның ярлы әдәбиятына «бик куп» ярлы нәрсәләр биргәнем өчен хәзер артыгы белән үкенәм. Билгеле, моңар мин генә гаепле түгел... бу гомуми бер фаҗигабез...» («Безнең юл», 6—7 саннар, 1927 ел.)

Баштагы елларда журнал үзенең йөзен эзли, шуңа күрә аның редакция составы да, форматы да, эчтәлеге дә еш үзгәреп тора. 1925 елның башында журнал редакция исеменнән белдерү ясый һәм «Безнең юл»ның «һәр нәрсәдән элек марксизм журналы булырга, мәсьәләләрне ленинизм буенча тикшерергә, ленинизмны һәр турыда юлбашчы назария итеп алырга, һәр төрле саташуларга, динчелек аумакайлыкларга каршы материализм яктысы өчен көрәшергә тырышачак», дип үзенең политик платформасын билгели. Журнал әдәбият, культура өлкәләрендә туып торган сорауларга җавап биреп барачагын әйтә.

Чыннан да, журналга игътибар көчәя, бу елларда аның эшенә турыдан-туры Галимҗан Ибраһимов ярдәм итүчеләргә дә кузгә ташлана. Ул, Халык Мәгариф Комиссариатының Гыйльми үзәге председателе буларак, гыйльми интеллигенция көчләрен Казан югары уку йортларына туплый, аларга юнәлеш бирә. Әдәбият һәм революция тарихын өйрәнүгә игътибар көчәеп китә. Ленин әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итү комиссиясенең председателе буларак та, Г. Ибраһимов журналны һәрвакыт истә тота. 1925 ел саннарында В. И. Ленинның «Беренче революциянең беренче баскычы (Ерактан хат)», «Пролетариатның бу революциядәге бурычлары (Апрель тезислары)» кебек хезмәтләре, Ленинның интеллигенция хакындагы фикерләре, «1905 нче ел революциясе һәм В. И. Ленин» кебек материалларның басылуы шул турыда сөйли.

Г. Ибраһимов «марксист язучыларыбызга» мөрәҗәгать итеп, тарихи материализм турында китаплар кирәклеге, 1905 ел революциясе эчендә татарларның хәрәкәтләрен өйрәнү өчен материаллар җыю турында язып чыга.

1927 елда беренче большевистик газета «Урал»ның чыга башлавына егерме ел тулу уңае белән «Безнең юл» журналы Мөхетдин Корбангалиевнең «Хөсәен Ямашев турында исемдә калганнар» (1 сан) исемле истәлеген бастыра. Бу материалны әле хәзергәчә тарихчылар бик яратып телгә алалар, гыйльми нәтиҗә ясаганда, аңа да таяналар.

ВКП(б) Үзәк Комитетының «Матур әдәбият өлкәсендә партия политикасы турында»гы резолюциясе журналның 1926 елгы 5—6 саннарында басылган. «Хәзерге татар әдәбиятына партия карашы» исемле мәкалә 1929 елның 6—7 саннарына урнаштырылган.

Журнал шулай ук халык хуҗалыгы, авыл тормышы һәм экономикага кагылышлы материаллар да бастыра.

Татар әдәбиятын өйрәнү һәм әдәби мирас, татар халкының авыз әдәбиятын җыю һәм аны өйрәнү кебек мәкаләләр арасында П. С. Коганның «Татар әдәбияты турында» (1927 ел, 8 сан) мәкаләсе әһәмиятле урын тота. Бу — рус галимнәренең (моңа тагын академик Павловичны өстәргә кирәк) татар әдәбиятына, аның күренекле язучыларына игътибар итә башлавының бер үрнәге.

Әдәби журнал, әлбәттә, әдәби материалларга киң урын бирә. Югарыда бер тапкыр әйтелгәнчә, һ. Такташ, Ш. Усманов, К. Нәҗми, Г. Толымбайский, Г. Кутуй, Х. Туфан кебек язучы-шагыйрьләр зур урын алалар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан танылып өлгерәләр. Аларга ияреп Фатих Хөсни, Нур Баян, Демьян Фәтхи, Шәйхи Маннур шигырьләре, Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир хикәяләре күренә башлый. Без ялгышмадык, хәзерге күренекле прозаик Фатих Хөсни журналга шагыйрь булып аяк баса.

Журналның беренче авторларыннан һади Такташ исеменә аерым тукталасым килә. Революция тудырган, партия һәм совет чынбарлыгы тәрбияләгән, талантлар арасында да йөзек кашы кебек балкып торган һади Такташның әсәрләре журналның аерым сәхифәсе, матур сәхифәсе. Менә аның 1925 елда «Сыркыды авылы» (1 сан)

басылып чыккан, икенче санда «Давылдан соң» поэмасының кисәкләре басылган. 1926 елның 1—2 саннарында «Нәни разбойник» басыла һәм гаҗәп көчле резонанс ала. Соңыннан «Чаян» журналы аны карикатуралы рәсемнәр белән иллюстрацияләп күчереп баса. Шул ук елның соңгы саннарында Такташның «Провокатор» исемле көчле политик лирикасы басыла.

Менә 1927 елның икенче саны. Ул әле дә һәрбер укучының күңелен үзенә тарта. Анда шагыйрьнең «Мәхәббәт тәүбәсе яки Зөбәйдәнең наборщикка булган гыйшкыни белән бетте» исемле поэмасы басылган. Исеме озын, ләкин редакция аны бирә белгән. «Мәхәббәт тәүбәсе» сүзләре генә калын баш хәрефләр белән җыелган. Укучы өч баганалы биттән поэманы укый башлаганчы, Такташның үзен күрә. Ул бөтен буйга басып тора, соры костюмыннан, кара шиблеттан, пиджагының сул як итәген артка таба чөеп, сул кулын чалбар кесәсенә тыккан, уң кулына, бармаклары арасына, папирос кыстырып, башын уң якка салыбрак тора. Поэманы да Такташ нәкъ шул кыяфәттә сәхнәдән сөйли иде. Инде күпме еллар узган. Менә хәзер дә Такташ журнал битеннән чыгып каршыңа басар да сине таң калдырып, поэмасын укый башлар кебек тоела. Ә ул укый белә иде...

1925 елдан башлап журналның барлык эшен дип әйтерлек Гомәр Гали ялгызы алып барды. Ул редакцияли дә, корректура да карый, хатларга җавап та яза, редакциягә килгән яшьләрне әдәби осталыкка өйрәтә, язучыларга «социаль» заказлар бирә иде. Ул арада типографиягә йөгереп барып кайта, редколлегия членнары белән дә бәйләнеш тотарга өлгерә. Теләсә кемне, теләсә кайда, хәтта урамда да кабул итеп, журнал һәм әдәбият мәсьәләләре турында әңгәмә алып бара.

1927 елны татар Мәдәнияте йорты оешкач, журнал редакциясе Наркомпрос бинасыннан Мәдәният йортына (хәзерге Яшь тамашачылар театры) күчте. 1928—29 елларда Мәдәният йортының секретаре булып эшләгәндә, миңа Гомәр Гали һ. б. язучылар белән аралашырга туры килде. Г. Гали белән безнең бүлмәбез янәшә ук булмаса да, эш араларында бик еш очраша идек. Шуңа күрә редакторның эш стиле дә, теге я бу язучыга карата мөнәсәбәте дә истә калган. Кайвакыт ул исемен әйтмичә генә берәр редколлегия членыннан зарланып куя, кайчак яшьләрнең җавапсыз чыгышлары турында ачынып сөйләргә керешә, шул ук вакытта үз сүзен берәр философның яки атаклы язучыларның афоризмнары белән дәресләп ала. Такташ яки Кутуй килсә, алар белән җәелеп, эч серләрен бушатып сөйләшә. Г. Гали Такташның талантын әйруча тәкъдир итә, аның әсәрләренә билгеле дәрәҗәдә юнәлеш тә бирә иде шикелле. Чөнки Такташ теге я бу газетада яки кичә генә булып узган җыелышта аның шигырьләренә каршы кизәнүләр, күсәк күтәрүләр булса, Гомәр Гали янына килә, алар бик озак сөйләшәләр... Мин аларның нәрсә сөйләшкәнен белмим, миңа шунысы ачык, борчылып кергән Такташ елмаеп, көлеп чыга һәм тынычланып кайтып китә иде.

Һәди Такташ 1929 елны «Мокамай» һәм «Алсу» поэмаларын язды. Алар бер үк санда янәшә басылдылар. Г. Гали, журналны бизәргә һичбер материаль мөмкинлеге булмауга карамастан, каяндыр акча тапты, художникка заказлар бирде һәм «Мокамай» поэмасы журналның ике якка ачылган битендә ак каеннар рәсеме уртасында басылды. Такташ поэманың шулай бизәлеп басылуына әйруча шат иде. Ул каеннар клишесын хәтта миңа да күрсәткән иде.

Мондый игътибар, билгеле, башка шагыйрьгә эләкмәде. Арада тик Х. Туфан гына бәхетле булып чыкты. Аның «Ике чор арасында» исемле поэмасы шагыйрьнең рәсеме белән басылды (1927 ел, 6—7 саннар.) һәм ул фото түгел, художник тарафыннан бик матур итеп махсус эшләнгән штрихлы рәсем иде.

Тәнкыйть-публицистика өлкәсендә журнал Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Толымбайский, Ф. Бурнаш, Х. Вәли, Г. Рәхим һ. б. киң урын биреп бара. Журналда шулай ук фикер алышу тәртибендә басылган мәкаләләр очрый. Бу уңайдан Г. Галинең язучылар оешмасы төзү мәсьәләсенә карата язган мәкаләләре бик кызыклы. 1927 елга кадәр әле язучыларның махсус оешмасы юк, ТАПП[1] оешу алдында тора, аерым түгәрәкләр әдәби хәрәкәткә тәэсир итә алмыйлар. Яшь талантларны үстерү, өлкәннәренә җитәкчелек кирәклеген редактор бик нык сизә. Чөнки ул журналның сыйфатын үстерү белән

---

[1] ТАПП — Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе.

дә бәйле. Ниһаять, әдәби оешмалар барлыкка килә... Һәм алар бераз эшләп, үзләренең йөзен массага таныткач, әдәби журналларны да яңабаштан оештыру эшенә чаралар күрелә.

* * *

«Безнең юл» исеме белән журнал 1930 елга кадәр чыкты. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретариаты утырышында татар әдәби журналларын яңабаштан оештыру мәсьәләсе карала. 1930 елның 20 июнендә булган утырышта түбәндәге карар кабул ителгән:

1. Пролетар гегемония һәм пролетариат әдәбиятының яңа кадрларын үстерү өчен әдәбият һәм сәнгать фронтындагы көрәшкә тагын да уңайлырак шартлар булдыру максатыннан чыгып, әдәби-художество, иҗтимагый-политик һәм тәнкыйть журналы булдыруны кирәк дип табарга. Аны Татарстан пролетар язучылары ассоциациясе органы дип исәпләргә. Бу журналның беренче саны Татарстанның 10 еллыгына чыгарырга.

2. Татарстанның 10 еллыгына, татар матбугаты нигездә латинлаштырылган шрифтка күчеп бетүен искә алып, «Яңалиф» журналын ябуны кирәкле дип санарга. Татиздат һәм Яңалиф Дәүләт Комитетына «Яңалиф» журналы буенча сметада каралган барлык сумманы яңа оештырыла торган ТАПП журналына бирергә кушарга.

3. «Безнең юл» журналын Наркомпрос органы буларак сакларга, анда культура-политик һәм гыйльми мәсьәләләрне киңрәк яктыртырга, шулай ук бу журналда татар совет язучыларын тагын да киңрәк төстә катнашырга җәлеп итәргә. Бу журнал өчен тарихи-революцион исем буларак, «Яңалиф» исемен сакларга.

4. ТАПП органы өчен редколлегия оештырырга: 1. Гомәр Галиев (җаваплы редактор), 2. Кави Нәҗми, 3. Газиз Усманов. «Безнең юл» журналы өчен: 1. Фатих Сәйфи (җаваплы редактор), 2. И. Рәхмәтуллин, 3. Г. Нигъмәти, 4. З. Гали. (КПССның Тат. өлкә комитеты партархивы. Ф. 15, опись 33, бәйләм 10, 88 бит.)

Бу тарихи документ беркадәр аңлатуны сорый.

Бердән, Казанда Татарстанның Яңалиф Дәүләт Комитеты органы булып, 1927 елдан бирле «Яңалиф» журналы чыгып килә. Ул журналның төп бурычы — татар хезмәт ияләрен, киң катлау массаны яңа әлифба — яңалиф белән таныштыру, шул шрифтка күнектерү, гарәп әлифбасы белән басылган әсәрләрне яңа шрифтка күчереп басу. Татарстанның ун еллык бәйрәме якынлашкан көннәрдә инде төп масса яңалиф шрифтын үзләштереп бетергән, журнал да үз бурычын нигездә тәгалләгән булганга, аны чыгарудан туктату дөрес чара булган. 1930 елның июленнән басыла башлаган «Яңалиф» журналы элекке журналның бары исемен генә саклый. Ул айлык әдәбият, сәясәт, сәнгать, экономика һәм тәнкыйть журналы булып чыга башлый. Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты (журнал мәгариф сүзен агарту сүзе белән алмаштырган) һәм Совет язучылары оешмасы органы булып мәйданга килә.

Партиянең өлкә комитеты секретариаты карарында ТАПП журналының исеме күрсәтелмәгән. «Яңалиф» белән бер үк вакытта, 1930 елның июль аенда, «Атака» журналы чыга башлый. Ул Татарстан Пролетариат Язучылары Ассоциациясе органы, айга ике мәртәбә чыга торган әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы булып тәкъдим ителә. ТАПП идарәсе һәм «Атака» журналы редколлегиясе укучыларга мөрәҗәгать итеп, болай яза: «Атака» журналы турыдан-туры татар пролетариат әдәбияты хәрәкәтенең үз журналы булып, татар пролетариат язучылары оешмаларыннан берсенең органы булып чыга... «Атака»ның төп бурычы партиянең матур әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә тоткан сәясәтен тормышка үткәрү өчен, пролетариат әдәбиятының гегемониясе өчен көрәшкә кайтып кала». («Атака», 1930 ел, 1 сан.)

Шул рәвешчә, бер журнал урынына ике әдәби журнал мәйданга килә. Боларның кайсысы «Безнең юл»ның дәвамы? Чынында алар икесе дә бер үк журналның дәвамы. Совет платформасында торган татар язучыларының уртак журналлары. ТАПП белән Совет язучылары оешмасы арасында оештыру ягыннан үзгәлекләр булса да, аларның иҗат принципларында бушлык яки киртә тормый. Иҗади мәсьәләдә кылычлар ялтыратырлык бәхәсләр дә булмаган, һәр хәлдә, бу нәрсә журнал битләрендә чагылмый.

ТАПП журналы буларак, «Атака» эшче яшьләргә, фабрик-заводтагы хәбәрчеләргә исәп тота, аларны актив иҗади эшкә чакыра һәм пролетариатка яраклы әйберләр бастыруга әһәмият бирә. Совет язучылары оешмасы органы буларак, «Яңалиф» журналы авторлар челтәрен шактый киң ала һәм «юлаучы» дип йөртелә торган авторларга да урын бирә. Гали Рәхим «Эшче» операсы турында» («Яңалиф». 1930 ел. 3 сан) яза. Г. Ризван, М. Галәү хикәяләре басыла һ. б. Шунысы характерлы, Г. Ризван хикәясенә бирелгән искәрмәдә редакция аны үсеп килүче «юлаучы» дип тәкъдим итә.

Күп кенә күренекле авторлар ике журналда да катнашалар. Ш. Камалның «Матур туганда» романыннан өзекләр ике журналда да басылган. Г. Толымбайский, Ф. Кәрим, Х. Туфан, И. Туктар, И. Гази, М. Әмир, М. Гали, Ә. Түрәй һ. б. ике журналга да хезмәт күрсәткәннәр. Алай гына да түгел, бераздан «Атака» журналын редакцияли башлаган Гомәр Гали 1931 елда «Яңалиф» журналының редколлегия составына керә. «Яңалиф»нең редколлегия члены Закир Гали 1931 елның 9—10 саннарыннан «Атака»ның редакторы булып эшли башлый. «Яңалиф»нең 3 нче санынннан ук Г. Нигъмәти вакытлы редактор булып кул куя, 4 нче саннан җаваплы редактор хезмәтен үти.

Бу ике журналның уртак сыйфатлары булган кебек, аерымлыклары да шактый. Айлык һәм калын журнал буларак, «Яңалиф» күләмлерәк мәкалә һәм хикәяләргә урын бирә. «Атака» аена ике тапкыр чыгарыла торган журнал буларак, күбрәк информацион характердагы материалларга, фотоиллюстрацияләргә игътибар итә. Кыска-кыска очерклар, парчалар, фоторепортажлар белән ул Советлар Союзында барган бөек төзелешләрне иңләп алырга омтыла. Казанда һәм республикада барган төзелешләрдән тыш ул журналда Урал, Кузбасс, Донбасс, Днепрострой, Магнитогорск, Кузнецк турында очерклар укырга мөмкин. Шулар арасында Шәриф Камалның «Бондюг» (1930 ел. 6—7 саннар), Фатих Хөснинең «Турбиналар һәм кешеләр» (1932 ел, 4 сан), Абдулла Алишның Казгрэс төзелешенә багышланган очерклары (1931 ел, 7 һәм 9 саннар), И. Туктарның Уралдагы төзелешләр, А. Әхмәтнең «Беренче чуен» (1932 ел, 9—10 саннар), К. Әмирнең «Чуен һәм корыч шәһәре» (1932 ел. 15—16 саннар), Г. Иделле, М. Гали, Н. Баянның колхоз-совхоз эшчеләренә багышланган очерклары игътибарга лаеклы.

Озакламый «Атака» журналы ТАПП һәм Татлокафның (Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы) берләштерелгән органы булып әверелә һәм ул үзенең битләрендә Кызыл Армия тормышы турында бик күп очерклар бастыра.

1930 нчы еллар, гомумән, очерк жанры чәчәк аткан чор. Татарстанда социализм төзелеше батырлары, Кузбасс шахтерлары турындагы Х. Хәйри очерклары «Яңалиф»тә басылганнар. «Атака» журналы битләрендә Галимҗан Мөхәммәтшин, Г. Хуҗи, М. Садри, Х. Мөҗәй, Ә. Гәрәй, И. Салахов, Ә. Түрәй, М. Сөндекле кебек яшьләр күтәрелә. Шулай да бер хакыйкатьне ачык әйтергә кирәк: шушы ике журнал яшәгән чорда вакыт сынавын узарлык, татар совет әдәбиятының мактанычы булырлык әсәрләр сирәк күренә. Һади Такташның «Киләчәккә хатлар»ы («Яңалиф». 1931 ел, 4 һәм 7 саннар), Фатих Кәримнең «Җиденче мич» поэмасыннан өзекләр, «Аникин» поэмасының баш өлеше, «Яшен яктысы» поэмасы 1931—32 еллардагы «Яңалиф» журналында басылалар. Боларга өстәп тагын Х. Туфанның «Бибиевләр»ен күрсәтергә мөмкин. Ф. Кәримнең ике поэмасы, Ш. Камалның романы кискәләнеп бирелүләрен күз алдына китерсәк, мактанырлык әсәрләребез тагы да кими. Моның, әлбәттә, сәбәбе ачык. «Атака» журналы, РАПП-ТАПП теорияләренә буйсынып, «фактлар әдәбияты» булдырырга омтыла. Фактларга нигезләнгән әсәрләр кеше рухын гәүдәләндерү хисабына үсми, бәлки аның тышкы күренешләрен рәсләү белән чикләнә. «Атака» журналының 1931 елгы 5—6 саннарда басылган мәкаләдә түбәндәге юллар бик характерлы: «...эшләмиләр дип кисеп әйтергә мөмкин түгел, егетләр эшлиләр, язалар, хәтта кайбер иптәшләр бик кыска сроклар эчендә дистәләрчә табаклы әсәрләр язып өлгертәләр. Ләкин кыска срок эчендә бөтен бер роман язуга карап кына ул иптәшнең темпын мактап булмый... Язучыларыбызның иҗат темпы белән социализм төзелеше темпы арасында, матур әдәбиятыбызның тематикасы белән киң массаларның культура һәм сәяси яктан үсеше арасында искиткеч зур тигезсезлек билгесе ята... матур әдәбият алдына куелган төп бер шартны — **конкретлыкны** (курсив редакциянеке — Г. К.) таба алмыйбыз».

Менә бу әдәбиятның түбән сыйфатлы булуын акларга юл калдыра торган «теоретик» караш! Теп бәла темп һәм конкретлык җитмәүдә дип раслый автор һәм шул чорның ударникларын гәүдәләндерү өчен Татарстанда үткәрелгән слет һәм конференцияләрдән файдаланмый калуны да күрсәтеп уза. Бу — шул ук фактлар, тышкы бизәкләр бөтенесен хәл итә дип ышану бәласе.

«Яңалиф» журналы да үз иптәшеннән ерак китә алмаган, билгеле. Алар — шул бер чор җимешләре. Аның карашы, язучы кадрларның намусы белән уйнау бик нык күзгә ташлана. Берәүнең дә хәтере сакланмаган, өлкән язучымы, башлап язучымы. Чыннан да хата ясаганмы, әллә уйдырмамы — аңа карап торылмаган һәм һуштан яздырырлык рецензияләр, эпиграммалар, мәкаләләргә урын иркен бирелгән. «Штык» романын язган Г. Ильяска да, «Җир тыңлый» романын язган Ф. Хөснигә дә, «Галимҗан Ибраһимов» исемле җыентыкта киткән «ялгыш һәм дошман» карашларга да бик авыр күсәкләр төшә. Әсәрләргә җитәрлек анализ ясалмый, шул кәе генә аударыла. Ф. Кәримгә язылган пычрак эпиграмма да шулар рәтенә керә. Ә инде контрреволюцион «җидегәнчеләр» турында әйткән дә юк, аларны «фаш иткән» резолюцияләр шактый җирләрдән тупланган булган. Бәхеткә каршы, тарих раслады: «Җидегән» дигән оешма уйдырма булып чыкты!

Шулардан соң «Әдәбият-сәнгать оешмаларын яңабаштан кору турында» ВКП(б) Үзәк Комитетының 1932 елгы 23 апрель карарын иркен сулыш белән укыйсың, аның никадәр вакытлы, актуаль булуына, алдагы перспективаларны күзаллап чыгарылуына шатланасың. Партиянең бу тарихи карары «Атака», «Яңалиф» журналларында басылган. Әлеге карар нигезендә оештыру эшләре башлана. Татарстан Совет язучылары союзын оештыру комитеты төзелә. «Атака», «Яңалиф» журналларын чыгаруны дәвам иттерергә, аларны Татарстан Совет язучылары союзының органнарына әйләндерергә, аларның характерларын үзгәртергә карар кылына. Бу карар нигезендә «Атака» журналы массовый-популяр художество һәм тәнкыйть журналына, «Яңалиф» исә сәнгать, сәясәт, әдәбият һәм сәнгать теориясенең теп проблемаларын эченә алган журналга әйләндерелергә уйланылган. Шул ук вакытта аларның исемнәрен дә үзгәртү кирәк табылган. Бу карарга ТАПП, ЛОКАФ, Совет язучылары җәмгыяте һәм колхоз пролетар язучылары оешмасы исеменнән 21 язучы кул куйган.

Оештыру эшләре дәвам итә, ә журналлар 1932 елның ахырына кадәр элекке исемнәре белән чыгып киләләр. 1933 ел башыннан «Совет әдәбияты» журналы чыга башлый. Шул исем астында ул 1965 елның 5 санына кадәр чыгып килде, 1965 елның 6 саныннан «Казан утлары» исемен алды.

Татарстан Совет язучылары союзының беренче съезды (1934) җыелганчы Оештыру комитеты эшли һәм «Совет әдәбияты» журналы аның органы була. Оештыру комитеты «Совет әдәбияты» журналын чын-чынлап югары сыйфатлы итеп чыгару өчен бик күп оештыру эшләре алып бара. Моңа кадәр таркау яшәгән әдәби көчләрне туплау өстенә, аларга идея-эстетик тәрбия бирү юлында да эш алып барырга кирәк була. Социалистик реализм методының нигезләрен татар совет әдәбияты үрнәкләрендә өйрәнүгә, Маркс, Энгельс, Ленинның әдәбият-сәнгать өлкәсендәге теоретик карашларын үзләштерүгә бәйле чаралар эшләнә. Әдәби мирас мәсьәләләрен, аерым язучыларның иҗатын өйрәнүдә эзлеклелек күренә башлый.

1933 елның 13—17 январенда Татарстан Совет язучылары союзы Оештыру комитетының киңәйтелгән пленумы уздырыла. Берничә көн дәвам иткән бу пленум эшлекле һәм күтәренке рухта уза. Элек «юлаучы» исеме белән йөргән язучылар да актив катнашалар, барысы да бердәм рәвештә ВКП(б) Үзәк Комитетының 23 апрель карарын яклыйлар һәм аны тормышка ашыру өчен җиң сызганып эшләргә әзер икәнлекләрен белдерәләр.

Ниһаять, журналның беренче саны Г. Нигъмәти редакциясендә тупланып бетә. Ул Әхмәт Фәйзинең «Флейталар» исемле поэмасы белән ачылып китә. Бу — бик характерлы, флейталар журналга да яңа моңнар, яңа хисләр алып керәләр. Афзал Шамовның иҗаты активлаша, ул бер-бер артлы «Ана» хикәясен, «Перекоп» исемле романыннан өзек, «Мәхәббәт һәм романтика» хикәясен бастыра. Шамил Усмановның «Легион юлы» исемле тарихи эпопеясе ел буе диярлек басылып бара. М. Галинең дә «Карпат» исемле күләмле әсәреннән әледән-әле өзекләр бирелә. Г. Разин имзасы белән Г. Баширнең хикәя һәм очерклары, Ф. Хөсни хикәяләре, Ф. Кәримнең «Тавышлы таң»

поэмасы, Ш. Маннур, Х. Туфан, Г. Мөхәммәтшинның матур лирик шигырьләре һ. б. укучыларга тәкъдим ителә. С. Батталның «Кешелек һәм күселәк» (1934) поэмасы шулай ук игътибарга лаеклы.

Бу активлык, иҗаттагы күтәренке рух беренче бишьеллыкның уңышлы тәгалләнүенә һәм икенче бишьеллыкка аяк баскандагы төзү пафосының куәтле булуына бәйле. Колхозчы-ударникларның съездына хәзерлек бара. Шул уңай белән кыска сроклы әдәби конкурс оештырыла һәм авыл хуҗалыгын яңа баштан кору темасына әсәрләр язарга чакырыла. Журналның 4—5 саннары тулысынча конкурска килгән яңа әдәби әсәрләргә багышлана. Шулар арасында М. Әмирнең конкурста беренче урынны алган «Безнең авыл кешесе» исемле хикәясе дә бар.

РАПП-ТАПП хаталарыннан арыну ничек бара соң? Язучыларның эшче, колхозчылар белән аралашулары көннән-көн арта һәм ул әдәби әсәрләрнең санында да, сыйфатында да сизелә. Язучылар ил белән бергә атларга һәм геройларының бишьеллыклар төзелешендә яңа кешеләр булып тәрбияләнү процессын гәүдәләндерергә омтылалар. Теоретик, публицистик мәкаләләрдә анализга куәт, марксизм-ленинизм методологиясен үзләштерә бару (Г. Нигъмәти, Г. Гали, К. Тинчурин һ. б.) күзгә ташлана. Тагын бер характерлы яңалык туа, журнал ара-тирә әдәби консультацияләр бирә. Бу яктан Х. Туфанның 1933 елда басылган «Совет әдәбияты» консультациясе» исемле мәкаләсе кызыклы. Ул ТАПП вакытында тамыр җәйгән ялгышларны төзәтергә омтылуы белән әйбәт. «Әдәбият мәсьәләләрен кирәгенчә аңлап җитмәвебез кимчелекләрне бетерергә уңайсызлый,— дип яза Х. Туфан.— «Әдәбият Магнитострое төзү» лозунгысын зур әйбер язу дип ялгыш аңлавыбыз кебек, «социализм геройларын бирү» лозунгысын да тиешенчә төшенеп җиткәнебез юк әле. Социализм төзү героен сурәтләп, киң итеп бирәсе урында, билгеле бер ударчик геройны турыдан-туры «фотографияләү» белән ялгышабыз».

Сүз уңаенда шуны әйтергә кирәк, «Казан утлары»ның бүгенге практикасында күренми башлаган квалификацияле әдәби консультациягә 30 нчы елларда сирәк булса да әйләнеп кайтканнар. Яшь язучының киләчәк язмышын хәл итә торган әдәби консультацияне Ф. Кәрим дә, Г. Бәшир дә, Ш. Маннур да язган.

Бу урында СССР язучылар союзы Оргкомитетының Ленин ордены белән бүләкләнгән Татарстанга һәм татар әдәбиятына игътибары хәчаюсен дә искә алмый булмый. Мәскәүдән Л. Сейфуллина, А. С. Новиков-Прибой, В. Киршон, Н. Юдин һ. б. Казанга бригада булып килеләр, язучылар һәм хезмәт ияләре белән очрашып, журналда да чыгыш ясыйлар. «Литературная газета» үзенең 1933 елгы 5 апрель санын (тулы ике битне) татар әдәбиятына багышлап чыгара. Анда Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Х. Туфан әсәрләре, татар язучыларының рәсемнәре һәм татар әдәбияты турында мәкаләләр басыла. Шундый хәзерлек нәтиҗәсендә, язучыларның беренче Бөтенсоюз съездында татар әдәбияты турында доклад куела. Болар барысы да журнал битләрендә үзенең чагылышын таба.

Язучыларның беренче Бөтенсоюз съездыннан соң фольклорны җыю, өйрәнүгә әһәмият арта. Фольклор җирлегендә соңрак яңа әсәрләр дә языла һәм алар беренче чиратта журналда басылалар. Бу өлкәдә Л. Җәләй, Г. Бәшир, Ә. Фәйзи, Т. Гыйззәт, М. Җәлил һ. б. эшчәнлеген әйтергә кирәк. Әдәби мираска караш бик нык үзгәрә, ТАПП вакытындагыча, элекке мирасны иске булганы өчен генә сөбереп түгү очраклары сизелми. Киресенчә, А. С. Пушкинның үлүенә 100 ел тулу уңае белән Бөтенсоюз юбилей комитеты төзелү, Шота Руставелинең тууына 750 ел, Т. Шевченко, Н. Добролюбов, Н. Некрасов кебек бөек язучыларның түгәрәк даталарга бәйләнгән юбилейларын уздыру татар язучылары өчен дә зур мәктәп булды. 1936 ел тулысы белән Пушкин юбилеена хәзерлек белән үзә. Пушкинның моңа чаклы тәрҗемә ителмәгән поэзия, проза һәм драма әсәрләре сайлап, үз итеп, татар теленә тәрҗемә ителәләр һәм журналның һәрбер санында басылып баралар. Шушы процесста шагыйрьләр үзләре дә шигъри осталыкка өйрәнделәр. Әхмәт Исхак, мәсәлән, «Евгений Онегин» строфикасын, аның рифма, ритм калыпларын татар шигъри үрнәгендә бирү мөмкинлеген күрсәтте. Аның журналда басылган «Геройның үлеме» поэмасы шул тәҗрибә җимеше иде.

Пушкин романсларын тәрҗемә итү, халык җырларына күңел салып эшләү, кардәш

халыкларның эпосларын өйрәнү 30 нчы елларның уртасыннан массовый җырларның чәчәк атуына йогынты ясады.

1936 елда СССРның Яңа Конституциясе расланды. Шул уңай белән татар язучылары да бик күп патриотик шигырьләр, җырлар, хикәяләр иҗат иттеләр һәм алар журналда үзенең чагылышын таптылар.

Журнал битләрендә һәрвакытта да классик әсәрләр генә басылмады. Бөек Ватан сугышына кадәр булган чорда да саксыз әйтелгән сүзләр, йомшак әсәрләр, шулай ук вульгар социологизмнан арына алмау (Г. Толымбайский мәкаләләре) күренешләре дә бар. 1937 елдагы кайбер саннарның күбесенчә тәрҗемә әсәрләрдән тупланулы яшь язучылар кадрын тәрбияләүнең никадәр кискен торганлыгын күрсәтә булса кирәк. Журналның «Яшьләр бите» ачып, аларның яшьлекләре өчен укучылардан ташлама сорау шикелле күренешләр булды.

Безнең әдәби журналыбыз үзенең яшәү дәверендә йөзләрчә халыкларның язучыларын үз укучыларына тәкъдим иткән. СССР халыклары язучылары, Көнчыгыш һәм Көнбатыш дөнья классиклары, хәзерге капиталистик илләрдәге, колониаль һәм ярым колониаль илләрдәге, империализмга каршы күтәрелгән халыкларның язучылары теге я бу күләмдә журналда чагылыш табалар. Ләкин шулар арасыннан иң системалы басыла торганнары рус һәм башкорт язучылары. Русның бөек классиклары белән рәттән хәзерге көндә дә яза торган безнең каләмдәш дусларыбыз даими рәвештә журналда басылып киләләр. Башкорт язучыларына килсәк, аларның өлкәннәре, мәсәлән, С. Кудаш 1923 елдан бирле, Афзал Таһиров, Давыт Юлтый, Гариф Гомәр, Гайнан Хәйриләр — 1925-26 еллардан ук, Амантай — 1927 елдан, Б. Бикбай — 1932 елдан, Мостай Кәрим — 1941 елдан, Хәниф Кәрим — 1943 елдан, Г. Рамазанов — 1945 елдан бирле һ. б. дистәләрчә каләмдәш дусларыбыз системалы рәвештә журналда урын табалар. Безнең әдәби журнал башкорт дусларыбызның да бишеге булып килде. Аларның кайберсе үзенең иҗат юлын шушы журналдан башлап җибәрде (Б. Бикбай, М. Кәрим һ. б.) дисәк, хата булмас.

* * *

«Казан утлары» үзенең 51 яшенә 621 нче сан белән аяк баса.

Шул рәвешчә, артта 600 саннан артык журнал, анда 2500 ләп авторның хикәясе, повесте, романы, шигырь һәм поэмалары, очерклары, тәнкыйть мәкаләләре, публицистик чыгышлары һәм рецензияләре, уйлану һәм борчылулары, ашкыну һәм ярсулары, иске мирастан табып алган хәзинәләре, фольклор һәм тел байлыклары, кыскасы, анда эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли татар совет культурасының житлегү һәм чыныгу үрнәкләре, халыкчанлык һәм партиялелек принципларының тантанасы, социалистик реализм өчен көрәш һәм аның җиңү юллары...

Журнал чыга башлаган көненнән алып бүгенгәчә интернациональ традицияләрдә торды, милли чикләнүчәнлеккә каршы булды. Ул үзенең битләрендә бөек рус язучыларының классик үрнәкләре белән таныштыра килде. А. Пушкин, М. Лермонтов, Н. Гоголь, Н. Некрасов, В. Белинский, Н. Чернышевский, И. Тургенев, Л. Толстой, А. Чехов һ. б. әсәрләрен һәм алар турында язылган гыйльми мәкаләләр урнаштырып килде. Социалистик реализм методына нигез салган Горький әсәрләре, аның публицистик мәкаләләре, хатлары журналда мактаулы урын билиләр. Совет әдәбиятын үстерүгә күп көч салган һәм татар совет язучыларының әдәби-рухи укытучылары булып танылган В. Маяковский, А. Фадеев, М. Шолохов, Ф. Гладков һ. б. лар журналда әледән-әле басылалар һәм искә алыналар.

Журнал үз укучыларын Көнбатыш Европа классиклары белән дә, СССР халыклары язучылары белән дә әледән-әле таныштырып тора.

Журнал Совет язучылары союзы органы булып чыга башлагач, социалистик реализм методы бердәм уртак иҗат методы булып кабул ителгәч, анда бу методны аңлата торган мәкаләләр күп басылды. СССР язучыларының 1934 елда булып узган беренче Бөтенсоюз съездыннан соң социалистик реализм принципларына әледән-әле игътибар ителде. Язучыларның беренче Бөтенсоюз съездында партия Үзәк Комитеты исеменнән тәбрик белән чыккан А. Жданов речен, М. Горький докладын, А. Фадеев һ. б. рус әдәбияты теоретикларының мәкаләләрен, «Правда» газетасының, «Большевик»

журналының редакцион мәкаләләрен тәрҗемә итеп бастыру социалистик реализм методы формуласын аңлатуга ярдәм иттеләр.

Кайчандыр журнал редакциясе катгый рәвештә: «...хәзерге вакытта романтизм безнең әдәбиятка иң зарарлы агымнарның берсе» («Безнең юл», 8 сан, 1927 ел) дип расласа, хәзер — язучылар съездыннан соң — бу мәсьәләдә үзенең позициясен үзгәртергә тиеш булды.

Социалистик реализм методы — катып калган бер нәрсә түгел, аны схоластик рәвештә аңлау зарарлы булыр иде. Тормыш алга бара, коммунизм җәмгыятенең нигезләрен салуда җиңү артыннан җиңүләр яулап алына. Шул тормышыбызны чагылдырган әдәбиятыбыз да социалистик реализм методы рамкаларын җәя төшә, тирәнәя, яңадан-яңа чагылышларын күрсәтә. Шуңа күрә дә бүгенге әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр бу проблемадан ераклашмыйлар. Киресенчә, тагын да киңрәк һәм тирәнрәк алып, иҗат процессының эченә кереп, гыйльми тикшерү эшләре алып баралар. Шушы юнәлештә «Казан утлары» бик кызыклы һәм әһәмиятле теоретик мәкаләләр бастырды. Метод, стиль, реализм һәм романтизм проблемалары, герой һәм масса, чор һәм образ, язучының иҗат методы һәм иҗат психологиясе, сәнгать төрләренең бер-берсенә тәэсире, матурлык критерийлары, ниһаять, әдәбият-сәнгать тарихын бәета торган яңа материаллар журнал битләрендә киң яктыртылалар.

Әдәби тәнкыйть вульгар социологизм йогынтысыннан арынганнан-арына барды, әдәби мираска игътибарын арттырды, марксистик-ленинчыл методологияне тирәнтен аңлау юлыннан күтәрелә килде. Әдәби тәнкыйтькә, әдәбият фәненә зур өлеш керткән тәнкыйтьчеләребез, галимнәребез җитеште. Х. Госман, М. Гайнуллин, Н. Юзиев, И. Нуруллин, Х. Хәйри, Г. Халит, М. Хәсәнов, М. Мәһдиев, Р. Мостафин, А. Әхмәдуллин, Н. Гыйззәтуллин, Б. Гыйззәт, Т. Галиуллин, М. Усманов, И. Илялова һ. б. иптәшләрнең хезмәтләре журнал аша халыкка юл алдылар һәм танылдылар.

Шуның белән бергә, әдәби тәнкыйтьнең төрләре ишәюен дә әйтергә кирәк. Ул— рецензия генә түгел, сәнгатьнең аерым бер ягын тирәнрәк ача торган гыйльми тикшеренү мәкаләсе дә, ул — язучының иҗат портреты яки китап күзәтү генә түгел, шагыйрь турында шагыйрь, язучы турында язучы уйлануы һәм жанрлар, методлар турында бәхәсләр дә...

Ләкин эшлисе эш күп әле. КПССның XXIV съездында әдәби тәнкыйтьнең җитди кимчелекләре күрсәтелде һәм ул тулысынча безнең тәнкыйть практикабызга да карый. Әдәби тәнкыйть партия сызыгын тагын да активрак уздырса, художество кыйммәте тудыручыларга сак мөнәсәбәтне таләпчәнлек такты белән кушып, принципиаль чыгышлар ясаса, билгеле, әдәбият өлкәсендәге уңышларыбыз зуррак булыр иде. Безнең тәнкыйтьнең әдәби хәрәкәткә тәэсире җитеп бетми. Аның җанлы әдәби хәрәкәтне җитәкли алу югарылыгына күтәрелергә мөмкинлеге бар. Әмма күп кенә әдәби әсәрләр аның күзенә күренми уза. Бу кимчелекләр журналның тәнкыйть-библиография бүлегенә игътибары җитмәү белән дә бәйле. Тәнкыйтькә журналда бик тар урын бирелә һәм шуның нәтиҗәсе буларак, яшь тәнкыйтьчеләр, башка жанрлар белән чагыштырганда, бик акрын үсәләр.

* * *

Журналның йөзен нинди жанр билгели? Гадәттә журналның йөзен проза билгели диләр. Бу дөрес, ләкин һәр очракта да түгел. Югарыда без һ. Такташ поэмаларына журналның нинди зур игътибар бирүен һәм аларның укучыга ничек тәкъдим ителүен әйткән идек. «Мәхәббәт тәүбәсе...», «Мокамай», «Алсу», «Киләчәккә хатлар» — совет әдәбиятының горурлыгы булып калдылар.

1953 елда журнал дүрт сан буе Муса Җәлилнең Моабит дәфтәрләре циклына кергән шигырьләрен бастырды. Шул журнал битләреннән үлемсез шигырьләр зур дөньяга таралдылар.

Х. Туфанның «Урал эскизлары», «Бездә туа яңа кешелек», «Башлана башлады» (1927), «Кайтырсың шикелле» (1956), «Кер чайкыйлар кызлар» (1958) һ. б. бик күп лирик шигырьләре журналның энҗеләре түгелмени? Яки Ф. Кәрим, Ш. Маннурның ут сызыгыннан язып җибәргән фронт шигырьләре, балладалары (1942—1944) йөзек кашы булмаслык әсәрләрмени?

Алыгыз Сибгат Хәким шигырьләрен. «Суд залыннан» циклы (1957), «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (1959), журналның 1965 елгы битен ачып җибәргән «Урләр аша» поэмасы — болар барысы да журналның йөзен билгели торган гражданлык поэзиясе үрнәкләре.

Мондый мисалларны күп китерергә мөмкин. Аннан соң шунысы да бар: журналның йөзе барлык жанрларны да үз итүендә чагыла. Ул шуның өчен журнал: анда хикәя дә, очерк та булырга тиеш, ялкынлы публицистика һәм утлы тәнкыйть, күңелләргә кереп утыра торган лирика һәм эпик поэма, саннан санга тезелеп килгән роман һәм нәни рецензия, әдәбият тарихына караган документ; язучының хаты һәм хроника; замандашның портреты һәм тарихка экскурсия... Болар һәркайсы укучылар өчен кызыклы һәм алар үз аудиторияләрен табалар. Алардан башка журнал юк, шулай булмаса, ул җыентыкка әверелер иде. Укучылар өчен кызыклы бер сан китерәсе килә: журналның ярты гасырлык юлында унбер меңнән артык исемдәге әсәр: роман, повесть, хикәя, шигырь, поэма, очерк, мәкалә, рецензия һ. б. маяк булып утырып торалар. Ничек аны хәзинә дип әйтмисең! һәм шулардан безнең «Татар совет әдәбияты тарихы» туган! Андый китап язылды, аны СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты коллективы барлыкка китерде. Тарихта беркетелгән казанчышлар — ул журналның да казанышлары, анда күрсәтелгән кимчелекләр — журналның да кимчелекләре.

Журналның йөзен билгеләргә заман үзе булыша. Сугыш елларындагы материаллар — фронт һәм тыл батырлыкларын сурәтләгән очерклар алгы урында тордылар. Ул чакта Верховный башкомандующийның приказлары да безгә әдәби журнал өчен табигый булып тоела иде. Чөнки аларга Совет Армиясенең сугыштагы җиңү адымнарын теркәп баручы тарихи документлар итеп карала иде.

Илебез бөек даталарга әзерләнә башлады. Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгын, даһи юлбашчыбыз, бөтендөнья хезмәт ияләренең укытучысы, Совет дәүләтен оештыручы, коммунистлар партиясен нигезләүче В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуны бөтен ил, барлык совет халыклары аерым бер күтәренкелек белән билгеләргә җыенды. Бу кайнар сулыш журнал битләрендә дә бик көчле һәм ышанычлы чагылды.

Журналның 1967—70 елгы саннарында Н. И. Альтман, А. Р. Вильямс, А. В. Луначарский, Н. К. Крупская кебек, юлбашчы белән бергә эшләгән, аны күреп белгән революционерларның истәлекләре, Назыйм Хикмәт, С. Щипачев кебек атаклы шагыйрьләрнең шигырьләре, төрле илләрдән, төрле телләрдән тәрҗемә ителгән хикәя, шигырьләр, истәлек-мәкаләләр басыла. Бу өлкәдә тагын татар язучыларының оригиналь әсәрләрен — публицистик хезмәтләрен, шигырь, поэмаларын, уйлануларын искә алырга кирәк.

Ф. Табеевның «Юл башы» һәм «Даһи Ленинча яшәргә һәм көрәшергә», М. Хәсәновның «Ленин тәгълиматы һәм татар халкының иҗтимагый-политик фикер тарихын өйрәнү мәсьәләләре», Р. Мостафинның «Минем горурлыгым», З. Нуриның «Ленинга — чәчәкләр», И. Низамовның «Сагындым мин Иделне!», И. Надыйровның «Халыклар шигъриятендә Ленин образы», Г. Әпсәләмовның «Без һәрвакыт Ленин белән», Г. Мөхәммәтшинның «Шушенскоеда яз» һ. б. оригиналь мәкаләләр безнең лениниананга өлеш булып керделәр.

Болардан тыш без С. Хәкимнең, Х. Туфанның, Н. Дәүлинең, Н. Арслановның һәм дистәләрчә башка шагыйрьләрнең илһамлы шигырь, поэмаларын укыдык.

Тирән уйланулар, яңа рухи дәрт һәм тыелгысыз ярсу, алга ашкыну кузгаткан бу даталар уңае белән кем генә үзенең сүзен әйтмәде, йөрәгендә кайнаган изге хисләрен җырламады! Нинди генә жанрда язылмасын, шушы даталарга бәйле рәвештә туган шигырь, җыр, публицистика, очерк, хикәя — алар куәтле оркестрның күтәренке моңын тагын да үстереп, аңа полифоник яңгыраш бирде, симфониягә әверелдерде.

Торган саен арта бара, Ильич,
Сиңе сагыну безнең йөрәктә,
Заман үзе шундый итте безне,
Заман үзе шуңа юнәлтә,—

дип язды Хәсән Туфан (1970) һәм бу безнең барыбызның да уртак тойгылары, уртак хисләре иде.

Октябрь. Ленин. Аларның баласы булып туган Татарстанның 50 еллыгы безне узган юлыбызга әйләнеп карарга мәҗбүр итте, коммунизм җәмгыятен төзү эшенә канатландырды.

Гомәр Усмановның «Кем идек без һәм кем булдык», Х. Госманның «Кабатланмас документ», А. Әхмәдуллинның, Т. Насыйровның, Т. Галиуллинның һ. б. публицистик мәкаләләре, дистәләрчә җырлар, шигырьләр — болар бик әһәмиятле документлар һәм үсешебезнең бөекләгән күзалларга булышучы материаллар. Аларны тарихчылар да, әдәбиятчылар да еллар буе җентекләп өйрәнерләр.

«Литературная газета»ның 1971 елгы 3 ноябрь санында Георгий Кублицкийның «Гасыр канатларында» исемле публицистик мәкаләсе басылган. Анда мин түбәндәге юлларны укыдым: «Күптән түгел Идел буе республикалары үзләренең ярты гасырлык бәйрәмнәрен билгеләп уздылар. Мисал өчен, бәлки, Татарстан бәйрәм хроникасыннан кайбер нәрсәләрне күрсәтеп үтәргә кирәктер. Республика бер көндә Казан губернасы бер елда эшләп чыгара алган промышленность продукциясе күләменнән артыграк продукция эшләп чыгара, һәм ул үз продукциясен 60 илгә озата. Чирек гасыр гына элек Татарстан беренче тапкыр промышленность нефтен алды. Шул вакыттан бирле аның күкрәгеннән миллиард тонна нефть алынды. Республикада татар теленә илебез халыкларының 65 теленнән меңләп авторның әсәре тәрҗемә ителгән. Татар язучыларының 750 дән артык китабы дистәләрчә телгә тәрҗемә ителгәннәр һәм ун миллионнан артык тираж белән басылып чыкканнар».

Ничек моның белән горурланмыйсың? Меңләп авторның әсәре татар укучыларына нигездә шушы журнал аша барып ирешкән ич! 750 дән артык китап, дистәләрчә телләргә тәрҗемә ителгәнче, башлап шушы журнал аша киң дөньяга карый башлаган.

Әйе, озын юл үтелгән. Нәни сукмактан башланып киткән бу юлны түшәргә, таш җәяргә, асфальт салырга кирәк булган икән, аны татар язучылары үз куллары, үз көчләре һәм сәләтләре белән эшләгәннәр. Очлы ташларны шомартканда чабаталар тетелеп калган, аяк-кул имгәнгән чаклар да булган, ләкин партиянең яшәү сулышы бөркеп торган кояшы, совет җәмгыятеннән сибелеп торган якты, җылы нурлар һаман рухландырып, дәртләндереп, илһамландырып торган.

Юл югарыга таба сузыла, үргә менә. Артта эреле-ваклы маяклар булып яңа әсәрләр сибелеп кала. Әгәр дә ул маякларның 750 дән артыгы яктылыгын бик күп халыкларга төшергән икән, бу юлны изге юл дип танырга кирәк.

Бишьеллыклар тудырган бөек төзелешләр, шул төзелешләрдә чыныккан, үзенең психологиясен яңабаштан төзегән батырлар язучыларның туганнары булды. Социализмга юл тоткан авылның һәм промышленностьның алдынгы кешеләре — стахановчылары белән язучылар арасындагы бушлык бетә барды. Язучылар шул каһарманнар белән бергә атладылар.

Яңа кешеләр, яңа мораль-этик нормалар, дәүләт күләмендә фикер йөртә белүче тирән акыл ияләре, шәхси бәхетне совет халкы бәхете өчен көрәштә күрә белүче, интернациональ рухлы көчле ихтыярлы кешеләр — язучыларның күптәнге хыяллары иде һәм аларны социалистик җәмгыять үстерде, аларны чикләнмәгән күләмдә тормыш материалы белән баетты. Шуларны сурәтләп яңа әсәрләр мәйданга килде һәм шул төзелешләрдә, героик көрәшләрдә яңа тип язучы формалашты.

Кызыл Армиянең 21 яшьлек комиссары Шамил Усманов, 1919 елда Оренбургны аклардан чистарткач, җиңү шатлыгы белән рухланып, бер төн эчендә «Канлы көннәрдә» исемле драмасын яза. Соңыннан ул бу әсәр турында болай дип сөйли: «Бер Америка язучысының, әсәре мең мәртәбә куелгач, баеп, миллионер булганын ишеткән идем. Минем «Канлы көннәрдә» дә, шөбһәсез, ул елларда меңнән артык куелгандыр. Гәрчә ул миңа бер генә тиен гонорар бирмәсә дә, рухани капиталы зур булды. Ул миңа алда язучы булырга юл ачты».

Әнә шулай революция тудырган язучылар яңа мораль, яңа рухи байлык алып килделәр. Бишьеллыклар чорында ул матур традицияләр үсте, тамыр җәйде һәм Бөек Ватан сугышы кырларында үзенең нинди батырлыкларга сәләтле булуын дөньяны таң калдырган мисалларда күрсәтте.

Илебез үсә, илебез белән бергә халыкның интеллектуаль сыйфатлары үсә, героик характеры формалаша. Шулар белән бергә язучы да чынлыга һәм политик белеме генә түгел, тормышны аңлау сәләте, аны иңләп алу колачы, идея-эстетик карашлары югары күтәрелә. Яңа төзелешләр яңа герой гына түгел, яңа ситуация, яңа конфликтлар да алып килә, матурлыкны аңлау критерийлары тирәнәя, осталык үсә. Шушыларга тагын жанрларны аңлау һәм аларның рамкаларын киңәйтү юлындагы уңышлы тәҗрибәләрне кушарга кирәк.

Чыннан да, лириканың төрләре ишәйде, поэма да рифмалы хикәя булу белән генә чикләнми, аның эпик, лирик төрләре дә, патетик формалары да барлыкка килде, журнал аларның матур үрнәкләрен укучыларга җиткерде.

һ. Такташ һәм Х. Туфан поэмаларыннан тыш, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, С. Хәким, Ә. Исхак, С. Баттал, Ш. Маннур, Н. Арсланов, И. Юзеев, М. Садри, Г. Хуҗи, Ә. Давыдов, Х. Камалов, С. Сөләйманова, Ә. Маликов поэмаларын искә алып китәсем килә.

Без журналда актив катнашучы каләмнәрнең барысын да телгә алып бетерә алмыйбыз. Бу — мөмкин түгел. Шулай да шагыйрьләрнең зур бер отрядын искә алмый ярамый. 50 ел эчендә җитлеккән шагыйрьләр армиясеннән башка журнал битләре төссез, күңелсез булыр иде. Г. Афзал, Ә. Баян, К. Булатова, Ш. Галиев, Р. Гәрәй, Р. Гатауллин, С. Гәрәева, Ә. Давыдов, Н. Дәүли, Ә. Ерикәй, Зөлфәт, Ә. Исхак, Х. Камал, Ә. Кари, М. Крымов, Г. Латыйп, З. Мәҗитов, Ә. Маликов, В. Мифтах, Ш. Мөдәррис, Э. Мөэминова, З. Нури, Б. Рәхмәт, Р. Фәйзуллин, М. Садри, Б. Сирин, М. Сөндекле, С. Урайский, Д. Фәтхи, Г. Хуҗи, М. Шабаев, С. Шакир, И. Юзеев, Ф. Яруллин һ. б. шагыйрьләр өчен журнал чын мәгънәсендә академия булды. Алар шунда канат чыгардылар, шунда югарыга күтәрелделәр, шунда үзләренең хис һәм тойгылары белән, уйлану, борчылулары белән уртаклаштылар. Шагыйрьләр турында сүзне очлаганда яшь шагыйрь Әхмәт Рәшитовның журналда (1970) басылган бер шигыре белән очлыйсы килә.

Еллар уза,
Ирләр үсә тора —
Тарих дәвам итә һаман да:
Малайларның ал хыялы аша
Киләчәккә карый замана.

Тик бу очракта мин «малайларның» сүзен «шагыйрьләрнең» дип кенә алыштырыр идем!

Драматургия өлкәсендә дә жанрларга тугрылыклы булырга омтылу сизелә. Бер нәрсә дә аңлатмый торган «пьеса»лар үзләренең төгәл билгеләмәләрен ала башладылар: драма, комедия, поэтик драма, драматик поэма, драматик повесть, водевиль, скетч... Шулар өстенә драманың иң авыр һәм иң куәтле бер төре: трагедия үрнәкләре дә күренә башлый. һ. Такташ, К. Тинчурин тәҗрибәләреннән соң бу өлкәдә Нәкый Исәнбәтнең уңышлары зур. «Спартак» (1935), «Мәрьям» (1943) шундыйлардан.

Баштагы елларда журнал драма әсәрләрен бөтенләй басмаган. Сугышка чаклы журнал битләрендә драма әсәре берән-сәрән күренсә дә, алар драмаларның бер күренеше яки бер пәрдәсе белән чикләнгәннәр. Бөек Ватан сугышыннан соң журнал редакциясе эшне киңрәк җәеп җибәрде һәм драма әсәрләрен тулысынча баса башлады. Мәсәлән, Н. Исәнбәтнең «Спартак» трагедиясеннән 1935 елда бер пәрдә басылган, 1943 елда «Мәрьям» трагедиясе һ. б. драмалар тулысынча басылганнар. Р. Ишморат, Т. Гыйззәт, Ә. Фәйзи, Х. Вахит, Т. Миңнуллин, С. Кальметов, С. Шәкүров, Г. Мөхәммәтшин, Ф. Хөсни һ. б. сәхнә әсәрләре журнал аша укучыларга барып җиттеләр. Шунысын да әйтергә кирәк, һади Такташның «Югалган матурлык» исемле роман-пьесасын (жанрны автор үзе билгеләгән) шагыйрьнең бер җыентыгыннан да таба алмыйсыз, ул бары шушы журнал битләрендә (1956, № 12) генә яши!

Ә. Фәйзи, М. Җәлил, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт тарафыннан язылган либреттоларны да опера драматургиясендәге зур адымнардан санарга кирәк.

Татар прозасының бай традицияләре бар, шулай да совет чорында бу өлкәдә дә

бик күп яңалыклар күрергә була. Егерменче елларда бик матур үрнәкләрен биргән нәсер хәзер дә үзенең яшәүчәнлеген күрсәтә. Кыска хикәя, новелланың классик үрнәкләрен Ф. Хөсни үзенең озак еллык эшчәнлегендә бик күп мисаллар белән баетты.

Революциядән соң прозаның элекке традицияләре бик ишәйде, төрләнде. Совет укучылары киң планда язылган социаль романнар көтте һәм алар тудырылды. Социаль төркемнәр язмышына бәйле катлаулы вакыйгалар яктылыгында, күп планлы романнар язылды. Нигезен Г. Ибраһимов салган социаль-тарихи роман («Безнең көннәр») да, тарихи вакыйгалардан тыш, тарихи шәхесләр тормышын яктырту юлында зур уңышлар бирде. Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы (журналның 1950, 1951, 1955, 1958 елдагы саннары), Шәйхи Маннурның «Муса» романы (1965 елгы саннарда), Атилла Расихның «Ямашев» романы (1967 елгы саннарда) шундыйлардан. Ләкин бездә якындагы һәм ерактагы тарихны күзаллый торган тарихи романнар да мәйданга килде. Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романы (1948), Нурихан Фәттахның «Әтил суы ака торур» (1970) романы укучыларның игътибарын үзенә тарткан тарихи романнар булдылар.

Болардан башка татар совет прозасының үсешенә сизелерлек йогынты ясаган тагын бик күп роман, повестьларны, драмә, поэмаларны санарга була. Тик роман жанрының тармакланып, җәелеп үсү мәсьәләсе турында сүз кузгалгач, бер нәрсәне әйтмичә ярамый. Роман жанры язучыдан иҗади батырлык таләп итә. Үз энергиясене һәм талант көченңе бөтенләе белән аңа багышлауны сорый. Язучының гыйльми-тикшерену эшләре дә җәелеп китә, фәлсәфи уйланулары, идея-эстетик критерийлары гаҗәп үткен төс алалар. Болардан тыш, сюжет, тел чаралары өстендә эшләгәндә, чын мәгънәсендә тылсымчы булуны, озак, бик озак вакытлар эш өстәле янынннан кузгалып китмәслек итеп үз-үзеңне бәйли алырлык ихтыяр көченә ия булуны сорый.

Журналның ярты гасырлык тәҗрибәсе бездә роман жанрының бик авырлык белән формалашуын сөйли. 30 нчы елларның ахырына кадәр зур күләмле әсәрләрчә бастыру практикасы да булмаган. Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлары», Ш. Камалның «Таң атканда» романнары журналда бөтенләй басылмаганнар, «Матур туганда» романының берничә бүлеге генә басылган. Зур булмаган повестьлар да берничә санга бүленеп бирелгәчнәр. М. Әмирнең «Безнең авыл кешесе» — озын хикәя. Ә ул 1933 елда дүрт санда ваклап басылган.

Иң зур күләмле повестьны беренче тапкыр 1937 елда алты санга бүлеп бастырганнар. Ул Гомәр Бәшировның «Сиваш» повесте.

Совет чорында формалашкан язучыларның роман тудыру омтылышлары 30 нчы елларда башлана. 1934, 1935 елларда Кави Нәҗми «Гарнизон» исемле романнан дип, 1947 елда «Туган ил» романыннан дип, аерым бүлекләр бастыра. Алар 1948 елның алты санында басылган «Язгы җилләр» романының бүлекләре булып чыгалар, дөресрәге, шул романның баштагы вариантлары булалар.

Ибраһим Газиның 1962 елда тәмамланган зур эпопеясенең басылу тарихы да кызыклы. Бөек Ватан сугышына кадәр үк 1940 елда И. Гази «Хәлимнең яшьлеге» исемле повестьтан аерым бүлекләрне ике тапкыр бастыра. Бөек Ватан сугышы язучыны үзенең яшьлеге белән бәйле Хәлим образыннан бик озакка аерып яшәтә. Язучы бик күп хикәяләр, очерклар, повестьлар һәм «Гади кешеләр» исемле роман да язып, укучыларга бүләк итә. Ләкин «Хәлимнең яшьлеге» аны һаман мавыктырып, илһамландырып тора. И. Гази 1949 елгы журнал саннарында шул повестьның беренче кисәген бастыра. Ләкин исеме «Онытылмас еллар» («Хәлимнең яшьлеге») дип куела. 1957 елгы журнал саннарында «Онытылмас еллар» романының икенче кисәге бирелә. 1962 елда исә җиде санга бүлеп бастырылган «Онытылмас еллар» повесть дип тәкъдим ителә.

Г. Бәшировның «Намус» романы татар совет язучыларының һәм журналның зур күләмле әсәрләргә юл тотуларын раслады. Журналның 1948 елгы саннарын ачып җибәргән «Намус» романына «Язгы җилләр» тоташып китте, аларга Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» (1949), «Газинур» (1951), «Мәңгелек кеше» (1960), «Ак чәчәкләр» (1965), «Яшел яр» (1969) романнары һәм повестьлары ялганды. М. Әмир «Ялантау кешеләре» исемендә (1953) романның беренче китабын башлый һәм «Саф күңел» исеме белән (1959) тәмамлый. Ф. Хөсни «Җәяүле кеше сукмагы» (1958) һәм «Угызының эле» (1961) романнарын бирә.

Өлкән буын язучыларының тәҗрибәсен урта буын язучылар һәм яшьләр дәвам иттерәләр. Югарыда телгә алынган романнардан тыш, Г. Ахуновның «Хәзинә» (1962) һәм «Хуҗалар» (1968) романнары, Э. Касыймовның «Гомер ике килми» (1964), А. Расихның «Ике буйдак» (1964), А. Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын» (1970), С. Рафиков, И. Салахов романнары, Н. Дәүли, Ә. Баяч, В. Нуруллин, Ш. Рәкыйпов, Г. Минский, Ф. Хәсни, И. Гази, М. Мәһдиев, М. Маликова, Д. Зөбәерова, Р. Төхфәтуллин, Э. Еники, М. Рафиков, Л. Ихсанова, Х. Сарьян, М. Хәбибуллин, Б. Камал, Г. Мөхәммәтшин һәм тагын бик күпләрнең повесть, хикәя, новеллалары 60 нчы елларның мул уңышын чын мәгънәсендә күз алдына бастыралар.

Очерк жанры 30 нчы еллардан ук, бишьеллыклар төзелешләрендә тәҗрибә туплап, Бөек Ватан сугышы елларында бик нык алга китте, сугышчан һәм оператив жанр икәнен танытты. Сугыштан соң исә бу жанр тагын да тирәнәю һәм эмоциональ ягын көчәйтү юнәлешендә үсте. Дистәләрчә замандашларыбызның җанлы портретларын бирде. Әнә шундый очерклар тәҗрибәсеннән документаль повестьлар үсә башлады. Моның мисалын журналда, мәсәлән, Ш. Рәкыйповның «Таңнар һаман матурмы?» исемле (1970) повестенда күрергә мөмкин.

Мәкаләмне истәлек белән тәмамлыйсым килә. Журнал аппаратында шактый еллар эшләгән кеше буларак, редколлегия члены сыйфатында утыз ел буе аның эшенә катнашучы буларак та миңа журналның эчке тәртипләре таныш. Шул турыда кыскача гына булса да берничә сүз әйтергә кирәк.

Һәрбер редакциянең, ломовой ат кебек, авыр йөк тартып баручы сотруднигы була. «Казан утлары» журналы редакциясендә дә андый сотрудниклар булды. Редакциянең бүгенге көнен алмаска да мөмкин, чөнки хәзер илнең гомуми экономик куәте үсү белән бергә, аның аппараты да киңәйде. Эш төрләре сотрудниклар арасында тигез бүленгән. Барыннан да бигрәк, журналга материал эзләп, төрле якка чабасы юк. Хәзер роман, повестьларны эзләмиләр. Калын-калын кульязмалар хәзер басылырга чират көтеп ята. Язучылар санының көннән-көн үсә баруы калынайганнан-калыная барган шушы журналның мәйданын тарайтып җибәрде... Ә бит без кайчандыр (әле бик күптән дә түгел) тиешле югарылыктагы материалны таба алмый интегә идек...

Югарыда мин Гомәр Галинең редакциядә ничек эшләвенә ишарә ясаган идем. Абдулла Гомәр турында да минем җылы сүз әйтәсем килә. Ул «Яңалиф» журналы оештырылганнан алып (1927 ел, журналның беренче чоры), 1943 елга кадәр өзлексез техник редактор һәм секретарь булып эшләде, 1958 елдан җаваплы редактор булды. Озак еллар ул журналның барлык авыр эшен үз җилкәсендә алып барды: техник редактор буларак, типография белән бәйләнешкә керә, секретарь буларак, кульязмаларны редколлегия өчен әзерли, хатлар яза, авторлар белән эшли һ. б.

Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган.

Партиянең Татарстан өлкә комитеты «Совет әдәбияты» журналын саклап калырга булды. Шул ук вакытта аппараттагы әдәби сотрудник штаты кыскарды. Бу вакытта журналны Гомәр Бәширов редакцияли иде. Озак та узмастан, партия оешмасы Г. Бәшировны фронтка, озак сроклы командировкага җибәрде, бөтен эш А. Гомәр җилкәсенә авып калды.

1942 елны Гомәр Бәшировны мин алыштырдым, Г. Бәширов Татрадиокомитетның баш редакторы булып китте. Журналдагы хәл авырлыгына матбугат йортының котып салкыннары килеп кушылды. 1941 елның кышыннан бирле Матбугат йорты ягылмый иде.

Менә без — А. Гомәр белән икәү — «Совет әдәбияты»ның чираттагы санын әзерлибез. Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый, салкын үзәккә үтә һәм без урамнан әйләнеп керәбез. Матбугат йортына караганда, урамда җылырак шикелле тоела безгә... Әнә шундый авыр шартларда кешенең нәрсәгә сәләтле һәм ни дәрәҗәдә чыдам икәнен ачык күрәсең. А. Гомәр журналга барлык энергиясен салып эшләде.

Сугыш сузылган саен авырлыклар арта бара, кәгазь кытлыгы, типографияләрдәге авырлык, кульязмалар җитмәү һ. б. Өстәвенә, редактор айлар буе чәчү, җыю кампанияләрендә йөри. 1943 елның җәендә типографиядә җыелмыйча, хәрәкәтсез яткан

журналларыбызның саны җидегә тулды. Димәк, җиде ай буе без укучыларга журнал җибәрә алмый тордык. Бу өзеклекне бетерү өчен, билгеле, партия оешмалары күп тырыштылар, ләкин типографиянең көчен сугыш заказларын үтәүдән тыярга кемнең кулы күтәрелсен.

Бу чакта А. Гомәр дә нәшриятка күчерелде. Без башта Әнәс Камал белән калдык, бераздан Ф. Хөсни килеп кушылды.

1943 елның октябрендә миңа тагын бер эш йөкләделәр: редакторлыктан бушатмыйча гына Язучылар союзының җитәкчесе итеп сайладылар. Бер көнне кич белән мине җитәкче итеп сайладылар, икенче көнне Мәскәүгә юл алдык.

Таҗи Гыйззәт, Кави Нәҗми, Нәкый Исәнбәт һәм мин Мәскәүгә китәргә һәм СССР язучылар союзының президиумында Татарстан язучылары союзының эше турында хисап бирергә тиеш идек.

Язучылар союзы президиумында хисап докладын миңа ясарга туры килде. Безнең эшебез мактанырлык түгел иде, шуңа күрә кимчелекләрне һәм аның сәбәпләрен төкми-чәчми сөйләп бирдем. Утырышны Александр Фадеев алып барды. Моңа кадәр ул Казанда ике тапкыр булып киткән һәм безнең хәл белән яхшы таныш иде. Мәсьәләне президиум утырышына кую безгә практик ярдәм күрсәтү, булышу теләге белән эшләнгән иде.

Президиумда ачыктан-ачык, җитди сөйләшү булды. Әйбәт, эшлекле тәкъдимнәр булды. Ләкин Александр Фадеевны мондый сөйләшүләр генә канәгатьләндермәде. Шушындагы сөйләшүләрнең практик нәтиҗәсе булсын өчен ул безне партиянең Үзәк Комитетына алып барырга теләгәнен әйтте.

Икенче көнне Таҗи Гыйззәт, Кави Нәҗми һәм мин Александр Фадеев җитәкчелегендә Үзәк Комитетка юнәлдек.

Үзәк Комитетның пропаганда бүлегендә миңа шактый зур хисап докладысөйләргә туры килде. Татарстандагы әдәби хәрәкәтнең торышы, нәшрият эшләре, язучы кадрларның барысы диярлек фронтның алгы ут сызыгында булуы, аларның солдат хезмәтен үтәү белән бергә, язучылык хезмәтен дә алып баруы турында, үзебезнең бик авыр хәлләрдә эшләвебез турында сөйләдек.

— Уңышлар турында сөйләмим, кимчелекләр турында әйтәсе килә,— дип башлаган идем сүзне. Кызып киткәч, бердәнбер әдәби журналыбызның бик мөшкел хәлдә яшәве турында да сөйләргә туры килде.

Кинәт мине сөйләүдән бүлдерделәр.

— Ничек? Сездә журнал чыгамыни?!

Фадеев мин утырган урындык артында басып тора иде, сорауны аңа да бирделәр:

— Ә сез, Александр Александрович, бу хәлне беләсезме?!

Миңа Фадеевның йөзе күренми, ул һаман бер кулын минем җилкәгә куеп басып тора. Һәм бик гади нәрсәне раслаган төсле, үзенең ягымлы тавышы белән:

— А как же, без җитәклибез! — диде.

Фадеев, чыннан да, бу хәлне белә иде. Шуңа күрә аның сүзе — бу шулай иде, шулай булырга тиеш! — дигән мәгънәдә яңгырады.

Казанда вакытлыча туктаган хәрби эшелоннардан «бер генә дана булса да журнал бирегез» дип килүче офицерлар турында, үзем командировкада йөргәндә, күрше Башкортстан районнарыннан берәр журнал яки китап соратып кеше җибәргән колхоз председательләре турында, редакциягә килгән хатлар турында сөйләдем.

Үзәк Комитеттагы иптәшләр безнең хәлне яхшы аңладылар. Авырлык белән булса да, журналны туктатмыйча чыгарып килүне мактадылар.

— Бу — сезнең подвиг! — диделәр.

Бу мактауны без партиянең Татарстан өлкә комитетының һәм журналда актив катнашучы барлык язучыларның казанышы дип кабул иттек.

Ул чакта журнал өч мең дана басыла иде, бу тираж аның лимиты. Үзәк Комитетта мәсьәләне ачыклагач, безгә сизелерлек ярдәм күрсәттеләр. Үзәк Комитет журналның тиражын ун меңгә (өч тапкырдан артык!) җиткерергә һәм бастыру өчен үз фондыннан өстәмә рәвештә кәгазь җибәрергә булды.

Партиябезнең шундый зур ярдәмен күреп, без яңадан туган кешеләрдәй, канатланып кайтып киттек. Шуннан соң журнал 10 мең тираж белән басыла башлады.

Партия органнарының «Совет әдәбияты» журналын сугыш чорында да саклап калу турындагы карарының әйтеп бетергесез зирәк акыл белән эшләнгәнлеген тормыш раслады. Аның һәрбер саны, кимчелекләре булуга да карамастан, теткәләнеп беткәнче укыла, кулдан-кулга күчә, тылдан бик кадерле бүләк төсендә фронтка юнәлә. Хәрби частьлардан махсус соратып алалар, кичектерми, фәлән-фәлән саннарын җибәрегез дип таләп итәләр, әгәр алар сораган саннар барып җитмәсә, шактый каты шелтәле сүзләр белән хат җибәрәләр.

Минем кулда кайбер хатлар сакланып калган. Г. Галиевнең хатында, мәсәлән, «Совет әдәбияты»ның тышлыгы да миңа якын, аны да окопта калдырып китәсе килми» дигән юллар бар.

«Журналның 11—12 санын алдым. «Кызыл Татарстан»дагы иптәшләр җибәргәннәр. Зур шатлык булды». (Ф. Кәрим. I. VII. 43 ел.)

«Без монда сез җибәргән журналны (№ 5) бик рәхәтләнеп укыдык, һәммәбез дә сезгә чын күңелдән рәхмәт әйттек һәм шул вакытта: «Ах, аның 1, 2, 3, 4 нче саннарын да укысаң иде!» — дип куйдык. (Ш. Маннур. 22. IX. 43 ел.)

«Журналларны берәр данә җибәрсәгез, бик яхшы булыр иде... Без монда Казаннан килгән һәрбер кәгазь кисәгенә балалар шикелле чын мәгънәсендә куанабыз». (А. Шамов. 5. IV. 44 ел.)

«Бүген ишегемнән ике сөенеч бергә йөгереп керде: өйдән — хат, сездән — журнал (7 нче сан).

Журнал килгән көн — бәйрәм көн миңа. Аның битләрендә мин үземнең әллә кайларга чәчелгән иптәшләремне, дусларымны очратып, бер рәхәтләнеп сөйләшеп утырам.

Менә хәзер дә... бөтен эшне ташлап, аның битләреннән куш-аякланып бер чабып чыктым. Бусы беренче танышу, ягъни разведка... Ә менә хәзер ныклап танышырга була. Мирсәй дусның бөтенебезгә мәгълүм озын-озын инверсияләре, Фатих Хөснинең үзе шикелле үк тынгысыз, дәртле, ялкынлы хикәясе, кыю һәм әр-яңа чагыштырулары (кимчелекләрне күрмим мин хәзер!), Маннурның, Ерикәйнең на редкость сөйкемле шигырьләре. Алар монда Азов буйларының караңгы, ләкин җылы ноябрь төннәрендә пычрак сөреп йөри торган Карамалы малаеның күңелен дөрләтеп тә, моңайтып та, әкайвакытны күз яшьләрен дә кыстап куялар...» (И. Гази. 1. XII. 43).

Мондый хатларны без тылдан да ала идек, очрашу вакытларында ишетә идек. Татарстан һәм Башкортстан районнарыннан, Казанга командировкага килгән уңайдан редакциягә кереп, журнал сораучы иптәшләрне кем генә хисапка алган! Алар бик күп иде. Бер вакыт хәтта Сахалин атавыннан килгән бер кыз:

— Мине Сахалиннан җибәрделәр. Безгә журнал кирәк, мин шуның өчен килдем! — диде.

Ул укытучы кызның соравын ничек канәгатьләндермисең...

Шул рәвешчә «Совет әдәбияты» журналы сугыш елларында халыкның юлдашы, сердәше, юанычы һәм куанычы булды. Ул аларны фидакарь хезмәткә, дошманга каршы кыю, әрсез сугышырга рухландырды, илһамландырды. Совет сугышчылары, журналны шинель изүләренә кыстырып, атакага күтәрелделәр, батыр сугыштылар.

Ләкин журналның эше һәр яктан да мактанырлык түгел иде, билгеле. Партия Үзәк Комитетының аталарча кайгыртуыннан соң, билгеле, типографиянең дә, нәшриятның да (журнал Татгосиздат басмасы булып исәпләнә) игътибары көчәйде, шулай да, бердән, соңга калып чыгуны тулысынча бетерә алмадык, икенчедән, эчтәлеген дә әле шактый баетасы бар иде. Язучыларның иҗат активлыгын күрсәтерлек көчләре бөтенесе диярлек фронтта. Казанда булганнары да берничә йөкләмә алып баралар, еш-еш командировкаларга чыгып китәләр. Вакыт-вакыт Казанда бер-ике язучы кала иде...

Фронт белән тыл арасында хатлар, кульязмалар йөри, аларның хәрәкәте хәзергечә житез түгел, шуның өстенә, сугыш вакыты, кешеләр генә түгел, хатлар, кульязмалар да һәлак булгалый... Бу безнең эшне тоткарландыра, кульязмалар җитми...

Сугыш беткәннән соң да озак еллар буе үзен сиздереп торган бер нәрсәне әйтергә кирәк. Татар совет язучылары Бөек Ватан сугышында актив катнаштылар. Рядовойдан башлап полковник дәрәҗәсенә кадәр. Корбаннар да зур һәм онытылмаслык булды: М. Җәлил, А. Алиш, Н. Баян, Г. Кутуй, Р. Ильяс, М. Вәдут, М. Әблиев, Д. Фәтхи, Әгъзам Камал, Х. Мөҗәй, Х. Рахман һәм йөзләрчә яшьләр сугыш кырла-

рыннан әйләнеп кайта алмадылар. Сугыш башланыр алдыннан консультация бюросы 980 яшь автор белән эшли иде. 980 — күбесенчә югары уку йортларында белем алучы яшьләр, алар бик зур дәрт белән язучылык осталыгын да үзләштерә башлаганнар иде. 980 — ул коры сан гына түгел, аларның һәркайсы һич тә булмаса бер шигырь яки хикәя, парча белән матбугат битендә ялтырарга өлгергән, ә шактый өлеше альманах, журналлар битенә күтәрелгән, күмәк һәм аерым җыентыкларда катнашкан яшь, өметле каләм ияләре иде. Берничә елдан аларның кимендә уннан бере татар совет әдәбиятының яңа буын алмашлары булып өлгерәчәкләр иде, мәрхәмәтсез сугыш әле ачылып бетәргә өлгермәгән шул яшь талантларның барысын дип әйтерлек үзенә йотты. 980 кешедән исән-сау әйләнеп кайтучыларның саны биш-алтыдан артмады.

Шушы югалтуның әдәби хәрәкәткә ясаган тәэсире 60 нчы елларга чаклы сузылды. Язучылар союзы членнарының озак еллар буе бер үк санда тирбәлеп торуы да, журналдагы кульязмалар кытлыгы да шул сугыш нәтиҗәсе иде.

Әдәби хәрәкәт ул әледән-әле яңа талантлар агылып торганда җанлы була, күңелле була һәм әсәрләр дә ишәя тора. Яшь, яңа көчләрнең килүе тукталып торса, чишмә чылтыравындагы сагыш моңнары куера башлый.

Сугышта югалтулар нәтиҗәсе буларак, журнал өчен кирәкле кульязмаларны вакытында өлгертү бик читенләшә. Шуңа күрә 40 нчы елларның ахырында, 50 нче еллар башында журнал роман-повестьларны русчадан тәрҗемә итеп бастырды. Зур күләмле тәрҗемә әсәрләрен тулысынча бастыру очраклары редакция портфеленең ярлылыгын раслый.

Сугыш елларында без бу авырлыкны нык сизә идек, тик ул чакта сугыш бетүгә авырлыклар да бетәр шикелле иде. Чынлыкта алай булмады.

Шуның өчен дә сугыш елларында солдат та, язучы да булган иптәшләр алдында аларның хезмәтен олылап баш иясе килә.

**Мин рядовой солдат бу сугышта,**
**Тик бер нәрсәм белән аерылам.**
**Рядовойлар төнен йоклаганда,**
**Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.**
**Бер минут та башка тынгы бирми,**
**Окоп почмагында утырам.**
**Аламын да куен дәфтәремне**
**Янып җыр язарга тотынам.**

Фатих Кәримнең 1942 елда окопта язылган бу шигыре татар фронтовик язучыларының күмәк портретын дөрес сурәтли. Ш. Мөдәррис, Г. Әпсәләмов, А. Шамов, И. Гази, Ш. Маннур, Ә. Еники, М. Садри, Г. Кутуй, Х. Госман, Г. Хуҗи, Ф. Кәрим, С. Хәким, Р. Ишморат, А. Әхмәт, Ә. Исхак кебек фронтовик язучыларның әзлекле ярдәмнәре булмаса, журналны чыгару мөмкин булмас иде. Алардан тыш фронтка вакытлы барып кайткан М. Әмир, Г. Бәширов, Г. Иделле, Ф. Хөсни кебек язучыларның Т. Гыйззәт, К. Нәҗми, Х. Хәйри, Ә. Камал кебек иптәшләрнең көндәлек булышлыклары журналның бер санын да калдырмыйча чыгарып барырга ярдәм итте.

Бу язучыларның шигырьләре, кайнар эзләре буенча язылган очерк, хикәяләре утлы көннәрнең кайнар сулышын беркеп торалар һәм алар елъязма кебек кыйммәтле материаллар.

Югарыда әйтелгән, һәркайсы татар совет әдәбиятына кыйммәтле хәзинә бүләк иткән шушы язучылар исемлегеннән берничәсен аерым күрсәтәсе килә. Юбилей икән, юбилейда кемнәргәдер бүләк тә бирелә, рәхмәт сүзләре дә әйтелә. Әнә шундый рәхмәт сүзләрен минем фронтовик язучылардан Габдрахман Әпсәләмовка, Афзал ага Шамовка юллыйсым, мәрхүм Шәрәф Мөдәррисне иң җылы тойгылар белән күңелдә яңартасым килә. Алар редакция йомышын тиз һәм төгәл башкаруда аеруча житезлек күрсәтәләр иде. Редакция бик өзелгән, бәсарга яраклы әйбер юклыктан йончыган чакларда, шифа булырлык очерклар, фронт хикәяләре, шигырьләр җибәрәләр иде.

Редакция аппаратында эшләүче Фатих Хөсни ул елларда журналның җаны булды. Ул кайнар дәрте белән ачлыкны да, салкынны да сизмәскә тырышып, фронттагы язучыларның барысына да хат язып чыга, редакциягә килгән кульязмаларны тәзәтә, чилә-пешлә материалларны, нерзыларын бәсә-бәсә, әмәлләп утыра, юктан бар ясый...

Фронттагы иптәшенең ышандырган әйберә килеп җитмәгәч, нервы дигәнең тагын тиздерә башлый. Журналның үзе килеп җитми, сүрәнлек күзгә бәрелә һәм Фатих Хөсни, бөтенесенә ачу итеп, бер тын алуда матур, җиңел һәм күңелне рәхәтләндерә торган новелла язып ташлый. Кирәк икән, рецензия яза, мәкалә бирә.

Ялсыз-нисез, көн-төн эштә чабу сәбәпле, мин бик каты авырып киттем. 1945 елны журналның эшен Газиз Иделле җитәкли башлады. Аңардан соң Кави Нәҗми, Афзал Шамов бер-бер артлы редактор булдылар. Мин яңадан редактор булып килгәндә, элекке сотрудниклардан берсе дә калмаган, редакция таркау хәлдә иде. Афзал абый профессиональ язучылык эшенә күчкән, журналның җаваплы секретаре Габдрахман Әпсәләмов шул ук максат белән редакция өстәлен калдырган, поэзия бүлеген җитәкләүче Сибгат Хәким дә иптәшләреннән аерылырга теләмәгән. 1950 елның 3 маенда, редактор буларак эшкә килгәч, мин буш бүлмәләрдән һәм укылмаган хатлардан башка берни дә, беркемне дә күрмәдем.

Мәсьәлә тиз ачылды. Татгосиздат — журналның материаль хәлен кайгыртучы һәм аны басып бирүче хуҗа — нәшриятның аппаратын кыскарту кирәк булган саен, бөтен авырлыкны журнал өстенә салган. Редактор белән җаваплы секретарь урыннары гына сызылмый калган.

Бай традицияле журналның эшен тукталган урыннан кузгатып алып китү өчен яңабаштан аппарат төзергә кирәк иде. Бу эш җиңел бирелмәде. Безгә партия Үзәк Комитеты ярдәм кулын сузды. Һәрбер бүлекнең үз мөдире — үз редакторы эшли башлады.

Кемнәр иде соң алар? Без эшне Булат Гыйззәтуллин һәм Гариф Ахунов белән башлап җибәрдек. Ул чакта бу исемнәр берни дә сөйләмиләр иде. Алар Казан дәүләт университетын яңа гына тәмамларга торалар һәм журналистлык эшеннән бик ерак иделәр. Журнал редакциясе алар өчен яңа бер университет булды.

Мин эшләгән елларда журналда Хәләф Курбатов, Рөстәм Башкуров, Нил Юзиев иптәшләр секретарь булып эшләделәр һәм аспирантура мәктәбеннән соң журналистлык мәктәбе узып, диссертацияләр яклап, гыйльми эшкә юнәлделәр.

Димәк, алар да... Хәер, мактауның кирәге юк. Мәрхүм Р. Башкуров менә дигән хезмәтләр калдырды, Н. Юзиев белән Х. Курбатовның гыйльми казанышлары һичкемдә бәхәс уятмыйлар. Болардан тыш университет аудиторияләреннән журналга килеп эшли башлаган Ләлә Хәйдәрова, Малик Хәмитов, Яхья Халитов иптәшләрнең уңышлы юл узганнарын әйтергә кирәк. Я. Халитов һәм М. Хәмитов инде күптән Язучылар союзына кабул ителделәр.

Әйе, ул еллардан соң бик күп сулар акты, тормышта зур үзгәрешләр булды. Журнал эшендәге уңыш һәм кимчелекләрне җәмәгатьчелек бер генә тапкыр тикшермәде. Ялгышлар да булды, партия органнары аларны төзәтү юлын күрсәтте, аталарча кайгыртучанлык, шелтә һәм мактау сүзләрен дә ишетергә туры килде... Журналның эше дәвам итә, ул бүгенге көн батырларын: химия, нефть, машина төзелеше, Кама автомобиль комплексы, индустриаль колхоз, совхоз, фән өлкәсендәге батырларның бөек рухи дөньяларын яктырту юлында эшли. Моның өчен хәзер өр-яңа буын әдәбиятка агыла. Журнал гасырының икенче яртысын алар дәвам иттерәчәк, тарихны алар тудырачак. Хәерле юл аларга!

Яшәсен яшьлек, ару-талуны белми торган иҗади илһам!

Муса Җәлил

# ПЕДАГОГИЯ УЧИЛИЩЕЛАРЫ ӨЧЕН ТӨЗЕЛГӘН ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН УКЫТУ ПРОГРАММАСЫ ПРОЕКТЫ ТУРЫНДА

Проект нигездә яхшы төзелгән. Ләкин яңадан бер кат карап, дөресләп чыгасы һәм эшлисе урыннары бар.

1. Башлап программаның төзелү принцибы турында шуны әйтергә кирәк:

Программага аңлатмалар бирелгән урында СССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының гражданнар тарихын укыту турындагы карары искә алынып, әдәбият тарихын укытканда да шул принциплардан чыгып эш итәргә кирәклеге әйтелсә дә, программаның үзендә бу нәрсә җитәрлек чагылмаган.

Программа буенча һәр гасырның социаль-экономик шартларына, сыйнфый көрәшкә гомуми характеристика бирелә дә, шушы сыйнфый көрәшнең ничек әдәбиятта чагылуы әйтелә. Әдәбиятны болай гына тикшерү ирекле-ирексез вульгар социологизмга алып барачак. Программаның бу күрсәтүенә таянып, кайбер укытучылар башта шул чорның экономикасын, нинди сыйныфлар булуы һәм аларның көрәшләрен сөйләп чыгып, әдәбиятны һәм аерым язучыларны механик рәвештә шул «гомуми характеристика»га яраштырып бәйләп куячак. Әдәбиятны болай тикшерү зыянлы нәтиҗәгә китереп чыгарырга мөмкин. Шунлыктан программаның бу өлешенә ачыклык кертергә һәм укытучыны ялгыш юлга җибәрмәслек, тулы, ачык төшенчә бирелергә тиеш.

Беренчедән, әдәбиятны һәм һәр язучының иҗатын шул чорның социаль-экономик шартлары, сыйнфый көрәш формалары белән механик бәйләнештә түгел, ә диалектик бәйләнештә тикшерергә кирәк. Ә бу инде әдәбиятны һәм язучыны чорның тулай социаль-экономик торышына туры китереп утыртып кую дигән сүз түгел.

Программада «шул чордагы тормышның һәм сыйнфый көрәшнең әдәбиятта чагылышы» турында гына әйтелә. Ләкин әдәбият тормышның һәм сыйнфый көрәшнең чагылышы гына түгел, ә бер үк вакытта билгеле бер формада шул тормышка һәм көрәшкә тәэсир итүче фактор. Аннан соң, язучы бер сыйныфның бер урында катып калган вәкиле буларак шул чорның социаль-экономик тормышын һәм үз сыйныфының карашын чагылдырып кына тормый, ул үсә, үзгәрә бара. Аның бер позициядән икенче позициягә күчүе, үзен тудырган средага каршы оппозициядә булуы, сыйнфыннан алга китеп, тулай кешелек карашларын чагылдыруы һәм каршылыклы булуы бик

мөмкин. Шуның өчен әдәбият һәм язучы — бик катлаулы объект. Аны тикшергәндә вульгар схемадан сакланырга кирәк.

Икенчедән, программада социаль-экономик шартларга, сыйнфый көрәшкә тулай характеристика бирелүе турында гына әйтелә. Ә шул чорның культура дәрәҗәсе, гомуми культура үсешенең аерым фактлары, сәнгатьнең башка тармаклары турында әйтелми. Әдәбиятны гомуми идеология-культура үсешеннән аерым алып карап булмый.

Мәсәлән, Г. Камалның драматурглык иҗаты турында сөйләгәндә, ничек итеп татарда беренче мәртәбә театр төзелүен, татар театрының үсеш юлын әйтмәскә мөмкин! Татар театрының тууы һәм үсүе — татар культура үсешендәге зур факт. Татар драматургиясенең һәм Г. Камалның иҗат үсешен аннан аерып карап булмый.

XIX—XX йөзләр әдәбиятын тикшергәндә җәдитчелек хәрәкәтенә тукталмыйча һич мөмкин түгел. Мәктәпләргә реформа, яңача укыту методы өчен көрәш, дингә реформа һ. б. татар культура үсешенең аерым тарихи фактлары. Боларга характеристика бирелмәгәндә, К. Насыйри, Муса Акъегет-задә һ. б. роле аңлашылмаячак. Татар яхуд төрек теле турындагы бәхәсләр, 1915 елгы тел ярышы һ. б. фактлар шулай ук әдәбиятка бәйләнгән тарихи фактлар.

Программада әдәбиятны менә шулай конкрет политик һәм культура фактлары белән тикшерү күренми. Шуның өчен программада һәр глава алдында [һәр класс һәм гасыр алдында] стандарт рәвештә кабатлана торган «шул чордагы социаль-экономик шартларга, сыйнфый көрәшкә гомуми характеристика, шул чордагы тормышның һәм сыйнфый көрәшнең әдәбиятта чагылышы» дигән җөмләне ачыкларга, тутырырга кирәк. Укытучылар схематизм юлы белән китмәсеннәр өчен, һәр глава алдында шул чорның характерлы яклары, төп политик һәм культура вакыйгалары әйтелергә тиеш. Әдәби хәрәкәтнең төп характерлы фактлары искәртелергә тиеш.

II. Программада «борынгы әдәбият» дигән главада бары XVII—XVIII йөздәге татар әдәбияты гына кертелгән. Бу нәрсә татарда шуңар кадәр әдәбият булмаган дигән караш калдыруы мөмкин. Шунлыктан, һичшиксез, кыскача гына булса да, бер яки берничә дәрестә XII—XVI йөз (Алтын Орда, Болгар, Казан ханлыгы) әдәбиятына характеристика бирелеп үтәргә тиеш.

III. XIX йөз әдәбияты тикшерелә торган главада татар әдәбияты тарихында зур урын тотучы берничә язучы төшеп калган. Алар: Габделмәних Габдәссәләм, Шәмсетдин Зәки, Курмаши, Фатих Халиди, Шакир Мөхәммәдов.

Бу язучыларның тарихи рольләре бәхәссез зур. Шуның өчен өстәргә кирәк.

IV. XX йөз әдәбияты тикшерелә торган главада шул чорның әдәби фактларын объектив гыйльми тикшерү урынына, тарихка тик беркатлы гына карап, юкка чыгару тенденциясе үткәрелә. Бу урында югарыда әйтелгән вульгар социологизм элементлары үзләрен сиздерәләр. Мәсәлән, бу чор әдәбиятта зур урын тоткан Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд кебек язучылар беренче вариантта бөтенләй төшерелеп калдырылганнар. Аннан соң кара белән генә, тырнаклар эчендә генә «укытучы Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд әсәрләреннән үрнәк алып кына күрсәтә» дип өстәлгән. Ягъни аларның контрреволюциягә баручы, реаль тормышны бозып күрсәтүче либераль буржуа язучылары булуларына мисал рәвешендә генә искә алырга тәкъдим ителә. Ә иҗатларын тикшерү бурыч ителми.

Бу — дөрес түгел. Идеологик карашлары, сыйнфый эчтәлекләре белән бу язучылар демократик язучылардан нык аерылдылар һәм буржуазия карашларын үткәрделәр. Ләкин алар шул ук вакытта зур мастерлар һәм эре художниклар. Эре художник буларак, алар татар әдәбиятының үсешендә зур роль уйнадылар. Алар шулай ук контрреволюциягә [...] киткән язучылардан да аерылалар.

Шунлыктан XX йөзнең буржуа карашлы булган бөтен язучыларын барысын да бер себерке белән себереп түгү дөрес түгел. Программаның бу өлешен төзәтү кирәк. Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, Н. Думави, Укмасый, С. Рәми кебек язучыларның иҗатлары тикшерелергә, аларның идеологик содержаниеләре әйтелү белән бергә, әдәбияттагы объектив урыннары, эре художник буларак, объектив рәвештә ул чорның төп характерлы якларын үзләренчә чагылдырмый үтә алмаулары күрсәтелергә тиеш.

V. Демократик язучыларның стильләре турында «критик реализм» диелә. Бу беркатлы бәя бирү булачак. «Реализм» дип әйтергә кирәк.

VI. Октябрь революциясенә кадәр әдәбият тикшерелгәндә, ни өчендер, М. Гафуриның 1917 нче елга кадәрге иҗаты гына алына да Г. Камалның революциядән соңгы иҗаты да алына. Аңлашылмый. Дөресе, Г. Камал да, М. Гафури кебек, ике дәвергә бүленеп тикшерелергә тиеш иде.

VII. М. Гафуриның «Ярлылар», «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» кебек характерлы прозалары ни өчендер кертелмәгән.

VIII. Г. Камалның «Банкрот», «Беренче театр» кебек иң характерлы, көчле комедияләре кертелмәгән. Г. Камал — комедия жанрының атасы һәм остазы. Бу яктан бу ике әсәр бик характерлы.

IX. Г. Тукайның халык иҗатыннан өйрәнүен һәм халык иҗаты өстендә эшләвен характерлый торган әсәрләре «Шүрәле», «Су анасы», «Таз» аның иҗаты тикшерелгән бүлеккә кертелмәгәннәр. Бу әсәрләр, балалар әсәре булудан бигрәк, халык иҗаты нигезендә туган әсәрләр булу ягыннан кыйммәтле. Г. Тукайның халык иҗаты белән бәйләнешен киңрәк ачарга һәм мисаллар бирергә кирәк. Шулай ук Г. Тукайның мәхәббәт һәм эчке кичерешләр лирикасы да кертелмәгән. Шулай итеп, Г. Тукай бер яклы гына — нәфрәт шагыйре булып кына тикшерелә.

X. Ш. Камалның 1917 елга кадәр иң көчле әсәре булган «Акчарлаклар» һәм «Козгыннар оясында» кертелмәгән, 1917 елдан соңгы бүлектә «Таң атканда» төшеп калган.

XI. Октябрьдан соңгы әдәбиятка ясалган керештә Ленин милли политикасының җиңеше, СССР халыкларының бөек дуслыгы, бөек рус халкының татар культурасын үстерүгә ярдәме турында һәм татар әдәбиятының интернационализм рухы белән сугарылуы, бөтен совет әдәбиятының бер кисәге булуы турында тулы әйтергә кирәк.

XII. Октябрьдан соңгы татар әдәбияты программада тәртипсез һәм бик сыек бирелә.

Беренчедән, ул дәверләргә бүленмәгән. 1919—20—23 нче елларда эшләгән һәм танылган язучылар 1932—35 елларда чыккан язучылар белән бергә буталып йөртеләләр. Икенчедән, әдәбият совет эпохасының тарихи дәверләренә һәм политик вакыйгаларына бәйләп тикшерелми. Программаның бу өлеше гомумән татар совет әдәбияты үсә диган бер гомуми фразадан гына гыйбарәт. Өченчедән, татар совет әдәбияты тарихында һичшиксез билгеле урын тоткан язучылар төшеп калганнар. Мәсәлән, М. Гали, Ф. Бурнаш, М. Әмир, Х. Туфан, С. Баттал, Г. Кутуй, Н. Исәнбәт, А. Шамов һ. б. Программаның бу өлешендә ниндидер куркаклык, перестраховка сизелә. Совет әдәбияты турында авыз тутырып әйтергә курку сизелә.

Минемчә, программаның бу өлешен яңадан төзергә кирәк. Татар совет әдәбияты һәм татар совет язучылары турында курыкмый, ачык, тулы әйтергә вакыт инде. Моның өчен һәр язучыны укып, яхшы белергә, мәйданга чыккан көннән алып, җентекләп тикшерергә, иҗат юлын белергә кирәк. Шулай белеп тикшерелсә, «имеш-мимеш» сүзләргә карап кына эш ителмәсә, программаны тулы төзергә мөмкин булган.

Октябрьдан соңгы әдәбият бик төрле һәм катлаулы. Язучылар барысы да бер төсле түгел. Төрлесе төрле иҗат юлы үттеләр. Төрлесе төрле чорда күтәрелделәр, төрле темага яздылар.

Шуның өчен аларны дәверләргә бүлеп, конкрет тарихи фактлар белән бәйләп тикшерергә кирәк. Мәсәлән, һ. Такташ, М. Максуд, Ф. Бурнаш, Г. Кутуй, М. Җәлил 1919—1923 ел чорында күтәрелеп чыккан язучылар булса, Ш. Маннур, Т. Гыйззәт, Н. Баян, М. Әмир, Ә. Фәйзи, И. Гази, Х. Туфан һ. б. 1924—1929 еллар арасында, Ф. Хөсни, Р. Ильяс, С. Хәким, Г. Хуҗи һ. б. шуннан соңгы елларда күтәрелделәр. Һәр чор үзенең билгеле эзен калдырды. Инде Г. Кутуй әдәбиятта футуризм-формализм мотивлары белән чыгып әкренләп үзгәрә килсә, Ф. Бурнаш, Н. Исәнбәт шулай ук икенче төрле йогынтылар аша — романтизмнан килделәр. Башкаларның шулай ук үз юллары бар. Совет әдәбиятын тикшерү тирәнрәк нигезгә корылырга тиеш.

XIII. Программада тәнкыйть һәм татар тәнкыйтьчеләре турында бер сүз дә юк. Революциягә кадәр татар әдәби тәнкыйтенә нигез салган Халфиннар бөтенләй төшеп калган кебек, совет тәнкыйтьчеләре К. Гази, Г. Халит, Х. Хәйри, Л. Җәләйләр турында да бер сүз дә юк.

XIV. СССР халыклары әдәбиятының эре вәкилләре тикшерелгәндә Белоруссиянең халык шагыйрьләре Янка Купала, Якуб Колас никтер төшеп калганнар.

**Минем программага карата ясый торган искәрмәләрем шушы. Тагын шуны әйтергә кирәк:**

**Программаның аңлатмалар өлешендә берничә мәртәбә «эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли әдәбият» дип кабатлана. Ләкин аны коры кабатлау — эш түгел [...]**[1]

**Эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культура конкрет рәвештә әдәбиятта нинди төстә, ничек чагыла! Совет әдәбиятының милли формасы нидән гыйбарәт, социалистик эчтәлеге нидән гыйбарәт! Менә шуны конкрет өйрәнү, тикшерү — безнең бурыч.**

**Кыскасы, әдәбиятны өйрәнү гыйльми, тарихи тирән нигезләргә корылырга тиеш.**

Татарстан Совет язучылары союзы
правлениесенең җаваплы секретаре М. Җ ә л и л.

РЕДАКЦИЯДӘН:

Бу документны күптән түгел генә СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел-әдәбият һәм тарих институты архивыннан КДУ аспиранты Ф. Мостафин табып алды.

---

[1] Документ кайбер кыскартулар белән бирелә. Кыскартылган урыннарга квадрат җәяләр куелды.

Асия Гыйниятуллина

# БӘХЕТЛЕ ЯЗМЫШ КЕШЕЛӘРЕ

## Алатауга карап...

Алма-Ата шәһәрендә, Абай проспектында урнашкан йортларның берсендә, Суфия апа Агеева яши. Ул — татар пролетариат әдәбиятына нигез салган Гафур Коләхметовның исән калган бердәнбер туганы — кече сеңелесе. Без аның белән бик тиз араца танышып, бер-беребезгә тәмам ияләнеп, хәтта дуслашып та өлгердек. Суфия апа йортында уздырылган өч көн, өч төн сизелми дә үтеп китте. Чын әдәби әсәрләрне йотлыгып укыган кебек, Суфия апа сөйләгәннәрне дә бирелеп тыңладым. Сәламәтлеге какшаган булса да, хәтере — яшьләр көнләшерлек.

Суфия апаның Казаннан китүенә кырык биш ел инде. Бер кеше гомере! Ләкин аның бөтен күңеле Казан, аның узганы, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйле. Ул шәһәребезнең, республикабызның үсеше, киләчәге, аның яшь кешеләре, татар әдәбияты, сәнгате, культурасы белән якыннан кызыксына, һәр нәрсәне бертекләп сораша, зур яңалыкларга, уңышларга куана.

Суфия апага без Татарстан язучылары союзы идарәсеннән, язучылардан күп сәламнәр, тәбрик хатлары, Гафур Коләхметовның тууына 90 ел тулу уңае белән уздырылган фәнни конференциягә, тантаналы кичәгә һәм юбилейга кагылышлы башка материаллар басылып чыккан республика газеталарын алып бардык. Бу истәлекле бүлекләрне Суфия апа бик зур дикъкать белән карап чыкты да:

— Бу искиткеч, йөрәк тетрәткеч,— диде.

Йөрәктән әйтелгән бу сүзләр әдәбият белгечләренә, язучыларга, әдәбият сөюче киң җәмәгатьчелеккә белдергән зур рәхмәт булып та ишетелде.

Көне буе диярлек Суфия апа кухнядан чыкмый. Башта мин моңа бик гаҗәпсендем. Ләкин сере бар икән аның: кухня тәрәзәсе Алатауга карап тора. Тауның ап-ак түбәләре



*Суфия апа Коләхметова-Агеева.*



*Гафур һәм Әмин Коләхметовлар, Гайшә Шәрипова.*

күк белән тоташкан сыман. Суфия апа шул Алатау түбәләренә, ишек алдындагы мул яшеллеккә карап ял итә, укый, яза, уйлана, чәй эчә...

— Суфия апа, бәлки, сездә Гафур абыйның әле моңарчы матбугатта басылмаган берәр фоторәсеме бардыр?— дип сорыйм мин аннан.

— Бер рәсем күрсәтә алам. Гафур абыйның сәламәтлеге нык какшаган көннәрдә, 1916 елның 14 августында төшкән соңгы рәсеме.

Суфия апа үзенең йокы бүлмәсеннән кухняга бер төенчек алып чыкты һәм ярым шаяру белән:

— Монда минем канцелярия,— диде һәм төенчектән Гафур Коләхметовның фотосын алып күрсәтте. Монда ул бер туган сеңелесе Шәмсекамәрнең кызы Гайшә һәм кече энесе Мөхәммәтдәмин белән төшкән. Туганнары һәм иптәшләре аны Әмин дип йөрткәннәр. Ул Хөсәен Ямашев һәм Гафур Коләхметов җитәкчелек иткән революцион оешманың Астраханьдагы махсус элемтәчесе булган. Ә Гайшә Шәрипова язучы-журналист. Күп еллар «Правда» газетасының сотруднигы, күп санлы хикәяләр, очерклар һәм «Гафур семьясы» дигән романның авторы.

Суфия апа белән без, җиренә җиткереп, ләззәтләнеп, сөйләшә-сөйләшә чәй эчәбез. Әмма Суфия апа сүзгә ифрат саран. Хәтерендә сакланган бай истәлекләрнең иң кирәклеләрен генә сайлап, бик үлчәп сөйли ул.

Чәй янында мин Суфия ападан үзенең узган тормышы, хезмәт юлы, замандашлары турында сөйләвен үтендем. Суфия апа исә үзенең «канцеляриясеннән» шактый таушалган бер калын кәгазь алып бирде һәм:

— Мин тагын бер касә чәй эчкән арада сез шушы документ белән танышып алыгыз, минем хезмәт юлым шул кәгазьгә бәйле,— диде.

1915 елның 22 апрелендә бирелгән 11418 номерлы диплом иде бу. Суфия апа 1908—1913 елларда Петербургта хатын-кызлар өчен махсус оештырылган медицина институтында укыган, 1914 елда барлык имтиханнарны тапшырган.

Диплом алган көннән башлап, Суфия апа, кырык ел дәвамында, татар, чуваш, мордва, мари, коми халыклары арасында врач булып эшли. Революциягә кадәрге Россия шартларында ул зур кыенлыклар, кыерсытулар күрә. Шулай булса да үзенең врач намусына тап төшерми, гадел, фидакарь хезмәте белән кешеләрнең тирән хөрмәтен казана.

— Суфия апа, сез укытучы да булгансыз дип ишеткәнем бар. Больницадан эшләп кайткач, төрле милләт балаларына рус телен өйрәткәнсез икән.

— Укыту эшендә миңа ирем ярдәм итте,— диде Суфия апа.— Фәхрелислам укытучы да, журналист та иде. Себердән Казанга кайткач, ул Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Гафур абый белән якыннан аралаша. Фәхрелислам рус телен, рус әдәбиятын бик әйбәт белә иде. Казанга кайткач, татар әдәбиятын яхшылап өйрәнде. Безнең семья белән ул мин Казанда гимназия тәмамлаган елны, 1908 елның җәй башында аралаша башлады. Аны Гафур абый белән иң башта Фатих Әмирхан таныш-

тырган. Шул танышудан ул Гафур абыйның якын дусты булып китә. Аннары ул безнең өйгә бик еш килеп йөри башлады. Ул вакытта минем бар уем укуны дәвам итү, врач профессиясен алу иде. 1908 елның көзендә Петербургка киттем, институтта укый башладым. Шул чорда Фәхрелислам барлы-юклы эшләп алган акчасын миңа җибәреп торды, ара-тирә Фатих абый Әмирхан да ярдәм итеп куя иде. 1914 елда без өйләнештек, 1915 елда улыбыз Үзбәк туды. Шулай итеп, семья тормышы башланып китте. Бу елларда Фәхрелислам, башлангыч татар мәктәбендә рус теле укыту белән бергә, балалар өчен үзе чыгара башлаган «Ак юл» журналында эшли, аңа Хәсни Кәрим, Шәһид Әхмәдиев, Зыя Ярмәки, Нәкый Исәнбәт һ. б. ярдәм итәләр иде. Ә мин Казанның әүвәлге Московский урамындагы татар хәрби госпиталендә Әбүбәкер Терегулов белән эшли идем. Икебезнең дә иҗат планнарыбыз зур иде, тик аларны безгә тормышка ашырырга туры килмәде. 1915 елның кыш айларында патша жандармериясе полковнигы безне, ягъни Агеевлар семьясын, бер тәүлек эчендә Казаннан сөрде. Моңа сәбәп итеп, Фәхрелисламның 1915 елда «Ак юл» журналында басылган «Ана җыры» исемле шигырен күрсәттеләр. Янәсе, Фәхрелислам халыкны патша хөкүмәтенә каршы баш күтәрергә өнди.

Фәхрелислам журналны Г. Шәрәфкә тапшырды һәм без Пенза губернасының Татар Енәсе авылына күчеп киттек. Шул елдан 1937 елга кадәр мин врач булып, ә 1937 елдан Тарбеев район больницасында (Мордва АССР) баш врач булып эшләдем. Фәхрелислам шушы Тарбеев районында укытты, инспектор булып эшләде, соңыннан аны Мәскәүгә чакырып алдылар һәм Мәгариф халык комиссариатына татар секциясе мөдире итеп билгеләделәр. 1937 елны ул яңадан Тарбеев районына кайтты, РОНО мөдире булып эшли башлады...

1938 елны мин Коми АССРга киттем. Ә Фәхрелислам Ак диңгез — Балтик каналына эшкә җибәрелде һәм шунда вафат булды. 1948 елда, Гайшә чакыруы буенча, Алма-Атага килдем. Шул көннән бирле биредә яшим, персональ пенсия алам.

Гафур абый соңгы көннәрен Татар Енәсендә, безнең йортта, безнең семьяда уздырды. Ул минем улым Үзбәкне бик ярата иде. Гафур абый Фәхрелислам белән сөйләшеп, киңәшеп утырырга ярата иде. Фәхрелислам Гафур абыйның кулъязмаларын укый, аларны тәртипкә сала иде. Ул көннәрне, Гафур абыйның сәламәтлеге начар булуга карамастан, уен-көлке, шау-шу белән бик күңелле итеп үткәрдек. Гафур абыем өчен май, каймак, сөт кебек ризыкларны ничек кенә булмасын, мин табарга тырыша идем.

Әмма Гафур абыйның хәле начарланганнан начарланды, ул 1918 елның 1 августында вафат булды.

Хәзерге Тарбеев районына кергән авыл кешеләре Гафур абыйны соңгы юлга заманына, вакытына күрә зурлап озаттылар. Абыйның кабере — Татар Енәсендә (Татарские Юнки). Йөрәгем хәзер дә бер нәрсәгә каты әрни: Татар Енәсеннән киткәннән бирле Гафур абыйның шактый кулъязмалары юкка чыкты. Аларның язмышын белмим. Ничек кенә эзләп карасак та, әлегә безнең аларны таба алганыбыз юк. Кем белә, Мордва АССРның, я булмаса Пенза шәһәренең дәүләт архивларында, аларның әле хәзергә бик тулы тикшерелеп бетмәгән материаллары, документлары арасында, безнең Гафур абыйның да кулъязмалары бардыр...

Төшке аштан соң без Суфия апа белән әңгәмәне дәвам иттек. Ул миңа Хөсәен Ямашев турындагы истәлекләрен сөйләде.

— Хөсәен кече күңелле, гади, һәркемгә ярдәм кулын сузарга торган кешелекле кеше иде. 1902 елны Гафур абый да, Хөсәен дә Казанда Учительская школаны тәмамлап чыктылар. Хөсәен барлык имтиханнарын «Отлично» билгесенә тапшырган иде. Чыннан да ул зур һәм тирән укымышлы, киң эрудицияле, рус, Европа культурасын яхшы үзләштергән егет иде. Шигырьне бик оста сөйли иде. Рус телен яхшы белү белән бергә, инглиз, француз телләрендә бик күп шигырьне яттан белә иде. Ул Гафур абыйны бик яратты, аны үз итте. Гафур абый белән киңәш-табышлары, укулары, язу-сызулары, дусларын җыеп сөйләшүләре, күп очракта, безнең йортта була торган иде. Хөсәен миңа да бик ошый иде. Буй-сыны тәз, төс-бите чибәр, әмма кубрәк үзе турында түгел, башкалар турында кайгырта иде. Безнең Гафур абый конспирация эшләрен бик оста өештырә, листовкалар чыгара, тәрҗемә эшләрен җиңел

башкара торган булган. Шуңа күрә аны иптәшләре, бигрәк тә Хәсәен, күз алмасыдай саклыйлар иде.

Хәсәеннең гомере, кызганычка каршы, бик кыска булды. Казан университетының соңгы курсында укыганда, китап кибетендә хатыны Хәдичәгә бүләк итәр өчен дип граммофон пластинкалары сайлап торган чакта ул кинәт үлә. Бу 1912 елның 13 марты була. Мин аның гәүдәсен анатомировать итүдә катнаштым. Шул чагында баштан нинди генә уйлар, күз алдыннан нинди генә кичерешләр, күренешләр узмады?!

— Суфия апа, сез Габдулла Тукайны да якыннан белә идегезме?

— Тукайны бик якыннан белә идем дип әйтә алмыйм. Шулай да, аның кайбер гореф-гадәтләре хәтердә сакланган. Ул Фәхрелислам белән якын дус иде. Бу дуслык Тукайның соңгы көннәренә кадәр дәвам итте. Әмма ул миннән уңайсызлана, тартына иде. Әгәр безгә килəсе булса, иң башлап, телефоннан шалтырата:

— Ислам, бүген Суфияны аналарына озат әле, мин сиңа кич утырырга бармакчы булам,— дип хәбәр итә иде.

Нишлисең, Тукайны үзем каршы алып, үзем зурлап хөрмәт итәсем, аның белән сөйләшеп утырасым килсә дә, зур шагыйрь безгә киләсе көнне әниемә китеп бара торган идем шул. Кай очракларда, анда качып, монда посып, өйдә калган чакларым да булгалады.

Тукайның буе-сыны, тышкы кыяфәте, киеме-салымы, үзен бик гади тотуы бер дә зур шөһрәт казанган олы шагыйрь диярлек түгел иде. Тыйнаклыгы турында әйтәсе дә юк инде.

Тукай белән Фәхрелислам сәгатьләр буена сөйләшеп утыралар иде. Шагыйрьнең кайнар пәрәмәч белән чәй эчәргә бик яратканын белгәнгә күрә, мин барысын алдан хәстәрләп куя идем. Мин әниләргә киткәч, уртак фикерләре күп булган ике ир, озаклап, хәтта самоварны әледән-әле яңартып чәй эчкәннәр.

Тукайны мәңгегә югалттык. Бу безнең семья, Гафур абый өчен генә түгел, барлык татар халкы өчен тирән фаҗига булды. Без, алдынгы татар хатын-кызлары, яраткан, үз иткән шагыйребезне соңгы юлына хөрмәт белән озату өчен кирәкле барлык эшләрне башкардык. Халыктан акча җыеп, табут өстенә ябар өчен зур кара хәтфә сатып алдык, аны кирәгенчә кисеп, кырыйларын ак ефәк лента белән тоташтырып тектек. Бөек шагыйрьне күмү барлык татар дөньясында, аның культура тормышында моңарчы күренмәгән гаҗәеп демонстрациягә әверелде. Казан урамнары, йорт аллары, капка, агач, киртә башлары, тәрәзә төпләре Тукайны соңгы юлына озатучылар белән шыгрым тулы иде. Безне, хатын-кызларны, зират капкасы төбендә калдырдылар, янәсе, шәригать кушмый. Буйсынмый нишлисең!

Гафур абый белән Фәхрелислам — Тукайны гүргә иңдерүчеләр, аның өстенә иң беренче бер уч туфрак салучылар...

28 май көне Суфия апа өчен аерата истәлекле көн булды. Бу көнне аның янына кадерле кунак — Казахстан язучыларының VI нчы съездына һәм бөек Абайның юбилей бәйрәменә Татарстан язучыларының вәкиле итеп җибәрелгән Хәсән ага Туфан килде. Өйгә керү белән, Хәсән ага, роза чәчәкләренең зур бәйләмен күкрәгенә куеп, Суфия апаны сәламләдә һәм бүләкне аның кочагына салды. Суфия апаның йөзе яктырып, шатлык нурлары белән балкып китте...

## Гайшә Шәрипова йортындагы хәзинә

Кояш Байсеитова урамы. Куе, бөдрә яфраклы агачларга тәмам күмелгән үзәк урамнарның берсе. Әмма Алма-Атага яңа килгән кешегә бу урамдагы кирәкле йортны табып алу ускиткеч кыен икән, чөнки йортлар тротуардан бик эчкә кертеп салынганнар һәм үзләрен чолгап алган агачлар арасыннан аларның хәтта түбәләре дә күренми. Шул урамдагы ике катлы таш йортта Гайшә апа яшәгән. Хәзер анда Гайшә

апаның кызы Асия ханым, аның ире һәм аларның ике уллары яши. Гайшә апа үлгәнгә ике ел булса да (ул 1969 елның 9 июлендә йөрәк авыруыннан кинәт вафат булган), аның эш кабинеты, нәкъ үзе исән чагындагыдай, һәркемнең игътибарын үзенә җәлеп итә, әйтерсең язучы, үзе иялашкан зур язу өстәле артында эшләп утыра, әйтерсең ул соңгы җөмләсен язып бетерү белән, матур елмаеп, безнең янга зур бүлмәгә чәй эчәргә чыгар кебек...



*Гайшә Шәрипова.*

Тәрҗемәче, язучы һәм журналист Гайшә апа Шәрипова татар әдәбияты тарихына, иң элек, Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен русчага тәрҗемә итүче булып керде. Ул бу эшен Галимҗан Ибраһимовның үзе белән иҗади элемтәдә, аның даими күзәтүе астында башкарган. Егерменче елларда алар үзара күп кенә хат язышканнар. Гайшә апа архивында Галимҗан Ибраһимовның ике дистәдән артык хаты саклана икән.

Алма-Атада ике мәртәбә рус телендә басылып чыккан «Гафур семьясы» исемле роман (соңгы басмасы 1969 елда басылып чыга) союз укучылары арасында популярлык казанды. Бу тарихи-этнографик әсәрнең авторы, югарыда әйткәнебезчә, Гафур Коләхметовның туганнан туган сеңелесе (Гафур абыйның аерата яраткан уртанчы сеңелесе Шәмсекамәрнең бердәнбер кызы) Гайшә апа Шәрипова. Бу әсәрне тулыландыру, эпик планда киңәйтү өстендә Гайшә апа армый-талмый эшләгән, гомере буена шул әсәре өчен тарихи-документаль материал җыйган. Гафур абый замандашларының, шул исәптән Суфия апасының истәлекләрен язып барган... Архивтагы материаллар арасында Суфия апаның Фәхрелислам Агеев турында сөйләп яздырган истәлеге дә сакланган булырга тиеш. Гайшә апа озак еллар буе Агеев һәм ул яшәгән чор, аның белән аралашкан кешеләр турында зур тарихи әсәр язарга уйланып йөргән һәм менә шул яңа әсәргә тотынам дигәндә генә, кызганычка каршы, вафат булган.



*1912 елда Гафур Коләхметовка якын иптәшләре тарафыннан бүләк ителгән сәгать.*

Гайшә апаның истәлекле әйберләре арасында имән тартмага салган сәгать бар. Аны 1912 елның сентябрендә Фатих Әмирхан, Галимҗан Шәраф, Хәдичә Ямашева һ. б. Гафур Коләхметовка аның укытучылык эшчәнлегенә ун ел тулу уңае белән бүләк иткәннәр.

Асия ханым семьясында кызыклы материаллар, тарихи документлар күп саклана. Аларның һәрберсе турында бер утыруда гына язып бетереп булмый. Шулай да тагын бер мәсьәләгә тукталасы килә.

Совет әдәбияты милли әдәбиятларның үзара иҗади бәйләнешләре, язучыларның үзара иҗади элемтәләре нәтиҗәсендә үсә, киңәя. Бу өлкәдә мәрхүмә Гайшә Шәрипова да күп көнә язучыларның әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп, аларны зур дөньяга чыгарган булган. Ул тәрҗемә иткән әсәрләр арасында Мохтар Ауэзов, Сакен Сәйфуллин, Сабит Муканов, Габидин Мостафин һәм башка күренекле казакъ, татар, рус язучыларының әсәрләре бар. Алар барсы да Гайшә апага йөрәктән әйтелгән сүзләр язып, китапларын бүләк иткәннәр. Автограф белән Гайшә апага бирелгән китаплар арасында Шәриф Камал, Мәхмүт Галәү һәм башка күренекле татар язучыларының да истәлекле басмалары бар. Гайшә апа йортында сакланган автографлы китаплар үзләре генә дә әдәбият тарихы, әдәбият музейлары өчен зур хәзинә.

## Зөлфия

Ташкентка барырга әзерләнәм: тугандаш үзбәк халкының сәнгатенә, әдәбиятына кагылышлы китаплар, белешмәләр, күренекле язучыларның иҗатлары, яңа әсәрләре белән танышам.

Рәхмәт инде язучы иптәшләргә. Габдрахман Минский миңа дусты Әсгат Мохтарның «Чинара» исемле яңа әсәрен укырга бирде. Халык иҗатына таянып язылган бу әсәр күңелдә тирән эз калдырды. Үзбәкстанда туып-үскән, шунда укыган, язучы булган Әсгат Мохтар, милләте буенча татар булса да, үзбәк әдәби телен, үзбәк халкының рухи байлыгын, аның гореф-гадәтләрен, бай традицияләрен искиткеч тирән һәм яхшы үзләштергән. Шуңа күрә дә аның һәр әсәрен үзбәк халкы укучылары алкышлап каршы ала.

Хәсән абый Туфанның Үзбәкстанда каләмдәш дуслары күп булуын яхшы белә идем. Ул миңа әманәт биреп җибәрде. Бер томлык сайланма әсәрләренең титул битенә ул түбәндәге юлларны язып бирде:

**«Ничек икән синең йөрәк! — дисәң,**
**Ничек икән гомер көннәрең! —**
**Кулымдагы китабымда, Уйгун,**
**Шигырьләрдә — минем йөрәгем.**

Үзбәк әдәбиятының аксакалына, мөхтәрәм Уйгунга, самими сәлам белән Хәсән Туфан». Икенче китабын Хәсән абый күренекле үзбәк шагыйре Миртимергә бүләк итеп тапшыруымны үтенде.

Үзбәк дусларга тапшырасы изге әманәтләр күп җыйналды. Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Зәки Нури, Ренат Харисов үз әсәрләрен Алишер Навои исемендәге Үзбәкстан Дәүләт китапханәсе укучыларына бүләк итеп җибәрделәр. Мин Ташкентта 1947 елда булган идем. Егерме дүрт ел эчендә шәһәр танымаслык булып яңарган. Урамнары, бакчалары, һәйкәлләре, культура сарайлары, торак йортлары, хәтта кешеләре — барысы да яшәргән төсле күренде.


Иң башлап үзбәк хатын-кызлары өчен чыгарыла торган «Саадат» журналына кердем. Аның редакторы — Үзбәкстанның халык шагыйре Зөлфия. Аның бер бәйләм шигырьләре Нури Арсланов тәрҗемәсендә «Казан утлары» журналында басылып чыккан иде. Зөлфия белән шул шигырьләр турында сөйләшеп утырдык. Татар телен яхшы белә, татар теленә тәрҗемә ителгән үз әсәрләрен җиренә җиткереп укый. Зөлфия тәрҗемәнең сыйфатына яхшы бәя бирде, Нури Арслановның үз иҗаты белән кызыксынды.

Зөлфия белән мин берничә мәртәбә очраштым. Һәр очрашудан, әңгәмәдән соң шагыйрәгә карата ихтирамым арта барды. Беренчедән, ул — хатын-кыз буларак бик күркәм. Аның буй-сыны зифа, йөзе сөйкемле, ягымлы. Икенчедән, Зөлфия-

нең эчке культурасы бай, белеме тирән, эрудициясе киң. Аның белән сөйләшеп утыру ифрат кызыклы: ул күп илләрдә, күп җирләрдә булган, күп язучыларны, сәнгать эшлеклеләрен якыннан белә. Аңа татар әдәбияты һәм культурасы да яхшы таныш.

— Мине башлап хәреф танырга, язарга өйрәткән укытучым татар иде. Каләмемне башлап тибрәтергә дулкынландырган кеше Тукай булды,— ди Зөлфия.

Һади Такташ, Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Гадел Кутуй, Муса Җәлил иҗатлары белән дә Зөлфия яхшы таныш. Аның ире, үзбәк халкының танылган шагыйре, Хәмид Алимҗан Һади Такташны яхшы белгән, Хәсән Туфан белән дус булган. Үзбәк шагыйренең түбәндәге әсәрендә Һади Такташ белән Хәмид Алимҗан иҗатларының үзара бәйләнешләре ачык күренә.



Зөлфия.

**ХӘМИД АЛИМҖАН**

*«Мәхәббәт*
*Ул үзе иске нәрсә,*
*Ләкин*
*Һәрбер йөрәк аны яңарта»...*

*ҺАДИ ТАКТАШ*

**Һәр йөрәкнең бер кояшы бар,**
**Һәр йөрәкнең гыйшык кунагы,**
**Һәр йөрәктә үрелеп мәхәббәт**
**Чәчәк ата, булып гөл багы.**

**Ләкин гүзәл Ләйлә язмышы —**
**Кара көннәр безгә ят бүген;**
**Һәм безгә ят Ширин бәхетен**
**Каплап алган кара шомлы төн.**

Зөлфиянең үз иҗаты да мине бик күптәннән дулкынландыра иде. Инде шагыйрәнең үзен күреп сөйләшкәч, аның иҗаты белән тагын да якыннанрак таныштым. Бүгенге көндә аның әсәрләрен туплаган 43 китабы бар. Үзбәкстанда, Мәскәүдә, илебезнең бик күп республикаларында, өлкәләрендә, чит илләрдә — унсигез телдә басылып чыккан.

Зөлфия Казанда ике мәртәбә булган: үзбәк сәнгате һәм әдәбияты декадасына һәм «Азат хатын» журналының кырык еллык юбилей бәйрәменә катнашкан.

— Татарстанда яшәүче якын дусларымны сагындым. Алар янына тагын барыр идем әле,— ди ул.

## Ул Такташны әти дип йөргән

Ташкент хәтле Ташкентка баргач, ничек инде Һади Такташ белән аралашкан кешеләрне, шагыйрьнең замандашларын эзләп тапмаска, алар белән күрешеп сөйләшмәскә? Кызганычка каршы, өлкән буын кешеләре бер-бер артлы бу фани дөньяны ташлап китәләр. Һади Такташны күреп белгән, аның белән аралашкан кешеләр дә азайганнан-азая бара инде.

Егерменче елларда Такташ белән аралашкан кешеләрнең берсе — карт журналист, 1927 елдан коммунистлар партиясе члены Шәриф Булатов. Ул Башкортстанның Балыклы авылында туган. Бала чакта ук ятим калган, ачлыкка интегеп, ят киеменә тилмереп буй җиткергән, бөтен тормыш авырлыкларын бер читкә куеп, ничек кенә булса да укырга тырышкан, аң-белемгә омтылган. Акмулла, Каюм Насыйри, Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал һәм башка бик күп күренекле татар язучыларының әсәрләре Шәрифнең иң яхшы киңәшчеләре, аерылгысыз тормыш юлдашлары булганнар. Тәлгерәк белем алу нияте белән Шәриф Оренбургка килә. Биредә ул Муса Җәлил белән бер мәктәптә укый, 1919 елда, Муса белән бергә, Ленин комсомолы сафына керә. Шул елны Шәриф «Хөсәения» мәдрәсәсе бинасында совет хөкүмәте тарафыннан көнчыгыш яшьләре өчен оештырылган кыска вакытлы курсларда укый, анда даими үткәрелә торган әдәби кичәләргә, концертларга, спектакльләргә актив катнаша.

Шәриф Һади Такташ белән 1919 елның ахырында таныша һәм алар бик дуслашып китәләр. Шагыйрь ачлы-туклы йөргән ундүрт яшьлек Шәрифне үзе белән ашханәгә чакыра. Гомумән, ул бу үсмер егеткә карата аталарча кайгыртучанлык күрсәтә. Шәриф хәтта Такташка «әти» дип, Һади исә аңа «улым» дип эндәшә торган була. Алар арасындагы дуслык 1921 елга кадәр, шагыйрьнең Оренбургтан Ташкентка китүенә кадәр дәвам итә.

— Һади искиткеч киң күңелле, изге ниятле егет иде,— дип сөйли Шәриф ага,— ул Оренбург губкомы оештырган «Юксыллар сүзе» исемле газетада җаваплы секретарь булып эшләде. Шул ук вакытта ул җаны-тәне, теше-тырнагы белән поэзиягә гашыйк иде. Аның һәр әсәрен яшьләр зур түземсезлек белән көтеп ала торган иделәр. Такташ кочак-кочак китап күтәреп йөри иде. Эшләп алган акчасының күп өлешен китап сатып алуга тота иде ул. Бигрәк тә Есенин, Гейне әсәрләре белән кызыксына иде...

Мин аңа үземне кызыксындырган сорауларны бер-бер артлы яудыра торам...

— Шәриф ага, сез Такташ белән тагын кайсы елларда очраштыгыз һәм ул кайда, нинди шартларда булды?

— Мин Такташ белән элемтәне өзмәскә тырыштым. «Олуг Төркестан» газетасында аның корреспонденцияләре еш кына басылып чыга иде. 1921 елның көзге айларында мин үзем дә Ташкентка күчеп килдем һәм татар культура-агарту институтына укырга кердем. 1922 елның башында без Һади Такташ белән кабат очраштык. Шул көннән башлап минем «әти» безнең институтка килеп йөри торган булып китте. Ул безнең «Кызыл укчы» исемле кульязма әдәби журнал белән кызыксына, безгә үзенең киңәшләрен бирә иде. Безнең институт ишек алдында приказчиклар клубы булып, шул клубта без, әдәби түгәрәк члennары, әледән-әле поэзия кичәләре оештыра идек. Һади Такташ чыгышлары безнең кичәләрнең дәрәҗәсен ифрат күтәрә иде. Әдәби кичәләргә татар яшьләре генә түгел, үзбәк, уйгур, каракалпак һәм башка милләт кешеләре дә йөриләр иде. Алар арасында яшь язучылар, шагыйрьләр, журналистлар, укытучылар, артистларны да күрергә була иде. Такташ исеме Ташкент, Бохара, Самаркандта, гомумән Үзбәкстан яшьләре, иҗат интеллигенциясе арасында киң танылган, аның иҗаты бик күпләрнең игътибарын үзенә җәлеп итә иде. Һади Такташ «Җир уллары» трагедиясен иң беренче безнең әдәби кичәдә укыды. Хәтта без бу әсәрне «әтинең» катнашында сәхнәгә куйдык. Зур уңыш белән узды. Клуб халык белән шыгрым тулган, басып торырга да урын юк иде.



*Һади Такташ «улы» Шәриф Булатов.*

Шуннан соң ул миңа «Урман кызы» поэмасының язылу тарихын сөйләп алды.

— Көннәрнең берендә мин, унҗиде яшьлек егет, куптән күзем төшеп йөргән бик чибәр бер кыз рәсемен (ул ниндидер журнал тышыннан киселеп алынган иде) клуб стенасыннан куптарып, үземнең торак бүлмәмә алып куйдым. Иртә торсам да, кич ятсам да, дәрес хәзерләп утырганда да шул кызга күз салам, аңа карап елмаям. Мин табынган шул кыз сурәтен күреп, «әти»: «Син бу рәсемне миңа бүләк ит әле»,— диде.

Мин «әти»нең үтенечен аяк астына сала алмый идем. Кыз рәсеме үземә бик кадерле булса да, аны «әти»гә бирдем. Шуннан берничә көн узмады, Һади Такташ безгә, институтта укучы курсантларга, үзенең «Урман кызы» исемле лирик әсәрен укыды, ул шигырь барыбызны да бик дулкынландырды. «Урман кызы» безнең яшь йөрәкләрнең иң нечкә кылларын тибретте, хисләребезне сафландырды. Бу әсәрен шагыйрь үзендә иң саф, иң нечкә йөрәк хисләрен кузгатуга сәбәпче булган кечкенә буйлы, гаҗәеп чибәр, мөлаем бер кызга атап язган иде. Белмим ул кыз, Әминә Абдуллина, хәзер исәндерме, кайда яши торгандыр? Егерменче елларда ул Ташкентта тора, без оештырган кичәләргә еш килеп йөри иде. Ул Әминәгә кемнәр генә гашыйк булмады икән?..



*Ә бусы Шәриф аганың соңгы еллардагы рәсеме.*

«Әти»гә мин бүләк итеп биргән чибәр кыз сурәте, күрәсең, үйләрында күптән әзер булган «Урман кызы»н кәгазьгә төшерү өчен кирәк булгандыр. Бәлки, Һади кыз сурәте белән Әминә арасында охшашлык тапкандыр. Ишетүем буенча, соңыннан Әминә Абдуллина озак еллар буе «Правда» газетасында эшләгән.

Шәриф абый искә алган Әминә Абдуллинага, я булмаса аның якыннары кулына безнең бу язма килеп керсә, аларга безнең үтенеч: кайда яшәвегезне бу юлларның авторына яки редакциягә хәбәр итсәгез икән.

Һади Такташ Ташкентта «Белем йорты» журналында җаваплы секретарь, кызылармеец мәктәпләрендә, коммунистик университетта укытучы булып эшләгән чакларында бик күп үзбәк язучылары, шагыйрьләре, журналистлары, аерым алганда, Хәмид Голәм, Гайрәти, Хәмид Алимҗан белән якыннан аралашкан.

Шәриф Булатов 1926—1928 елларда Казанда Татрабфакта укыган. Әлбәттә, Казанга килеп төшү белән, Шәриф «әти»се янына бара. Бу вакытта Такташ Рыбнорядный урамында, бәләкәй генә, тар гына бер бүлмәдә яши һәм «Азат хатын» журналында җаваплы секретарь булып эшли.

— Шунысы кызык,— дип сөйли Шәриф ага,— Ташкентта мин бүләк итеп биргән кыз сурәте һаман да Һади Такташ бүлмәсендә эленеп тора иде. Мин Казаннан киткәндә дә (1928 елда) үз урынында иде әле.

Шәриф Булатов рабфакта укыган елларында Мәдәният йортында уздырылган әдәби кичәләргә, язучылар белән очрашуларга йөри, үзе дә газета-журналларда «Яшь йөрәк», «Ш. Булат», «Шәриф Булат» имзалары белән әсәрләрен бастыра...

## Такташ белән күрештем

«Гулистан» журналының 1971 елда чыккан беренче саны. Анда Һади Такташның тууына 70 ел тулу көненә багышланган материаллар: шагыйрьнең рәсеме, «Киләчәккә хатлар» поэмасының беренче хаты үзбәк теленә тәрҗемә ителеп басылып чыккан һәм шулай ук «Балалар аталар хакында» диган рубрика астында «Һаман сафта» исемле мәкалә бирелгән. Бу мәкаләнең авторы шагыйрьнең улы, сәнгать фәннәре кандидаты, художник Рафаэль Такташ. Шул ук «Гулистан» журналының җиденче санында Рафаэль Такташның «Һәйкәлләр гомере мәңге...» исемле мәкаләсе белән танышырга мөмкин. Бу мәкаләдә Үзбәкстандагы монументаль һәйкәлләрнең сәнгатьчә эшләнүләре анализланган.

Мин Рафаэльнең үзе белән танышырга теләдем.

Рафаэль Һади Такташка фәкать зәңгәр күзләре белән генә охшаган. Әтисен ул нәни чакта гына белә. Әнисе Гөлчәһрә Хәмзина, Татрабфакны тәмамлагач, Мәскәү университетының юридик факультетына укырга керә. 1930 елны ул, Казанга кайтып, үзе янына Рафаэльне алып китә. Рафаэль әтисенең җанлы образын күңелендә изге итеп саклый. Ул әтисенең иҗатын яхшы белә.

Рафаэль Такташ «Атам һәм анам турында» диган язмасында Һади Такташ турында кызыклы гына истәлекләр язган. Әмма алар әле тулысынча беркайда да басылмаганнар.

Урал, Кырым, Мәскәү, Ленинград — Рафаэль яшәгән, укыган, рухи яктан формалашкан җирләр. Мәскәүдә ул Суриков исемендәге художество институтында укыган, Ленинградта сәнгать институтын тәмамлаган. Хәзер ул докторлык диссертациясе яза. Рафаэль — сәнгать фәне буенча күп кенә хезмәтләр авторы. Алар арасында Татарстанның халык художнигы Бакый Урманче иҗатын яктырткан фәнни-популяр очерк та бар. Ленинградта институт тәмамлагач, Рафаэль Ташкентка килгән, Үзбәкстанның бай архитектура сәнгатен, аның искиткеч үзенчәлекле, чын сәнгатьчә эшләнгән һәйкәлләрен җентекләп өйрәнгән. Аның гыйльми хезмәтләре әнә шуларга багышланган.

Үзбәк дуслар Рафаэль турында:

— Ул үзбәк халкына зур хезмәт күрсәткән галим. Үзбәкстан сәнгате үсешенә, аның фәненә Рафаэль Такташ зур өлеш кертте. Без барыбыз да аны ихтирам итәбез,— диләр.

Үзбәкстанның танылган художнигы Рузи Чарыев Рафаэль Такташның портретын язган. Бу портрет 1971 елда «Шарк йолдызы» журналының алтынчы санында басылып чыккан.

Рафаэль, алда әйткәнебезчә, үзе дә художник. Аның квартирасында барлык стеналар төрле стильдә, төрле жанрда язылган картина, этюд, эскизлар белән тулы. Нинди генә күренешләр сурәтләнми ул картиналарда — Үзбәкстан һәйкәлләре, яңа Ташкент күренешләре, портретлар.

Егерменче елларда Ташкентта, Бохарада, Самаркандта Һади Такташ үзбәк халкы арасында культура-агарту эше алып барган. Хәзер инде аның улы, Рафаэль Такташ, шул ук өлкәдә яңа шартларда әтисенең традициясен дәвам итә.

Гомумән, Рафаэль әтисе исемен горур йөртә. Ул, галим һәм художник буларак, бөтен сәләтен халыкка хезмәт итүгә багышлаган.

Ерак юлларда йөреп, бүгенге көндә бәхетле язмыш белән яшәүче әдәбият-сәнгать кешеләрен, яки әдәбият-сәнгатькә мөнәсәбәте булган кешеләрне күргәч, аларның истәлекләрен тыңлагач, күңелдә бер уй туа, мәдәниятебезгә бик тә кирәкле материалларның шактый өлеше әле читтә чәчелеп ята. Югалып, әрәм булып беткәнче аларны хуҗаларча нык кул белән җыйнап алырга кирәк.

Миргалим Харисов

# ТЕАТР һӘМ ДРАМАТУРГ

*Драматурглар киңәшмәсеннән репортаж*

Театр. Аны яше дә, карты да ярата. Театрга барган көн — бәйрәм. Без ул көнне сабан туена чыккандай әзерләнәбез. Театрдан без рухи баеп, чистарып чыгабыз.

Бу элек тә шулай иде, хәзер дә шулай.

Кайчандыр кино сәнгате театрны бетерә дип борчылганнар иде. Әмма театр бетмәде. Аннары өйләргә телевизор кереп утырды. Менә инде телевизор театрны күмә дип курәзәчелек итә башладылар. Анысы да акланмады. Халык театрга күбрәк омтыла, күбрәк йөри башлады. Соңгы елларда республикабыз театрларын елына ике миллион чамасы кеше карый. Аның өстенә, күпме халык театры, күпме культура йорты эшли, елның елында халыкка күпме яңа спектакль күрсәтелә.

Татар театрының абруе көннән-көн үсә. Театрларыбызның гастроль маршрутлары да чиксез киңәйдө. Аларны хәзер бездә генә түгел, илебезнең теләсә кайсы почмагында көтеп алалар. Әле соңгы елларда гына академия театрының Мәскәү һәм Уфа шәһәрләрендәге, Минзәлә театрының Урта Азия республикаларындагы гастрольләре — моның ачык мисалы.

Партиябезнең XXIV съезды Директиваларында болай дип язылган: «Бишьеллыкның төп бурычы социалистик житештерүне кызу темплар белән үстерү, аның нәтиҗәлелеген күтәрү, фән-техника прогрессы һәм хезмәт житештерүчәнлеген үстерүне тизләтү нигезендә халыкның материаль тормыш һәм культура дәрәҗәсен шактый күтәрүне тәэмин итүдән гыйбарәт».

Материал байлык тудыру ягыннан карагандa, театр житештерү чыганагы түгел. Әмма идеология эшендә, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә театр — партиянең ныклы ярдәмчесе.

Бу зур һәм мактаулы бурычны ничек үтәп чыгарга? Барыннан да элек, мәсьәлә драматургиягә кагыла. Театрның рухи эчтәлеген нәкъ менә драматургия билгели. Камил эшләнгән сәхнә әсәре юк икән, бер генә иҗат коллективы да тирән эчтәлекле, зур фикерле спектакль куя алмаячак.

Бүгенге татар драматургиясендә, татар театрында эшләр ничек?

1971 елның октябрь ахырында Әлмәттә уздырылган бик житди һәм һәр як өчен дә (театрлар өчен дә, драматурглар өчен дә, шулай булгач, тамашачы өчен дә) файдалы сөйләшү әнә шул мәсьәләгә багышланган иде.

Монда драматурглар, театр эшлеклеләре, артистлар, тәнкыйтьчеләр катнашу, мәсьәләне һич тартынмыйча уртага куеп сөйләшү киңәшмәне җанлы һәм бәхәсле итте.

— Безнең драматургиябез ни хәлдә? Ул әле илебезнең зур тормышын гәүдәләндерә алдымы? Тормышыбызны әйдәп баручы көчне — эшче образын тулы итеп, бөрлык интеллектуаль куәте белән күрсәтә алдымы? Республикабызның йөзен билгеләүче нефть кешесен, химикны, төзүчене, фәндә яңа сукмаклар салып баручы галимне гәүдәләндерү юлында осталыгыбыз житәрлекме?

Татарстан язучылар союзы председателенең урынбасары, театр тәнкыйтьчесе Гази Кашшаф киңәшмәне ачкан чакта, алдагы сөйләшүләрнең төп юнәлешен билгеләп, әнә шундый сораулар куйды. һәм бу со-

раулapгa бераз гына ачыклык кертеп, ул болай дип дәвам итте:

— Хикмәт сорауларны киңәйтүдә дә, драматургиянең тематик мәйданын билгеләүдә дә түгел. Эш — остальыкта, сәнгать югарылыгына күтәрелүдә, чорыбызга тиң геройны һәркем кабул итәрлек, һәркем дулкынланырлык итеп бирә белүдә.

Бүгенге драматургиядә кызыклы процесс бара. Психологик әсәрләр тудыруга игътибар көчәю — күңелле күренеш. Хәзерге әсәрләрдә әхлакый-этик проблемалар, шәхси бәхет һәм иҗтимагый бурыч, тарих һәм кеше кебек проблемалар яктыртыла. Ләкин, нинди генә проблема күтәрелмәсен, ул көрәшсез, конфликтсыз гәүдәләнә алмый. Шуңа күрә драматургның идея позициясе мөһим роль уйный. Драматург көрәш объектын дөрес билгеләсә, әсәр үткен һәм мавыктыргыч була.

Киңәшмәдә Язучылар союзының драма секциясе җитәкчесе Аяз Гыйләҗев драматургиябезнең, театрларыбызның бүгенге хәленә багышлап, үткен, хәтта, әйтергә мөмкин, усал доклад ясады. Аның белән килешүчеләр һәм килешмәүчеләр булды. Доклад зур гына бәхәс кузгатты.

Ә дөреслек кем ягында?

Иң элек докладтагы дәлилләргә күз салыйк. Ни өчен драматургиябез моннан берничә ел элек тамашачыны канәгатьләндермәде?

Аяз Гыйләҗев әйткәнчә, бүгенге драматургиянең чын йөзе аның сугышчан характерда булуында. Дөньякүләм капма-каршы ике идеология бәрелешендә, кичә һәм бүген бара торган каты көрәш бездән ачык фикерле, чорыбыз, бүгенге совет кешеләре таләп итә торган югары зәвыклы, тирән эчтәлекле әсәрләр сорый. Бары шундый әсәрләр генә режиссерларны, рәссамнарны, актерларны, гомумән, театрның бөтен звеноларын кузгата ала, аларда иҗади яну уята, бары шундый әсәрләр генә киләчәк коммунизм кешесен тәрбияли ала. Тормыш барышына актив катнаша ала торган көчле рухлы, коммунистик һәм гуманистик идеалларга тугры геройлар, сугышчан характерлы актив образлар гына тамашачы күңеленә тәэсир ясый, аның күңеленә үтеп керә, мәңгегә урын ала.

Элегрәк елларны мондый әсәрләр тумадымыни? Театрларыбыз яшәде, алар көн саен тамашачыга спектакль күрсәтте бит.

А. Гыйләҗев фикеренчә, элекке елларда кайбер драматурглар кечкенә масштаблар белән уйлый торган геройларны, аларның вак интересларын, бер көн эчендә, артык көч куймыйча хәл ителә торган проблемалар күтәргәннәр. Хәй Вахит иҗатын докладчы әнә шундый характерда дип бәяләде.

Нигезлеме бу сүзләр?

Әйе, бер карaганда, нигезле. Кызыклы ситуацияләр, образлар таба белгән, сәхнә законнарын, «тамашачы күңелен» өйрәнеп алган җор телле драматург пьесаларга кытлык чакта сәхнәне туендырып килде. Тамашачыны театрда тотты. Әмма аның йөгерек каләменнән бер-бер артлы чыккан комедияләр соңга таба гел бер-берсенә охшаш конфликтларга корылулары, юктан мәзәк ясап, тамашачыны көлдерергә тырышулары белән тамашачы зәвыгын боза башладылар. Аларда тамашачы бүгенге героик чорыбызны, зур тормышыбызны, уйландыра алырдай олы язмышларны күрмәде. Ул хакта үз вакытында язучылар җыелышында да, матбугат битләрендә дә, тамашачылар конференцияләрендә дә әйтелә килде. Ләкин Хәй Вахит аңа карамады, яза торды, театр ул язганны куя торды.

Хикмәт нәрсәдә соң алай булгач? Аяз Гыйләҗев әйткәнчә, гел җиңел пьесалар гына язгач, ник театр бу драматург белән саубуллашмаган да, ник тамашачы аннан йөз чөермәгән?

Иҗатындагы кимчелекләре булуга карамастан, дисталәгән пьеса язган (алар журналда басылды, аерым китаплар булып чыкты, үзешчәннәр тарафыннан куелды) авторны алай ук битәрләргә хаклымы соң без? Беренчедән, әле аларның барысын да бер калыпка салып булмый. «Беренче мәхәббәт» республикабызның Г. Тукай премиясен алды, «Күк капусы ачылса...» тәнкыйтьчеләр тарафыннан да шактый югары бәяләнде, Бакуда һәм башка театрларда куелды. Икенчедән, еллар буе үз сәхнәсендә бу авторга урын биргән академия театрының барлык эшен, артистлар, режиссерлар иҗатын сызып ташлау булып чыкмыймы бу?

Минем монда хөрмәтле драматургыбыз Мирсәй Әмир сүзләрен китерәсем килә.

— Мин Хәй Вахитны күп тәнкыйть иткән кеше,— диде Мирсәй ага.— Ләкин аның барлык иҗатын гаепләп чыгу дөрес түгел. Ул драматургиягә гомерен багышлады. Әлбәттә, аның кимчелекләре шактый, әмма үзе генә гаепleme икән ул монда?

Чынлап та, кайда булган соң ул чорда башка драматурглар? Ник шәбрәк әсәрләр

тудырмаганнар да ник сәхнәләрне яулап алмаганнар?

Безнеңчә, моннан берничә елгы уңышсызлыкларыбыз өчен бер драматург Хәй Вахитны гына гаепләү һәм аның йөзендә татар драматургиясенә тулаем бәя бирү бик үк дөрес булмастыр, өстәвенә, Хәй Вахитның соңгы еллар татар комедиясенә яңа төсмерләр, ысуллар өстәүдә керткән өлешен дә онытү ярамас.

Дөрес, докладта бар гаеп авторларга гына ташланды дип әйтеп булмый.

Театрлар бүгенге авторларның әсәрләре белән генә яшәмәделәр, дип дәвам итте Аяз Гыйләҗев. Дөнья әдәбияты, рус һәм татар классикасы, тугандаш халыкларның иң әйбәт әсәрләре татар сәхнәсендә уйналып килә. Әмма театрның чын йөзен, аның иҗат юлын дөнья әдәбияты үрнәкләре белән берлектә, шуларга тиң булырлык иҗат ителгән милли әсәрләр генә билгели. Театр үзенең төп принципларын милли әсәрләр югарылыгында гына чишә ала. Театр белән драматургия бер-берсенә ярдәм итеп, бер-берсенең үсеш дәрәҗәләрен билгеләп, бер бөеклектә баралар. Бер театрның да үз драматургиясеннән аерылып китеп, беренчесенең алдарак барып, икенчесенең артта калу очрагы юк. Шул уңайдан кайбер театр җитәкчеләренең үз репертуарларын бары тик тәрҗемә әсәрләрдән генә тупларга яратуларын, милли репертуарга бармак аша карауларын, нәтиҗәдә бер адым артка атлауларын аерым басым ясап әйтергә кирәк.

Докладчының бу фикерен башка иптәшләр дәлилләр белән ныгыттылар. Сәнгать фәннәре кандидаты И. Илялова һәм драматург Т. Миңнуллин анализлаганча, соңгы елларда Әлмәт һәм Республика күчмә театрларының репертуарында шактый зур процентны тәрҗемә әсәрләре алып тора. Әлбәттә, теге яки бу театрны илебездә иң яхшы театрлардан саныйбыз икән, тамашачы аның спектакльләрен карау өчен чират тора, аннан рухи баеп чыга, шуның өчен ул һәркайда яратып каршы алына икән, без бу театр репертуарында дөнья һәм рус классикларының әсәрләрен дә, тугандаш халыклар һәм үз драматургиясенең дә үрнәкләрен күрәбез. Әмма һәр нәрсәнең чамасын белергә кирәк. Театрның чын йөзен иң элек милли драматургия билгели.

Тәрҗемәгә әсәрләр сайлаганда да без еш кына талымсызлык күрсәтәбез. Әйтик, Татар дәүләт академия театрында кыргыз язучысы Ч. Айтматов повесте буенча эшләнгән «Гүзәләм Әсәл» спектакле республикабызның Г. Тукай премиясенә лаек булган икән, СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов башкаруындагы Король Лир образы һаман да безнең күз алдыннан китми тора икән, Әлмәт театрының «Анам кыры», «Юлдан язган» спектакльләре тамашачылар өчен зур фикер, олы хис алып килгән икән, бу эшләрне без иҗат коллективларының зур уңышы, үз тарихында якты бер хатирә булып калачак сәхифә дип исәплибез. Ләкин тәрҗемә ителгән әсәрләрнең барысы да тиешле идея-художество югарылыгында булмый. РСФСР Культура министрлыгы тараткан әсәрләр арасында да, үзәк нәшриятларда басылганнарында да, яхшылары белән беррәттән, идея-художество ягыннан бик үк югары дәрәҗәдә булмаганнары да җитәрлек. Ни өчендер еш кына театр җитәкчеләре һәм режиссерлар әнә шундыйларга игътибар итәләр. Моны бары тик таләпчәнлекнең һәм иҗади принципиальлекнең җитмәве белән генә аңлатып була. Әгәр шулай булмаса, Әлмәт театрында «Вәгъдә каены», Республика күчмә театрында «Онытма мине, кояш» кебек җитлекмәгән әсәрләр куелмас иде.

Тормышта һәрвакыт үзгәрешләр булып торган кебек, сәнгать тә бер урында гына таптанып тора алмый. Театрга яңа буын кешеләре, яңа эшлекләләр килә. Яңа тамашачылар үсә, режиссерлар туа, яңа актерлар ялтырап үтә. Драматурглар да шушы үсеш югарылыгында, аның үзәгендә булырга бурычлылар. Югары талант белән сугышчан характерлы әсәрләр язарга булдыклы драматурглар гына бүгенге көрәшнең алгы сызыгында торалар, дип дәвам итте Аяз Гыйләҗев. Тамашачы, театр, драматург. Бу өч буынның берәве генә артта калса да, сәнгать үсүдән туктый. Болар — бер-берсенең үсешен билгеләп, тыгыз контактта яшәргә тиешле буыннар. Режиссерлар һәм артистлар бер яктан, таләпчән тамашачы икенче яктан язучыны чын киеренкелектә тотканда гына, язучы, чын тормыш эчендә кайнап, якты киләчәгебез өчен көрәш мотивлары белән рухланып яшәгәндә генә бүгенге көн сәхнәсен бизәрлек әсәрләр туа.

Соңгы елларда театрлар тормышында үзгәреш байтак. Яңа режиссерлар, яңа авторлар тормыш тирәнлегенә аңлы рәвештә, максатлы рәвештә үтеп керә башладылар. Алар тормышның олы һәм кече вакыйгалары аша зур проблемаларны, чо-

рыбызның алдынгы фикерләрен чишәргә тырышалар. Һиһаять, хәзерге заман татар драматургиясенә җитди уйлану, фәлсәфи гомумиләштерү хас. Элегрәк мондый юнәлештәге әсәрләр бер-ике авторда күренеп-күренеп кенә китсәләр, хәзерге заман драматургиясенең йөзен билгеләүче Ш. Хөсәенов, Т. Миңнуллин, Ю. Әминовларга шул уңай сыйфатлар хас. Бу авторлар, төрле жанрларда эш күрсәтеп, мәгълүм дәрәҗәдә уңышка ирештеләр, театрлар тормышында яңарыш тудырдылар дип авыз тутырып әйтә алабыз. Театрларга иҗади йөзләре төрле-төрле булган, әмма иҗат принциплары уртак драматурглар килде. Аларның әсәрләре, дөнья, рус классикасы, тугандаш халыкларның иң әйбәт пьесалары белән берлектә, алар белән янәшә торып, театрларыбызның кайберләренә сизелерлек үсеш, яхшы исем китерделәр.

Бу очракта докладчы белән килешмәү мөмкин түгел. Чыннан да, «Профессор кияве», «Зөбәйдә — адәм баласы», «Әни килде», «Миләүшәнең туган көне», «Ир-егетләр», «Язылмаган законнар», «Тамырлар», «Умырзаялар» кебек әсәрләр иҗат иткән бу өч автор бүгенге татар драматургиясе үсешенә шактый уңай йогынты ясадылар. Ләкин бу драматурглар каләме астыннан чыккан әсәрләр тел-теш тидермәслек, инде татар драматургиясе үз югарылыгына күтәрелде, чәчәк ату чорын кичерә, дип «авыз тутырып» әйтү бик үк дөресме? Әллә Мирсәй Әмирнең, егетләр, тынычланырга ашыкмыйк әле, дигән сүзләренә колак салу урынлырakмы? Болай дип үз-үзебезне тынычландыру нигә кирәк, ди ул. Күзгә күренеп торган уңышларыбыз булган хәлдә дә драматургиябезнең һаман да артта икәнлеге берәүгә дә сер түгел бит. Бармы соң безнең әсәрләр буенча союз күләмендәге сәхнәгә күтәрелгән спектакльләр? Бу мәсьәләдә казакъ, кыргыз, әзәрбайҗан, башкорт һәм башка тугандаш халыклардан калышабыз түгелме? Филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллинның: кая соң бүгенге Миңлекамаллар, дип борчылуы бу фикерләрне тагын да куәтли төшә. Чынлап та, егерме ел эчендә республикабыз илебезгә бер миллиард тоннадан артык нефть бирде. Нефть ташкыны республикабызның тышкы йөзен генә үзгәртеп калмады, кешеләрне, аларның рухи йөзен баетты. Европада иң зур булган Зәй ГРЭСы төзелде, Казанда, Түбән Камада гигант химия комбинатлары сафка басты, хәзер Чаллыда, зур кыенлыкларга карамастан, дистәләрчә мең кеше автозавод сала, алар арасында үз республикабыз төзүчеләре дә күп, инде хәзерге колхозчыларны, аларның дөньяга карашларын, рухи халәтләрен дә без элекке еллар белән һич чагыштыра алмыйбыз. Күпме бездә геройлар, хезмәт алдынгылары! Ә бүгенге сәхнәбездә күрәбезме без аларны? Күбрәк игътибарны сәхнәдә исерекләрне, җилкуарларны тәрбияләүгә юнәлтмибезме? Туфан Миңнуллинның: «Тискәре геройның зур булуы кирәк, ул зур булса, аның белән көрәшүче уңай герой табыла», дигән фикере сәхнәбездә дә тамыр җәя башлады түгелме? Азат Әхмәдуллин аңа каршы чыкты: «Мәсьәләне болай кую драматургиянең иҗат юнәлешен буташтырырга мөмкин»,— диде ул. Киресенчә, уңай геройны тиешенчә күрсәтә алганда гына аның кылган эшләре бөтен матурлыгында күренер, аның көрәше тулы ачылыр, ул көрәшкән тискәре герой да тиешенчә гомумиләштерелгән буларак сурәтләнер. Ә ни өчен әле уңай герой үзе шикелле үк эреләштерелгән тискәре герой белән бәрелештә генә тулы ачыла дип аңларга? Миңлекамалларга каршы көрәшкән Кылый Хәлимнәр, Маймүнәләр ул кадәр үк эре жуликлар түгел ич! Ләкин шуңа да карамастан, Миңлекамал үз чорындагы иң уңышлы тасвирланган эре характер булудан туктамый. Югарыда, уңай геройлар якты килечәк өчен көрәштә туа, дигән идек, ә көрәш булган һәр урында конфликт бар. Димәк, геройның тормыш авырлыклары белән, производство кыенлыклары белән көрәшен сурәтләү аша да геройны тулы итеп ачарга мөмкин.

Шулай булгач, сәхнәбездә әле эре геройлар — тамашачыны тирән дулкынландырырлык, аны үз артыннан ияртерлек, зур көрәшкә өндәрлек образлар җитенкерәп бетмәгәч, тынычланырга урын юк, җиң сызганып эшләргә дә эшләргә кирәк. Бу фикерне киңәшмәдә тамашачылар исеменнән чыгыш ясаган атаклы нефтьче, ВЛКСМ Үзәк Комитеты члены Ш. Таипов та раслады. Ул «Әлмәтнефть» промыселлар идарәсенең гаять зур эшләре һәм батыр йөрәкле кешеләре турында конкрет мисаллар белән сөйләп бирде.

Әйткәнебезчә, яхшы спектакль бары тик яхшы драма әсәре нигезендә генә туа ала. Ләкин бу әле театр драматург яхшы әсәр китергәнне көтеп торырга тиеш дигән сүз түгел. Югары художестволы әсәр театр белән иҗади дуслыкта гына

туа. Моннан инде театрның, режиссерның драматург белән бәйләнеше мәсьәләсе килеп чыга.

Г. Камал, К. Тинчурин, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, М. Әмир, Р. Ишморат һәм башка талантлы драматургларның иң яхшы әсәрләре театр белән якын бәйләнештә, режиссерлар, актерлар ярдәмендә барлыкка килгәннәр, дибез икән, бу хәл хәзерге театрларыбызга һәм драматургларыбызга да матур үрнәк булып тора.

Театрларыбыз драматургларыбыз белән ничек эшли соң? Докладка һәм чыгышларга колак салсак, бездә дә бу күркәм традицияләр дәвам иттерелә һәм ул ярыйсы гына нәтиҗәләр бирә икән. Барыбызга да мәгълүм: Юныс Әминев үзенең беренче әсәре булган «Язылмаган законнар»ын Минзәлә театры, аның баш режиссеры С. Өметбаев ярдәмендә сәхнәгә менгерде, аннан соң язылган тагын берничә әсәре дә шушы коллектив фатихасын алды, драматург буларак ул шушы театрда канат җәйде, үсте. З. Шәһиморатов, С. Шәкүров күп еллардан бирле шушы коллектив белән иҗади бәйләнештә яши, шундый дуслык нигезендә театр сәхнәсендә Ә. Баяновның «Һәйкәл» спектакле туды. Әлмәт, Республика күчмә театрлары җирлегендә дә мондый мисалларны шактый китерергә була. Академия театры сәхнәсендә күрсәтелгән «Намус хөкеме» спектакле дә — театрның баш режиссеры М. Сәлимҗановның яшь драматург Д. Вәлиев белән армый-талмый эшләве нәтиҗәсе.

Монда, бәлкем, өлкән драматургыбыз Риза Ишморат сүзләренә дә берникадәр колак салу зыян итмәстер. Драматург, бер әсәр язып аны тамашачыга җиткерим, сәхнәгә куйдырыйм, дип уйлый икән, диде ул, ул, һичшиксез, баштан ук бер театр белән иҗади бәйләнешкә кереп эш итәргә тиеш. Темасы, куйган проблемасы, образлары белән театрны кызыксындырамы ул әсәр, юкмы? Әгәр кызыксындырмый икән, аны язып тору да кирәкми. Бу һәр ике як өчен дә вакыт әрәм итү генә булачак. Сәхнә әсәрләре билгеле бер план, конкрет задание белән ярашып барлыкка килергә тиешләр.

Шигырь иҗат итүне, поэма тудыруны, хикәя, повесть, роман язуны үз агымына куярга мөмкин (әлбәттә, моның белән бик үк килешеп бетеп булмый), диде Риза Ишморат, ләкин драматургка андый хокук бирелмәгән. Театрда көн саен спектакль күрсәтелә. Ул елына берничә премьера чыгарырга тиеш, моның өчен әсәр кирәк.

Шунда ук өлкән драматург үз тәкъдимен дә кертә: инде үзләрен сәләтле драматург дип таныткан иптәшләрне (үз теләкләрен, иҗат мөмкинлекләрен исәпкә алып, әлбәттә) конкрет бер театрга, бер режиссерга беркетеп, конкрет задание биреп яздырырга кирәк, ди ул.

Әлбәттә, бу — бик четерекле эш. Иҗат эшендә алай конкрет күрсәтмә бирү авыр. Пьеса түгел, хәтта кечкенә генә шигырь язарга бирелгән заказның да илһамны кузгата алмавы бар. Ләкин Риза Ишморат фикерендәге түбәндәге икенче бер нәрсә белән килешми мөмкин түгел. Чын художник илһамны күктән көтеп ята алмый, халык һәм җәмгыятебез алдындагы гражданлык бурычын аңлау аны илһамландыра, иҗатка этәрә.

Монда тагын игътибардан читкә калмаска тиешле бер момент бар. Әгәр театр үз драматургларын булдырган икән, әгәр ул алар белән иҗади бәйләнешне юлга салган икән, әмма үз драматургы булган өчен генә театр әлеге авторның иҗатына ташлама ясамаска тиеш. Ә хәзер, чынлап караганда, андый ташламалар ясала. Мисалны республикабызның һәр театрыннан китерергә була. Киңәшмә вакытында күрсәтелгән спектакль булгач, Әлмәт театры сәхнәләштергән «Сөенеч һәм көенеч»не (С. Кальметов) генә алыйк. Бу очракта режиссер Гали Хөсәенов авторга «аю» хезмәте күрсәткән кебек булган. Сәхнәгә җитлекмәгән әсәр куелган. Гази Кашшаф сүзләре белән әйткәндә, өстән караганда, монда көрәш мәйданы да бар шикелле, бәхәс кухня эчендә түгел, иҗтимагый күләмдә алына. Ләкин ул барыбер ир белән хатын арасындагы конфликтка әверелеп кала. Инженер проекттан баш тарткач, аның хатыны бу эшкә кереша һәм шул нигездә семьяның череклеге, мещанлыгы фаш була, семья таркала. Кешенең интеллектуаль үсеше, аның производство интереслары өчен тырышып йөрүе ясалма бер фонга әйләнеп кала.

Әлбәттә, семья арасындагы низаглар, ир белән хатын арасындагы фикер каршылыклары турында пьеса язарга ярамый, дип берәү дә әйтми. К. Треневның «Любовь Яровая»сын искә төшерик. Анда да семья таркала, анда да ир белән хатын арасындагы конфликт өскә калкып чыга. Әмма бу конфликт «табагач атып талашуга» гына түгел, иҗтимагый әһәмият

дәрәҗәсенә күтәрелә, автор ике сыйныф бәрелешен чагылдыра.

Зур драматургларның үз әсәрләрен һичбер иренмичә, кат-кат эшләүләрен беләбез. Бу очракта да театр Сәет Кәлбәттовтан шуны таләп итәргә тиеш иде.

Инде театр тәнкыйтенә тукталыйк.

Бездә тәнкыйтьчеләр юк түгел. Тәнкыйть мәкаләләре әледән-әле газета-журнал битләрендә күренеп тора, спектакльләргә рецензия басыла. Ләкин җитәрлекме алар, үткенме, файда китерә торганмы? Дөресен әйткәндә, әле бездә зур фәлсәфи уйланулар белән тирән анализ ясаган, олы фикерләр әйткән мәкаләләр, хезмәтләр юк дәрәҗәсендә. Теге яки бу спектакль турында язылган рецензияләрдә принципиаль анализ ясалмый, теге яки бу кешенең хәтерен калдырмас өчен тәнкыйтьче мәсьәләнең үзәгенә төшеп тормый, читләтеп кенә үтеп китә. Шул көнгә кадәр академия театрының үткәне, бүгенгесе турында төпле бер хезмәт юк. Моннан унбиш еллар элек талантлы артистларның монографияләре чыгарылган иде. Инде аларны күптән табып булмый, ә яңалары күренми. Дөрес, тәнкыйтьче-галимнәребез тарафыннан татар театры тарихы язылган, ләкин анысы да әле кулга кергәне юк.

Шунысын да әйтергә кирәк, драматургларыбыз, режиссерларыбыз, актерларыбыз арасында тәнкыйтьне өнәп бетермәүчеләр дә бар. Мирсәй Әмир әйтмешли, үзен тәнкыйть иткән өчен берәүнең дә әле бер тәнкыйтьчегә рәхмәт әйтеп кулын кысканын күрмәссең. Ләкин тәнкыйть вак интересләр өчен түгел, бүгенге драматургиябезне үстерү өчен кирәк. Шуңа күрә, тәнкыйтьчеләрдән принципиаль булу, заман таләпләре нигезендә тирән уйлана белү таләп ителә.

«Шик юк ки,— диде Л. И. Брежнев КПССның XXIV съездында сөйләгән отчет докладында,— әгәр дә безнең әдәбият, художество тәнкыйте партия линиясен тагын да активрак үткәрсә, таләпчәнлекне такт белән, художество кыйммәтләрен иҗат итүчеләргә игътибарлы мөнәсәбәт белән бергә бәйләп, зуррак принципиальлек белән чыгыш ясаса, совет әдәбиятының һәм сәнгатенең уңышлары тагын да зуррак булыр, ә кимчелекләр тизрәк бетерелер иде».

Бу сүзләр һәр тәнкыйтьчене уйландырырга, кирәкле нәтиҗәләр ясарга мәҗбүр итәргә тиеш.

Профессиональ театрлардан башка республикабызда дистәләгән халык театрлары, йөзләгән үзешчән драма коллективлары да бар бит әле. Профессиональ театрларга куйган таләпләрне без аларга да куябыз. Ә кем кайгырта соң аларның репертуары турында? Республикада халык иҗаты йорты, үзешчән сәнгать йорты, аларның репертуар бүлекләре бар. Ләкин кайсы зур драматург үзенең иң яхшы әсәрен тотып иң башта бу йортларга барды? Бу йортларга килгән авторлар я театрларда кабул ителмәгән, я әле үз гомерендә беренче тапкыр кулына каләм тотып чиле-пешле әсәр язган кешеләр була. Ә тамашачы бер үк. Шулай булгач, аларга, профессиональ театр күрсәтәме, әллә халык театрымы, барыбер — яхшы әсәр кирәк. Югары сыйфатлы пьесалар җитешмәү аркасында халык театрлары сәхнәсендә «Чишмә җыры» (Чаллы халык театры, М. Кашапов әсәре), «Уяну» (Зеленодольск халык театры, Д. Гомәров әсәре) кебек түбән зәвыклы спектакльләр күрсәтелә.

Киңәшмә һәркемдә тирән фикерләр, М. Әмир сүзе белән әйтсәк, язасы килү теләге тудырды. Аның Казанда түгел, нәкъ менә Әлмәттә үткәрелүе еллар буе театр тәнкыйте һәм җәмәгатьчелек фикере ишетмичә читтәрәк калып килгән Республика күчмә театры, Әлмәт, Минзәлә театрлары кебек гел «тәгәрмәчләр өстендә яшәүче» театрлар өчен бигрәк тә файдалы булды. Киңәшмәдә Әлмәт театрының баш режиссеры Гали Хөсәенов, Республика күчмә театрының баш режиссеры Равил Тумашев, Минзәлә театрының баш режиссеры Мулланур Мостафин, Г. Камал исемендәге Татар академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов, драматурглар Габдрахман Минский, Юныс Әминев, Диас Вәлиев, Татарстан культура министры Булат Гыйззәтуллин чыгыш ясап, татар драматургиясе, татар театры турындагы уй-фикерләре белән уртаклаштылар, бәхәстә катнаштылар.

Моннан ике ел элек Әлмәттә «Татар әдәбиятында хезмәт кешесе образы» дигән темага зур киңәшмә үткәрелгән иде. «Казан утлары»на һәм Татарстан китап нәшриятына эшчеләр тормышыннан язылган күләмле әсәрләрнең килүе арта төште, аларның сыйфаты да яхшырды.

Драматурглар киңәшмәсе дә эзсез калмас. Өзек көтмәсләр, драматургларыбыз чорыбызга лаек әсәрләрне күбрәк иҗат итәрләр дип ышанасы килә.

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**А. КИРЕЕВ. Башкирский народный героический эпос. Рус телендә. Уфа. 1970.**

Халык эпосы әсәрләрен җыю, матбугатка чыгару һәм өйрәнү бүгенге фольклор фәне алдында төп бурычларның берсен тәшкил итә. Бу мәсьәләгә башкорт фольклористикасында да иң җитди игътибар бирелә. Кирәй Мәргән, С. Галин, Ә. Харисов һәм башка галимнәрнең шушы юнәлештәге фәнни тикшеренүләре моны бик ачык раслый. Бу хезмәтләр арасында аеруча әһәмиятлесе — К. Мәргәннең күптән түгел Уфада рус телендә басылып чыккан «Башкорт халкының героик эпосы» исемле монографиясе.

Китапның беренче бүлегендә күп кенә методологик мәсьәләләр кузгатыла. Автор шунда үзе күтәргән проблеманы нигезли, башкорт халык иҗатын җыючылар һәм өйрәнүчеләр турында яза, эпик традицияләрне саклаучы һәм дәвам иттерүче халык талантлары турында кызыклы мәгълүматлар китерә.

Эпик легендалар барлыкка килүнең тарихи алшартларын ачыклаганнан соң, автор конкрет материалга мөрәҗәгать итә. Башта башкорт эпосының бик борынгы формасы саналган иртәкләргә фәнни анализ ясала. Аларның иң күренеклесе — «Урал батыр». Бу иртәк халык аңының «табигать ияләре» белән бәрелеше һәм халык батырларының мифик көчләргә каршы көрәшүе идеяләре белән сугарылган. Шушы ук идея башкорт һәм татар халык иҗатларында киң таралган «Зая Түләк белән Су Сылу» легендасында да чагыла. (Ләкин соңгысының үзәген инде социаль конфликт тәшкил итә.) «Урал батыр» исемле әлеге иртәктә төп сурәтләү объекты итеп гаилә өчен көрәш алынган. Монография авторының фикеренчә, социаль конфликт «Акбузат» иртәгендә тагын да ачыграк гәүдәләнә. Әсәрдә «семья өчен көрәш мотивлары халык бәхете өчен көрәш дәрәҗәсенә үсеп җиткәләр».

Фольклор әсәрләрен теге яки бу эпоханың үзенчәлекле яклары белән чагыштырып өйрәнү авторга аерым әсәрләрнең эпос үсешендәге генә түгел, бәлки гомумән башкорт фольклоры үсешендәге урынын һәм әһәмиятен ачыкларга ярдәм иткән. Моны без «Кара юрга», «Коңгыр бога» кебек үзенчәлекле әсәрләргә, шулай ук күп кенә төрки халыкларның фольклорында киң таралган «Алпамыш һәм Барсын-Сылу», «Кузы Күрпәч һәм Баян Сылу» шикелле дастаннарга бирелгән анализда ачык күрәбез.

Башкорт эпосында халыкның чит ил басып алучыларына каршы көрәшен чагылдырган әсәрләр күренекле урын алып тора. Бу XIII гасырдан башкорт кабиләләренең, башка бик күп халыклар белән бергә, монгол изүе астына эләгүенә бәйләнгән. Алтын Урда Аксак Тимер тарафыннан тар-мар ителгәч, башкорт җирләре аерым ханлыклар арасында бүлгәләнә. Шушындый шартларда илне һәм халыкны чит яулардан саклау төп тема булып әверелә, һәм бу халык эпосының башкорт фольклорына гына хас булган төрендә — кобаерларда аеруча ачык чагылыш таба. Шунысы бик кызыклы: кобаерлар өчен, автор күрсәтеп үткәнчә, героик эчтәлек кенә хас. Бу — кобаерлар башкорт халкының үз бәйсезлеге өчен көрәшендәге аеруча авыр шартларны поэтик сурәтләү чарасы буларак барлыкка килгән дигән сүз. Ватан һәм ил батырлары турындагы «Идегәй белән Морадым», «И Уралым, Уралым», «Иделйорт» кебек кобаерлар циклы моны бик ачык күрсәтеп тора. Бу кобаерларга автор тарафыннан шактый җентекле һәм тирән анализ ясала.

Башкорт халык эпосы бик бай һәм төрле-төрле. Эпик легендаларның саф фольклор формалары (әгәр шулай әйтеп булса) белән бергә, башкорт халык иҗатындагы китаплар һәм кульязма чыганаклар аша кергән сюжетлар да бар. Кирәй Мәргән

хезмәтендә шундый легендаларның да аерым үрнәкләре тикшерелә. Автор үзенең игътибарын төрки халыклар арасында шактый киң таралган «Йосыф һәм Зөләйха», «Таһир-Зөһрә», «Буз егет» кебек сюжетларга юнәлтә. Ул бик дөрес күрсәтеп узганча, халыклашу процессында бу әсәрләр халыкның дөньяга карашы белән бәйләнгән кайбер үзгәртелүләр кичергәннәр. Ләкин тулаем алганда, автор фикеренчә, алар, халык репертуарына соңгырак тарихи чорларда гына үтеп кергәннәр һәм героик легендалар кебек әһәмиятле роль казана алмаганнар.

Автор эпосның эстетик асылын ачыклауга да игътибар биргән. Бу мәсьәлә «Эпик әсәрләрнең формалары, теле һәм стиле» дип исемләнгән махсус бүлектә карала. Барыннан да элек, автор халыкның дөньяга карашындагы борынгы үзенчәлекләрнең эстетик яктан ничек формалашуына игътибарны юнәлтә, эпостагы төп образларны анализлый, иртәк һәм кобаерларның тел-стиль үзенчәлекләре турында сөйли. Бу мәсьәләләргә җентекләп тукталып тормастан, шуны гына әйтәбез: аларның барысы турында да укучы китапта тирән фикерләр һәм кызыклы күзәтүләр таба алачак.

Хезмәтнең төп проблемасы героик эпосның үзенчәлекләрен ачыклау булса да, автор моның белән генә чикләнми. Тикшерүнең нигезенә салынган тарихилык принцибына таянып, галим эпик традицияләрнең яңа шартларда дәвам итүе, шуның бер чагылышы буларак, тарихи җырлар һәм бәетләр тууы турында сөйли. К. Мәргән язганча, башкорт кабиләләренең ирекле рәвештә Рус дәүләтенә кушылуы тәмамланганнан соң үткән соңгы өч-дүрт гасыр мөһим тарихи вакыйгалар белән характерлы. Тарихи җырлар тууның үзенчәлекле алшарты булып нәкъ әнә шул хәл хезмәт иткән. Фольклорның бу жанры халык иҗаты үсешендә яңа баскыч булып тора.

Башкорт халкы арасында соңгырак тарихи чорларда тарала башлаган бәет жанры да тикшеренүченең игътибарыннан читтә калмый.

Билгеле, хезмәт аерым кимчелекләрдән дә азат түгел. Монографиянең кайбер урыннарында текстлар белән җитәрлек сак эш итмәү сизелә. Героик легендаларны артык нык яратуы нәтиҗәседерме, авторның халык репертуарына китаплар һәм кулъязма чыганаклар аша кергән легендаларга беркадәр игътибарсызрак каравы күренә. Шушы ук нәрсә бәетләрне анализлаганда да сизелә.

Билгеле, бу кечкенә җитешсезлекләр хезмәтнең кыйммәтен һич тә кимәтә алмыйлар. Гомумән алганда, К. Мәргәннең логик эзлекле һәм тирән эчтәлекле бу тикшеренүе башкорт фольклор фәненә мөһим өлеш булып тора.

ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ,
филология фәннәре кандидаты.

# АЛТЫН БӨРТЕКЛӘР

*(К. Насыйри сүзлекләрендә фольклор әсәрләре)*

Бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри ярты гасырдан артыграк дәвам иткән иҗади-фәнни эшчәнлегендә халык иҗаты әсәрләрен җыю, өйрәнү һәм матбугатка чыгару эшенә даими һәм җитди игътибар биреп килде. «Кырык бакча», «Фәвакиһелҗөләсәә», «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре», «Казан татарларының әкиятләре һәм аларны башка халыкларның әкиятләре белән чагыштыру» кебек хезмәтләрендә, шулай ук үзе чыгарган календарьларда ул күп санлы әкиятләр, бәетләр, риваятьләр, җырлар, мәкальләр һәм табышмаклар бастырды.

Ләкин шуны әйтергә кирәк, бу санап кителгән хезмәтләр К. Насыйри җыйнаган халык иҗаты материалларының барысын түгел, бер өлешен генә тәшкил итәләр. Аның фольклор мирасын әле җентекләп барлап чыгасы һәм бер урынга туплыйсы бар. Бу мөһим эшне төп ике юнәлештә алып барырга кирәк. Бер яктан, К. Насыйриның гыйльми китапханәләрдә һәм архивларда саклануы кулъязмаларын өйрәнү зарур. Башлангыч тикшеренүләр күрсәткәнчә, аларда байтак кына фольклор әсәрләре булырга тиеш. Икенче яктан, галимнең тарих, этнография, тел белеме һәм башка фәннәргә караган хезмәтләренә мөрәҗәгать итү бик файдалы булачак. Хикмәт шунда ки, К. Насыйри үзенең фәнни хезмәтләрен, җае чыккан саен, халык иҗаты әсәрләре белән бизи, нәфисли барырга яраткан. Әйтик, Зәя өязенең Тау иле авылы турында ул болай яза: «...Тау иленең бер ягында ниһаятьсез биек таудыр. Шуның өчен Тау иле хосусында берәр мисраг һәм бәетләр ишетелгәне бар:

**Тау иленең таулары,**
**Өзелә камыт баулары.**
**Кәмыт бавын ялгый-ялгый**
**Сызыла йөрәк майлары** [1]».

Я булмаса, татарларда килен төшерү гадәтләре турында сөйләгәндә, К. Насыйри кызның атасы өеннән алып китә торган әйберләрен санап чыга да мәкаль ярдәмендә нәтиҗә ясап куя: «...Шуның өчен дә әйткәннәр: **«Киткән кыздан пумала курка»** [2].

Халык иҗаты материалларын галим тел белеменә багышланган хезмәтләрендә, бигрәк тә сүзлекләр төзегәндә, аеруча киң файдалана. Бу җәһәттән ул төзегән аңлатмалы сүзлек — «Ләһҗәи татари» [3] күренекле урын тота. Сүзлекнең кайсы гына битен ачып карама, анда, ком арасындагы алтын бөртекләре сыман ялтырап, я җыр строфасы, я мәкаль һәм әйтем, я табышмак, я такмаза килеп чыга.

Сүзлек төзегәндә К. Насыйри фольклор әсәрләренә төрле-төрле максатлардан чыгып мөрәҗәгать итә. Күпчелек очракларда ул аларны сүзнең мәгънәсен ачып бирә торган контекст итеп файдалана. Мәсәлән, **«Абагы да җабагы»** — иске вә ертык киемле, шахсы вә тәрбиясез мәгънәсендәдер...» дип аңлатма бирә дә, соңыннан шуны халык җыры белән дәлилләп, ныгытып куя:

**Югары очның кызлары**
**Абагы да җабагы.**
**Түбән очның кызлары**
**Алтын-көмеш табагы.**

Яки икенче бер мисал: **«Аркылы — Өй аркылы аркан аттым.** Бер җомактыр (табышмактыр — Х. М.). Ягъни, өйнең бер ягын-

---

[1] К. Насыйри. Сайланма әсәрләр. 2 басма. Казан. 1956 ел. 149 бит.
[2] Шунда ук. 180 бит.
[3] К. Насыйри. Ләһҗәи татари. Казан. 1 кисәк — 1895 ел. 2 кисәк — 1896 ел.

нан икенче ягына аркан ташладым. Салават күпере». Кайчакта К. Насыйри халык иҗаты әсәрләрен аңлатыла торган сүзнең синонимы буларак китерә. «Ыгы-зыгы» дигән сүзнең мәгънәсен ул түбәндәгечә ача: «...Тимер юлларда халык кайсы керә, кайсы чыга. **Ата угылны белми, ана кызны белми,** диерләр».

Халык иҗаты әсәрләрендә телнең сүзлек фонды үзенең бөтен байлыгы белән чагыла. Кайчандыр актив кулланылышта булып та, соңыннан җанлы сөйләм теленнән төшеп калган күп кенә архаик сүзләр фольклор текстларында еш очрыйлар. Табигый ки, К. Насыйри мәсьәләнең бу ягына да җитди әһәмият биргән. Кайбер мәкаль һәм табышмакларны ул аерым архаик сүзләрне аңлату һәм аларның элек татар телендә кулланылган булуларын исбатлау өчен файдалана. Мәсәлән: «**Тарла** — иген җире, асылда **тарлаудыр**. Лөгатемездә (телебездә — Х. М.) — бары бер җомакта мөстәгъмәл күренә (кулланыла — Х. М.). **Тарлавына тары сачдем, татлысына кинәндем** (мунча)». Яки: «**Тырантай**... карчыга җенесеннән бер коштыр ки, аның белән саед (аулау, ау — Х. М.) кылырлар... Ләкин лөгатемездә бер мөгаммада (табышмакта — Х. М.) мөстәгьмәлдер... **Туз чиләктә тырантай уйный**». Шушы ук алым диалекталь сүзләр белән эш иткәндә дә кабатлана. «**Сук**... киндер орлыгының сөтедер ки, кесәл белән ашарга хәзерлиләр. **Кесәле өйдә, сүге тышта**».

Күп кенә сүзләр, нинди контекстта кулланылуларына карап, төрле-төрле мәгънә төсмерләре белдерә алалар. Андый очракларда да кирәкле мисалларны К. Насыйри халык иҗаты әсәрләреннән китерергә ярата. Өзелмәк фигыленең күп мәгънәлелеген күрсәтү өчен ул түбәндәге халык җырына таянган:

**Өзелә чәчәк җилләр искәндә,**
**Өзелә йөрәк искә төшкәндә.**

Каюм Насыйри, халык иҗатын тирәнтен аңлаучы һәм кайнар яратучы буларак, фольклор әсәрләренең үзләренә дә кызыклы-кызыклы аңлатмалар, искәрмәләр биреп бара. Күп кенә мәкальләрнең һәм әйтемнәрнең халык телендә кайсы очракларда, нинди мәгънәдә кулланылуларын күрсәтә: «**Авызыңа бал да җау** (май — Х. М.) — яхшы хәбәр китергән кешегә әйтәләр»; «**Халык авызы капка,** ягъни: халык теләсә ни сөйләр, туктатыр хәл юк»; «**Өйрәледә бер кич, боткалыда ике кич,** ягъни: кән-төн кеше өстендә йөри»; «**Ырыкныкы ырыкка, шырыкныкы шырыкка,** ягъни: мал хәрамнән килгән булса хәрамга, хәләлдән килгән булса хәләлгә димәктән кинаядер» һ. б. Кайбер урыннарда галим мәкаль һәм әйтемнәрнең этимологиясен — аларның ничек килеп чыгуын да ачыкларга омтыла. Мәсәлән, бик сирәк күренүче кешегә «**Кара төлке булдың**» дип әйтү гадәте бар. Бу чагыштыру нәрсәгә нигезләнгән? Чөнки кара төлке — төлкенең бик сирәк очрый торган кыйммәтле төре. «**Мал — бавыр ите**» дигән мәкальнең ясалуын К. Насыйри бавыр янындагы итнең аеруча тәмле булуы белән аңлата.

Җыйнап әйткәндә, «Ләһҗәи татари»ны тулы нигез белән фольклор казнасы дип атап була. Без биредә кайбер әсәрләрне генә телгә алып уздык. Мондый мисалларны дистәләп китерергә мөмкин булыр иде. Әйтик, сүзлектәге мәкаль һәм әйтемнәр саны **170** тән артып китә. Тагын шунысы бик мөһим: монда теркәлеп калган халык иҗаты әсәрләренең байтагы К. Насыйриның башка хезмәтләрендә очрамый.

Билгеле булганча, 1975 елда бөек мәгърифәтченең тууына 150 ел тула. Бу күренекле дата хөрмәтенә аның тарафыннан язып алынган халык иҗаты материаллары махсус җыентык яки сайланма әсәрләренең аерым бер томы итеп матбугатка чыгарылыр дип ышанырга кирәк. «Ләһҗәи татари» сүзлегендәге фольклор әсәрләре дә бу олы мираска кыйммәтле бер өстәмә булып керергә лаеклар.

**ХУҖИ МӘХМҮТОВ,**
**филология фәннәре кандидаты**

Садыйк Чанышев

# МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ

Мирхәйдәр Фәйзи белән без 1919 елның язында таныштык. Үземнең туган авылым Юлыкка кайткан идем, шунда китапханәбезгә яңа китапханәче килүен һәм аның инде айдан артык эшләвен әйттеләр. Элек безнең авыл китапханәсендә махсус китапханәче юк, ул вазифаны үтәү авыл мәзиненә өстәмә эш итеп кенә йөкләтелгән иде. Шунлыктан китапханәнең билгеле эш сәгатьләре дә, юньле бүлмәсе дә юк иде. Мәзин аны бик сирәк һәм анда да кыска вакытка гына ача да, китергән китапларны тиз генә кабул итеп, яңаларын биреп җибәрә торган иде. Ә хатын-кызларга исә мәзингә күренеп йөрү гомумән тыелган булып, алар китап алу һәм китап тапшыруны бары тик мәзин хатыны аркылы махсус көннәрдә генә гамәлгә ашыралар иде. Ул заман өчен авылда китапханә булу мактаулы эш саналса да, менә шушы кимчелекләр нәтиҗәсендә безнең китапханәнең халыкны агартуда әллә ни зур эш майтара алганы юк иде. Шуңа күрә дә мин, яңа китапханәче килгәч, эшләр ничегрәк бара башлады икән дип кызыксынып, кайтып төшкән көнне үк китапханәгә кагылырга булдым. Иң элек шул нәрсә ачыкланды: яңа китапханәче эшли башлаган көннәрендә үк китаплар өчен махсус бүлмә булдыру чарасын күргән, эш сәгатьләрен билгеләгән һәм даими эшли башлаган икән.

Мин барганда Мирхәйдәр Фәйзи китапханәдә яңа китапларга карточкалар тутырып утыра иде. Ул мине якты йөз, тәмле сүз белән каршылады. Үзара танышканнан соң, иң элек мин аның өс-башының бик чиста һәм пөхтә булуына игътибар иттем. Юк, кыйммәтле материалдан тегелгән кием түгел иде ул. Гади генә, ул заманда бик күп кешеләр киеп йөри торган костюм-чалбар иде. Әмма әнә шул гади генә костюм да, чиста һәм яхшы итеп үтүкләнгән булганлыктан, бик затлы булып күренә һәм Мирхәйдәрнең үзенә килешеп тора иде. Киеме генә түгел, китапханәсе дә искиткеч чиста иде Мирхәйдәрнең. Стеналарына китапны яратырга өндәгән лозунглар, китапханәнең эш сәгатьләрен күрсәткән расписание, китап укучылар белергә тиешле кагыйдәләр эленгән. Өстәлендә алфавит буенча төзелгән китаплар карточкасы. Шкафлардагы китаплар шулай ук алфавит тәртибендә тезеп куелган. Кыскасы, Мирхәйдәрнең үз эшен яратып эшләве аермачык күренеп тора иде. «Китапханәчеләр менә шушылай булырга тиештер инде ул» дип, куанып куйдым мин ул көнне. Һәм аны якын итеп, үз итеп кайтып киттем.

Шуннан соң без Мирхәйдәр белән җае чыккан саен очраша башладык, дуслашып киттек. Миңа аның тагын бер матур ягы ачылды: ул гаҗәеп кешелекле, кыен чакта ярдәмчел иптәш булып чыкты. Бер вакыт шулай спектакль алдыннан Мирхәйдәрнең үтенүе буенча мин әдәбият һәм сәнгать турында доклад ясадым. Ләкин ул докладым бик үк уңышлы чыкмады һәм шуңа сәхнәдән бик нык кәефсезләнеп кердем. Мирхәйдәр ул кичтә булачак спектакльнең режиссеры да, актеры да, грим салучысы

да иде. Бер сүз белән әйткәндә — борылырга да арасы юк. Шулай булса да, ул минем хәлемне күреп һәм аңлап өлгергән булган икән: мин сәхнәдән керүгә, юатып, борчылмаска кушып, язу язып җибәрде. Язуы да тегенди-мондый гына түгел, гадәтенчә, матур һәм тигез хәрефләр белән язылган иде.

Үзенең китапханәчелек вазифасын төгәл үтәү белән бергә, Мирхәйдәр халыкны китапханәгә тартуга, әдәбиятны пропагандалауга да күп көч куйды. Юлыкка килеп эшли башлаган айларында ул авыл яшьләреннән драматик түгәрәк оештырды. Түгәрәк членнары тиздән спектакльләр дә куя башладылар. Бу эшне дә Мирхәйдәр башлап йөрде. Ул заман өчен зур түземлелек һәм тырышлык сорый торган эш иде бу. Хатын-кызларның күбесе спектакльдә уйнарга теләми, ә теләүчеләренә исә әтиәниләре рөхсәт итми иде. Шуңлыктан хатын-кызлар ролен дә ир-атлар башкарырга мәҗбүр. Ә мондый хәл спектакльнең тәэсирен шактый киметә һәм Мирхәйдәрне бик нык борчый иде. Әмма тора-бара без әлеге кимчелектән котылуның җаен барыбер таптык. 1919 елның сентябрендә мине Тимәс кантоны ревкомының халык мәгарифе бүлегенә секретарь итеп куйдылар. Тимәстә дә драмтүгәрәк бар, әмма анда да хатын-кызлар спектакльләр уйнауда катнашмыйлар иде. Аптырагач, Тимәснең хәрби коменданты вазифасын үтәүче Сәгыйтов агай кызларны, бигрәк тә укытучыларны, спектакль уйнарга боеру тәртибендә мәҗбүр итә башлады. Шулай итеп, Тимәстә эшләр җайланып китте. Ә Юлыкта хәл гел элеккечә иде әле. Минем Әдһәм исемле бертуган энем дә Юлыкта яшь һәм Мирхәйдәр оештырган драмтүгәрәкнең актив членнарыннан берсе иде. 1920 елның гыйнварында Әдһәм Тимәскә килеп, минем янга керде дә бу хатын-кызларны ничек итеп спектакльләргә тартырга икән соң, дип аптырап сөйли башлады. Күп уйлап тормадым, иптәш Сәгыйтовтан үрнәк алып, түгәрәк җитәкчесенә, спектакль уйнау өчен кирәк булган хатын-кыз укытучыларны түгәрәк эшенә тарту хокукы бирелүен әйтеп, кантон җитәкчесе исеменнән язу яздым, печать бастырдым да аны энемә биреп җибәрдем. Бүгенге күзлектән чыгып караганда бу хәл шактый сәер күренә. Әмма ул чакта шулай итмичә булмады: бозны кузгатып җибәрергә, чирканыч алырга кирәк иде. Һәм, чыннан да, хатын-кыз укытучыларны боерык тәртибендә сәхнәдә уйната башлауга күп тә үтмәде — бу хәл гадәткә кереп китте: укытучылар гына түгел, авыл кызлары да үзләре теләп түгәрәк эшендә катнаша башладылар. Шунысын да ассызыклап әйтим, мәсьәләнең шушылай чагыштырмача ансат хәл кылынуын түгәрәкнең җитәкчесе Мирхәйдәр Фәйзи булуы ифрат зур роль уйнады. Аның искиткеч инсафлы, ышанычлы, гадел һәм сабыр булуын бөтен авыл халкы белә, аны хөрмәт итәләр иде. Шуңлыктан ата-аналары түгәрәккә йөрергә теләүче кызларына башта бик нык каршы торсалар да, тора-бара хәер-фатихаларын бирмичә булдыра алмадылар. Әле моннан өч-дүрт ел элек кенә хатын-кызлар сәхнәгә чыгып уйнау түгел, урамда да ир-ат күренсә дә битен яулык чите белән каплап үтәргә тиеш булганлыгын искә алсак — зур үзгәреш иде бу. Авыл тормышында үзенә күрә бөтен бер революция иде.

Ә һәр революциядә контрреволюцион элементлар була. Мирхәйдәрнең драма түгәрәге эшен әйбәт кенә җайга сала башлаган көннәрдә ул түгәрәкнең таркалу куркынычы килеп чыкты. Һәр яңалыкка каршы торучылар коткысы белән Юлыкның берничә егете бер көнне тавыш-гауга куптарганнар. Түгәрәк членнарының байтагы шүрләп калган, спектакльләрдә уйнаудан баш тарта башлаганнар.

Шулай итеп, тагын бер кат кантон җитәкчесе исеменнән бик нык кисәтүле хат язып, драмтүгәрәк эшенә аяк чалучыларны тәртипкә китерергә туры килде. Әгәр тагын шундый эшләре кабатланса, хөкемгә тартылачаклары мәгълүм булгач, теге тәртип бозган егетләр килеп гафу үтенделәр. Аннары үзләре үк спектакль барган вакытларда тәртип саклый башлап, Мирхәйдәрнең ярдәмчеләренә әверелделәр.

Мирхәйдәр Юлыкта ике елга якын яшәде һәм авыл халкының рухи тормышын яктырту эшендә тирән эз калдырып китте. Шул ук Юлык та Мирхәйдәр иҗатына бик нык тәэсир итте. Әдипнең безнең авылга килү очрагы үзе үк аның иҗатына турыдан-туры бәйле. Эш менә болайрак була. 1915 елда Орск шәһәренә хәрби хезмәткә китеп баручы бер бик чибәр, тапкыр сүзле, шат күңелле җырчы һәм гармунчы егетне очрата Мирхәйдәр. Безнең Юлык авылының Әдһәмов Вафа исемле егете була ул. Вафа үзенең һәр яктан уңганлыгы, осталыгы белән әдипкә бик зур тәэсир итә һәм аны татар әдәбиятының алтын фондына кергән, әле хәзер дә сәхнәдә уйналып

килә торган «Галиябану» пьесасын язарга, шул пьесаның төп герое Хәлил образын тудырырга рухландыра. Менә шуннан соң Юлыкка килә Мирхәйдәр. (Бу турыда миңа ул үзе сөйләде.) Юлыкта ул тагын бер әйбәт әсәрен — «Кызыл йолдыз» пьесасын иҗат итә. Бу әсәре шулай ук Юлык тормышына нигезләнеп язылганлыгын Мирхәйдәр Фәйзи миңа үзе әйтте. Хәер, автор үзе әйтмәсә дә, әсәр белән таныш булган безнең як кешесенә моның шулай икәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде.

Китапханәдә тырышып эшләү белән беррәттән, драма әсәрләре язуга да күп көч сарыф иткәнгә күрә, Мирхәйдәрнең болай да шәптән булмаган сәламәтлегә тагын да ныграк какшый башлаганлыгы тора-бара аның йөзенә үк чыкты. Ул ябыгып калды. Хезмәт хакы да аз булганлыктан, шул хәлендә яшәсә, аның эшләре бөтенләй мөшкелләнеп китүе бик ихтимал иде. Менә шуларны күздә тотып һәм әдипнең хәлен бераз яхшырту максатыннан чыгып, кантон халык мәгарифе бүлеге һәм Тимәс яшьләре драмтүгәрәге инициативасы белән Мирхәйдәр Фәйзи кантон үзәгенә — Тимәскә чакырып китерелде. Ул анда драмтүгәрәкнең режиссеры, җитәкчесе һәм «Кызыл Урал» газетасының редакторы булып эшли башлады. Аның хезмәт хакы бераз артты, материаль хәле арулана төште. Әмма бу — мәсьәләне тулысынча хәл итү түгел иде әле. Мирхәйдәрнең хәлен яхшырту өчен аңа күп мәртәбә уңайлырак шартлар тудырырга кирәк иде. Ләкин аякны юрганга карап сузарга туры килә шул. Мирхәйдәрнең материаль хәлен сизелерлек яхшырту бары тик 1924 елда гына мөмкин булды. Башкорт тау-завод тресты идарәсе (мин ул чакта шул трестта председатель урынбасары булып эшли идем) Мирхәйдәр Фәйзине Тубинск рудникы эшчеләре клубы китапханәсенә мөдир итеп эшкә урнаштырды һәм аңа бүтән китапханәчеләргә караганда шактый зур хезмәт хакы билгеләде. Кирәк булган әдәбиятны һәм җиһазларны китапханәгә кайтарту хокукы да Мирхәйдәрнең үзенә тапшырылды. Мирхәйдәрнең күңеле күтәрелеп китте һәм дәртләнеп эшкә кереште.

1925 елда әлеге трест идарәсе бакыр эретү заводы салынган Баймакка күчерелде. Мирхәйдәр Фәйзи дә безнең белән Баймакка килеп эшен дәвам итте. Анда да ул үз вазифасын һич авырсынмыйча, яратып башкарды. Халыкта, бигрәк тә яшьләрдә, китап укуга мәхәббәт уятуда, драма түгәрәге оештыруда күп көч куйды. Шул тырышлыгы нәтиҗәсендә ул халык арасында бик тиз танылды, аны һәркем хөрмәт итеп карый иде.

Соңгы өч-дүрт ел эчендә материаль хәле әйбәтләнүгә карамастан, Мирхәйдәр Фәйзинең бала чактан ук какшап калган сәламәтлегә яхшыра алмады. Әле 1919 елда, Юлыкта яшәгән чагында ук, ул нык кына тиф белән авырып алды. Ул көннәрдә мин хәрби хезмәткә чакырылу буенча Орскига барырга тиеш идем. Юлга чыгар алдыннан саубуллашырга дип фатирына баргач, Мирхәйдәр миңа кәефе әйбәт булмавын, йөрәге аркасында үлеп китүдән шикләнүен әйтте. Хәтта шул чакта аның күзеннән яшь тә бәреп чыкты. Мин аны мөмкин булганча юатырга, тынычландырырга тырыштым һәм Орскига барышлый туганнарына кагылып, хәлен сөйләп бирергә вәгъдә иттем. Мин вәгъдәмне үтәдем. Шуннан соң аны, туганнары килеп, Юлыктан үзләренә алып кайтканнар, һәм ул шуннан савыгып кайтты.

Мирхәйдәр безнең танышлыкның беренче көннәреннән үк йөрәгенең начар эшләвеннән зарланып, үзендә йөрәк авыруы булуын әйтеп килде. Шуңа күрә беркайчан да ашыгып йөри алмыйм мки, дия иде ул. Үзендә йөрәк авыруы бар дип уйлау аркасында бервакыт шактый мәзәк хәлгә дә калган. 1922—1925 елларда Башкортстан тау-завод трестының управляющие булып безнең Юлык авылында туып-үскән Габитов агай эшләгән иде. 1926 елда аны Башсовнархоз председателе итеп куйдылар һәм менә шул агай Мирхәйдәрне берничә көнгә үзенә кунакка алып киткән иде.

Бер дә бер көнне, Габитов агай эштән кайтып кергәндә, Мирхәйдәр бик кайгырып, урында ята икән. Габитов агай ни булды дип сорагач:

— Йөрәгем әллә нишләде: шундый каты тибә, хәтта караватлар селкенә! Дарулар да эчеп карадым, әмма барыбер файдасы юк,— дигән Мирхәйдәр.

Тикшерә торгач менә нәрсә мәгълүм булган: ул көнне Габитов агайлар өенә күрше урамда дизель двигателе эшләтә башлаганнар да, шуның нәтиҗәсендә тегеләр квартирасының идәннәре дерелдәгән икән. Ә ул дерелдәү ритмы, гөнаһ шомлыгына каршы, Мирхәйдәрнең йөрәк тибеше рктмына туры килгән дә, шуңа аның үз йөрәге шулай каты тибә тесле тоелган. Мәсьәләне аңлатып биргәч, Мирхәйдәр көлеп җибәргән дә урыныннан торып, бөтенләй «савыгып» киткән.

Сүз дә юк, йөрәге дә авыртулы булгандыр. Әмма Мирхәйдәрнең иң куркыныч авыруы — үпкә авыруы булып чыкты. Аның ябыклыгы да, хәлсезлеге дә йөрәк авыруыннан битәр үпкәләренә бәйле иде. Аңа дәваланырга кирәклеге көн кебек ачык, әмма ул ничектер бу мәсьәләгә артык әһәмият бирми иде.

1922 елның җәендә мин ялга чыктым һәм ялымны күчмә башкортларда (ул чакта ул тирәләрдә башкортлар ярым күчмә тормыш алып баралар, иртә яздан кара көзгә тикле тирмәләрдә яшиләр иде) үткәрергә булдым. Исмәгыйль дигән бер бай белән сөйләшеп, аның кунак тирмәсендә яшәргә, хуҗалыгыннан көн саен дүрт чирек (12 литр) кымыз алырга һәм кирәк чакта атын алып торырга килештем. Шунда, кунак итеп, үзем белән Мирхәйдәрне дә алып барырга булдым. Аның да ял вакыты туры килгәнлектән, Мирхәйдәр кыстатыбрак кына булса да ризалашты, һәм ул елны без аның белән шактый күңелле ял иттек. Байның кымызы шәп иде. Атнага бер тапкыр егерме километрга базарга барып, ит алып кайтабыз да ике көн яңа ит ашыйбыз (шуннан ары да ашар идек тә — саклап булмый). Бүтән көннәрдә мин алып килгән кипкән бәрәңгене суда җебетеп майда кыздырабыз, каймаклап чәй эчәбез, ә иң мөһиме — чәчәкле һәм хуш исле дала һавасын туйганчы сулап, арганчы далада йөрибез. Хәйдәрнең дусты чакыруы буенча, шул ял вакытында ике генә көнгә «Урал буенда» исемле пьеса героинясы Зифаның прототибы Гайшә туып-үскән җиргә — Мортазин Шәрип хуторына да барып килдек.

Исмәгыйль инде алтмыштан узган карт иде. Шулай булса да, ул моннан берничә ел элек кенә яшь бер чибәр кызга өйләнгән икән. Аның яшь хатынына егерме бишегерме алтыдан ары юк иде бугай. «Бугай» дип шуңа әйтәм, чөнки без аны нибары бер генә мәртәбә, анда да «ялгыш кына» күреп калдык. Ә менә чибәрлеккә, һичшиксез, бер күрүдә дә истә калырлык чибәр иде ул. Нигә кирәге булды соң әле ул байбичәнең дип гаҗәпләнмәгез. Хикмәт шунда, кич ятарга урын җәйгән чакта, мендәребез астына кыстырылган каен тузы килеп чыкты. Ул тузга кызлар почеркы белән мәхәббәт җыры язылган иде. Ләкин кем эше икән соң бу! Без тирмәдә булганда яныбызга бернинди хатын-кызның да кереп караганы юк, гомумән, күчмә башкорт хатын-кызлары безгә күренмәскә тырышалар иде. Ләкин без кайтканда тирмәбез җыештырылган, чәй кайнатылган һәм аш-су әзерләп куелган була. Төнлә атлар көтүче агайның әйтүенә караганда, безнең тирмәне байның әлеге яшь хатыны белән туганнан туган сеңелесе бергәләп җыештыралар икән. Тик кайсысы шушылай шигъри җанлы икән соң боларның!

Икенче көнне далага йөрергә чыкканда Мирхәйдәр, теге җырга җавап итеп, тагын да шәбрәк шигырь язып калдырды. Андыйга бик маһир кеше иде ул!

Без түземсезлек белән көтә башладык: җавап булырмы! Төшкә кайту белән үк мендәр астын карадык — җавап юк иде. Тагын далага чыгып киттеп, юри озаклап йөреп кайттык — ләкин бу юлы да мендәр асты буш булып чыкты. Икенче, өченче көнне дә җавап булмады. Һәм без инде тәмам өметебезне өзә язган идек. Ләкин дүртенче көнне кичкә Мирхәйдәр мендәре астына берьюлы өч каен тузы кыстырып куелганын күреп шаккаттык. Аларның өчесенә дә әлеге таныш почерк белән искиткеч җылы шигъри хат — мәхәббәт хаты язылган иде. Мирхәйдәр аңа каршы тагын шигырь язып калдырды. Шулай итеп, көн саен хат алышу башланды.

Мирхәйдәр, ялы бетү сәбәпле, миннән берәр атна алданрак кайтып китте. Пьеса язганда кирәкләре чыгар әле дип, теге серле каен тузларын да үзе белән алды.

— Мондый хатлар тагын килер әле, Садыйк. Исемеңне атамаса да, сиңа языла бит инде болар. Килгән хатларга җавап бир, тик берсен дә югалтма, җыеп бар,— диде.

Ул хатлар берсе дә кемгә булса да атап язылмаган, шуңа күрә Мирхәйдәр аларны миңа адресланган дип, ә мин аңа язылган дип уйлый идек. Әмма алар Мирхәйдәргә язылган булганнар икән, чөнки ул кайтып китү белән хатлар килми башлады.

Әйе, хатларның адресаты ачыкланды. Ләкин аларны әлеге кыз язганмы, әллә яшь хатыны язганмы — анысын мин хәзер дә өзеп кенә әйтә алмыйм. Шунысын гына өзеп әйтә алам: ул хатлар Мирхәйдәрнең күңелен күтәрде, аңа рухи көч, иҗади дәрт бирде.

Ял итәргә дип кенә килгән булсак та, Мирхәйдәр анда да туктаусыз иҗади уйланып йөрде. Хәтеремдә, ул «Мәдинәкәй» исемле җырның көе татарныкымы, башкортныкымы икәнлеген һәм аның тарихын белергә теләде. «Мәдинәкәй» исемле пьеса яза

башлаган икән дә, әлеге җыр шул пьеса өчен кирәк булган икән. Мин шул чакта «Мәдинәкәй»нең кем көе булуын өзеп кенә әйтә алмадым. Соңыннан, сораша-эзләшә торгач, аның тарихын белүчеләрне очраттым һәм алар сөйләгәнне Мирхәйдәргә язып җибәрдем. Тарихына караганда, «Мәдинәкәй» татар көе булып чыкты. Мирхәйдәр миңа пьесасын инде тәмамлап килүен, аның сюжеты мин язып җибәргән тарихтан шактый аермалы булуын, әсәрен «Хәмдия» дип үзгәртүен әйтеп, җавап бирде. Ахыр чиктә ул аны «Ак калфак» дип атады.

Үпкәсе авыру булуга да карамастан, Мирхәйдәр беркайчан да төшенкелеккә бирелмәде, гел шат күңелле, актив иде. Яшьләр белән пикникка чыккан вакытларында җыр һәм уеннарны башлап ул оештыра, үзе дә яшәреп киткәндәй булып, шаярып-уйнап йөри иде. Һич тә онытасым юк, ул Юлыкта яшәгәндә бер көнне без аның белән авыл тирәсендә, таулар буена йөрергә чыккан идек. Шунда һич көтмәгәндә генә кисәкле булып болыт килеп чыгып, яшен яшьнәргә һәм ишеп яңгыр коярга тотынды. Без тау куышына ышыкланырга мәҗбүр булдык. Болай караганда бер дә көлкеле хәл түгел. Әмма Мирхәйдәрнең кәефе шул тикле шәп иде, ул, ялт-йолт итеп торган яшенгә дә, җирләрне селкетеп күк күкрәүгә һәм коеп яуган яңгырга да исе китмичә, рәхәтләнеп шаян җырлар җырлап утырды, хәтта, балаларча кызып китеп, тыпырдатып биеп тә алгалады.

Ләкин аның авыруы еллар үткән саен көчәя барды. Аңарчы артык исе китми генә йөрсә дә, 1926 елда Мирхәйдәр, ниһаять, дәвалану өчен Кырымга барырга карар кыла. Шунда барышлый ул, Уфада тукталып, сәхнәдә куелган пьесалары өчен тиешле булган гонорарын да алып китәргә ниятли. Әмма труппа җитәкчесе аңа, бер айсыз акча булмаячак, чөнки кассада акча юк, дип җавап бирә. Ә Мирхәйдәр шул акчага да ышанып юлга чыккан була. Эшләр менә шулай кыенлашып киткәч, аптырашка калып, Мирхәйдәр минем янга (мин ул чакта Башкорт дәүләт планы председателе урынбасары булып эшли идем) керде. Мин тиз генә әлеге труппа җитәкчесе белән бәйләнешкә кердем һәм, аның акча булу белән түлим дигән сүзенә ышанып, тиешле акчаны биреп җибәрдем. Вәгъдә иткән вакытыннан бик күп соңга калып булса да, Мирхәйдәр ул акчаны соңыннан чыннан да миңа кайтарды.

Икебез ике җирдә эшләгәнлектән, безнең Мирхәйдәр белән очрашуларыбыз сирәгәйде. Әмма без араны өзмәдек. Хат аша хәбәрләшеп тордык. Аның хатларының бөтенесе дә дип әйтерлек «Садыйк дус» дип башлана һәм бик җылы итеп язылган була торган иде. Кызганычка каршы, әдипнең хатлары миндә сакланмаган. Әгәр сакланган булсалар, мин бу истәлекләремне бик күп мәртәбә тулырак яза алыр идем.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СССР ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНДА

СССР язучылары союзы идарәсенең чираттагы утырышында Союздаш республикаларның әдәби журналларындагы әдәби тәнкыйть мәсьәләләре тикшерелде. СССР язучылары союзы идарәсе секретаре, Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе Зәки Нури утырышта ясаган чыгышында «Казан утлары» журналындагы әдәби тәнкыйтьнең бүгенге торышына тукталды.

## ДОНБАССТА СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ АТНАЛЫГЫ

ВЦСПС, СССР язучылары союзы һәм Украина язучылары союзы тарафыннан Донбасста СССР оештырылуга 50 ел тулуга багышланган әдәбият атналыгы үткәрелде. Россия шәһәрләреннән, Украинадан, Белоруссиядән, Әзәрбайҗаннан, Грузиядән, Латвиядән, Таҗикстаннан, Төркмәнстаннан, Татарстаннан, Башкортстаннан, Кабардино-Балкариядән, Адыгей автономияле республикасыннан, Дагстаннан килгән язучылар Донбасстагы шәһәрләрдә, район үзәкләрендә һәм авылларда булып, йөзгә якын әдәби очрашу үткәрделәр. Бу очрашуларга утыз меңнән артык кеше катнашты.

Донбасста Франциягә яки Япониягә караганда күбрәк күмер чыгарыла, паровозлар эшләнелә. Бу турыда КПССның Ворошиловград өлкә комитетындагы әңгәмә вакытында сөйләнде. Татарстан язучылары вәкиле Зәки Нури әңгәмәгә катнашучыларны татар язучыларының иҗаты, татар әдәбиятының бүгенге торышы белән таныштырды.

КПССның Ворошиловград өлкә комитеты, хезмәт ияләре һәм шахтерлар исеменнән, татар язучыларын Донбасска татар әдәбияты атналыгы үткәрергә чакырды.

Ворошиловград шәһәренең Ленин районындагы Маяковский исемендәге культура сараенда эшчеләр, шахтерлар, инженер-техник хезмәткәрләр язучыларны зурлап каршы алдылар. Зәки Нури хезмәт ияләренә Татарстаннан сәлам тапшырды, үзенең әсәрләрен укыды.

Кырыктан артык язучы Ровеньки шәһәрендә булдылар һәм анда яшь гвардиячеләр истәлегенә оештырылган музейны карадылар, хезмәт ияләре белән очраштылар. Ә аннан Краснодон шәһәренә киттеләр. Краснодонда «Яшь гвардия» мемориаль комплексы һәм музее белән таныштылар.

Күренекле совет язучысы, «Яшь гвардия» романы авторы А. А. Фадеевның тууына 70 ел тулу уңае белән «Яшь гвардия» исемендәге культура сараенда тантаналы кичә булды. Кичәне Украина коммунистлар партиясенең Краснодон шәһәр комитеты беренче секретаре Иван Ляхов ачты. Совет язучылары исеменнән Краснодон хезмәт ияләрен котлап, Алим Кешоков чыкты. Залда утыручылар Александр Фадеевның магнитофон лентасына язылган речен тыңладылар. Зәки Нури А. А. Фадеевның Бөек Ватан сугышы елларында Татарстанда булуы, татар язучылары белән элемтәсе турында сөйләде. Кичәдә уннан артык язучы һәм шахтерлар бригадиры, Социалистик Хезмәт Герое А. Колесников чыгыш ясады.

Зәки Нури шулай ук, бер төркем язучылар белән бергә, Ворошиловград өлкәсенең Старобельский, Белокуракинский, Новопсковский район культура йортларында авыл хезмәт ияләре белән очрашуларга катнашты.

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНДА

РСФСР язучылары союзы идарәсенең Мәскәүдә, Үзәк әдипләр йортының Зур залында үткәрелгән чираттагы пленумына Россия федерациясенең күренекле прозаиклары һәм шагыйрьләре, әдәби журналларның баш редакторлары, РСФСРдагы язучылар оешмасы җитәкчеләре һәм илледән якын яшь язучы катнашты. Кереш сүз белән РСФСР язучылары союзы идарәсе председателе С. Михалков чыкты. Г. Коновалов белән Д. Кугультинов яшь прозаиклар һәм яшь шагыйрьләр әсәрләрендәге сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе, аларның гражданлык һәм иҗади йөзе турында доклад сөйләделәр.

«Елганың агышы һәм диңгезгә коюы кебек үк, әдәбиятка яшь, яңа көчләрнең даими килеп торуы табигый һәм зарури күренеш,— диде Татарстан язучылары союзы идарәсе председателе, СССР язучылары союзы идарәсе секретаре Зәки Нури.— Әдәби алмаш тәрбияләү зур һәм мактаулы бурычыбыз. Шулай ук зур әдәбиятка аяк басучылар алдында да җитди һәм катлаулы бурычлар тора: алар халык һәм заман алдында үз иҗатлары өчен, үзләренең иҗтимагый йөзе өчен тирән җаваплылык сизәргә тиешләр».

Аннары оратор Татарстаннан пленумга чакырылган яшь шагыйрь Зөлфәт, яшь

драматург Диас Вәлиев һәм башка яшь язучылар иҗатына да тукталды.

Василий Федоров поэма жанры алдында торган бурычлар турында сөйләде. Ул татар шагыйре Илдар Юзеевнең «Соңгы сынау» исемле драматик поэмасын әдәбиятта эз калдырырлык күренеш дип билгеләп үтте. Докладларга карата фикерләре әйтеп, утыздан артык кеше чыгыш ясады.

Пленумга Татарстаннан «Казан утлары» журналының баш редакторы Г. Ахунов, шагыйрь С. Хәким һәм РСФСР язучылары союзының ревкомиссия члены, Татарстан язучылары союзының Әлмәт бүлеге секретаре Р. Фәйзуллин, шагыйрь Гәрәй Рәхим катнашты.

## ЧИК САКЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА ИҢ ЯХШЫ ӘСӘРЛӘРГӘ КОНКУРС

Чик сакчылары гаскәрләренең политик идарәсе, СССР язучылары союзының хәрби әдәбият комиссиясе һәм «Пограничник» журналы редакциясе иң яхшы хикәягә, очеркка, повестька һәм бер пәрдәлек пьесага конкурс игълан итте.

Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләрдә чик сакчыларының героик эшләре, замандашларыбыз характерындагы иң яхшы сыйфатлар сурәтләнергә, фидакарь, зирәк, көчле ихтыярлы сугышчы тәрбияләү процессы күрсәтелергә тиеш.

Конкурс 1972 елның 1 гыйнварыннан 1973 елның декабрена кадәр үткәрелә.

Конкурска 1972 елның 1 гыйнварына кадәр беркайда да басылып чыкмаган әсәрләр кабул ителә. Конкурс дәвамында басылып чыккан әсәрләр турында автор жюрига хәбәр итәргә тиеш. Кульязмалар, машинкада басылып, ике данәдә җибәрелә. Очеркның күләме 15 биттән, хикәянең 25 биттән, повестьның 100 биттән артмаска тиеш.

Иң яхшы әсәрләрнең авторларына түбәндәге премияләр биреләчәк.

**Иң яхшы повестька:**

**Беренче премия — 600 сум.**
**Икенче премия — 400 сум.**
**Өченче премия — 300 сум.**

**Иң яхшы хикәягә:**

**Беренче премия — 250 сум.**
**Икенче премия — 150 сум.**
**Өченче премия — 100 сум.**

**Иң яхшы очеркка:**

**Беренче премия — 200 сум.**
**Икенче премия — 150 сум.**
**Өченче премия — 100 сум.**

Болардан тыш яшь авторлар өчен 100 әр сумлык өч кызыксындыру премиясе һәм иң яхшы бер пәрдәлек пьеса өчен 350 сумлык премия билгеләнде.

Кульязмаларны: г. Москва, Главпочтамт, а/я 848 адресы буенча девиз белән җибәрергә (авторның исеме, атасы исеме, фамилиясе һәм адресы аерым конвертта девиз, әсәренең исеме күрсәтелеп җибәрелә).

## ФӘННИ СЕССИЯ

СССР оештырылуга 50 ел тулуга багышлап, Казан Горький музее, СССР фәннәр академиясенең М. Горький исемендәге дөнья әдәбияты институты белән берлектә, Питрәч районы культура йортында фәнни конференция үткәрде. Конференциядә филология фәннәре докторы, профессор Б. А. Бялик (Мәскәү) «Горький һәм хәзерге заман», Казан Горький музее фәнни хезмәткәре Ю. Елизарова «Горький һәм совет язучылары» дигән темаларга докладлар укыдылар.

## ЗУР БҮЛӘК

Совет әдәбиятына күрсәткән зур хезмәтләре өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән күренекле татар язучысы Габдрахман Әпсәләмовны хөкүмәтебез Октябрь революциясе ордены белән бүләкләде.

## СИБГАТ ХӘКИМГӘ 60 ЯШЬ

Республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле шагыйрь, Г. Тукай һәм М. Горький исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәкимгә 60 яшь тулу көнен киң итеп билгеләп үтте. Шәһәр һәм авыл клубларында, китапханәләрдә, югары уку йортларында мәктәпләрдә шагыйрь иҗатына карата әдәби кичәләр үткәрелде, китап күргәзмәләре оештырылды.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында үткәрелгән тантаналы кичәгә галимнәр, язучылар, журналистлар, укытучылар, укучылар, студентлар, бик күп әдәбият сөючеләр катнашты. Сибгат Хәкимнең тормышы һәм иҗади эшчәнлеге турында докладны Г. Ахунов ясады. Республикабыз предприятиеләре, завод-фабрикалары, колхозлары, учреждениеләре, югары уку йортлары, мәктәпләре вәкилләре шагыйрьне котлап адреслар тапшырдылар, истәлекле бүләкләр бирделәр.

Соңыннан сәнгать осталары һәм үзешчән сәнгать көчләре катнашында зур концерт булды.

Хөкүмәтебез Сибгат Хәкимне 60 яшь тулу уңае белән һәм совет әдәбиятына күрсәткән зур хезмәтләре өчен илебезнең иң югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкләде.

## КАВИ НӘҖМИНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

СССР Дәүләт премиясе лауреаты Кави Нәҗминең тууына 70 ел тулу көненә багышланган юбилей кичәсе Актерлар йортында үткәрелде. Язучының тормышы һәм иҗади эшчәнлеге турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Нур Гыйззәтуллин ясады.

## ЗӘКИ НУРИГА 50 ЯШЬ

Шагыйрь Зәки Нурига 50 яшь тулу уңае белән Чүпрәле районында, шагыйрьнең туган авылы Татар Төкесендә, «Ялкын» колхозының үзәге Иске Кәкерле авылында һәм район үзәгендә әдәби-музыкаль кичәләр булып үтте. Әдәбият белгече Н. Хисамов шагыйрьнең тормышы һәм иҗади-иҗтимагый эшчәнлеге турында сөйләде, Зәки Нури, Н. Дәүли, Б. Камалов үзләренең әсәрләрен укыдылар, иҗат планнары белән уртаклаштылар. Татарстанның атказанган артисты Г. Рәхимкулов, Наҗия Теркулова һәм Рабига Сибгатуллина татар композиторларының Зәки Нури сүзләренә язылган җырларын башкардылар. Кичәләр вакытында шагыйрьнең бик күп китаплары сатылды. Мәктәп укучылары аны Почетлы пионер итеп алдылар. Якташлары З. Нурины котладылар, истәлекле бүләкләр бирделәр.

Татар дәүләт академия театры бинасында З. Нури иҗатына багышланган тантаналы кичә үткәрелде. Аның тормышы һәм иҗади-иҗтимагый эшчәнлеге турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт ясады. Юбилярга бик күп котлау адреслары, истәлекле бүләкләр тапшырылды. Соңыннан Татарстанның сәнгать көчләре зур концерт бирделәр.

Юбилей уңае белән СССР язучылары союзы идарәсе секретариаты, СССР халыклары әдәбиятлары советлары бюросы һәм Әдәби тәрҗемә советы шагыйрьгә түбәндәге котлауны җибәрде:

«Кадерле Зәки Шәрәфетдинович!

Сез әдәбиятка Бөек Ватан сугышы фронтларыннан килгән совет язучыларының данлы буыны вәкиле. Илебезнең көнбатыш фронтында сугышка кереп, Сез, Белоруссия җирен тәмам азат итеп бетергәнче, партизаннар сафында сугыштыгыз, Константин Заслонов җитәкчелегендәге данлыклы партизан берләшмәсендә разведка начальнигы булып эшләгән эшегез сезнең поэзиянең төп эчтәлеген билгеләде, 1945 елда басылып чыккан беренче шигырьләр җыентыгында да, башка китапларыгызда да, поэма һәм очеркларыгызда да талантлы чагылыш тапты.

Татар укучысын тугандаш халыкларның рухи байлыгы белән таныштыруда да Сезнең хезмәтегез зур. Сез Лермонтов һәм Некрасов, Шевченко һәм Махтумкули, Есенин һәм Твардовский, Гафур Гоҗәм һәм Якуб Колас, Петр Хузангай һәм Рәсүл Гамзатовның күп кенә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә иттегез. «Дуслык бәйләме» сериясендә күп милләтле совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре сезнең тәрҗемәдә аерым китаплар булып даими чыгып килә.

Шунысын да билгеләп үтү күңелле: Сез, күңелегезнең бөтен кайнарлыгын һәм оештыру талантыгызны туган әдәбиятны үстерү эшенә биргән хәлдә, шигъри иҗатыгызны зур иҗтимагый эшчәнлегегез белән бәйләп алып барасыз.

Сезнең сугыштагы батырлыгыгыз һәм әдәбият үсешендә күрсәткән зур хезмәтләрегез югары хөкүмәт бүләкләре белән билгеләп үтелде.

Кадерле дустыбыз, сәламәтлек, зур иҗади уңышлар һәм бәхет теләп, Сезне туганнарча кочакларга рөхсәт итегез».

## ОЧРАШУЛАР

Фронтовик язучылардан З. Нури, Г. Паушкин, Н. Дәүли, Ю. Белостоцкий һәм әдәбият белгече Р. Мостафин Казан югары команда-инженерлык училищесында булдылар, курсантларга татар язучыларының фронтта күрсәткән батырлыклары турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләре белән таныштырдылар.

* * *

Шагыйрь Н. Дәүли һәм прозаик Ю. Белостоцкий Казан сәүдә клубында сәүдә хезмәткәрләре белән очрашып, үзләренең иҗат планнары белән уртаклаштылар, яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Казан дәүләт университеты студентлары язучы Нурихан Фәттах белән очрашты. Язучы үзенең «Әтил суы ака торур» романының язылу тарихы һәм тарихи романны язганда туа торган кыенлыклар турында сөйләде, киләчәктә дә тарихи әсәрләр өстендә эшләячәген әйтте.

* * *

Арча педагогия училищесында Сибгат Хәкимгә алтмыш яшь тулуга багышланган әдәби кичә булды. Анда язучылардан С. Хәким, Г. Ахунов, Ш. Галиев, Р. Харисов катнашты.

* * *

Шундый ук кичәләр, С. Хәким, М. Мәһдиев, Г. Рәхим, Ф. Миңнуллин, Т. Галиуллин, Ф. Урманчеевлар катнашында, Алабуга педагогия институтында, культура-агарту мәктәбендә дә үткәрелде.

* * *

Казан шәһәренең Ленин районындагы химиклар культура сараенда үткәрелгән әдәби кичә дә Сибгат Хәким иҗатына багышланды. Тәнкыйтьче Р. Мостафин оргсинтез заводы эшчеләренә, инженер-техник хезмәткәрләренә шагыйрьнең тормышы һәм иҗади эшчәнлеге турында сөйләде. Сибгат Хәким үзенең иҗат планнары белән уртак-

лашты һәм яна әсәрләрен укыды. Казанда яшәүче рус шагыйре Н. Беляев укучыларны шагыйрьнең рус теленә үзе тәрҗемә иткән шигырьләре белән таныштырды.

* * *

Бер төркем яшь язучылар — Р. Гатауллин, Ә. Рәшитов, Р. Мингалимов, З. Насыйбуллин, М. Әгъләмов, М. Зарецкий, Ә. Синегулов һәм В. Монасыйпов — КПСС өлкә комитетының партия мәгарифе йортында республикабыз районнарыннан килгән авыл Советы председательләренә үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Шагыйрь М. Ногман, җырчылардан Г. Рәхимкулов һәм Ф. Сөләйманова Балык Бистәсе районының Ямаш, Югары Тегермән, Түбән Тегермән, Казаклар, Шемербаш, Котлы Бөкәш, Чаллы, Мәшләк, Биектау, Яңа Сала, Күгәрчен авылларында булып, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр.

## АБДУЛЛА АЛИШ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

Куйбышев районының Абдулла Алиш исемендәге совхоз дирекциясе, партия комитеты һәм профсоюз оешмасы Абдулла Алиш исемендәге премия билгеләде. Бу премия елга бер мәртәбә совхозның иң яхшы эшчесенә бирелә.

Абдулла Алиш исемендәге премиянең беренче лауреаты — совхоз көтүчесе Н. Хафизов.

## ЯЗУЧЫГА БҮЛӘК

Гражданлык оборонасы буенча пропаганда эшендә актив катнашуы, газета-журналларга гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы ветераннары турында очерклар һәм мәкаләләр язуы, авыл клубларында, китапханәләрендә бу темага карата лекцияләр укуы, кичәләр үткәрүе өчен язучы Самат Шакирны Татарстан АССР Гражданлык оборонасы штабы «СССР Гражданлык оборонасы отличнигы» билгесе белән бүләкләде.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Прозаиклар секциясенең чираттагы утырышында филология фәннәре кандидаты, язучы М. Мәһдиев «Хикәядә осталык» дигән темага доклад ясады. Докладчы классик язучыларның хикәяләргә булган таләпләре турында сөйләде, хәзерге язучыларның кайбер хикәяләренә анализ ясады. Доклад буенча фикер алышуга Ф. Хөсни, Б. Камалов, М. Рафиков, Н. Дәүли, Х. Сарьян һәм Г. Миннул катнашты.

## ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ

«Татарстан яшьләре» газетасы каршында эшләп килгән әдәби берләшмәнең отчет-сайлау утырышы булды. Биредә эшләнгән эшләргә йомгак ясалды, яшь әдипләрнең тикшерелгән әсәрләрен матбугат битләрендә күбрәк бастыру һәм шәһәрләрдәге башка әдәби берләшмәләр белән цикллы элемтә урнаштыру кирәклеге турында әйтелде. Яңа бюрога М. Хәбибуллин, Ә. Рәшитов, Ш. Маннапов, Ф. Сафин, Р. Миннуллин, Ф. Хәкимова һәм Р. Хәмидуллин кертелде. Берләшмә председателе итеп шагыйрь Әхмәт Рәшитов сайланды.

* * *

Казан дәүләт университетының «Әллүки» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышы педагогия институтының әдәби түгәрәге членнары белән бергә үткәрелде.

Студент-әдипләр киләчәктә дә бергәләп эшләргә, дуслык җепләрен тагын да ныгытырга кирәк дигән теләк белдерделәр.

## ШАМИЛ УСМАНОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРИЗ

«Трудовые резервы» стадионында гражданнар сугышы ветераны, күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Шамил Усманов исемендәге приз өчен традицион ярышлар булып үтте. Бу ярышларга Свердловск, Нижний Тагил, Куйбышев, Пенза, Ульяновск һәм Казан шәһәрләреннән йөзгә якын тимераякта шуучы спортчылар катнашты. Беренче урынга Татарстанның профсоюзлар командасы чыкты. Икенче урынны Нижний Тагил шәһәренең «Спутник» командасы алды.

*Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналыбызның бишенче саны «Казан утлары»ның 50 еллыгына багышлап чыгарыла. Сез анда партиянең Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Ә. Т а б е е в н ы ң республикабыз турындагы зур мәкаләсен укырсыз.

Журналның проза бүлегендә Ш а м и л Б и к ч у р и н н ы ң «Каты токым» дигән романы басыла башлый. Ф ә н и л М а н с у р о в н ы ң «Яктытауда бүз тургайлар» дигән повесте да Сезнең игътибарны җәлеп итәчәк.

Бу санда татар шагыйрьләре зур мәйдан тотачак. «Һәр шагыйрьдән бер шигырь» дигән баш астында республикабызның егермедән артык шагыйре катнашачак.

Төрле буын язучыларының журнал турындагы фикерләре, элек басылган саннардан публикацияләр, юмор бүлеге һ. б. материаллар да Сезгә күп мәгълүмат бирер дип өметләнәбез.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210